

# КАЗАН УТЛАРЫ

2

ФЕВРАЛЬ

1982



**ИЛДАР УРМАНЧЕ.** Р. Мостафинның «По следам оборванной песни» (Мәскәү) китабына ясалган рәсемнәр.

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ һӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 елның май аеннан башлап чыга

2

ФЕВРАЛЬ

1982

## Бу санда

СССРның ТӨЗЕЛҮЕНӘ 60 ЕЛ

Н. АРСЛАНОВ. Уналты гына икән. Шигырь . . . 3

А. РАСИХ. Ямашев. Роман . . . . . . . . . 4
Н. ДӘҮЛИ. Ветеран йоклый алмый. Шигырьләр . 47
Г. КАШАПОВ. Солдат иртә ир була. Лирик-драматик хроника . . . . . . . . . . . 53
Р. МИҢНУЛЛИН. Йолдызлар арасында. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . 107
М. РӘФИКОВ. Тол ана. Шигырьләр . . . . 114
Д. СИРАЙ. Солдат улыма хатлар. Шигырьләр . 116

УНБЕРЕНЧЕ БИШЬЕЛЛЫК: КЕШЕЛӘР һӘМ ЭШЛӘР

М. ВӘЛИЕВ. Себер язмалары . . . . . . . 120

ОЧЕРК һӘМ ПУБЛИЦИСТИКА

Ш. ХАММАТОВ, И. ЗАКИРОВ. Муса Җәлил һәм Мәскәү матбугаты . . . . . . . . . 130
Ф. НАСЫЙРОВ. Упкыннар аша . . . . . . 136

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Ф. МИҢНУЛЛИН. Заман һәм повесть . . . . 142
С. МАННАПОВ. Дөньяның кыл уртасында . . . 150

КИТАП КҮЗӘТҮ

А. ХАЛИКОВ, М. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН. Фәнгә яңа өлеш . . . . . . . . . . . . . 157
Р. ЯГЪФӘРОВ. Күңел юанычы, тормыш көзгесе . 160
Кечкенә рецензияләр . . . . . . . . . 163

ХАЛЫК ИҖАТЫ

М. САДРИ. Себер татарлары әкиятләре . . . . 166

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА һӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА

**Г. САТТАРОВ.** Уйберенче караш . . . . . . . 178

И. И. ШИШКИННЫҢ ТУУЫНА 150 ЕЛ

**Х. ЯКУПОВ.** Якты тәрәзәләр урманга карый . . 185

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 190

Баш редактор: ЗӘКИ НУРИ

Редколлегия: ШАМИЛ БИКЧУРИН, РАЗИЛ ВӘЛИЕВ, АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ, МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ, ЗӨЛФӘТ, ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН, ТУФАН МИҢНУЛЛИН, РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ (*баш редактор урынбасары*), РӘФЫЙК НӘФИКОВ, АТИЛЛА РАСИХ, КОЯШ ТИМБИКОВА (*җаваплы секретарь*), СИБГАТ ХӘКИМ, ФАИЛ ШӘФИГУЛЛИН, НИЛ ЮЗИЕВ

---

Техник редакторы *Р. Сөләйманова*
Корректорлары *Ф. Кадыйрова, Т. Сибгатуллина*
Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.
**Телефоннар:** баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-61, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63; сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-63, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

---

Производствога бирелде 28/X-1981 ел. Басарга кул куелды 12/I-1982 ел. ПФ 04002. Кәгазь форматы 70×108$^1/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 65.044 экз.
Заказ Д-389. Бәясе 90 тиен.

---

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1982 ел.

# СССРның төзелүенә 60 ел

## Нури Арсланов

### Уналты гына икән

АЛТМЫШ ул бик кызыклы
сан —
УН җирдә АЛТЫ гына,
УНны алга куеп язсаң —
Бары УНАЛТЫ гына.

Уналты яшәр кыз төсле
Хәйран республикабыз!
Сизеп тора безнең эшне —
Тәмам гашыйк икәнбез.

Бизәнгән-ясанган сылу,
Күз кысып куя безгә;
Янәсе: «Мөмкин яр булу,
Бөтен эш үзегездә!

Егетләрчә җиң сызганып
Көч куйсагыз әгәр дә —
Миңа бирәлсәгыз байлык
Таудай өеп мәһәргә:

Сары гәрәбәдәй акса
Игеннәр амбар-амбар,
Туйга кәрван-кәрван кайтса
Төрле машина-маллар,

Тулып торса тимер сандык
Модалы киемнәргә,
Муллыктан ил торса балкып,
Охшап киң Иделләргә... —

Ди Республика дигән кыз, —
Яратсагыз әгәр дә,
Миңа шуларны бирсәгез
Ярап куяр мәһәргә!»

Күрсәнә, АЛТМЫШТА
дисәң —
Тик аты гына икән!
Үзебезчә исәпләсәң —
УНАЛТЫ гына икән.

Ул дип кирәк яну-көю,
Ул бит мәңге яшь сылу:
Бик зур бәхет аны сөю,
Аның сөйгәне булу!

Атилла Расих

# ЯМАШЕВ

РОМАН

*Өченче китап*

## 30



Менә мин Шам шәриф белән саубуллашып, Мәдинәгә киттем. Поезд сәгать иртәнге сигездә кузгалды. Бу юл бик җәфалы булырга охшый. Вагоныбызга зур-зур төенчекләре белән гарәп хатыннары кереп тулды. Үкереп җылашалар. Мин нишләргә белмичә, тәрәзәгә капландым. Ичмаса вагонның алгы ягына да чыгып булмый, үтәрлек түгел.

Поезд җәнүпкә таба тау-таш араларыннан бара. Тәрәзәдән күренгән манзара искиткеч, ләкин вагон эче түзәрлек түгел, сасы, тынчу, күнел болгана. Бары бер юаныч бар, ул да булса, поезд яңа станциягә тукталган саен вагонда халык кими бара.

Көндезләрен бик эссе булса да, төнлә шактый салкын икән биредә. Сентябрь җилләре бездәгедән ким түгел. Ә көндезләрен эссегә чыдарлык түгел, ашыйсы килми, бары эчү-эчү. Ярый әле, якташларның киңәше буенча, Шамда бер чүлмәк сатып алган идем. Шуңа станциядә су тутырып керәм дә, эчеп сусынымны басам. Чүлмәктәге су көн нинди эссе булса да җылынмый икән. Миңа бераз җан керде, сулышлар иркенәя башлагач, үземә кирәкле юлдашлар турында да уйлана башладым. Хәер, бу төен, һич уйламаганда, ансат кына чишелде. Мин утырган купега сап-сары бер малай килеп керде. Башында фәс, өстендә җөббә. Ул туп-туры минем янга килде дә: «Сез татар түгелме, әфәндем»,— дип сорады. Мин үземнең кем икәнлегемне әйткәч, ул үзенең Бәдретдин ишан малае Габделми икәнлеген аңлатты. Күрше вагонда аның энесе һәм әнисе Салиха абыстай утыралар икән. Әле әнисе олы улын берәр үз кешебез юкмы икән дип, состав буенча җибәргән. Габделми миннән үзләренең вагонына күчүемне үтенде, юлдаш булыр идек, диде. Аларның бу юллардан беренче тапкыр узуы икән. Мин алар янына күчтем. Шулай итеп, юлдаш табылды. Аларның бәләкәй җиз самаварлары да бар. Вагон алдына чыгып аны гөжләтеп кайнатып җибәрәбез дә кайнар сәйлүн чәен эчеп барабыз. Салиха абыстай алтмыштан узса да нык әле, үзен баш итеп тота. Егетләр исә икесе дә егермеләр тирәсендә, шактый тере, чаялар, тик хәзер, күрәсең, бу яңа урында алар каушый төшкәннәр, йөзләрендә, күзләрендә һәрвакыт аптырау сизелә.

---

Ахыры. Башы журналыбызның беренче санында.

Сәфәребезнең өченче тәүлегендә без Мәдинә вокзалына килеп туктадык. Бу шәһәрнең өйләре бер-берсенә ябышып торгандай, урам дигән нәрсә бөтенләй юк. Йортлар таштан, балчыктан өелгән. Үзләре бик биек, өйнең һәр каты саен тәрәзә урынына рәшәткәле тишекләр генә уелган. Мәдинәнең читендә анда-санда хөрмә бакчалары күренә, ләкин шәһәр үзе бушлыктагы төш өемедәй.

Мин Шамнан ук, якташларның киңәше буенча, Мәдинәгә телеграмм суккан идем. Ялгышмаганмын икән. Мәдинәдә яшәүче Исмәгыйль әфәнде телеграмманы алган, улын иртәп мине каршыларга төшкән. Без, Салиха абыстайлар белән бергә ике катыр яллап, әйберләрне арбаларга төядек тә Исмәгыйль әфәнделәргә юнәлдек.

Бу җиһанда татарның булмаган ягы юктыр дигән фикер миндә көчәйгәннән-көчәя бара. Баксаң-күрсәң, ерак Гарәбстанның кырыендагы изге шәһәрләрнең берсе булган Мәдинәдә дә татар кварталы бар икән. Кайчандыр туган җирләрен ташлап киткән, бәхет эзләп-эзләп тә таба алмаган якташларым, үзләренә бер мәхәллә ясап, биредә яшиләр имеш. Алар үзләренең телләрен саклыйлар, гореф-гадәтләрен югалтмаска тырышалар. Ләкин озаккамы соң? Менә Исмәгыйль әфәнденең дә сүзләре мәзәгрәк чыга, аның өчен гарәпчә сөйләшү ансатрак икәнлеген чит телне ипи-тозлык кына белгән кеше мин дә тоям.

Әйе, без шулай Минаха дигән киң мәйданны үткәч, Баб-Мәҗиттән кереп, таш коймага уелган капка янына тукталдык. Безне озатып баручы Исмәгыйль әфәнденең улы, без килдек, дип кычкыруга, кемдер, югарыдан җепне тартып кына, ишекне ачты. Исмәгыйль әфәнделәрнең өс өч катлы икән. Өченче катка мендек. Ишектән каршыбызга ябык чырайлы, авыру йөзле бер татар хатыны килеп чыкты. Алай да апа йөзен каплаганчы күреп өлгердем, күрәсең, чырайсызлыгын яшерү өчендер инде, битенә иннек яккан. Бу Исмәгыйльнең хатыны Нәфисә апа икән. Ул, ят ир-атны күрү белән, тиз генә ишектән кереп югалды. Без шәрыкча җыештырылган иркен генә бер бүлмәгә урнаштык. Салиха абыстайны хатыннар бүлмәсенә чакырып алдылар. Без ирләр генә калдык. Утырышып дога кылдык. Самавар кайнатылган, кабартма пешкән иде. Эсселектән котылу өчен, җилпәзәләр селки-селки, озаклап чәйләргә керештек. Кичкырын чиратлашып ишегалдындагы бәләкәй таш мунчада юынып чыктык. Безгә йокы урынын тирәсе ихаталанган түбәгә җәйделәр.

Көндезгә аштан соң дәлил Исмәгыйль әфәнде безне Хәрәм шәрифкә алып барды. Ул ифрат зур таш койма белән ихаталап алынган корылма. Биш манарасы да бар. Дүртесе дүрт почмакта, берсенә баш манара диләр. Аһысы пәйгамбәребезнең кәгъбәсе янындарак. Хәрәм шәрифнең дүрт капкасы бар икән. Без Бабылисламнан кердек. Пәйгамбәребезнең яшел атласка укалап чиккән, кашагалар тоткан каберен күрдек. Чардуган коймасы сары җиз белән әйләндереп алынган. Аңа салаватлар язылган. Дәлил кычкырып салават кылды. Аның артыннан без дә әкрен генә зиярәт кылып йөрдек. Зиярәт Әбүбәкер, Гомәр, хәзрәте Фатыйма ризалыгына да кылынды.

Мәдинәдән шактый еракта хөрмә бакчалары урнашкан. Шунда пәйгамбәребезнең ана ягыннан абзасы, хәзрәте Хәмзәнең кабере бар. Шуңа зиярәт кылдык. Якында гына Әхәд тавы күренә. Аның итәгендә бер мәчет. Әүвәл шул мәчеткә кергәч бер ташны күрсәттеләр. Ул ташта пәйгамбәребезнең Әхәд сугышында төшкән ике теш эзе бар икән. Шуны карадык. Артыбыздан калмый ияреп йөрүче хәерчеләргә сәдака өләштек. Я, хода, Мәдинәдә дә, кая барма — хәерче. Өйгә кайтышлый бер хөрмә бакчасына тукталып ял иттек. Гарәбстан чүлләрендә мондый хөрмә агачлыкларын күрү үзе генә дә җанга рәхәтлек бирә. Җәйге көннең кеше түзмәслек эссе айларында Мәдинәнең хәлле кешеләре, шул

бакчаларга чыгып, айлап, атналап яталар икән. Агачлык арасында чишмәдән китерелгән судан хауз ясалган.

Мәдинәдәге русиялеләр бергәрәк яшиләр. Алай гына да түгел, гарәпләр, төрекләр белән артык аралашмыйча үзара гына йөрешәләр. Безне Исрафил әфәнде дигән казанлы татар кунакка чакырды. Кичен шуларда булдык. Анда хаж юлы турында сөйләштек, Мәдинә татарлары туган-үскән яклары белән бик кызыксыналар. Әйе, ни әйтсәң дә алар кызганыч, читкә ыргытылган кешеләр иде. Бу минем күңелемә вәсвәсә сала. Элекке теләкләрем, уйларым җимерелә башлады.

Якшәмбе көн иртәнге алтыдан ук торып Мәккәгә сәфәр чыгарга җыендык. Мәдинәдән Мәккәгә юл чүлләр, таулар аша сузылган. Монда тимер юлы юк. Дөягә утырып, дөя кәрваны белән генә бару мөмкин. Иртәнге чәйне эчкәч, озаклап дога кылып, ходага тапшырып, кафилә[1] туплана торган урынга юнәлдек. Исмәгыйль әфәнденең бөтен гаиләсе безне озата төште. Без кузгалып китәсе мәйдан дөяләр, кәрванчы бәдәвиләр, хаҗилар һәм озатучылар белән тулы иде. Тирә-юньдә шау-шу. Барыбыздан да катырак бәдәвиләр кычкырына. Без, хаҗга баручылар, хәзер биле буылган озын ак күлмәкләрдән, башларыбызда бәдәви шәле. Менә, ниһаять, бер генә өркәчле сузан муенлы дөяләрне чүктереп, аларга утыра торган җайланмалар аса башладылар. Без озатырга килүчеләр белән саубуллашырга җыендык. Хатын-кыз җылаша, барсы да хәердога кыла. Безгә Салиха абыстайның олы улы Габделми мәхдүм белән утырырга куштылар. Бераздан әкрен генә кәрван кузгалды. Бик озын, борылып карасаң ахыры күренми торган кафилә, салмак кына Мәккә-и-мөкәррәмәгә таба юл алды. Безнең янда гына Исмәгыйль агайның дөясе. Анда безнең әйберләр дә асылган. Исмәгыйль ага шулар уртасында өркәч өстендә зонт тотып бара. Ирләр утырган шүрдуф дип аталган җайланманың алды ачык, хатын-кызларныкы исә бөтен тирә-ягыннан ябылган. Һәр кешенең баш очында чүлмәк, анда тешеңне сындырырлык салкын су.

Мәдинә күздән югалу белән мин сузылып яттым. Тирбәлеп барам, көн эссе булса да, минем бишектә рәхәт, җиләс. Башымда нинди генә уйлар кузгалмый. Мин менә бер казакъ баен саваплы итү өчен хаҗга барам. Юк, мин аны саваплы, җәннәтле булсын дип бармыйм. Мин бит инде күптән дингә шикләнеп карый башлаган кеше. Гарәбстанга килеп изге урыннарда булганнан соң минем шөбһәләрем арта гына төште. Ә нигә барам соң мин шулай булгач, ни өчен мин үземнең намусыма хыянәт кылып, үз-үземне алдап, диңгез кичеп, сахралар, таулар аша узып, инде дөя юллары буенча чүлләр, таулар узып хаҗга барам? Мин шул соравыма җавап табарга тырышам. Сәер кеше булып чыктым мин. Берәүләр үзләренең кыйблаларын бик ансат кына табалар һәм, һич тайпылмастан, шул юл буйлап баралар. Ә икенчеләр исә, гомумән, ниндидер кыйбла, ниндидер мәслек эзләү белән газап та чикмиләр. Ашыйлар, эчәләр, үрчиләр, дөнья рәхәтеннән авыз итсәләр шөкерана кылалар, үзләрен бәхетле саныйлар. Нәрсә эзләп хаҗ юлларында йөрим икән мин? Әйе, күңелем каршылыклы, кургашындай авыр шик-шөбһәләр белән тулы. Минем тормыштан берни дә барып чыкмады. Мәсләгемне тапмадым. Кешеләрчә матур гаилә кора алмадым. Өзелеп яраткан кемем бар соң минем? Өйләнеп карадым. Чибәрлегенә кызыгып, байлыгына, кайнарлыгына кызыгып, Гөлҗиһан белән тордым. Ләкин безнең арада мәхәббәт дигән тойгының эзе дә булмады. Тупас, оятсыз, тәрбиясез хатын иде Гөлҗиһан. Безнең арада бары хайвани мөнәсәбәтләр генә хөкем сөрде.

Әйе, шулай да мин үз гомеремдә бер чибәрне өзелеп яраттым. Ул Рабига атлы иде. Рабига Габитова. Мин беренче тапкыр аны трамвайда

[1] Кафилә — атлы-дөяле юлчылар төркеме.

очраттым һәм үсмер балаларча тилереп гашыйк булдым, аңнарымны югалттым. Ул туташ әле дә минем күз алдымда елмаеп, үзенең ягымлы йөзе, кыйгач кашлары белән тулган айдай балкып тора. Ләкин мәхәббәттә дә егетлек, эзлеклелек, хәтта көрәшә белү кирәк икән. Ә миндә андый сыйфатлар булмады. Хәзер инде менә Гарәбстан чүлләрендә гиз, туган илне сагына-сагына дөядә тирбәлеп бар...

Ниһаять, без Мәдинәдән чыкканга унбер көн дигәндә, Мәкка-и-мөкәррәмәгә якынлаштык. Анда пәйгамбәребезнең сөекле хатыны хәзрәте Мәймүнә кабере. Шул җиргә җиткәч, безне мөһаҗирләр, хәерче балалар кара болыт кебек сарып алды. Бөтен тирә-юньне тавыш күмде. Мөһаҗирләр кычкырып үзләренә төшәргә чакыралар, хәерче балалары, җылый-җылый хәер сорашалар. Хәзрәте Мәймүнә кабере янынннан коръән укып үттек, сәдака өләштек.

Икенде вакыты узганда Мәкка-и-мөкәррәмәгә җиттек. Безне тагы каршы алучылар чолгап алды. Араларында кечерәк кенә бер татар малае. Күрәсең, безнең татар икәнлегебезне бик тиз танып, безгә төшегез дип, арттан ияреп бара башлады. Өйдә минем эти-әнием һәм апамнан башка берәү дә юк, төшегез, өчебез дә Хәрәм шәрифкә якын дигәч, без Салиха абыстайлар белән киңәштек тә шунда төшәргә булдык.

Менә без Мәккәнең киң урамнарыннан узабыз. Бөтен җирдә халык кайнаша. Кайсы җәяү, кайсы бер өркәчле дөядә, яки шөлдерләр тагылган бизәкле сбруйлы ишәкләргә атланган. Ирләр барысы да актан киенгән, башларында ак кәләпүш. Байтак барганнан соң, күп урамнар, тыкрыклар узып, без бер мәйданга килеп чыгабыз, кафилә туктала. Оеган аякларыбызны язу өчен дөяләр янында йөренәбез, аннан теге татар малае артыннан (аның исеме Салих икән) фатирга керәбез...»

Шушы урында Җәгъфәрнең көндәлеге өзелә.

## 31

Әдәбият түгәрәге исеме астында үткәрелгән татар иҗат интеллигенциясенең даими утырышлары бәләкәй генә булса да бер тарихка ия иде. Хәзер татар шагыйрьләре, әдипләре, артистлары арасында бик нык-лап идеология эшен көйләргә кирәк иде. Бу эшкә большевиклар да, меньшевиклар да, максималистлар да һәм тагы дөнья кадәр «изм» әһелләре бергәләп кереште. Табигый ки, бердәмлек була алмады. Түгәрәк утырышларында шактый кызу бәхәсләр булгалады, эш хәтәр әрләшүләргә, хәтта ораторлар бер-берсен хәкарәтләүгә кадәр барып җитте. Кыскасы, һәрбер фирка вәкиле, тыңлаучыларны үз ягына аударырга тырышып, булган барлык белем мөмкинлеген бушата башлады. Ахыр чиктә Хөсәеннәр, Галимҗаннар тарафы җиңеп чыкты. Аларның оппонентлары дулап, әдип һәм артистларны наданлыкта, аңгыралыкта гаепләп чыгып киттеләр — түгәрәкнең утырышына йөрмәс булдылар. Хәзер инде бу түгәрәккә йөрүчеләр саны кими төшсә дә, анда, Хөсәен фикеренчә, акны карадан аера торган белемле һәм талантлы кешеләр калган иде. Түгәрәкне конспирация шартларында уздыра башладылар. Инде марксизмны системалы рәвештә пропагандаларга була иде.

Хөсәеннең теләкләре зур иде. Ул бу көннәрдә Ленинның философик әсәре «Материализм һәм эмпириокритицизм» китабы йогынтысы белән илһамланып яши. Бу катлаулы философик әсәрне ул озаклап, төпченеп, белемле рус революционерлары ярдәмендә укып чыкты. Гаҗәп бөек, вакыт таләпләренә тулы җавап бирә торган катлаулы бер әсәр иде бу. Хөсәеннең бу әсәрдә язылганнарны ничектер аңлаешлы рәвештә татар иҗат интеллигенциясенә дә житкерәсе килде. Алар өчәүләшеп, Хөсәен,

Гафур, Галимҗан, моның турында озак баш ваттылар. Ниһаять, анык бер фикергә килеп, эшкә керешергә булдылар.

Бүгенге түгәрәк утырышы гадәттәгечә төнге унберга билгеләнгән иде. Хөсәен, лекциядән кайту белән, күчереп һәм өстәмәләр кертеп яңадан конспектларын тәртипкә китерде. Кәефе шәптән түгел түгелен: күкрәк кыса, тән кызыша, тамак төбен кытыклап ютәллисе килеп тора. Ләкин шулай да, Хөсәен эшен әйбәт башкарды. Ул иртәнге якта Балык базарына азык-төлек алырга бер барып кайткан иде инде. Һава җылыта төшкәнлеген шунда чамалады. Әтисеннән калган мех эчле тунны кигәч, эчтән артык җылы киенмәде, кара сатин күлмәк тә, таушала төшкән көндәлек пинжәген генә киеп барырга булды. Бераздан дәресләрен әзерләп утырган Хәдичә дә үз бүлмәсеннән Хөсәен янына чыкты. Ул хәзер теш дәвалау кабинетында практика үтә. Ире белән янәшә утыргач та бүген үзе күргән кызык хәлләр турында сүз башлады.

Бер карасаң, нинди күңелле бу ачык йөзле чибәр хатын белән яшәү, дип уйлап алды Хөсәен, шуның әллә нинди сөйкемле сөякләре бар. Ә бер карасаң, бөтенләй миннән читләшкән, уй-фикерләремә каршы килеп, минем ашкынуларымны тибәреп кенә торучы авыр табигатьле бай кызы. Хөсәен араларында көзен булып узган бозылышу көннәрен хәтерләде. Ихтимал, эш аерылышуга кадәр үк барып җитәр иде. Әгәр дә... аларның икесенең дә укулары булмаса. Тәгаен Хәдичә Чистаена кайтачак иде, әгәр уку башланырга тормаса, әгәр аның теш табиплеге мәктәбен озакламый тәмамлап чыгасы булмаса.

Хөсәен, Хәдичәне тыңлый-тыңлый һәм шулай уйлана-уйлана чәй эчкәч, тәмләп тәмәке тартырга кереште.

— Ташлар идең инде шул тәмәкеңне,— диде кинәт Хәдичә, йөзен чытып,— сәламәтлегең болай да ташкүлчим, Хөсәен. Бераз врачлар сүзенә дә колак салырга кирәк бит!

— Ташлыйм, ташлыйм, Хәдичәкәй, менә күр дә тор, ташлыйм,— диде Хөсәен, сүзне уенга борып елмайган хәлдә.

— Бөтен бүлмәне төтен белән тутырдың. Минс дә, валлаһи, авыруга сабыштырасың инде.

Хәдичә ландрин тартмасыннан ясалган форточканы барып ачты, Хөсәен исә папиросын көл савытына төртте.

Юк кына нәрсәләрдән дә соңгы вакытта зур күңелсезлекләр чыгып куя. Бик ихтимал, бу тәмәкедән башланган сүз дә күңелсезлекләр алып килер. Ләкин Хөсәеннең бүген бик-бик җитди эше бар, ул үзенең болай да шактый какшаган нервларын сакларга тиеш.

Сәгать унынчы иде инде, Хөсәен җыенып өйдән чыгып китте.

— Мин бүген соң кайтырмын,— диде ул Хәдичәгә,— борчылып торма.

Балык базарында трамвайга утыргач ул, нәкъ Суфияга охшаган бер рус кызын күрде. Бу кыз да зифа буйлы, кара кашлы, кара күзле иде. Хөсәен, трамвайдан төшеп калганга кадәр, Суфия турындагы уйларыннан аерыла алмады. Гафурның борчылуыннан көлеп, тыштан батырланып, гамьсез кылану ансат иде. Ләкин акыл никадәр генә логикасын саклап үз юлыннан бара бирмәсен, хисләр читкә тарта, күңелне алгысыта, җилкендерә һәм талгын бер рәхәтлек бирә торган халәт тудыра иде. «Тукта, Хөсәен,— диде ул, ниһаять үз-үзенә,— синең мөһимрәк эшләрең бар, үзеңне кулга ал. Син бит бүген халкыңның каймагын тәшкил иткән кешеләр белән җитди темага сүз башлаячаксың, тукта, төп эшең турында уйлан».

Хөсәен бүгенге чыгышын ничек башлау, катлаулы философик әсәрне ничегрәк гади итеп төшендерәчәге турында бер генә тапкыр уйланмады. Ул сүзне, әлбәттә, объектив чынбарлык, материя һәм аның кеше тарафыннан тоелуы турында башлап җибәрер. Менә шуннан соң инде Хөсәен идеализм вәкилләренең мәсьәләгә карашын ачып бирачәк.

Субъективизмның нәрсә икәнен аңлатыр. Махизм турында, рус идеалистлары Богданов һәм башкалар турында Ленин карашын бәян итәр. Һәм ниһаять, революцион үзгәрешнең объектив закон нигезендә була торган бер хәл икәнен нигезләп исбат итәргә кирәк.

Хөсәен, булачак әңгәмәне кичереп бара торгач, керәсе капкасын чак узып китмәде. Гафур анда иде инде. Утырышлар ике катлы агач өйнең өске катында уздырыла иде соңгы вакытта. Тәрәзәләре ныклап томаланган иркен бүлмәдә Гафур ялгызы гына иде. Ленин әсәрен караштырып утыра. Ул Хөсәен кергәч китаптан башын күтәрде.

— Сиңа тагы яңалык әйтә алам: мөфти хәзрәтләренең егерме биш еллык юбилеенда үзенең гүзәл баритон тавышы белән Камил Мотыйгый әфәнде коръән укыган.

— Булыр, булыр аңардан.

Гафур җилкәсен җыерып куйды.

— Кемгә ничек бит. Берәүләр акны карадан бик тиз аера, икенчеләр гомер буена эзләнеп тә, төп юлын таба алмыйча теге дөньяга китә. Между прочим, Петербургта Бохара әмире акчасына салына торган мәчет төгәлләнгән. Ул ифрат дәрәҗәдә биек, матур икән. Манарасы бөтен шәһәргә күренеп тора, ди.

Хөсәен тагы көлемсерәп:

— Булыр, булыр,— диде.— Мулла итеп Муса Бигиевны чакырганнар, ди. Шулаймы?

— Әйе, мин дә шулай дип ишеттем.

Хөсәен, тынычсызлана төшеп, стенадагы сәгатькә карап алды. Сәгать угы унбергә якынлаша иде инде.

— Борчылма, барысына да хәбәр ителгән,— диде Гафур,— хәтта бер яңа иптәш тә булачак.

— Яңа иптәш? Кем соң ул, мәгълүм кешеме?

— Тукай протекциясе буенча. Исхак Бикчурин дигән бер яшь иптәш. Габдулла әфәнде аңа бик җылы караштa. Чын мәгънәсендә социалист, пешкән, җитешкән, ди. Үзе талантлы гына икән, шигырьләр язарга һәвәс, ди.

Хөсәен, тәшвишләнә төшеп, йөзен чытты.

— Син рөхсәт бирдең инде аны алып килергә?

— Беләсең бит Габдулланың холкын. Аның ачы теленә беркем дә түзә алмас.

— Алай икән,— дип куйды Хөсәен бармакларын өстәлдә тыпырдатып.— Ә син беләсеңме соң, дускаем, провокаторларның, хаиннәрнең хәзер барысы да аякка бастырылганлыгын. Габдулла әфәндене мин дә яхшы беләм. Ул ифрат шәфкатьле һәм адәм баласына гашыйк кеше. Ләкин ул, никадәр демократ һәм сизгер күңелле булса да, революция солдаты түгел. Аның әйткәннәренә генә ышанырга ярамый. Галимҗан бу хәлне беләме?

— Юк, мин аның белән киңәшә алмадым, Хөсәен.

Хөсәен тирән сулап алды да бераз уйланып торганнан соң:

— Безгә бер чит кеше аркасында программаны бөтенләй яңача корырга туры килә,— диде.

Хөсәен бүлмә буйлап арлы-бирле йөренергә тотынды. «Кем белә, бәлки ул Исхак атлы кеше охранкадан җибәрелгәндер, бәлки ул Тукайга «койрык» булып тагылган кешедер, җасустыр» дип уйлый иде Хөсәен. Әйе, сүз бүген гомумән әдәбият һәм философия турында барачак. Әдәби әсәрләрнең философик сөземтәсе, классик әсәрләр нинди фәлсәфәгә корылган, яңа философик әсәрләр нindирәк, аларның мәгънәви асылы нидә? Ленин әсәре турында, авторын әйтмичә генә, шулай ук аның бүген тикшерелергә тиеш булган әсәренең исемен дә атамыйча гына сөйләргә булды Хөсәен. Аны моңарга билгесез кешенең түгәрәккә килүе мәҗбүр итә иде.

Төнге унберләр җиткәндә берәм-берәм төн кунаклары күренә башлады. Алар арасында Галиәсгар Камал да, Габдулла Кариев та, Габдулла Тукаев та бар иде. Чыннан да, шагыйрьгә ияреп бер яшь кеше килгән иде. Бу ярым европача, ярым шәкерт кыяфәтле егетне Тукай: «минем яшь дустым — Исхак әфәнде»,— дип таныштырды. Габдулла Кариев бүген генә Уфадан кайтып төшкән икән. Сәйяр труппасының җитәкчесе үзенең юл мажараларын, Уфа хәлләрен сөйләгән арада Хөсәен Исхакны күзәтеп утырды. Егетнең маңгаендагы миңенә игътибар итте, аның бик тыйнак рәвештә оялчан гына аска карап утыруын абайлады.

Исхак турында Хөсәен анык кына берни дә белми иде әле. Ләкин аның унъеллык революцион тәҗрибәсе сак булырга өнди, катлаулы вакыйгаларда чарланган сизгерлеге тагы да киеренкеләнә, тагы да үткенләнә төшкән иде.

## 32

Ел азакларында Хөсәен Суфияның уңышлы рәвештә врачлык курсын тәмамлап Петербургтан Казанга кайтуын ишетте. Бу хәбәрне аңа Хәдичә әйтте. Инде менә бишенче көн Хөсәен суык тидереп, кәефсезләнеп, өеннән чыга алмыйча ята иде. Бу хәбәр аңа яшәү сулышы, дәрт өстәгәндәй булды. Зифа гәүдәле, садә һәм сөйкемле Суфия елмаеп күңел түренә килеп баскач, ул ирексездән урыныннан торып китәргә теләде. Ләкин шундук тыелып калды һәм эченнән генә үз-үзеннән көлә башлады.

Хәдичәнең күз карашы сак, бу хәбәрне ишеткәч, Хөсәеннең һәр мимикасын, хәрәкәтен җентекләп күзәтеп тора иде ул. Хөсәен моны сизде һәм үзен тыныч тотты.

— Бик әйбәт булган, аны котлап безгә Гафурларга барырга кирәк,— диде.

— Үзе дә килер әле. Ул бит синнән биһуш,— диде Хәдичә, кырку гына.

«Хәдичә, акылыңа кил, ул бит мине абыйсының дусты буларак кына хөрмәт итә», димәкче иде Хөсәен, ләкин бу сүз дөреслеккә туры килмәгәнгә күрә алай әйтмәде.

— Юкка, юкка син бу сүзләрне әйтәсең,— диде ул бераздан.— Синең беркемне дә гаепләргә хакың юк.

Баштагы күңел күтәренкелеге кинәт кенә сүрелде. Хәдичә исә кискен рәвештә борылып чыгып китте.

Авырып түшәктә яткан арада Хөсәен күп уйланды, булган хәл-әхвәлләрне анализларга, һәр вакыйганың асылына төшенергә тырышты. Юк, ул Хәдичә белән гомерен кичерәчәк. Хәдичәнең болай саташулары вакытлы күренеш, ул уку һәм тынычсыз тормыш аркасында арып киткән. Менә мәктәбен бетерер, үз һөнәре остасына әверелер, шул чак үз урынына басар, һәм нәкъ элеккечә Хөсәеннең якын ярдәмчесенә әверелер.

Университетта укуыннан артка калмас өчен ул әз генә хәле яхшыра төшкәндә дә кулына китапларын алды. Аңа бергә укый торган студент дуслары да көн аралаш кереп йөрделәр. Лекция конспектларын калдыра торган булдылар. Араларында аерата Вәлихан Таначев чын дусларча мөгамәләдә иде. Ул озак-озак утырып Хөсәенгә университет вакыйгаларын сөйли, лекция темасы буенча өстәмә материал табып китерә, кыскасы, ул Хөсәенне ихлас күңелдән якын күргәнлеген эш белән исбатлый иде. Бу бай малае бер нәрсәдә генә Хөсәеннең тарафдары түгел иде. Ул да булса революцион хәрәкәтне бөтенләй дөрес дип тапмый, марксизм кебек тәгълиматлардан уттан качкандай читкә тайпыла.

Хөсәеннең уйлары кемнән һәм нидән генә башланмасын, ахыр чиктә үзенең революцион эшенә кайтып кала. Казан комитеты ничә тапкыр инде охранка тарафыннан туздырылып ташланды. Ләкин жандармерия ни генә кыланмасын, ул тагы үсеп чыга, тагы Казан эшчеләре арасында үзенең прокламацияләрен тарата башлый, тагы марксистик түгәрәкләрен торгыза, стачкалар, забастовкалар оештыра иде. Революцион күтәрелеш көннән-көн ныгый, һәм шул ук вакытта охранканың кабәхәтлеге дә арткаңнан-арта бара. Үзенең барлык ялчыларын, шпионнарын, филерларын, сатлык җасусларын аякка бастыра, эшчеләр хәрәкәтен бишектә чагында ук буып үтерергә ашкына. Хөсәен һәм аның дуслары моны яхшы аңлыйлар, шуңа күрә прогрессив милли интеллигенцияне бу бәладән саклап калуны шулай ук үзләренең изге бурычы итеп саныйлар иде. «Габдуллага ияргән бит бер ябышкагы,— дип уйлады Хөсәен,— бу тәгаен шуннан... Күңелем сизенә — «Дүртенче отдел» Тукайга үрмәләтә башлаган үзенең җыланнарын».

Хөсәен Тукайның дошманнары бик күп икәнлеген яхшы белә иде. Шагыйрь бер генә тапкыр сөйләмәде бу турыда. Инде хәзер тирә-юньдәге дошманнар җитмәгән, ак патшаның кабәхәт куштаннары шагыйрьгә үреләә. Хөсәен бу турыда уйлап аз уфтанмады. Аның теге утырыштан соң ук авырып егылуы күңелен отыры нык газаплады. Юкса ул иртәгәсен үк аулакта Габдулла белән сөйләшергә ниятләгән иде. Хәл белергә килеп чыккан туган тиешлесе, ышанычлы кеше, партия члены Мәхмүт Алиевтан да ул Исхакның кем икәнлеген ачыклавын үтенде. Әле бүген шулар турында уйланып ята иде. Кемдер ишек шакыды. Хәдичә укуда. Ул, гадәттә, Хөсәен ишек ачырга торып мәшәкатьләнмәсен дип, ишекне бикләмичә генә китә. Хөсәен: «Керегез, ишек бикле түгел»,— дип кычкырды.

Бүлмәгә Суфия килеп кергәч, ул бер мәлгә хәйран калды. Кызның бөтен килеш-килбәте көләчлек, нур белән тулган иде. Тыштагы суык аның бит очларын кып-кызыл иткән, күзләре очкынлы, тигез матур тешләре кызны аерата яктыртып торгандай итә.

Суфия кулындагы пакетларын өстәлгә куйды да:

— Авырып китүегезне ишеттем дә, Хөсәен абый, килергә булдым. Хәдичә апа кайда?

Хөсәен караватына якынлашкан кызга елмаеп кулын сузды.

— Кулларым суыктыр,— диде Суфия.— Тышта шулкадәр суык. Әллә утыз, әллә кырык градус бардыр, валлаһи.

— Хәдичә апаң укуда,— диде Хөсәен,— ул шулай мине калдырып китәргә мәҗбүр, чөнки аның да имтиханнары якынлаша бит. Утыр, әнә урындык алып минем яныма утыр, Суфия.

Суфия аның әйткәннәрен үтәде. Утыргач, җинелчә елмайган хәлдә, Хөсәеннең йөзеннән күзләрен алмый тын гына торды. Аның күзләрендә тирән мәхәббәт, сагыну күрде Хөсәен. Аңа төбәлеп карамаска тырышты.

— Ничек соң, курсны уңышлы тәмамладыңмы? Сине чын күңелдән тәбрик итәм. Мондый бәхет һәркемгә бирелми.

— Рәхмәт, Хөсәен абый. Минә кулларым чак кына җылынсын да мин синең авыруың белән кызыксынырмын. Мин бит хәзер врач, сине карарга минем тулы хокукларым бар.

— Бер врач килеп минем үпкәләрне тыңлап, пульсларымны санап киткән иде китүен. Алай да синең теләгеңә каршы килеп булмас. Әз генә булса да тәҗрибә туплауда булышырмын, бәлки. Петербурда ниләр бар соң? — диде ул кинәт җитдиләнеп.— Безнең егетләр ни бетерәләр? Мулланур?..

— Бәлки беләсеңдер, аны бит политехнический институттан чыгарганнар иде. Шуннан ул Мәскәү университетына керергә тырышып карады. Ләкин аның маңгаендагы революционер дигән мөһерен анда да күргәннәр. Ә минә узган көз ул Петербургның психоневрологический

институтына бик шома гына узды. Беләсеңме, кем батырчылык иткән аны уку йортына алырга. Ректор үзе, әлеге данлыклы профессор Бехтерев, мировая величина. Ләкин Мулланурның икътисади[1] яклары шәптән түгел, Хөсәен абый. Газеталарга мәкаләләр язып, килерен бераз җайлый, ә этисеннән принципиально акча алмый.

Бернична ел элек инде Мулланурның этисе — елына кырык мең доход алучы коммивояжер Муллаян — гаиләсен ташлап, Варвара исемле кордебалет артисткасына өйләнгән иде. Этисенең бу адымын Мулланур гафу итә алмады. Шуларны яхшы белгән Хөсәен уйга калды: «Бу дәртле егет озак укый алырмы болай?»

Ул арада Суфия Петербург хәлләренә күчте. Хәбәрләр сөйләнеп беткәч ул, кулларын юып керде дә, сумкасыннан халатын алып өстенә киде.

— Хәзер эшкә керешәбез.

Ул Хөсәеннең уңайсызланыбрак калуын тойды. Катгый бер тонда:

— Юк, Хөсәен абый,— диде,— нинди уңайсызлану ди ул. Мин менә шушы минутта Суфия түгел. Син минем кадерле Хөсәен абыем түгел. Мин — врач, син — пациент. Күлмәгегезне күтәрик әле.

Хөсәен нәни балалар кебек аңа буйсынды. Суфия исә бөтен дикъкатен туплап, аның йонлы күкрәгендә стетаскобын күчерә-күчерә, үпкәләрен тыңларга кереште. Хөсәеннең температурасы күтәренке булуыннан ук аның хәлен аңлаган иде кыз. Ләкин үпкәсен тыңлаганнан соң, аның йөзе кинәт үзгәрде. Моңарчы һаман көләчлек сирпеп торган кыяфәтенә аның күләгә кунды, күзләре тоныкланып китте.

— Ю-ук, Хөсәен абый,— диде ул,— болай булмый. Бүген үк хәстәренә керешергә кирәк. Ничек кенә булмасын акча табарга һәм сине Кырымга китәргә кирәк! Башкача мөмкин түгел.

Хөсән күлмәк чабуларын рәтләгән хәлдә көлеп куйды.

— О, син бигрәк строгий доктор булып кайткансың икән, Суфия. Нинди Кырымнарга бару ди ул. Син миңа әйбәт дарулар яз. Менә күрерсең, мин өч көннән аякка басачакмын.

Суфия һаман җитди кыяфәттә калып, Хөсәеннең сүзләрен юкка чыгара торды.

— Сәламәтлек белән шаярырга ярамый, Хөсәен абый кадерлем. Сиңа тиз арада терелергә кирәк, ә моның өчен Кырым һавасын сулау, Уфа кымызын эчеп тазару шарт.

Хөсәен тагы көлемсерәп куйды.

— Телисеңме, Хөсәен абый, әйдә икәү бергәләп Кырымга китәбез. Менә ихлас күңелдән әйтәм, бик теләп сине дәвалаучы врачың булыр идем. Хәдичә апага хәзер авыр чак, ул бара алмый. Мин синең доктороң да, аш-су җитештерүчең дә булырга риза, керләреңне юарга да авырыксынмам. Ризамы син шуңа? Мин хәтта акча юнәтү юлларын да табармын дип уйлыйм.

Хөсәен Суфияның кулын учына алды. Иркәләп кызның күзләренә карады.

— Сөйкемле һәм мәрхәмәтле бер гүзәл кыз син, Суфия. Рәхмәт шулай кайгыртуыңа. Син миңа карата шундый олы кайгыртучанлык күрсәткәч тә миңа рәхәт булып китте. Ярты сырхавым күккә очты. Син Кырым дисең, ә уку? Мин бит университет бусагасын атлап кергәнче, беләсеңме, күпме сират күперләре кичтем, никадәр сынаулар уздым. Хыялым тормышка аша башлагач кына барысыннан да ваз кичимме? Ә эш, минем өчен барысыннан да изгерәк булган революцион эш нишләр, Суфия?

Суфия башын селкеп Хөсәенне тыңлап утырды.

— Бу кадәр минем Гафур абый булырсың икән! Икегез дә бер чыбыктан сөрелгән кешеләр. Сәламәтлегең бит уку өчен дә, эш өчен дә

[1] Икътисади — экономик.

кирәк, Хөсәен абый. Болай җиңел уйлап, аякка баса алмаслык хәлгә калсаң, укый да алмаячаксың, революцион эшчәнлегеңне — изге бурычыңны да башкара алмаячаксың, аңлыйсыңмы шуны!

— Әйткәннәрең дөрес, Суфия, ләкин миндә бит әле җитди авыру түгел, менә күрерсең, бер-ике көннән университетка йөри башлармын. Эшемне дә дәвам итә алырмын дип уйлыйм.

— Аңларга тырыш зинһар, син авыру, Хөсәен абый.

— Ул сиңа шулай тоела. Һәрбер яңа пешеп чыккан һөнәр иясе үз һөнәренә кагылышлы һәрнәрсәне арттырып күрүчән. Син дә, минемчә, шулай.

— Юк, юк, ихлас күңелдән һичбер арттырусыз, гиперболасыз әйтәм.

Суфия, ышандыра алмавына рәнҗеп, елмаерга мәҗбүр булды. Түзмәде, тын гына, эчке бер әрнү белән сөйләп китте.

— Хөсәен абый, неужели син бер нәрсә дә аңламыйсың? Мин синең язмышың өчен, синең белән беренче күрешкәннән бирле куркып, дәһшәтләнеп яшим. Сау-сәламәт чагыңда да мин синең өчен, революцион эшең өчен ут йотып яшәдем, инде хәзер икеләтә ут йотам. Минем башка бер генә ир-ат турында да болай уйлаганым, аның өчен болай кайгырып яшәгәнем юк иде. Неужели син шуны аңламыйсың?

Хөсәеннең йөзе үзгәреп китте. Аның ирония аша елмаюы бетте, күз карашлары җитдиләнде, моңсулык һәм гаҗизлек йөгерде аның кыяфәтенә.

— Барысын да аңлыйм, Суфия,— диде ул күңелсезләнеп.

— Аңлагач, минем ихлас киңәшләремә дә колак салыгыз.

— Тик син дә бер нәрсәне аңласаң иде... Мин бит өйләнгән кеше, хатыным бар. Шулай булган хәлдә ничек инде мин...— Хөсәен башын калкытты,— беләсеңме нәрсә, Суфия, әйдә без синең белән чын дуслар булып кына калыйк. Әгәр хисләребезгә ирек бирсәк, безнең берни дә барып чыкмаячак, син дә, мин дә янып көлгә әйләнәчәкбез.

— Бервакыт син, Хөсәен абый, Хәдичәбикә апаның кияүгә чыгу вакыйгасын сөйләгән идең. Син аның, яшьлеген корбан итеп, үзеннән күп олы кешегә тормышка чыгуын тәнкыйтьләгән идең. Хәтереңдәме, мәхәббәтне корбан итү — противоестественно дигән идең? Ә хәзер нәрсә? Минем дә күзләрем бар, Хөсәен абый, мине шундый откровенностька барырга мәҗбүр иткәнсең икән, әйтим инде, мин синең кичерешләреңне тоймыйм мени? Язган хатларыңның юл араларында ниләр ятканын сизми идем мени? Бу ничек була инде? Безнең арадагы мөнәсәбәтләр шулай җиңел генә корбан ителә мени?

— Юк, юк,— диде Хөсәен, тавышын күтәрә төшеп.— Син бу очракта дөрес хөкем йөртмисең. Эш башкачарак тора...

## 33

Истамбулның Иске шәһәр өлешендәге балчык өйләрдән торган бормалы урамнары буйлап бер кеше бара. Аның өстендә тузып беткән, ямау өстенә ямау салынган кием, башында кыршылып беткән кызыл фәс. Йөзе артык борчулы, сагыштан изелгән. Иңбашларын салындырып баруы һәм йөзен баскан кара куе сакал-мыегы аны, ким дигәндә, илле биш-алтмыш яшьләрдә итеп күрсәтә иде.

Бу кешенең Истамбул портларын, базарларын, хәтта урамнарын тутырган эшсез этрәк-әләмнәрнең берсе икәнлеген күрү белән чамаларга булыр иде. Ярый әле, Азия белән Европа чигендәге борынгы бу шәһәр көньякның шәфкатьле кояшы астына урнашкан, монда кышкы айларда да кар ятмый, җылы була. Хәер, төньяк җиле исә башласа, кинәт суыта, кайда кереп ышыкланырга белмисең, ләкин ул өч-дүрт көннән соң тагы туктала, тагын җылы шәфкатьле җил исә башлый.

Әлеге кеше, тирә-юнена карана-карана, борылмалы урам лабиринтларын байтак гизгәннән соң, ниһаять, таш коймага уеп ясалган бәләкәй капка янына тукталды. Урамы да, йорт номеры да ул эзләгәнчә иде. Кыюланып ул капкага өч тапкыр йодрыгы белән сукты. Шундук ишегалдыннан карлыккан ямьсез тавыш белән эт өргәне ишетелде. Хуҗа да озак көттермәде, этне тыяр өчен аңа кычкырына-кычкырына, капкага якынлашты.

— Рәхим итегез, әфәндем,— диде ул капканы ачып. Ләкин хуҗаның йөзеннән, бу йолкышны күрү белән, сәер аптырау галәмәтләре узды. Ул, нидер хәтерләргә теләгәндәй, җитдиләнеп, кунакка караган килеш, күзләрен йомгалады.

— Хәтерлисезме, Мөхлис әфәнде, без кичә сезнең белән кәһвәханәдә сөйләшеп утырдык. Сез миңа, ничек тә ярдәмсез калдырмам, дип, адресыгызны бирдегез.

Хуҗаның йөзе кинәт яктырды. Сап-сары куе кашлары өскә күтәрелеп китте, тешләре сирәкләнгән авызы ачылды. Ул кеткелдәп көлде дә:

— Хәтерләдем, хәтерләдем, ничек хәтерләмәскә, аркадаш,— диде,— ватандашлар дигәндә — җан фида. Сезнең исемегез Җәгъфәр бит әле.

Җәгъфәр бик канәгать иде. Кичәге сөйләшүне оныткан ахры дип, ул Мөхлиснең йөзендәге аптырауны күргәч, бик курыккан иде.

«Миһербанлы, үз сүзендә тора торган адәм икән», дип уйлады Җәгъфәр. Ул арада хуҗа, ихлас күңелдән кунакчыллык күрсәтеп, аны стеналары келәмнәр белән бизәлгән шактый бай өенә алып керде. Төрек гадәте буенча, бәләкәй генә чынаякларда кофе китертте. Татарчалап яулыгын почмаклап бәйләгән хуҗабикә поднос белән кунакка кофе алып кергәч, Җәгъфәр аягүрә басты.

— Сез мине, ханым, мондый сәләмә киемнәр белән зиннәтле хөҗрәгезне ямьсезләндерүем өчен гаеп итмәгез инде, кичерегез мине,— диде,— мин асылда болай йөри торган адәм түгел идем, ләкин язмыш миңа карата ифрат рәхимсез булды — менә шул көнгә калдым.

Кәһвәханәдәге Мөхлис белән булган кичәге әңгәмәдән Җәгъфәр бу кешеләрнең күптән инде бирегә килеп урнашуын, җирле гадәтләрне үзләштергәнлеген, җайлашып әйбәт кенә яшәүләрен белгән иде. Хуҗабикә нәкъ Җәгъфәр белгән татар апалары кебек киенгән иде. Ул, авызын яулык очы белән каплый төшеп:

— И, нинди гаеп итү ди ул. Без үзебез дә лаеш шулпасын аз эчмәдек, бәләбез,— диде.

Хуҗа елмаеп, Җәгъфәрне кофе эчәргә чакырды.

— Ягез әле, ватандаш, Җәгъфәр әфәнде, сөйләп җибәрегез. Ничек сез мондый көнгә калдыгыз, нинди ярдәмгә мохтаҗлык бар?

Җәгъфәр уңайсызлана төшеп:

— Кичә мин сезгә барысын да бәйнә-бәйнә сөйләгән идем инде,— диде.

— Кичә? — диде Мөхлис, нечкә тавыш чыгарып тагы кеткелдәп көйде.— Кичә бәлки сүз булгандыр, ләкин кичәге кичәгедә калган...

Җәгъфәр күңелсез генә елмаерга мәҗбүр булды.

— Барысы да сөйләнде, барысы да.

— Шулайдыр, шулайдыр. Тик минем тагы ишетәсем килә. Чөнки хәтеремнән чыккан.

Җәгъфәр бәләкәй чокырдан куе кофены бер чөмерде дә:

— Мин нәрсә сөйләдем кичә? Бер бай казакъның бәдәле буенча хаҗга бардым, дидем. Хаҗ кылдым...

— Бәрәкалла,— дип куйды Мөхлис.

— Кайтышлый миңа Истамбулда тоткарланырга туры килде. Чөнки бай вәгъдәсен үтәмәде, кайтыр өчен дигән акчаны ул Истамбулга җибәрергә тиеш иде, җибәрмәде. Дөресрәге, җибәрә алмаган ул, чөнки мин хаҗга киткәч, бай вакытсыз дөнья куйган. Ә уллары аның васыятын

үтәмәгәннәр, миңа акча җибәрмәделәр. Шулай итеп мин биредә торып калдым. Хәлбуки бик кайтасым килә. Чөнки туган илнең кояшы сезнең як кояшыннан рәхимлерәк икәненә төшендем.

— Аңламыйм, кардәш,— диде Мөхлис.— Дингез кичәрлек берничә лира да акча таба алмадыгызмы?

— Таба алмадым. Ихлас таба алмадым. Башта менә килер, менә килер дип Русиядән акча көткән идем. Аннан авырып киттем. Мондагы һава миңа килешмәде. Шулай итеп мин шушы көнгә калдым.

Җәгъфәр үзенең хаждан кайтышлый Истамбулда нинди мажаралар кичерүен сөйли башлады.

Әйе, барысы да аның бүгенгедәй күз алдында. Ул Истамбулга килеп төшкәч тә, Туктыбайдан киләсе акчаны эзләп китте. Бай аны Истамбулның мөселман мәхәлләсе — Солтан Фатыйхта яшәүче бер кырымлы сәүдәгәргә җибәрергә тиеш иде. Җәгъфәрнең акчасы шул кадәр аз калды, ул берәр кунакханәгә урнашу түгел, хәтта атлы трамвайга утырырга да җөрьәт итмәде. Күз алдына китермәгән иде ул хаж юлында шул кадәр хәерче күп булыр дип. Акчаны уйламыйчарак тотты, бай хаҗилардан калышмаска теләп, сәдаканы күбрәк өләшеп ташлады. Ә менә теге кырым татарын эзләп барганда миллион ярым халык булган, әллә ничә чакрымга сузылган, зиннәтле дә, фәкыйрь дә шәһәр урамнары буйлап адым саен сорашып көне буе сөйрәлде. Ул төрек телендә чыккан китапларны аңлап укый иде. Төрекләр белән аңлашу миңа ансат булачак дигән фикердә яшәде. Ләкин бик каты ялгышканын соңыннан гына аңлады. Хәер, беренче ихтыяҗын ул ничек тә аңлата алды, мәгәр төрекләрнең сөйләмәнә төшенә алмыйча аптырап бетте. Җитмәсә төрекләр үз шәһәрләрен үзләре белмиләрме, шунда күпчелеге, сорау белән мөрәҗәгать итсәң, тел шартлатып, иңбашын сикертә дә китеп бара. Юлында очраган искиткеч зиннәтле мәчетләргә, христиан бистәсендәге Америка, Англия, Франция, Италия байларының биек таш пулатларына ул кызыксынып карамый булдыра алмады. Никадәр алҗымасын, хәлдән таймасын, ул күңелен әз генә дә төшермәде. Чөнки ул үзенең озакламый акчалы буласын белә. Ә акчаң булса, чит ят җир дә туган өең кебек, дип уйлый иде.

Ниһаять, ул кичкырын гына Туктыбайның яхшы танышы кырымлы сәүдәгәрне эзләп тапты. Ә бит Истамбулдан китәр алдыннан аңарда бер тапкыр булган иде. Хәер, ничек булган иде? Башта трамвайда барды, аннан извозчик яллады ул вакыт. Ә хәзер менә юлны оныткан.

Җәгъфәрнең җәяүләп килүенә, арыган кыяфәтенә шаккатып калган кырымлы сәүдәгәр аңа акчаның килмәвен әйтте. Башта Җәгъфәр ышанмады. Олы кешенең болай шаяртуына сәерсенеп куйды. Елмая төшеп:

— Андый хәлнең булуы мөмкин түгел,— диде.

— Валлаһи, акчагызның килгәне юк,— диде сәүдәгәр.

Җәгъфәрнең күңеленнән «алгандыр, алгандыр да үз кесәсенә салып куйгандыр», дигән ямьсез уй узды. Ул, өнсез калып, хуҗаның артсыз кәнәфиенә ауды. Аның чамадан тыш арудан, ачлыктан башы әйләнә, йөрәге урыныннан кубардай булып тибә иде.

— Нишләргә инде миңа? — диде ул, ниһаять,— ничек кенә тормыш итәргә? Ышаныгыз, Әхмәт әфәнде, минем кесәмдә бары тиеннәр генә калды. Нишлим мин, киңәш бирегез, алла хакына.

— Андый бәлагә очрагансыз икән, минем өем сездәй кунак өчен һәрвакыт ачык. Миһман булыгыз, акчагыз килгәнче минем өемдә яшәгез. Алла теләсә, әкренләп барысы да җайланыр.

Хуҗа ихлас күңелдән сөйли иде. Шунда аның карак булмавына Җәгъфәр ышанды, әле генә бу кеше турында шундый әшәке уйлавына оялып та куйды.

Җәгъфәр Әхмәтләрдә бер ай яшәде. Һәркөнне, өметләнеп, Русиядән килгән пароходларны каршылады. Хәбәр көтте, һич югында, хажга

сәфәр кылучы берәр якташын очратып, мондый гаҗәп хәлнең сәбәбен белергә теләде. Нинди генә уйлар кичермәде ул башыннан. Әле ул хаҗга барыр алдыннан булган теләкләреннән айнып бетмәгән иде. Аның башына: «Нигә миңа Русиягә кайтырга, биредә калганда яхшырак булмасмы, ни әйтсәң дә төрки халык», дигән уйлар да килгәләде. Ләкин шул бер ай эчендә, Истамбулның фәкыйрь-фокрасы арасында йөргәндә ул күп гыйбрәтле хәлләрне күреп, элеккe өметләрен җилгә очырырга мәҗбүр булды. Кыш дими, җәй дими урамнарда эшсез халык айкала. Акчалылар урамнарда тезелеп киткән кәһвәханәләрдә көннәр буе утыра, хур-хур тартып кәефләнә, бер бәләкәй чокыр кофе белән ярты көн әвәрә булып ләчтит сата. Әйтерсең лә эш, хезмәт дигән нәрсәне белмиләр бу кешеләр. Базарлары исә хәерче, сукбай белән тулган. Юк кына нәрсәләр сатып, кайберәүләр чынлап кәсеп иткәндәй, көннәрен уздыралар. Ә банклар, завод-фабрикалар, хәтта зуррак биналар да чит ил байлары кулында. «Кызык,— дип уйланды Җәгъфәр,— бу төрекләр кулында нәрсә генә кала инде болай булгач. Менә сиңа мөстәкыйль төрки ил! Игенчеләр иле, крәстиян иле. Ә бит авыл кешеләре дә ишәкләре кебек алама, ябык, фәкыйрь...» Бер ай эчендә Җәгъфәр аз-маз сөйләшергә дә өйрәнде. Һәрхәлдә, төрек телендә үз теләген яхшы ук аңлата ала иде инде. Хәтта стенага арка терәп, җирдә утырган чакларда гәпләшү өчен әшнәләр дә табылды. Ул шулай каршылыклы уйлар белән булашып, өметен өзмәстән, һаман көтте. Ай да ун көн дигәндә хаҗга баручы бер бай казакъ пароходтан төште. Шул кеше хәл-әхвәлләргә ачыклык кертте. Ул Туктыбайны яхшы белә икән. Туктыбайның вафат булуын, үзенең байны җирләгәндә җиназасында катнашуын, аңа зиратта бик шәп итеп манаралап кабер куышы ясалуын һәм хәзер Туктыбайның шунда кыямәт көнен көтеп мәңгелектә ятуын сөйләде.

Соңгы өметләр дә өзелгән иде хәзер. Җәгъфәр бит, акча килер дә, үзен ач үлемнән коткарган миһербанлы кырымлы сәүдәгәр Әхмәт белән исәп-хисапны өзәр, үзен айдан артык вакыт ашатып-эчертеп, йомшак түшәгендә йоклатып, әз генә дә караңгы чырай күрсәтмәгәне өчен тиешле рәвештә, рәнҗемәслек итеп акчасын түләр, бурычлы булып калмас, дип уйлаган иде. Инде хәзер барысы да җимерелде. Җәгъфәргә бердәнбер юл — алардан китү, нинди эш туры килсә шуны башкарып, акча туплау кала. Ул, көннәрдән бер көнне, хуҗага аны-моны әйтмичә, пристаньга киткән җиреннән кире кайтмады. Әйдә, минем кебекләр монда күп әле. Илдә чыпчык үлми, дип фикер йөртте. Мәгәр аңа эшләргә дә туры килмәде. Авырып егылды — һава килешмәде.

Әле, үзенә ярдәм кулы сузарга әзер торган Мөхлис сорау биргәч, Җәгъфәр шуларны хәтерләде. Әйе, аның дингез кичәрлек кенә дә акчасы юк шул. Ул менә ничәнче кабат инде акчаның ничек авыр төшүен, әгәр кесәңдә булмаса, сиңа аны беркем дә бирмәячәген аңлады.

— Аркадаш,— диде Мөхлис,— мин сезгә, кичә килегез, ярдәм күрсәтермен дигәнмен икән, бик дөрес әйткәнмен. Ул хакыйкатән шулай. Әмма минем ярдәмем киңәш рәвешендә булыр. Белә торгансыздыр, кайчагында файдалы киңәш хәмсин[1] миллион лирадан да кадерлерәк. Сүземне тыңласагыз, акчалы да, киемле дә, тораклы да булачаксыз. Һәрхәлдә, сез миңа гомер буе рәхмәт әйтеп яшәячәксез.

Мөхлиснең үзенең дә кәефе күтәрелеп китте. Салынкы кашлары астыннан күренгән соры күзләре җемелди башлады. Күгелҗем иренле зур авызы җәелеп китте.

— Мин бик тәшәккермен сезнең шундый әйбәт ярдәмегез өчен. Тыңлыйм сезне.

[1] Хәмсин — илле (сан).

— Мена нинди киңәш,— диде Мөхлис. Әйтеләчәк сүзнең кадерен арттырырга теләгәндәй, елмайган килеш, Җәгъфәргә карап торды.

— Сез беләсез микән, Җәгъфәр әфәнде, безнең Истамбулда казанлыларның күп булуын. Алар бер-берсе белән һәнүз [1] аралашып яшиләр һәм беркайчан да бер-берсенә кыен хәлгә калырга ирек бирмиләр. Шималь төрекләре арасында, әйтергә кирәк, ифрат дәрәҗәдә гүзәл инсаннар да аз түгел. Бик зур галимнәр, татар дөньясының күренекле хадимнәре дә бар. Сез аларга мөрәҗәгать итсәгез, мотлактан максадыңызга ирешерсез вә безнең уртак ватаныбызга якын көннәрдә кайтып китәрсез.

— Кемнәрне күздә тотасыз сез, Мөхлис әфәнде? — диде Җәгъфәр, нидер сизенеп күңелсезләнә башлаган хәлдә.

— Иң беренче адрес булыр могътәбәр Йосыф әфәнде Акчураныкы, диде Мөхлис.— Шундый бөек зат турында ишеткәнегез бар идеме?

Җәгъфәр бөтенләй күңелсезләнеп башын аска иде.

— Мин ул бөек затта булдым, Мөхлис әфәнде. Мин аны бик-бик яхшы беләм. Ул миңа ярдәм күрсәтә алмавын бик ачык аңлатты.

— Сөбханалла,— дип куйды Мөхлис аптыраудан, куе җирән кашларын маңгай уртасына кадәр күтәреп,— ничек инде алай?

— Шулай, мәсләкләребез бер түгел. Ул бераз сөйләшкәч тә мине үзенең дошманы сыйфатында күрә башлады.

Мөхлис аптыраудан кулларын җәеп җибәрүдән башка хәрәкәт ясый алмады. Ул өметсезләнә төшеп:

— Мин сезгә тагы бер адрес тәкъдим итеп карыйм алайса,— диде.— Шулай ук ифрат могътәбәр, бөтен дөньяга мәгълүм дин әһеле. Бусы бүгенге көндә шулай ук безнең изге Истамбулда яши.

— Сез Рәшит казыйны күздә тотасызмы? — дигән сорауны бирүен Җәгъфәр сизми дә калды.

— Әллә анда да булдыгызмы?

— Мәгаттәәссеф [2], булдым һәм шулай ук безнең юллар башка булып чыкты.

— Нәрсә сез... әллә?... — Мөхлис төртелеп калды.— Әллә сез чын дәһриме? [3] Әллә сез Русиядән бирегә социализм чирен алып килүчеме? Ул чагында, әфәндем, сезгә Мостафа Сөбхиләр кампаниясенә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Бәлки алар ярдәм итәр.

— Адресын бирегез,— диде Җәгъфәр шактый битараф кыяфәттә.

## 34

Хөсәен шулай да үз сүзендә торды, терелеп аякка басу белән, Тукайны күреп сөйләшергә ашыкты. Тынгысыз шагыйрь «Болгар» номерыннан «Амур» номерына күчкән икән. Габдулла бүлмәсендә ялгыз утыра иде. Ул Хөсәенне күрү белән, гадәтенчә якты чырай күрсәтеп, урыныннан сикереп торды һәм Хөсәенгә урын тәкъдим итте. Бу бүлмә «Болгар»дагысыннан иркенрәк тә, чистарак та булып күренде Хөсәенгә. Ул шагыйрьне яңа куышка күчүе белән котлады.

— Монда ничектер аулаграк,— диде Габдулла,— барысыннан да элек монда көфер почмагы исе күңелне ул кадәр болгатмый. Үзегездә ни хәлләр бар соң, Хөсәен әфәнде? Авырый дип ишеткән идем, ябыккансыз.

Хөсәен, бу турыда сөйләшмик, бик кечкенә мәсьәлә дигәнне аңлатып, кул селтәде дә үзен кызыксындырган сорауны бирде.

---

[1] Һәнүз — һаман, әле дә.
[2] Мәгаттәәссеф — үкенечкә каршы.
[3] Дәһри — алласыз, динсез, материалист.

— Безнең мәҗлескә син бер яшь егет ияртеп килгән идең. Теге көнне сөйләшергә мөмкинлек чыкмады, бүген сорыйм әле. Кем иде ул?

Габдулланың зирәк акылы шундук бу сорауның төбендә ни ятканын чамалап алды. Шагыйрьнең ябык йөзенә кинаяле елмаю билгесе чыкты.

— Сез инде, Хөсәен әфәнде, берәр җасус фәлән түгел идеме дип сорамакчы буласыздыр?

— Әлбәттә, шундый сорау бирергә тиеш табам мин, Габдулла.

— Ул бернинди җасус та, хыянәтче дә түгел. Ул сөттән ак, судан пакь, фәрештәдәй бер яшь зат, ләкин ифрат бәхетсез.

Габдулла Исхакның моннан бер ай элек бүлмәсенә килеп керүе, шигырьләрен күрсәтеп, киңәшләр соравы, шул очрашудан соң бик еш, көн аралаш диярлек Габдуллада булуы, аның бик беркатлы, мөлаем егет икәнлеге турында сөйләп алды.

— Һәм син ул егет ниндиерәк караштагы кеше дигән нәтиҗә ясадың инде?

— Ул — әле каләм очы да тимәгән чип-чиста кәгазь, Хөсәен әфәнде. Зинһар өчен хафа булмагыз. Аның өчен мин ручаюсь. Шик-шөбһәләр аркасында берүк төнге йокыларыгыздан мәхрүм калмагыз.

— Әгәр дә дөньяда охранка, патшаның итагатьле хадимнәре, жандарм идарәсе булмаса, бәлки мин йокымнан мәхрүм дә булмас идем. Әмма хикмәт шунда: соңгы вакытларда илдә революцион хәрәкәт яңадан күтәрелә башлагач, охранка безнең арага гына түгел, сезнең арага да, әфәндем, пачкалап-пачкалап шпионнар җибәрә башлады. Миңа мәгълүм булганча, ул хәтта безнең күренекле язучыларыбыз арасыннан да шпионнар вербовать итәргә чамалый.

Габдулла көлеп үк җибәрде.

— Монысы инде, минемчә, сезнең фантазия, Хөсәен әфәнде!

Хөсәен урындыгын Габдуллага якынрак тартып утырды.

— Син сабыйга ничек аңлатырга соң,— диде ачынып.— Ул егетнең синең арттан куелган күзәтүче булуы бик ихтимал. Һич булмаса шуны әйт: ул «судан пакь» кеше алдында тиешеннән артык туарылмадыңмы?

— Мин ул егеттән әз генә дә шикләнмим. Шул гына житмәгән иде. Эттән күп дошманым. Әле өстәвенә сез мине шпион белән куркытмакчы буласыз!

— Син өеңдәге дошманнарың белән үзең дә исәп-хисапны өзә аласың. Алар үрдәк бирсә, син аларга каз тоттырасың. Ләкин бу дошман хәтәррәк, дустым. Әллә син соңгы вакытта язганнарыңны патша ялчылары гафу итәр дип уйлыйсыңмы?

— Нәрсә яздым мин?!

— «Килсә байның ач халыкны күзгә-күз мыскылласы, яллый ул, әлбәт, пароход, ансы — байлар юргасы. Ярда торган ач халыкка йөз дә бормый, туп-туры, юргалый ул шунда тиз-тиз, кайда бай сайфиясе»— синең шигырьдән бит. Аннан: «Ул хәзер туктар синә, и ач авыл, мохтаҗ авыл! Җимерек өй каршында ич оҗмах кеби кәйфиясе»,— дип яздың. Әллә син байлар, эксплуататорлар сыйныфын яклаучы хөкүмәт бу сүзләрең өчен сине гафу итәр дип уйлыйсыңмы?

Габдулла кашларын җыерып, бераз уйланганнан соң, ачылып көлемсерәде.

— Афәрин. Шигырьләремне сез генә түгел, мин үзем дә яттан беләм.

— Анысы гаҗәп түгел,— диде Хөсәен,— синең шигырьләр басылып чыгу белән укучы тарафыннан да ятлана.

Габдулла, гадәтенчә, сул күзен кысарак төшеп, башын калкыткан хәлдә, кычкырып укырга тотынды:

— Фәкыйрь кеше! Кемнәр синә иман таккан?
Тәзкирәңә[1] мөслим диеп игълан таккан?

[1] Тәзкирә — паспорт, рәсми документ.

Кемнәр сине, намаз диеп, сәҗдә диеп,
Юкка тузанлы мәсҗедләрдә аунаткан?
Тагын сиңа ярченлек сәфаләтен [1]
Корал итеп йөретәләр җәһаләтен [2]
Гуаһлыклар бирәсең син, «әшһаде» дип,
Син ни белдең? Кемгә мәкъбул шаһадәтең? [3]
Мискин фәкыйрь, иркен сулыш та алмыйсың,
Аһ-ваһыңнан һичбер вакыт бушанмыйсың;
Көчләү сине сарих [4] золым иман белән:
Иртәгә ач үлмәм дип тә ышанмыйсың.

— Я, моның өчен миңа нинди җәза билгеләнәчәк?

— Шигырең искиткеч, миңа бик ошый. Син бу шигырьдә патша строена каршы кул күтәргәнсең. Бастыра алмавың инде сиңа, дускаем, күп нәрсә турында сөйли булса кирәк. Патша хәзрәтләре мондый шигырь язучыларны яратмый, аларны себе́р җибәрә.

— Димәк себер? — диде Габдулла,— тик алар җыенганчы, мин үзем китеп бармагаем.

Чыннан да, Габдулланың кыяфәте бик сулган иде. Аның үпкә чире белән газаплануын, тәртипсез тормыш, әйбәт тәрбия күрмәү аркасында көннән-көн хәле начарлануын һәркем белә иде. Хөсәен шагыйрьнең чыраена карап ирексездән уйга калды. Ни өчен аның китапларын бастырып, капитал туплаучы нәширләр, мәгърифәтче-меценат булып кыланучы байлар бу феноменаль талант иясен, ашыгып килүче газаплы үлемнән коткару турында уйламыйлар.

— Патша хәзрәтләре дигәннән, иска төште әле. Мин бер нәрсә турында мотлак сезнең белән киңәшергә тиеш.

— Киңәшербез. Ләкин миңа сүз бир, Габдулла. Яныңа сырышкан кешеләр белән, әгәр алар сыналмаган икән, аерата сак бул. Икенче тапкыр бу Исхакны, никадәр генә якын күрсәң дә, безнең утырышларга алып барма. Ризамы?

— Бер тапкыр дамы?

— Кайчан алып барырга мөмкин икәнлеген мин үзем сиңа хәбәр итәрмен, шулай сөйләштекме? Инде әйт. Киңәш итәргә теләвең ни турыда?

— Киңәшем шул: үзегез белгәнчә, патша хәзрәтләренең подданныйлары Романовлар династиясенең 300 еллыгын зур тантана белән билгеләп үтәргә җыена.

— Хуш?

— Миңа төрле даирә вәкилләре шул көнгә карата бер шигъри нотык язарга кушалар, янәсе бу милләткә хезмәт күрсәтү булачак, янәсе бу эш нәтиҗәсендә халкыбызның патша каршында абруе артачак, кызлар гимназиясен ачып җибәрүләре дә бар, ятим балаларга приют ачылуы да ихтимал. Янәсе эш бары миңа гына терәлеп калган.

— Теге мөфти хәзрәтләренең егерме биш еллыгыннан соң дарелмөгаллимат [5] ачылуы кебек икән. Төрле даирә вәкилләре дидең, шәт эшчеләрдән вәкил булмагандыр?

— Эшчеләрдән булмады,— диде Габдулла,— авыл агайларыннан да мондый үтенеч белән килүче күренмәде. Ләкин килгән кешеләрнең күбесе хөрмәткә лаек, алдынгы милләт хадимнәре. Алар белән исәпләшмичә мөмкин түгел.

— Син нәрсә дип җавап кайтардың инде аларга?

---

[1] Сәфаләт — түбәнлек, хурлык.
[2] Җәһаләт — наданлык.
[3] Кемгә мәкъбул шаһадәтең? — Кемгә кирәк шаһитлегең, аны кем кабул итә?
[4] Сарих — ап-ачык.
[5] Дарелмөгаллимат — хатын-кызлардан укытучылар хәзерли торган уку йорты.

— Өзеп бер сүз дә әйтмәдем. Башта сезнең белән киңәшәсем килде.

— Миннән киңәш сорасаң шул: әзлекле булырга, үз кыйбланңа табынып яшәргә кирәк. Әгәр син, нәрсәгәдер өметләнеп, патша каршында үтенеч белән бил бөгәсең икән, моннан берниндп дә файда көтмә. Бары канлы Николайның кем икәнлеген белүчеләр каршында абруең гына төшәчәк. Нинидер яхшылык телибез икән, без патшаны тәхетеннән бәреп төшерергә, Романовларның нәселен корытырга тиеш. Катымы? Бәлки шулайдыр, дустым, ләкин аларга шуннан башка берниндп дә хөкем чыгарып булмый.

— Әле революция давылларына ерак, Хөсәен әфәнде. Буламы әле ул? Ә безгә яшәргә кирәк. Дипломат та була белергә кирәк бит. Төрле юллар белән, хәтта котлау шигырьләре белән дә без халкыбызга ниндидер яхшылык итүләре, ташлама ясаулары өчен көрәшергә тиеш кебек, минемчә.

— Ялгышасың, Габдулла. Язма син андый нәрсәне?

— Әгәр мин шигырьне эзоп теле белән язып, халыкның йөрәгендә кайнаган уй-тойгыларны укучыма җиткерә алсам?..

Хөсәен уйга калды.

— Юк, синең исемеңә берниндп дә тап төшәргә тиеш түгел. Әйтә алмыйм, ничек кенә син бу максатыңа ирешерсең икән?

Кинәт кемдер ишек шакыды.

— Керегез!— дип кычкырды Тукай.

Бүлмәгә шаулап Габдулла Кариев килеп керде. Кергән кайнарлыгы белән Габдуллага нидер әйтмәкче иде, Хөсәенне күреп тукталып калды. Шушы араларда, спектакльләрен куярга рөхсәт сорап аның Петербургка баруы турында Хөсәен ишеткән иде инде, артистның пайтәхеттән кайткач, Тукайга беренче сугылуыдыр дигән фикергә килде ул.

— Я, ничек соң, Миңлебай, сәфәрең уңдымы?

— Мең бәла белән,— диде Кариев,— столоначальникларның бусагасын таптап, йөз суымны корытып, бөтенләй кешелек сыйфатларымны югалта яздым.

Ул, Тукайның кулын кысып, исәнләшкәннән соң, Хөсәен янына килде. Аның кулын байтак вакыт ычкындырмыйча тотып торды.

— Кеше өстеннән шундый издевательство, Хөсәен әфәнде. Бюрократиянең иң кабәхәт формасы. Барысы аяк чала, барысы рисвәт өмет итә. Ә фәкыйрь татар артистында нинди акча булсын ди. Сәмәне калил [1] һәр вакыт. Ярый әле Петербург яшьләре кичә уздырырга булышты. Шулай итеп кирәк акча тупладык.

— Шулай да әйләндереп чыккансыз, молодец,— диде Хөсәен.

— Миңа башка юл юк. Ул минем тормышым, Хөсәен әфәнде. Әгәр мин рөхсәт кәгазен ала алмасам, мотлакан Невага ташланачак идем. Менә, аллага мең шөкер, максатка ирешелде. Бүген үк генеральный репетиция, ә иртәгә «Купеческое собрание» бинасында спектакль куябыз.

Татар театрының башлыгы Габдулла Кариев янып, дәртләнеп яши иде. Хөсәен аларның нинди авыр тормыш кичерүләрен, фанатик печән базары әһелләре тарафыннан никадәр мыскыл ителүләрен, рәнҗетелүләрен белә. Хәтта араларындагы Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжскаяга Печән базарындагы дин мөтәгассыйблары [2] беркөнне һөҗүм иткәннәр. Ярый иптәшләре килеп чыккан һәм хулиганнардан артистканы коткарган. Шул талантлы, берниндән курыкмыйча үзен татар

---

[1] Калил — [illegible] түгел.

[2] Мөтәгассыйб — фанатик.

театрын тудыруга багышлаган нәфис туташка фанатикларның куллары күтәрелсен инде, моннан да түбәнрәк вәхшилекнең булуы мөмкинме?!

Узган очрашуында Тукай Хөсәенгә әле беркая да басылмаган яңа шигырен укыган иде. «Мәдхия» дип аталган ул шигырь нәкъ шул Сәхипҗамалга багышланган:

Күр: ничек, иртә кояш чыкса, җиһанга нур тула,—
Һәр күңелләр нурланадыр, чыкса Гыйззәтуллина.
Бу икәүгә тәңре биргән бертигез зур мәртәбә:
Берсе уйный күк йөзендә, берсе уйный сәхнәдә.

Бу юлларны Хөсәен шундук хәтәрендә калдырды. Инде Тукай бик дөрес сыйфатлаган шул кешегә һөҗүм итсеннәр имеш. Хөсәеннең йөзенә кан йөгерде. Кариев исә ул арада Хөсәенгә зарланган сыман итеп үзенең булачак бенефисы турында сөйли башлады. Әйтүенә караганда, аның һич кенә дә бенефислар белән маташасы килми, хәлбуки аны артистлар һәм театр сөюче алдынгы яшьләр кыстыйлар, уздырырга кирәк дип айга-вайга куймыйлар икән.

— Бик дөрес эшлиләр,— диде Хөсәен сүзгә кушылып.

— Нәрсәсе дөрес, Хөсәен әфәнде, әле «Сәйяр» труппасы биш яшьтәге сабый бала гына. Минем бишьеллык хезмәтем ул исәпкә алынырлык дәвер түгел.

Тукай утырган урыныннан торып Кариев янына килде.

— Биш ел дисең син. Исәпкә алынырлык дәвер түгел дисең. Барысы да, Миңлебай җаным, күз алдымда бит. Азмы газаплар кичермәдегез сез шул арада, цивилизациягә ия милләтләрнең артисты син күргән газапларны илле елда да кичерми. Хәтерлә әле: поездга билетлык акча булмау аркасында ничәмә тапкыр киемнәрегезгә кадәр сатып, хәерче хәлендә гастрольләрдән кайттыгыз. Ничәмә тапкыр сезне, полиция, Печән базары каһарманнары, хафизлар, тиречеләр, вәһаплар, итче әптериләр эзәрлекләде. Инде көненә бер сынык икмәксез ач утырган көннәрегез турында әйткән дә юк. Башка берәү булса, төкереп китәр иде. Мәсәлән, мин синең урыныңда булсам, валлаһи, чапан, чалма сатып алыр идем дә, киенеп, шәригать кушканча, үземнең баритон тавышым белән мәҗлестән мәҗлескә йөреп коръән укыр идем, бәлеш ашар идем, сәдака җыяр идем. Хәтереңдәме, Уральскида синең коръән укып җыйган акчаңа без ничә ай яшәдек?

— Юкны сөйләмә,— диде Кариев,— син үзең дә миннән ким кыйналмыйсың. Мин синең урыныңда булсам...

Сүзне Хөсәен бүлдерде.

— Мин тулысынча Габдулла әфәндепең фикеренә кушылам,— диде ул.— Ул хаклы. Сез онытмагыз: ул бенефисның иҗтимагый, хәтта сәяси ягы да бар бит әле. Хәтерлисезме, унынчы елны Галиәсгар әфәндененң әдәби эшчәнлегенә ун ел тулу юбилеен уздырган көннәрне? Нинди резонанс алды ул?! Онытмагыз, Кариев, булачак бенефис сезнең өчен генә түгел, ул сезнең аңа театрны пропагандалау да, ул, ахыр чиктә, безнең милли культурага хезмәт итү дә.

Кариев елмайган кыяфәттә ике кулын да өскә күтәрде.

— Сдаюсь, дусларым. Мин бирегә, бенефислар уздырып шөһрәт куып вакланма, синең болай да вакытың чикле, дигән сүзләрне ишетү өчен килгән идем. Инде хәзер килешмичә мөмкин түгел, башка чарам юк.

Шуның белән бу турыда сүз бетте, Кариев, соңгы инстанция итеп, Тукайга киңәшкә килгән иде булса кирәк. Сүз башка нәрсәләргә күчте. Тимерша Соловьевның тыңгысызлыгы, аның Печән базары татарлары өчен «Буф» исемле кино-театр ачуы турында сүз булды. Пурешкевичның Казандагы «Дворянское собрание» бинасында өч сәгатьлек

мәгънәсез докладын, аның Кытай куркынычы турында зарлануын искә алдылар, мөфти юбилее турында, Фәйзулла Туишевның Казанда эреле-ваклы гармуннарда концерт биреп, тамашачыны шаккатыруын сөйләштеләр. Провокатор Азефның кулга алынуын, вәзирләр шурасы рәисе Виттның Киев театрында эсер Багров тарафыннан атылуы, бу араларда мәдрәсәләрдә полициянең тентү артыннан тентү уздырып торулары турында, бу эшнең Оренбургта, Малмыжда, Сарапулда, Түнтәрдәге мәдрәсәләрдә булуы хакында сүз иярә сүз китте.

— Түнтәрдәгесе тәгаен Ишми ишан доносы буенча инде,— диде Тукай.

— Әлбәттә шулай,— диде Кариев.— Син аны үзеңнең шигырьләреңдә мәңге онытылмаслык итеп тасвирладың. Нәкъ үзе!

— Буби мәдрәсәсендәге хәлләр дә игътибарга лаек. Нәҗип Думави кулга алынган бит.

— Менә тапканнар чын революционерларны!— дип куйды Тукай.

— Аларны пантюркистлыкта да гаеплиләр,— диде Хөсәен.

— Мин мондый нәрсәгә ышанмыйм, валлаһи ышанмыйм. Патша сатраплары тарафыннан провокация әзерләнә, янәсе безнең халык пантюркизм һәм панисламизм идеаллары белән яши, шуңа күрә аны юк итәргә кирәк, бетерергә. Эшнең асылында шул ята. Әле Петербурда миңа кайбер татар зыялылары белән очрашырга, сөйләшергә туры килде. Алар, ап-ачык итеп, Парижда чыга торган «Мусульманин» журналының һәм Петербурда чыгарыла торган «В мире мусульманства» газетасының хуҗасы Хаҗи Тләшинең провокатор булуы турында сөйлиләр.

— Туктале, Миңлебай,— диде Тукай,— син сүзне Буби турында башладың, аннан әллә кайларга кереп чумдың. Син анык белдеңме, ул Буби мәктәбенә укырга киткәнме?

Кариев хәйләкәр генә елмаеп куйды, Хөсәенгә карап алды.

— Нигә син аны «ул» дип атыйсың, Хөсәен әфәндедән бер серем дә юк дисең бит. Туп-туры сора, мәгъшукәм Зәйтүнә диген.

Хөсәен дә елмаеп Габдуллага текәлде. Тукай исә канәгатьсез һәм оялган бер кыяфәттә аска карап сүзсез генә утыруында булды. Күренеп тора: Тукай үзенең Зәйтүнәсен һаман да әле оныта алмый иде. Аның белән очрашудан өметен өзмәгән, Чистайдан яңа хәбәрләр көтә. Бу юлы исә мәхәббәтенә бәйләнешле сүзгә кушылуын шагыйрь үзе дә сизми калды.

— Зәйтүнә узган көзне Бубига кызлар мәктәбенә укырга киткән шул. Мин моны анык беләм.

Габдулла Кариев бик тәфсилләп Зәйтүнә турында сөйли башлады. Янәсе ул бик чибәр кыз, аның йөзе шундый, кашы мондый...

Шушы урында Габдулланың түземе төкәнде, ул үз-үзен тота алмастан:

— Житте сиңа, Миңлебай,— дип кычкырып җибәрде,— нәрсә син аның турында әйбәт аргамакны мактагандай сөйлисең!

— Гафу ит,— диде Кариев,— иң мөһим сүземне генә әйтим дә бу турыда бер кәлимә сүз дә булмаячак. Мин сиңа вәгъдә итәм, Апуш, безнең труппа быел Чистайга барачак. Мин анда Зәйтүнә мәсьәләсен ачыклаячакмын. Ант итеп әйтәм. Хөсәен әфәнде шаһит!

## 35

Исхак үзенең чарлактагы тар бүлмәсендә чәй эчеп утыра иде. Аста аяк тавышлары ишетелде. Тәгаен «Житель» үзе шыгырдавык баскычтан менә башлады. Исхак «Житель» исемен йөртүче җасус Төхфәтне аяк басуларыннан ук, баскычның нинди тавыш чыгаруыннан ук таный.

Исхакның йөзеннән кан качты, ул агарынып калганын үзе дә сизде. Хәзер җикерену, акырынулар башланачак, Төхфәтнең явыз карый торган котсыз күзләре Исхакның бәгыренә кадалачак һәм шуннан соң... Егетнең тез буыннары йомшарып мамыкка әйләнгәндәй булды, йөрәге авырттырып кысылды, колаклары гөжли башлады. Ул, эчәргә дип җыенган чәен калтыранган кулында тоткан килеш, дәһшәтләнеп әҗәлен көткәндәй, үзенең патронын көтеп торды.

Ишектән керү белән, Төхфәт кашларын җимерер, явыз карашын Исхакка текәде. Исәнләшү юк, хәл белешү юк, сүзне туп-туры эштән башлады.

— Ничә көн узды, ә син тик ятасың. Нигә язып бирмисең, хәшәрәт?!

Исхак аякка басты, кулындагы чокырын һаман өстәлгә куярга онытып, кызганыч бер елмаю белән әйтте:

— Әйдәгез узыгыз, менә чәйдән авыз итегез. Сөйләшик, аңлашыйк, Төхфәтулла абый!

Төхфәт өстәл янында торган урындыкны ачу белән дыңгырдатып бүлмә уртасына куйды да аякларын чалыштырып утырды. Аның күзләре әле һаман мескен бер кыяфәттә басып торган Исхакта, кыяфәте әле һаман ачулы, бернинди рәхим-шәфкать вәгъдә итмиләр иде.

— Сөйләшеп, аңлашып торасы юк, беткән җан? Барысы да сөйләшенгән, аңлашынган. Утыз сумны алып кесәңә бөгәрләп салдыңмы, эшлим, барысын да көне сәгате белән язып торам, дидеңме? Менә шулай. Инде аңлашып торасы калмаган. Нигә, хәшәрәт җан, теге идән асты җыелышыгыздан кайткач та язып, донесениеңны тиешле урынга тапшырмадың? Шуны да аңламыйсыңмыни, чүпрәк баш, анда бит синең язуыңны көтәләр. Утыр! Торма алдымда тәре баганасы кебек калкынып!

Исхак башта алдап котылмакчы булды. Утырып, чокырын тәлинкәсенә куйды, елмаерга итте, янәсе ягымлылык күрсәтә.

— Ә мин ул язуны язган идем, Төхфәт әфәнде, тик каядыр куйганмын, югалтканмын.

Күрәләтә ялганны ишетү белән, Төхфәт чәчрәп урыныннан купты, Исхакка ташланды.

— Ах, син, кабәхәт җан,— Төхфәт Исхакның казаки изүен йомарлап, бугазына китереп төртте.— Әйт, нигә язып бирмәдең? Син бит миңа антлар эчеп вәгъдә биргән кеше. Син бит, хәшәрәт җан, тегеләр алдында минем йөзгә пычрак атасың. Мин бит синең өчен поручаться иттем.

Төхфәт Исхакны, изүеннән тоткан килеш, аягына бастырды. Аның буылудан кызарып чыккан йөзенә төкерде дә каты этеп кире урынына утырды. Исхак, дәһшәт көйрәгән күзләрен ачкан килеш, һаман Төхфәткә карап торуында булды. Битендәге төкрекне түбәтәе белән тиз генә сөртеп алды. Ниһаять, балаларча чырылдап җылап җибәрде.

— Нәрсә, ни дәрәҗәдә кабәхәт икәнлегеңне аңладыңмы? — диде Төхфәт,— давай, җыла, җыла. Мин сине кызганам ди, көтеп тор!

Төхфәт, явыз көлемсерәгән кыяфәттә, күз яшьләрен мул агызып, үксеп һәм үксү аркасында аңлашылырлык сүз дә әйтә алмый азапланган Исхакка карап утырды.

Ниһаять җасусның түземе төкәнде.

— Җитте сиңа! — дип кычкырды.— Юкса мин сине хәзер үк каталажкага озаттырам.

Исхак озак җылаганнан соң бераз өнен җыя алды, сулыгу аркасында өзеп-өзеп сүз башлады.

— Мине кичер, алла хакы өчен, Төхфәт әфәнде, алла хакы өчен кичер, син дә бит минем кебек үк мөселман бәндәсе. Алла хакы өчен дип әйтәм, кичер. Мин эшли алмыйм. Мин булдыра алмыйм мондый

эшне. Мин, валлаһи әгъзам, аның кешесе түгел. Кичер мине, алла хакына, җаным. Башка барлык йомышларыңны үтәргә риза. Әйт, менә телең белән идән сөрт дип, сөртәм. Тик бу эшне генә булдыра алмыйм.

— Булдыра алмыйм дисең? Әзугә кул куйганда, утыз сумны казаки кесәңә салганда ни уйладың? Юк инде, җаныем, синең койрык бозга каткан хәзер, җыласаң да, үкереп җирдә аунасаң да бернинди файда юк.

Исхак тагын бераз шыңшыды да кинәт үҗәтләнеп:

— Мин артык ул охранкага эшләмим, үтерсәләр дә эшләмим,— дип кычкырды.

— Ни өчен? — дип сорады Төхфәт ясалма бер тынычлык белән.— Тегеләргә сатылдың мыни?

— Мин беркемгә дә сатылмадым?

— Соң эш нәрсәдә? Ни өчен шундый изге хезмәттән баш тартасың?

— Бернинди изге түгел ул җасуслык.

— А, җасуслык?! Сиңа шулай дип аңлаттылармы халык һәм падишаһ хәзрәтләренең дошманнары? Син шуларның сүзенә ышандыңмы?! Менә нәрсә, озакламый аларның тамырларын бөтенләй корытачакбыз. Син белмисең әле, башың яшь, безнең кебек туган туфракка хезмәт итүчеләр аларның үзләре арасында да бар. Хәзер охранкага аларның иң кәттәләренең исемлеге керде. Ә син җасуслык, җасуслык дигән буласың. Әз генә түз. Хезмәт ит, эшнең барлык серләренә үзем төшендерәм. Гомерлек ганимәт малы җыярсың. Картайган көнең бал-май эчендә үтәр, менә дигән бай кәләш алып җибәрерсең, җүләр, гөбәдиягә к... куйма.

Исхак тәмам алҗып, терсәгенә таянды да күзләрен йомып, минле маңгаен учына куйды.

— Сүземне тыңла,— диде Төхфәт бу юлы дустанә бер тонда революционерларның кем ярдәме белән һәм ничек тотылганын шәрехләгәч,— бу изге эш. Син бит халкыбызның иң затлы, иң абруйлы кешеләре ни әйткәнлеген беләсең. Алар бит барысы да безнең халыкка карата Россия патшаларыннан да хәер-хаһрак кеше юк, җир йөзендә бер генә патша да мөселманнарны бу дәрәҗәдә сөйми, диләр. Ничек итеп безнең халыкка изгелек күрсәткән шул патшага хезмәт итмәскә!?

— Кемнәр әйткән?— дип куйды Исхак.

— Кемнәр дип, халкыбызның иң олы кешесе Исмәгыйль бәк Гаспринский хәзрәтләре әйткән. Инде килеп халкыбызны йокыдан уяту өчен көрәшүче мөгътәбәр Рәшит казый әйткән. Укыганың бармы аның «Мирьатын»?

Исхак дәшмәде. Әйе, аның кайчандыр укыганы бар иде Рәшит казый язмаларын. Әле Тукайлар белән бергә булганда Хөсәен Ямашев, үзебезнең әдәби хәзинәгә кагылып, «Мирьат»ны да, башкаларны да бик нигезле сүтеп ташлаган иде. Андый әсәрләрнең милли азатлык өчен көрәштә зарарлы икәнлеген аңлатты. «Я, хода,— дип уйлады Исхак,— кемнәр кулына килеп эләктем мин, я хода». Ул баштарак җиңелрәк карады шул. Бу явыз Төхфәткә алдын-артын уйламыйчарак ризалык бирде. Төхфәт исә эшне зурга җибәрде, юк-бар сәбәп табып Исхакны охранка кулына тоттырды. Хәер, эш анда гына мени. Эш бит ачлыкта. Исхак — фәкыйрь шәкерт, өйдән бер тиенлек ярдәм килми башлагач, кая барып бәрелергә белмәде. Бай шәкертләргә самавыр куеп, вак йомышларын башкарып карады. Мәгәр тегеләр табыныннан калган калдык-постык ризык яшәү өчен җитәрлек түгел иде. Исхак, мәет козгыныдай, үлгән кешеләрнең җеназасын каравыллап йөри башлады. Янәсе, сәдака эләгеп, шуңа яшәп булмасмы. Ләкин ул да аны рәхимсез ачлык җәфасыннан коткара алмады. Кул эшенә, әйбер ташу, утын

яру кебек эшләргә Исхак сәләтсез иде. Сынамады түгел, сынап карады. Тик аны беркем дә алмады. Аңа «җан көеге» дип карадылар. Менә шул чакны явыз Төхфәт очрады аңа. Аны ашатты, ярдәм кулын сузды. Бераздан, һич гаепсезгә, Исхак полиция участогына эләкте. Юкса, бернинди гаебе юк иде ласа. Печән базарында бер итче, Исхак кесәгә керде, янчыгымны алды, дип дау куптарды. Халык җыелды, участокка алып киттеләр. Ул арада аны, ни өчендер, Казан урамнары буйлап конвой белән охранкага озаттылар. Ә анда инде барысы да булды, кызыктыруы да, куркытуы да. Шулай тозакка төште Исхак. Тиздән ул Төхфәтнең күптән шунда эшләгәнлеген, охранканың ышанычлы бер агенты икәнлеген белде. Алай гына да түгел, Төхфәт Исхакка киңәшләр, эшләр тапшыручы сыйфатындагы бер башлык булып китте. Ул ни теләсә, нәрсә кушса шуны башкарырга тиеш иде хәзер Исхак. Баштарак шәкертләр арасында кайнашырга, кем ничегрәк уйлый, сөйли, шуны белергә куштылар, янәсе шәкертләр арасында революция чире кагылганнары, панисламистлар, пантюркистлар юкмы. Аннан соң, менә мондый «олы» эшкә җигелергә куштылар егеткә. Исхакның гомерендә шигырь чыгарганы юк иде. Аның өчен Төхфәт шигырьләр язып бирә башлады. Менә шуларны Тукайга күрсәт, үзем яздым дип әйт, диде. Менә шулай башланды Исхакның шагыйрьләр арасына кереп, бер генә юл шигырь язмаган хәлдә дә, өметле «яшь шагыйрь» булып китүе.

Корбанына һөҗүм итәргә торган юлбарыстай каршына утырган Төхфәткә карап, ул шуларны хәтерләде. Исхак чын шагыйрьләр белән аралашмаса, аларның төнге җыелышларында булмаса, ул кешеләрнең халык бәхете өчен үзләрен һич кызганмыйча тырышуларын якыннан күрмәсә, бәлки хәзерге көнгә калмас та иде. Ләкин аңарда намус чаткысы сүнмәгән иде әле. Көннәрдән бер көнне аның күзләре бөтен тирә-юньне ачык күрерлек булып ачылды, һәм ул чираттагы әләген язмаска булды.

— Менә нәрсә,— диде Төхфәт,— син тынычландың, әйткәннәрне аңладың булса кирәк. Синең өчен тагын ике шигырь чыгардым әле мин. Тукаеңа күрсәт, әгәр яраса, Тукай химаясе белән бастыр. Араны өзмә, үзеңне тыйнак кына, элеккечә тот, ярарга тырыш, син аны булдырасың. Ә тегеләр узган төнге утырыш турында бүген язып, иртәгә почта ящигенә илтеп сал. Менә сиңа конверт, менә сиңа кәгазь, менә болары әлеге шигырьләр. Ә инде әйткәнне эшләмәсәң, үзеңә үпкәлә. Беттем дип исәплә. Үзен фаш иткән, я эштән баш тарткан җасусларны беләсеңме нишләтәләр? — Ул тынып торды. Аннан күңелсезләнеп өстәп куйды.— Шунысы үкенечле: үзем була алмыйм ул Тукайлар арасында. Бишенче елдан бирле мине белүчеләр бар. Шикләнүләре бик мөмкин. Юкса, күрсәтер идем мин аларга!

Ул ашыкмыйча гына урыныннан торды да ишеккә таба юнәлде. Ишек тоткасына кулын сузгач, тагы Исхакка таба борылды.

— Карасана, синең белән әвәрә булып, эшнең иң әһәмиятлесен онытканмын ич.

Ул яңадан өстәл янындагы утыргычка килеп утырды. Әмер тоны белән әйтте.

— Ал әле каләм белән кәгазь!

— Нәрсә тагы?— диде Исхак йөзен чытып.

— Әйткәнне эшлә! Кәгазь белән каләм ал. Менә мин әйткәнчә язарсың!

Исхакка хәзер барыбер иде. Ул үзен төштәгедәй тонык хис итте. Дәфтәрдән бер бит кәгазь ертып, өстәлгә ташлады, кулына каләм алды.

— Яз,— диде Төхфәт,— әйбәт итеп, ачык итеп яз. Менә болай диген: «Хөрмәтле Хөсәен әфәнде, гафу үтенәм, әмма сезне кисәтүне үзем-

нең инсаният бурычым дип саныйм». Яздыңмы шулай дип? Карыйм әле.

Төхфәт шадра йөзен өстәлдә яткан кәгазьгә якынлаштырып язуны укыды да, күрәсең канәгать булып калды, эшен дәвам иттерде.

Исхак ул әйткәннәрнең барысын да язды, бернинди каршылык күрсәтмәде. Чөнки бу эшләрнең аңа бөтенләй кирәге юк иде инде хәзер. Ул үзен башка дөньяда тоя иде.

Төхфәт, кәгазьне кулына алып, урыныннан торды. Аны селки-селки киптерде һәм кесәсенә бөкләп тыкты да, бер сүз әйтмәстән, чыгып китте. Аның баскычны шыгырдатып гөрс-гөрс аска төшүен Исхак, төштәге кебек, нииндидер авыр, калын томан пәрдәсе аша гына ишетте.

Аяк тавышлары тәмам тынгач, ул кинәт үзен иркенлектә сизде, йөзенә аның чалыш, зәһәрле бер елмаю чыкты. Ул өстендәге иске казакиен салып караватына ташлады да, һаман әле шул явыз елмайган хәлендә, стенага карап, зиһенен җыярга тырышып ятты. «Төкерәм мин сезнең дөньягызга,— диде кычкырып,— төкерәм, төкерәм!». Ул кинәт торып, бүлмә ишегенең келәсен төшереп килде, пыялаларында салават күпере төсләре чагылган бәләкәй тәрәзә янына килде. Каршыда биек таш дивардан башка берни дә күренми иде. Исхак шуны, беренче мәртәбә күргәндәй, озаклап карый башлады. Авылын, кечкенә инеш буена урнашкан агач мәчетле, тузган күперле авылын, салам түбәле, мүкләнгән бүрәнәләре ярылып киткән өйләрдән торган, үзе кайчандыр уйнап үскән авыл урамын хәтерләде. Исхакның этисе мәзин иде. Бичара, гомере буена авыл мулласының тормышына, дәрәҗәсенә кызыгып яшәде. Фәкыйрь булды, чөнки гомерендә тугыз кызга бер ир бала гына дөньяга килгән иде. Ә ике имана җир белән әллә кая китеп булмый. Әйе, Исхакның этисе бердәнбер кадерләп үстергән улын бик тә инде мулла итәсе килде, аның бай, мөлкәтле, бәхетле булуын теләде. Казанга Касыйм хәзрәт мәдрәсәсенә укырга җибәрде, үз авызыннан өзеп булса да аңа ярдәм итте. Хәзер ул юк инде. Биек агач башларында күңелне шомландырып каргалары кычкырынган зиратта дүрт елдан бирле ята...

Исхак, кинәт ни эшләргә кирәклеген хәтерләп, мич артында яткан бау кисәген кулына алды. Бермәл аңа чирканып карап торды, аннан бауны караватка ташлады да өстәл янына килеп, дәфтәр битен ерта башлады. Аңа ачык итеп: «Төкерәм мин сезнең дөньягызга!» дип язып куйды. Аннан уйга калды. Тагы язды...

### 36

— Сөйлә, Карый, нинди яңалыклар алып кайттың миңа,— диде Тукай.— Алып кайткан хәбәрләрең бәгыремне телгәләячәкме, яки син мине бәхет ширбәтеннән авыз иттерәчәксеңме?

Ике дус Тукай бүлмәсендә утыралар иде. Чистай шәһәрендә «Сәйяр» гастрольләреннән соң, Габдулла Кариевның әле генә Казанга кайтып төшүе иде. Артистның Тукайга биргән вәгъдәсе бар. Ул, Чистайга бару белән, шагыйрь гашыйк булган кызны күреп сөйләшергә, Тукай тапшырырга кушкан карточканы (әгәр җае туры килсә) Зәйтүнәгә бүләк итәргә тиеш иде.

Гастрольләр шактый озакка сузылды. Һәрхәлдә, Тукайга шулай тоелды. Чөнки ул түземсезлек белән һәр көн Карыйны көтте, ул алып кайтачак хәбәрләрне нинди генә рәвешләргә кертеп күз алдына китермәгәндер. Менә, ниһаять, Карый кайтып төште.

Тукайның зур өмет белән көтүен аңлаган Кариев сүзен тыныч кына башлады.

— Апуш,— диде,— бәхет ширбәтләрен сиңа эчерерлек хәбәрләр

алып кайтмасам да, син тынычланырлык, дөресрәге, өметләрең өзелмәслек әйбәт хәбәр алып кайттым.

Тукайның күзләре яктырып китте.

— Я, я, сөйлә, мин тыңлыйм,— диде ул түземсезләнеп.

— Ашыктырма,— диде Карый тыныч кына,— мин хәзер барсын да чәчми-түкми тапшырачакмын. Чистайга барып төшкән көннән иртәгесен үк мин синең Зәйтүнәңне эзләп киттем. Бәхеткә каршы, аның туганнан туган абыйсы, Ибраһим Камалетдинов дигән кеше очрады, шул мине озата барды.

— Я, ничек каршы алды соң ул сине?

— Сабыр ит. Дөресен әйтергә кирәк, ул синең мәгъшукаң бик фәкыйрь гаиләдән икән үзе. Биш бала арасында, өч яшеннән үк әтисез үскән ятимә кыз икән. Бу кадәресен теге Ибраһим атлы егет сөйләде. Өйләре дә тавык кетәге кебек кенә — шәһәр читендәге бер алачык.

Карый Зәйтүнәнең өен тасвирлавын тыңлаганда Тукай ирексездән: «Мин аны өзелеп сөям, ә нинди гаиләдән, нинди тәрбия алып үскән кыз икәнлеген дә анык белмим ләбаса», дип уйланды. Бары шуны гына белә иде Тукай: Зәйтүнәнең ике абыйсы да Казанда Бәхтиевләр магазинында приказчик булып хезмәт итәләр. Ләкин Тукайның аларны күргәне дә, алар белән сөйләшкәне дә юк. Нинди кешеләр алар, алла белсен.

Тукайның Зәйтүнә белән беренче кабат очрашуы моннан өч ел «Эльислах» идарәсендә булды. Соңыннан Фатих Әмирхан бу очрашуны Зәйтүнә үтенече белән оештырганлыгын сөйләде. Ә Зәйтүнә исә Фатихка кодача туры килә икән. Ул вакытта газета идарәсе Екатерининский урамында Аппаковлар өендә иде. Зәйтүнә белән беренче очрашуын һич онытасы юк аның. Ул көнне идарәдә Тукай, Фатих, Вафа Бәхтияров, Фатихның энесе Ибраһим утыралар иде. Көтмәгәндә, уйламаганда идарәгә ике кыз килеп керде. Тукай, чәчәк авыруыннан калган чагырлыгы аркасында, хатын-кыз белән аралашырга яратмый иде. Ул үзенең тышкы кыяфәте белән шагыйрьлеге арасындагы тигезлекне таба алмыйча гомер буе газапланды. Ә кызлар исә бик кыю булып чыктылар — аерата яшьрәге. Фатих, юри үч иткәндәй, җитмәсә: «Туташлар, Тукай әфәнде белән таныш булыгыз,— дип, кызларны тәкъдим итте. Олысын — Бәдриҗиһан, кечесен — Зәйтүнә дип атады. Кызлар бик бай киенмәсәләр дә, килешле генә аксыл күлмәкләрдән, бәләкәй генә хәтфә калфактан, яшь, зифа, чибәрләр иде. Тукай теләмичә генә, кырын күз белән генә, кызларга күз ташлап алды. Олысы буйчанрак, зәңгәр күзле, чибәр, ләкин йөзендә беленер-беленмәс шадралары бар. Ә кечесе исә коңгырт-кара күзле, каләм кашлы, бөтен җире килгән, сөяктән ясалгандай төз борынлы, килешле авызлы кыз икән. Тукайның шундук күңеленә сеңеп калганы — Зәйтүнәнең ягымлылыгы, йөзенә, күзләренә чыккан мөлаемлыгы булды. Мондый да ягымлылык белән матурлык бергә килер икән! Габдулла тагы да югала төште, кызга яңадан күтәрелеп карарга батырчылык итмәде, кызның үзенә таба сузылган җыйнак матур кулын ашыгып кына кысты да, бик җитдиләнеп, өстәлгә текәлде. Зәйтүнә исә, һаман аңардан күзләрен аера алмыйча, карап тора иде әле. Ниһаять, Тукай бер сүз дә дәшмәгәнгә булса кирәк, кызлар читкәрәк китеп, стена буендагы урындыкларга урнаштылар, Фатих белән сүз башладылар.

Тукай өстәлгә текәлсә дә, күңелендә һаман Зәйтүнә сурәте тора иде әле. Аның шундук борылып күзләре талганчы кызга карап торасы килә иде. Мәгәр акыл моңа рөхсәт бирми һәм шагыйрь ике ут арасында калган иде.

Кызлар идарәдә шактый озак утырдылар. Зәйтүнә сүзчән булып чыкты. Ул Чистайлыларга хас җиңелчә мишәр акценты белән ни турындадыр сөйли, сирәк-мирәк аңа апасы кушыла. Зәйтүнәнең сүзләре

хәтердә калмаса да, Тукайның колагында тавышы һаман яңгырап торды. Кызларның идарәдә булуы рәхәт тә, газаплы да иде. Ул үз гомерендә беренче кат мондый әкәмәт бер хәлгә тарыды. Байтак утырып, кызлар чыгып киткәннән соң да, үз номерына кайтып караватына яткач та, Тукай, үзе дә сизмәстән, Зәйтүнә турында уйлаудан аерыла алмады. Бу ифрат татлы иде. Бу татлы һәм куркыныч та иде.

Ул көнне, моңарчы бер дә булмаганча, Тукай бәхетле төшләр күреп бик тыныч йоклады.

Беренче күрешүдән соң Зәйтүнә белән яңадан өчме-дүртме тапкыр очраштылар алар. Берсе «Әльислах» редакциясе янында урамда, икенчесе «Шәрык клубы»нда, өченчесе пристаньдә. Әйе, тагы бер тапкыр ул Зәйтүнәнең апасы белән барганын күреп, трамвай тәрәзәсеннән генә исәнләшеп үтте.

Габдулла бу минутларны энәсеннән җебенә кадәр хәтерендә саклый, әгәр кирәк булса, бу минутларның һәр мизгелен тәп-төгәл, бәйнә-бәйнә сөйләп чыга ала. «Шәрык клубы»нда Тукай шигырь укып сәхнәдән төшкәндә, Зәйтүнә аның өстенә конфетти сипте, аның очкынлы күзләре мәхәббәт, соклану белән Габдуллага текәлгән иде. Алар ул көнне залда стена буенда бик озак сөйләшеп тордылар. Вәгъдә бирештеләр. Габдулла да, Зәйтүнә дә танцыга өйрәнергә һәм һәрвакыт бергә танцевать итәргә булдылар. Алай гына да түгел, Габдулла кичә беткәч Зәйтүнәләрне озатып куярга сүз бирде. Ләкин кыюсызлыгы, оялуы аркасындамы Тукай кызга биргән вәгъдәсен үти алмады.

Ул көнне Тукай үзенең булдыксызлыгын, сүзендә тормавын төне буе каһәрләп чыкты. Шул төнне аның башына кызыклы бер шигырь темасы да килде. Берәү эссе көндә бик теләп су коенырга уйлый, ләкин ул судан чиркана, суны җилкә аша, тәненә тидермичә читкә коя. Коя да шатлана, ярый әле тәнгә тимәде, ди. Минем мәхәббәтем дә шундый бит, дип ут йотып уйлады Тукай. Ләкин бу чын, олы мәхәббәт иде, сүнми дә, бетми дә торган бер илаһи нур иде. Инде Зәйтүнәне трамвайдан күргәннән соң да, аның матур, җыйнак, йөрәккә яшәү җылысы бирә торган кулын кысканнан соң да ул шигырьләр язды, тегә су коенучы мәзәк кеше турында да шигырь язды. Мәгәр һаман, бер кем дә сизмәсен дип, үз исемен яшереп бастыра иде. Кызык гыйшык иде бу!

Кыз әниләре белән Чистайга кайтып китәргә җыенгач, Тукай аны озатырга булды. Устьега да төште, Зәйтүнәләр китәсе пароходны да эзләп тапты, ләкин кызныңниндидер ят егетләр белән пароход палубасында торганын күргәч, кинәт каушап калды, аның янына барырга җөрьәт итмәде. Әйе, кызык гыйшык иде бу! Тукай тагы төн ката үзен табалап чыкты. Йөрәген кисеп бирерлек дәрәҗәдә яраткан кешеңә шундый вәгъдәсезлек күрсәт инде! Дөньяда булмаслык хәл.

Хәлбуки кызның сурәте күңелендә үскәннән-үсә барды. Ул гел Габдулла белән янәшә булды, бер генә минутка да онытылмады. Тукайның Зәйтүнәне өзелеп яратканлыгы инде якын дус-ишләренә дә билгеле иде.

Фатих Әмирхан аның исеменнән язган хатка шундый авыр җавап килгәч тә әле ул өметен өзмәде. «Зәйтүнә үзе язмаган бит, бәлки аның исеменнән кемдер араны болгатып йөридер», дип уйлады. Инде шул билгесезлекне Чистайдан кайткан Кариев бүген бетерергә тиеш иде.

— Без Ибраһим Камалетдинов белән аларның өенә барып кергәндә, Зәйтүнә япа-ялгызы гына чигү чигеп утыра иде,— дип сүзен дәвам итте Кариев.

Тукай аны бүлдерде.

— Ниндидер сылтау белән баргансыздыр бит, әллә шулай тиктомалдан барып кердегезме?

Кариев күз кысып баш чөйде.

— Син нәрсә, әллә мине чапансыз дивана дип белдеңме? Сәбәп бик муафыйк иде. Безгә бер артистка җитмәде. Уйнамас микән дип, Зәйтүнә туташка үтенеч белән бардык.

— Һичек соң, ризалык бирдеме?

— Мин баргач булмыймы соң инде?

— Мактанма әле, төп мәсьәләгә якынлаш.

— Дөресен әйтим, валлаһи, Зәйтүнә Фатих хаты турында берни дә белми. Хат аның кулына бөтенләй эләкмәгән дә. Күрәсең, хатны әнисе алган да, кемнәргәдер укытып, үзенең карашын Зәйтүнә фикере итеп яздырган. Син берни уйламыйча хатны хәзер туп-туры кызның үзенә яза аласың. Ул сине ярата.

Тукайның йөзенә ниндидер рәхәт бер тынычлану йөгергәндәй булды. Күренеп тора, ул җиңеләеп калган, авыр көтү газапларыннан котылган кебек иде.

— Юк, дустым,— диде ул,— мин аңа бернинди хат та язмаячакмын, бернинди тәкъдим ясамаячакмын. Минем өчен иң кадерлесе: синең соңгы сүзләрең. Рәхмәт, миңа башка берни дә кирәкми. Миңа шулай, мелла кем.

## 37

Чакырылмаган кунаклар китеп, бүлмәсендә тынычлык урнашкач та Тукай эшкә кереште. Бу көннәрдә аның илһам чишмәсе челтерәп кенә түгел, гөрләп, ургылып ага иде. Башка бер-бер артлы кыю фикерләр килә, күңел яңа гүзәл күренешләр, сурәтләр белән тула. Өзлексез язасы, барысын да актарып кәгазьгә ташлыйсы килә. Язу да ансатлаша, сүзләр, җөмләләр, строфалар да каләм очыннан язып өлгермәслек тизлектә сибеләләр. Шагыйрь өчен иң бәхетле минутлар бу! Дөнья мәшәкатьләре, рәнҗүләр, авырулар барысы да онытыла, күңел түрендә шигырь бөреләнә, чәчәк ата.

Андый минутларда Тукай бер утыруда шигырен башыннан ахырына кадәр язып чыга. Күп очракта, иртәгесен, шигырьне әллә ни төзәтәсе, үзгәртәсе дә калмый. Габдулла мондый чакларда «кай җиребез белән без Галиәсгар әфәндедән ким!» дип үзалдына кәефләнеп тә алгалый, чөнки драма остасының турыдан-туры акка язуын белә. Ул гомумән тирләп-пешеп, гүр азаплары кичереп, чәчләрен йолкый-йолкый язучыларны аңламый да, яратмый да.

Ләкин ялгызлыктан файдаланып, дәртләнеп эшкә керешкән Габдуллага бу юлы да ирек бирмәделәр. Һәрвакыт ачык торган ишектән каударланып Солтан Рахманколый килеп керде. Элек ул кәефләнеп, салмак кына атлап, Тукай бусагасын уза иде. Уза һәм үзендә «рәт» барлыгын игълан итеп, Тукайны күңел ачарга чакыра иде. Бүген Солтанның чырае качкан, күзләре түгәрәкләнгән, кашлары маңгаена менгән иде. Солтан, сулышына буылып, бераз карап торганнан соң:

— Тукай, эшләр харап бит,— диде,— ишеттеңме, безнең Исхак асылынып үлгән.

Габдулла утырган урыныннан корт чаккандай сикереп торды.

— Теге минем яшь дусмы?

— Шул инде. Кичә кич үзенең җырлагына соңгына кайткан да керләр элә торган бауга асылынып үлгән.

— Бернинди язу да калдырмаганмы?

Солтан анык белмәвен аңлатырга теләп, җилкәләрен җыерып куйды.

— Ниндидер язу калдырган, имеш. Әйтүләренә караганда, «Төкерәм мин сезнең дөньягызга», дип язган булса кирәк.

Икесе дә ни әйтергә белмичә, байтак вакыт тын тордылар. Тукай әле моннан ике көн генә элек Исхакның үзенә кереп чыгуын, аларның шигырь төзелеше, Сәгыйть Сөнчәләй, Нәҗип Думави турында сөйләшеп утыруларын әйтте.

— Әйе, аннан ул тагы минем Истамбул хәбәрләре белән ни дәрәҗәдә кызыксынуымны сорады,— диде Тукай,— мин аңа шул үзебезнең газитләрдә басылган хәбәрләрдән артыгын белмим, дип җавап бирдем. Ул миңа Истамбулда коточкыч пожар булуы, утның Галата бистәсеннән чыгып, бөтен шәһәрне каплавы һәм ун мең йортның күз ачып йомганчы янып бетүе турында әйтте. Беләм, дидем мин, газеталарда бу турыда басылган. Бик кызганыч, йорт-җирләре янып бөлгенлеккә төшкән төрек кардәшләрне чын күңелдән кызганам, дидем.

Тукай, серле рәвештә уйланып, түшәмгә текәлеп торды.

— Хөсәен әфәнде миңа ул егеттән сак булырга кушкан иде,— диде,— соңгы очрашуымда мин аның кисәтүен дә хәтерләдем һәм ни өчен бу Исхак тиктомалга кирәкмәс нәрсәләр белән кызыксына башлады әле дигән сорау башымнан узды. Аннан, мин әйтәм, җүләрләнмә, бу егет бит беркатлы, фәрештә кебек пакь кеше, аның турында әллә ниләр уйлап гөнаһлы булма, дим. Яратмыйм мин, Солтан, андый тормышны. Политиканың шул инде: үзара шик тудыра, адәм балалары арасына шөбһә киртәсе сала. Әмма шулай да сәер, нинди сәбәпләр аркасында яшь-яшь кеше үзенә кул салган икән?

— Бәлки Хөсәен әфәнде хаклы булгандыр? Бәлки пычрак эшкә тыгылып, аннан чыгу юлын табалмыйча, яшәүгә нәфрәт тугандыр күңелендә.

— Теләсә ни генә булсын, ул — иң элек кеше,— диде.— Шуңа күрә мин аны чын күңелемнән кызганам. Син аның фатирын беләсеңме?

— Мәхмүт белә. Узган ел син аларда яшәгән идең бит, шул Мәхмүт. Полиция Исхакның гәүдәсен анатомический театрга, университетка алып киткән инде кичә үк.

— Җәл,— дип куйды Тукай, кесәсеннән бәләкәй генә портманит чыгарды, акчаларын өстәлгә бушатты, кесәләрен актарып андагы бакырларын өстәлгә салды да күңелсезләнеп Солтанга карады.

— Бар булган байлыгым шул, җанкисәгем.

— Нигә ул?

— Һич югында берәр венок сатып алырга иде. Җитмәгәнен зинһар үзеңнән куш, ә мин сиңа түләрмен.

Солтан елмайды да Тукайның иңбашына орынды.

— Җүләр син, Тукай. Кем инде мордар киткән кешегә веноклар куя. Күр дә тор, полиция яшерен генә күмдерәчәк, чөнки аның Казанда беркеме дә юк.

Тукай сыкранып йөзен чытты, бүлмә буенча әрле-бирле йөреңергә тотынды.

— Һич югында Исхак истәлегенә берәрне күтәрик. Бар, алып кер, пожалысты.

Солтан чыгып киткәч тә әле Тукай йөренүен дәвам итте. Ул Исхакның үлеменә хәйран калган иде. Ничек инде кеше ирекле рәвештә, үзе теләп үлә ала. Тукай моны башына сыйдыра алмый иде. Ул күп кайгы-хәсрәтләр кичерде, ятимлектә күп рәнҗү-кыерсытулар уздырды, инде шагыйрь булып дан-шөһрәткә ирешкәч тә аны рәнҗетүчеләр саны кимемәде, дошманнары һаман күбәя торды. Өстәвенә сәламәтлеге начарланды, ул шагыйрьгә әйтеп бетергесез газаплар китерде. Ләкин Тукай беркайчан да бу газаплардан һәм хәкарәтләрдән үлеп котылу турында уена да китерә алмый иде.

Солтан кайтып кергәч, алар половойдан чәй, пәрәмәч китертеп, тавышсыз-тынсыз гына ашау-эчү белән мәшгуль булдылар. Беравык

тынлыктан соң Тукай сүз башлады. Әйтерсең лә беркем дә үлмәгән иде, баягы авыр уйлардан котылып Тукай бөтенләй башка нәрсәләр турында сөйли башлады.

— Мин бик озак баш ватканнан соң Романовлар нәселенең 300 еллыгына карата бер ода язарга булдым. Шуның турында һаман баш ватып йөрим.

Солтан кызыксынып Тукайга текәлде.

— Моны ничек аңларга, төп мәсләгеңнән чигенү дипме?

Тукай кыза төште.

— Син мине беләм дип уйлыйсың инде! Үзең дус дип йөргән буласың. Шулкадәр дус итәсең, хәтта минем бүлмәмдәге әйберләрне үзеңнеке белән буташтырасың кайчак.

Солтан шаркылдап көлеп җибәрде. Ул бервакыт Тукайның көзгесен алып чыгып киткән иде, шуны хәтерләде.

— Ничегрәк язарга уйлыйсың инде?

— Син минем саф шагыйрь генә булмавымны беләсең. Мин бу юнәйдан дипломат буларак уйланам. Патшага җылы хисләремне белдергән булып татар халкының изелүен, җәберләнүен ничегрәк әйтергә икән дип уйланам. Бәлки Николайга да сүзләрем барып җитәр... Белмәссең, бәлки татардан азган берәр патша якыны: менә татар шагыйре нәрсә язган, дип аңа тәрҗемә итеп күрсәтер дә...

— Патша синең фикереңне сизмәс дип уйлыйсыңмы?

— Шигырь югарырак менгән саен күбрәк кешегә ишетелә, ниһаять, ул тарихка кала. Ә форсаттан файдалана белергә кирәк безгә һәрдаим.

— Анысы шулай. Тик укучы аңлармы сине? Халык бәхете өчен көрәшүчебез изүче патшаны мактый башлаган димәсме?

— Менә мин шуның турында баш ватам да. Син әйткәнне Хөсәен әфәнде дә әйткән иде бервакыт.

— Ихтыярың, эшләп кара.

— Зирәк укучы аңлаячак мине, тарих та кабул итәчәк. Мин ул шигыремне шундый итеп корачакмын, чөнки ул минем башның менә шушы почмагында өзлексез тулганып тора.

Солтан көлеп куйды.

— Башың ничә почмаклы соң синең, Тукай, ничә теманы берьюлы сыйдыра ала?

Тукайның да күзләре ялтырый башлаган иде.

— Минем баш Кисекбашныкыннан күбрәк нәрсә сыйдыра анысы. Аерма шунда: Кисекбашныкы ахмак нәрсәләр белән тулган булса, минеке даһи уйлар белән тулы.

— О, мактана да башлады берәү.

— Нишлисең инде. Бәшири мине мактамый, Сәгыйть мине мактамый, Габди мине мактамый, һич югында үземне-үзем мактап, бер юаныйм, дим.

— Аның каравы сине Галиәсгар Камал мактый, Фатих Әмирхан мактый, Сәгыйть Сүнчәләй мактый. Ә барыннан да битәр, барлык укучың сине мактый. Бу инде аз түгел!

Тукай кәефләнеп көлеп җибәрде.

— Беләсеңме тагы кем мактый мине,— диде.— Дәрмәнд мактый. Син хәтерлисеңдер, ул мине үзенең газетасында эшләргә Оренбургка чакырды һәм нәрсә дигән. Шигырьләреңнең һәр юлына илле тиеннән түләрмен, дигән. Илле тиен! Гадәттә биш тиен түлиләр бит. Ничек, минем базар югарыракмы?

Тукай шаркылдап көләргә тотынды. Ләкин аның көлүе ютәлгә әйләнде. Солтан урыныннан кубып, буылып йөткергән дустына ярдәмгә ашыкты. Аңа су салып бирде, ябык кечкенә аркасыннан кочты.

Кыш керү белән Тукай бик каты авырый башлады. Дус-ишләре шагыйрь янына кергәндә, аның хәзер күбрәк караватында ятып торган чагы була иде. Үпкә чире аны тәмам алҗытты, аяктан екты. Ул гына җитмәгән, көн аралаш бизгәге килеп интектерә. Шагыйрь тәмам кипте, су сипмәгәндә гөл ничек сула, ул да шулай сулды. Мәгәр иптәшләре белән сөйләшкәндә сер бирмәгән булып маташа иде ул. Суык тигән булса кирәк, янәсе, мунчадан тирләп кайткач, салкын сыра эчкән иде. Шул гына.

Ләкин аның янында еш булучылар — шагыйрьләр, нәширләр һәм гомумән әдәбиятны яраткан кешеләр — егетнең авыр бер хәлдә икәнлеген ачык күрәләр иде. Авылга китәргә кирәк, авылга, дип киңәш бирделәр аңа. Анда тыныч булачак, ни әйтсәң дә авыл һавасы Казан һавасы түгел — шифалы, чиста. Авылның сөте, катыгы да була.

Ләкин быел да авылларда халык ачлык кичерә иде. Декабрь керер-кермәс, игенченең келәтләрендә икмәк заты калмый, агайлар эш эзләп шәһәрләргә, шахталарга китәләр. Шуңа күрә Тукай башта икеләнде, ләкин көннән-көн начарланган кәефе аны соңгы саламга тотынырга мәҗбүр итте. Ул әледән-әле авылдан үзенә килеп чыгучы туган-тумачасын күздән кичереп сайлана башлады. Бәлки Хәлилрахман белән сөйләшеп карарга дыр, дип уйлады Тукай. Хәлилрахман — Кырлай мулласының улы, балачактан ук таныш, Казанга килгән чагында Тукайның хәлен белергә керми калмый. Юк, ни өчендер күңеле тартмады Тукайның. Дөресрәге берәүгә дә ялынасы килми иде аның. Горур табигате түбәнсенеп үтенергә рөхсәт бирми иде. Ул бит авыруын хәтта иң якын иптәшләреннән дә яшерә. Чөнки авыру итеп, кызганып карауларын теләми. Шулай да көннәрдән бер көнне ул кайтып хәл җыярлык авылын да, кешесен дә эзләп тапты. Бу — Өчиле авылыннан Кәшфелкәбир абзасы иде. Кәшфелкәбир Габдулланың әнисенең ата бер, ана башка туган энесе. Туганлык артык якын булмаса да Кәшфелкәбир атлы чандыр агай бик ачык күңелле, ягымлы һәм туган җанлы иде. Ул да Казанда булган саен керми калмый. Менә Рабига апаңнан, дип күчтәнәчен дә кыстырып килергә онытмый. Һәм барыннан да битәр, ул Тукайның шигырьләрен ярата иде. Тукайның шигырь укуын тыңлап ул сәгатьләр буе утырырга риза. Бөтеренке мыек чалгыйлары бит очларына кадәр күтәрелгән булыр, иреннәрендә елмаю, күзләрендә ләззәт очкыннары җемелдәр.

Валлаһи, шул Кәшфелкәбир абыйдан да муафыйграгы юк, дип уйланды Тукай, үзе әйтүенә караганда алар хәлле торалар, сыерлары, тавык, үрдәкләре бар. Ул түземсезлек белән Кәшфелкәбирнең килеп чыгуын көтте. Хәлбуки хәлләр начарланганнан-начарлана гына барды. Ниһаять, ул бөтенләй урыныннан торалмас булды. Номерга кереп йөрүче половойдан чәй соратып ала, я кергән-килгән аша аныеын-моныеын алдырта, ләкин бер каба да, һич теләмәгәнлеген тоеп, кашыкны өстәлгә куя иде.

Бу хәлне күреп торган Солтан Рахманколый, Кәшфелкәбирне чакырып Тукай исеменнән үзе хат язды. Үзе чыгарып почта ящигына салды. Инде туган итсә Кәшфелкәбир абзасы килми калмас.

Кәшфелкәбир килде. Һәм Тукайның ни хәлдә икәнлеген белеп борчуга калды. Хатка яздыралар аны, багалмам, диде, әгәренки мин белгән булсам, сиңа ястык-мендәрләр, төлып та алып килгән булыр идем. Урамда бит чатлама суык, төкерек җиргә җитми ката. Кышкы чиллә бит, чиллә! — Алайса, болай сөйләшәбез инде, энем, — диде Кәшфелкәбир — мин Өчилегә кайтыйм да, әйбәтләп хәстәрен күреп, хас сине алырга килим. — Ул шулай диде дә, китеп тә барды. Әлбәттә, ул изге теләк белән, энесенә яхшылык эшләү өчен шулай итте. Мәгәр Тукайның

чирс Кәшфелкәбирдән дә житезрәк иде. Иптәшләренең фикеренчә, шагыйрьне хәзер үк авылга озатырга кирәк иде, ниндидер мәрхәмәтле хатын-кыз аны карарга тиеш иде, бары шул чагында гына Тукайга жан өреләчәк, ул кеше булачак иде.

Эшне озакка сузмас өчен, Тукайның Өчилегә китәргә ризалыгын алгач та Рахманколый, Габдуллажан Харис, тагы берничә егет юлаучы эзләп печән базарына йөгерделәр. Анда Сәрдә авылыннан килгән толыплы бер абзый да табылды. Кушылып тиешен агайга түләделәр һәм иртәгесен, көн яктыру белән, Тукайны авылга озаттылар.

Өчилегә житкәндә шагыйрьнең чанадан төшә алырлык та хәле калмаган иде инде. Аны каршы алырга дип урамга хужалар йөгереп чыкты. Кәшфелкәбир белән аның хатыны Рабига Тукайны кадерләп өйгә алып керделәр, чишендереп йомшак түшәккә яткырдылар. Тиз арада Рабига кечкенә өйне дә жылытты, аны тәртипкә китерде. Бу Тукай өчен махсус әзерләнде. Тынычлык кирәк иде аңа. Алай гына да түгел, шагыйрьнең ялгызлыкта каласы килә иде.

Габдулла Өчилегә барып урнашкач, бер атна буе яткан урыныннан тора алмады. Бик аз сөйләште, аз ашады. Ләкин мәрхәмәтле Рабига апасының тәрбиясе, әйбәт авыл һавасы аны әкренләп аякка бастырды— ул кулларына, иңбашларына көч-куәт куна башлавын тойды. Көннәрдән бер көнне ул тәрәзә каршысындагы бәләкәй өстәл янына килеп утырды. Яткан көенчә генә сызгалаган шигырьләрен акка күчерә башлады. Аның аппетиты да ачыла төште, инде жиңгәсе керткән иртәнге жылы сөтне дә чокырында калдырмый эчеп куя иде. Савыгу куанычы йөзенә чыкты, шагыйрьнең теле ачылды. Ул шаян сүзләр дә әйткәли хәзер, моңлы тавышы белән жырлап та куйгалый. Аллага шөкер, диештеләр хужалар, кунагыбыз тернәкләнеп килә. Я хода, битенә алсулык куна башлады, йөзен ягымлы елмаю бизи, ходага шөкер, тырышлыкларыбыз бушка китмәде.

Рәхәт иде Тукайга бу тыныч Өчиле авылында. Тәрәзәдән урам күренә. Аны кар көртләре басып киткән, тәрәзәгә арыш башаклары рәвешендә бозлар каткан, пәрдәне бер яккарак жибәрә дә Габдулла урамны карап утыра. Тормышы турында уйлана — Зәйтүнәсен хәтерли, иптәшләрен искә төшерә, күңелендә шигъри образлар туа. Урам юлыннан сирәк-мирәк олаулар үтә. Тагы бөтен дөньяны тынлык баса. Нарат агачыннан салган өйдә күмәчкә ягып ашарлык саф һава. Монда Болак исләрен, сабын заводы исләрен аңкыткан Казан һавасы юк.

Янә берәр атнадан соң Габдулла ишегалдына да чыга башлады һәм бер көнне, бик нык киенеп, авыл мәктәбенә дә барып кайтты.

Габдулла язның беренче аен авылда каршылады. Бик күп эшләде. Үзен аерата яхшы сизгән көннәрдә аны өстәлдән аеру читен иде. Инде март аеның кояшлы бәләкәй тәрәзәдән елмаеп карар көннәр килгәч, ул Казанга кайту турында уйлана башлады. Инсаф кирәк, диде үз-үзенә, хужалар һич авырыксынмаган кебек тә, алай да инсаф кирәк. Нигә, мин Казанда да тыныч квартирга урнаша алам ич. Печән базары тирәсендә генә яшәргә димәгән. Казанның бик күркәм, гүзәл почмаклары да бар бит. Кайтырга кирәк. Кайтам да аулак кына квартира табам. Хужалар ашын да, суын да әзерләсеннәр, керләрне усыннар, урын-жирне алыштырсыннар, андыйга гына житәрлек акчам бар. Монда артык калып булмый, мин савыктым, аякка бастым, рәхмәт хужаларга.

Ул Кәшфелкәбир белән Рабиганың кыставына карамастан, Казанга кайтырга жыенды. Аны Кәшфелкәбир үзенең жирән байталында, әйбәтләп толыпка төреп, астына ястыклар салып, кадерләп, Казанга алып китте.

Март яз ае булса да, буранлы көннәргә бик юмарт. Ярый әле Тукай бәхетеннәндер буран артык котырынмады, ачы жил иссә дә, буран

җәяүледән узмады. Чыпчык авылына җитеп, бер марҗада кундылар, чәй эчтеләр, атны ял иттереп, иртәгесен тагы Казанга юл тоттылар.

## 39

Теге көнне Мөхлис исемле Истамбул сәүдәгәре төрек социалисты Мостафа Сөбхыйны искә алса да, аның адресын да, нинди рәк кеше икәнен дә белми икән. Ул бары «Ифһам» исемле сул газетада еш-еш аның мәкаләләре басылуын гына хәбәр итте. Хәер, Җәгъфәр аның исемен ишетеп башта бик дәртләнгән иде дә, соңыннан суынды. Мин андыйларны күрмәгәнмени, Казанда шул ук Хөсәеннәр, Гассаннар, Гафурлар һәм тагы бик күп башкалар юк идемени. Алар бит үз халыклары турында кайгыртмыйлар. Бу да шуларның еракта гы бер кардәшедер, дип уйлады.

Ә Йосыф Акчура белән очрашу болай булды: Истамбулда русия татар талабалары (шәкертләре, студентлары) өчен махсус клуб ачылган икән. Шул клуб Йосыф әфәндедең рухи җитәкчелегендә яши икән. Акчуринның шул клубта еш булуын, алай гына да түгел, аның шунда татар студентларына дәрес тә бирүен әйткәннәр иде Җәгъфәргә. Шундый зур кеше ярдәме белән ач үлемнән һәм сырхауларда н котылып булмасмы дип, көннәрдән бер көнне ул шунда китте. Клуб дигәннәре шәһәрнең Европа өлешендә таштан салынган шактый зур бер бина икән. Ул яшеллеккә күмелгән бакча эчендә. Беренче килүендә сакчы аны ишегалдына да кертмәде. «Саилчеләргә, бродягаларга монда урын юк, күздән югал!» — диде. Мыекларын бөтереп, колакларына чаклы җиткергән төреккә ни кадәр генә үзенең русияле икәнен, кайчандыр шәкерт булуын, бөек зат Йосыф Акчураны күреп белүен аңлатмасын, теге аның саен күзләрен тасрайтып, селтәнә-селтәнә, Җәгъфәрне эт урынына күреп кууын гына белде.

Икенче тапкыр Җәгъфәр акыллырак булды. Үзе белән пристань тирәсендә көн итүче һәм, җае чыкса, хаммаллык (әйбер ташучылык) белән акча табучы танышларыннан вакытлыча киемнәр алып, адәм рәтләрәк киенде. Һәм шул адәм рәтле кыяфәттә янәдән татар талабалары клубына китте. Бу юлы бәхеткә каршы аңа клубка килүче татар егетләре очрады. Алар Россиянең төрле почмакларыннан килгән егетләр һәм барсы да хәлле кешеләр гаиләсеннән иде. Җәгъфәр аларга үзенең хәлләрен сөйләгәч, кызгандылар булса кирәк, якташ кеше, ярдәм итәргә кирәк, дип үзләре белән эчкә алып керделәр. Йосыф Акчура әле дәрес бирә иде. Җәгъфәр аны класс ишеге ярыгыннан гына күзәтте. Ияк очын гына каплаган очлы сакал, янга тарап салган җиту чәч, өр-яңа соры костюм, галстук, пенсне. Европа зыялысының менә дигәне, фырт киенгәне. «Әз генә дә үзгәрмәгән икән», дип уйлады Җәгъфәр. Ул аны нәкъ шушылай затлы киемнән һәм шундый ук кыяфәттә моннан биш ел элек Ука елгасында «Густав Струве» пароходында күргән иде. Әйе, чак кына тазара төшкән ахры, йөзе түгәрәкләнгән, соргылт күз кабаклары йомыла төшкән, баскан килеш, өстәлгә бармак очларына таянган хәлдә нидер сөйли. Класста исә утызлап кеше тавышсыз-тынсыз гына аны тыңлыйлар. Җәгъфәр игътибарын җигеп, лекторның ни сөйләгәнен ишетергә тырышты. Йосыф Чыңгыз хан заманнары турында, төрки халыкларын берләштереп, чыңгыз бабаларыбыз дәрәҗәсендә шәүкәтле булу мөмкинлекләрен эзләргә кирәклеген аңлата иде.

Җәгъфәр бераз ишек янында торганнан соң, ишек ярыгыннан күзәтүенә уңайсызланып, киң коридор буйлап китте. Зур тәрәзәләрдән кышын да, җәен дә үзенең яшеллеген җуймый торган клуб бакчасына карап торды.

Ул әрле-бирле йөренгән арада дәрес тәмамланды, киң ачылган класс бүлмәсеннән Йосыф Акчура килеп чыкты. Ул Җәгъфәргә игътибар да

итмәде һәм Җәгъфәр үзе аның алдына килеп басмаса, бәлки узып та киткән булыр иде.

— Йосыф әфәнде, — диде Җәгъфәр аның алдына чыгып, — мине кичерегез, мин сезне эзләп килгән идем.

Акчура Җәгъфәрне башыннан аягына кадәр карап чыкты, һәм йөзенә бернинди аптырау яки шатлану билгеләре чыгармастан:

— Сез кем буласыз, кайдан? — диде.

— Минем сүзем берничә минутка тартылыр, мөмкин булса аулакрак барып сөйләшер идек.

Алар аерым бер бүлмәгә кереп утырыштылар. Җәгъфәр шундук үзенең ничек Истамбулга килеп эләгүен сөйләп бирде.

— Минем үтенечем шул, — диде ахырдан, — мин сезнең ярдәмегезгә мохтаҗ.

— Нинди ярдәмгә?

— Икътисади ярдәмгә, Йосыф әфәнде.

Акчурин ничектер иренеп кенә елмайды да кулларын җәеп куйды.

— Гафу итегез, минем хакимиятемдә банклар юк. Аннан мин бит әле сезне якыннан белмим дә, сез кем, нинди мәсләк кешесе?

— Сез соң минем нинди мәсләк кешесе булуымны теләр идегез?

— Үзен төрек кавеменнән дип исәпләгән һәрбер кеше иң элек безнең төп йортыбыз булган төрек йортына хезмәт итәргә тиеш. Сез минем биредә, Истамбулда, «Төрек йорты» исемле журнал нәшер иткәнлегемне беләсездер ич? Ул журнал барлык кыйтгаларда тарала. Ул барлык төрки халыкларны госманлы төрекләр байрагы астында җыярга тиеш. Менә мин дә, әгәр сез шималь төреге икәнсез, сезнең шул миссиягә хезмәт итүегезне теләр идем.

— Мин сез әйткән идеалга ышансам, бәлки бик теләп хезмәт итәр идем. Ләкин мин ул юлны дөрес дип тапмыйм. Хәер, монда килер алдыннан миндә шундыйрак караш юк түгел иде.

— Нинди юл дөрес соң сезнеңчә?

— Минемчә, төрекнең үзен әҗнәби[1] баскан. Ә безнең халыкның чишелергә тиешле үз мәсьәләләре бар.

— Хуш?

— Ул Русия патшасы табаны астыннан котылырга тиеш.

— Бу эшне ничегрәк башкарырга уйлыйсыз соң сез? Бәлки Русия патшасына каршы татар корал тотып күтәрелергә тиеш диптер?

— Бәлки шулай итептер!

— Буш хыял. Рус патшасы бер көн эчендә татарның башын кисеп ыргытачак.

— Арнаутлар төреккә каршы ничә елдан бирле көрәш алып баралар. Төрек бит бер дә аларның башын кисеп бетерә алмый. Белмәссең, бәлки беркөн алар үз максатларына ирешерләр дә әле, мөстәкыйль Албания дәүләте төзерләр. Инде Болгарны алыйк. Алар Төрек коллыгыннан көрәш аркасында котылмадылармени?

— Сезнең чагыштыруларыгыз ялгыш. Татар ялгызы гына берничек тә күкрәгеп киереп аягына баса алмый. Аның ирекле булуын телибез икән, бу — барлык төрки халыкларын берләштерү, бер йодрыкка туплау, көч җыю юлы белән генә мөмкин. Башка юл юк, әфәндем.

Акчура бераз тынып торды да күгелҗем күз кабакларын кыса төшеп сорады.

— Большевиклар социаль революция ярдәмендә милли азатлыкка ирешеп була дигән карашта торалар. Сез шул карашны дөрес дип тапмый торгансыздыр бит?

— Юк, мин андый карашта тормыйм. Хәлбуки, татар большевигы Хөсәен Ямашев заманында минем бик якын кешем иде.

[1] Әҗнәби — чит ил кешесе.

Иосыфның йөзенә кинәт дәһшәт билгесе чыкты.

— Якын кешегез иде?! — диде ул, тиешеннән артык кычкырып.

— Әйе, якын кешем иде.

— Алайса булмады инде, мәгъзур.

Иосыф урыныннан торды.

— Иосыф әфәнде, сез минем идеалларым, мәслегем белән исәпләшмәстән, миңа якташ кеше буларак кына ярдәм кулыгызны сузыгыз,— дип ялынды Җәгъфәр.— Миңа күп кирәкми, бурычларымны түләрлек һәм туган илгә кайтып егылырлык берничә лира акча. Инде, һич югында, җитәрлек акча табарлык берәр эшкә урнаштырыгыз. Бик үтенәм.

— Гафу итегез, минем вакытым чикле. Мин сезнең белән артык була алмыйм, — диде Иосыф Акчура.

Ул ашыгып ишеккә таба юнәлде.

Әле Мөхлис белән сөйләшкәндә Җәгъфәр шуларны һәм тагы да Рәшит казый белән очрашуын да хәтерләде. Бу шөһрәтле дин әһеленең Петербургта «Өлфәт» исемле журнал чыгарганлыгын, китаплар язуын, өзлексез үзенең идеалларын таратып, бөтен дөнья буенча гизеп йөрүен Җәгъфәр күптән белә иде. Ул аны шулай ук беренче мөселман съездыннан күреп белә иде. Рәшит казыйның Япониягә барып, япон халкын ислам диненә күндерергә тырышып йөрүләре, ниһаять, бер Ямаука атлы япон кешесенең мөселман динен кабул итеп, Габдрәшит әфәнде белән Россиядә, Төркиядә лекцияләр сөйләп йөрүе турында да татар газеталарында укымады түгел. Акчура белән эш барып чыкмагач, Җәгъфәр, сорашып, Рәшит Ибраһимовның кайда яшәгәнлеген белде дә шуны эзләп китте. Казый Мулла Курани мәхәлләсендә үз өендә яши икән. Җәгъфәр шул адрес буенча аны эзләп тапканда, хәлдән тайган, сөйләшерлек рәте дә калмаган иде. Коймага сөялгән ярым тере Җәгъфәрне Рәшит казый үзе чыгып алды, култыклап өенә алып керде. Бу җиту сакал-мыеклы, яңак калкымнары артык чыгынкы, башына яшел фәс кигән кеше беренче очрашуда Җәгъфәрдә җылы өметләр кузгатты. Җәгъфәрнең татар икәнлеген белгәч, Рәшит аның белән аерата якын итеп сөйләште. Чәй эчертте, сыр, йөзем белән сыйлады. Ләкин эш шуннан узмады. Чөнки Җәгъфәр адәм рәтле сүз башлау белән Рәшит казыйның әле һаман ислам флагы ярдәмендә барлык мөселманнарны оештыру дәрте белән янып йөргән кеше икәнлеген аңлады. Җәгъфәрнең дингә булган мөнәсәбәте хәзер бөтенләй башка иде. Ул хаҗ кылып кайтканга кадәр, бик нечкә җепләр белән генә булса да, дингә бәйләнешле бер кеше иде. Әмма хаҗга бару, юлда искиткеч шарлатанлыкларны күрү аңардагы бу соңгы җепләрне дә өзеп ташлады. Рәшит казый белән дин флагы һәм шул җирлектә оешу, күпчелеге европа капиталы кул астында изелгән мөселман халкын азат итү турында сүз башлагач, ул үзенең дингә мөнәсәбәтен сиздерми кала алмады. Бу исә кинәт Рәшит казыйның Җәгъфәргә булган карашын үзгәртеп җибәрде. Әйе, бу карт чын мәгънәсендә Казандагы клирикаль муллалар кебек, дингә ихлас күңелдән бирелгән һәм башка бернинди дә юл юк дип яшәүчеләрнең берсе иде. Рәшит казый аңа матди ярдәм күрсәтмәде. Акчура кебек үк тупас кыланмаса да, үзенең Җәгъфәрдәй дәһриләр белән сөйләшергә теләмәвен шактый ачык аңлатып озатып калды.

Җәгъфәр тагы урамда, өйсез, гаиләсез этрәк-әләмнәр арасында калды. Хәленнән килгән вак йомышлар башкарып, бер-ике телем икмәклек, бер ике уч йөземлек, бер дә булмаса, бераз тут җимеше алырлык акча табып яшәде. Йортсыз-җирсез сукбайлар белән берничә тапкыр полиция подвалларында да утырып чыкты. Берзаман Италия белән сугыш башланды. Бу Триполитания өчен башлаган сугыш Истамбулдагы көнкүрешне тагын да авырлаштырды. Инде Италия белән сугыш Төркиянең гарәп җирләреннән ваз кичәргә мәҗбүр ителүе белән тәгәлләнергә өлгермәде, Балкан ярым атавында болытлар куера баш-

лады. Греция белән Крит өчен бәхәс җитмәгән, Болгария белән конфликт өскә калкып чыкты.

Кешене өмет яшәтә. Әгәр ул өзелсә, кеше тормышка кул селти, үлә, яки рухи һәлакәткә дучар ителә. Җәгъфәр моны аңлый иде. Ул хәтта физик үлемне рухи үлемнән өстенрәк күрә. Шулай көннәр, айлар узып, соңгы терәкләрен дә югалткан бер көнне ул порт эшчеләре арасында Мостафа Сөбхине очратты. Озын буйлы, кара кыска мыеклы, житу чәчле, күзлекле бу профессор нәкъ кайчандыр Җәгъфәр Казанда очраткан революционерлар кебек, порт эшчеләрен үз хокуклары өчен көрәшергә чакыра иде. Җәгъфәр төркемнең эченәрәк узып, ораторга якынрак килде. Мостафа Русия пролетариатыннан үрнәк алырга, алар кебек үк төрек буржуазиясе белән көрәшергә чакыра иде.

Бу төрек революционеры белән очрашу Җәгъфәрдә яшәүгә дәрт уяткан кебек булды. Ул үзенең дә кайчандыр Казанда дәртләнеп йөргән чакларын хәтерләде. Ул бу күзлекле сузан кешенең алдына барып, үзегезгә алыгыз мине, ни кушсагыз шуны эшләргә риза, минем Россиядән алып килгән тәҗрибәм бар, димәкче булды. Ләкин кыймады. Чөнки аңа эчке бер тавыш, син бит барыбер моны булдыра алмыйсың, синең моңа көчең җитми, син хәтта, үз халкыңның хезмәт ияләре өчен дә көрәшкә ташлана алмадың, ә инде сиңа ят төрекләр өчен көрәшү бөтенләй акылга сыймаслык эш, дия иде.

Җәгъфәрнең дәртләре кабыну белән шунда ук сүнде. Ул эчке тавышы белән килеште. Көннәр тагы ярым йокымсырап, ачлы-туклы хайвани вак омтылышлар белән узды. Ул үзенең кешелек сыйфатларын бөтенләй югалта башлаганлыгын әкренләп тоя бара иде. Үлем, җисми үлем аның өчен рухи үлемнән әйбәтрәк иде. Котылгысыз рәвештә бозлы таудан шуып төшкәндәй, әнә шул үзе теләмәгән үлемгә бик кызу шуып баруын тойды Җәгъфәр.

Ниһаять, ул бер катгый карарга килде. Төн уртасында үзе кебекләр белән бер-берсенә сыенып яткан тынчу, ташландык куыш эченнән чыкты да Мәрмәр диңгезе буена китте. Ул яр буенда бик озак әрле-бирле йөренде. Тирә-юньдә тынлык хөкем сөрә иде. Әле күптән түгел генә янып, бары кисәүләре, җимерек хәрабәләре генә калган Ермәк таш дигән урын иде бу. Менә ай да зур булып, тулы булып Солтан Әхмәт җамигы артыннан күтәрелде. Зур мәчетнең манарасы яктырып китте, тирә-юньдәге җимерек, кара хәрабәләре ап-ачык күренә хәзер. Ә алда Мәрмәр диңгезе. Ай яктысы диңгез аркылы зур якты юл ясаган. Босфор ачык булып калыкты. Бу тирәләр барысы да хәзер Җәгъфәр өчен, никадәр ят булсалар да, күңелгә сеңгән урыннар.

Җәгъфәр гасабиланып һаман йөрүендә булды. Катгый карар күптән кабул ителгән иде инде. Ләкин ул моңарчы һаман сузды, һаман нидер көтте. Ниһаять, киеренкелек соңгы ноктасына җитте. Ул, муенына таш тагып, Мәрмәр дулкыннарына чумды.

## 40

Чәршәмбе иртәсе Хөсәенне төксе бер кыяфәт белән каршы алды. Урамда март бураны котыра. Өйдә бу беленерлек салкын. Хөсәен, уянып, юрган астыннан чыгу белән, иңенә пинжәген салды да кухня якка кереп мич ягып җибәрде, чәйнекне керосинкага утыртты. Юынып, киенеп тәрәзә янәгындагы календарьга үрелгәндә, кинәт күңелне болгатып, баш әйләнүен тойды. Бермәл күзләрен йомып торды, баш әйләнүе узгач, календарь битен ертып алды. Бүген уночынчы март иде.

Хәдичә үз бүлмәсендә йоклый. Ул төне буе имтиханга хәзерләнеп утырды. Хөсәенгә, мине үзең университетка китәр алдыннан гына уятырсың, дигән иде. Әйдә, йокласын, бу араларда аңа йокы бик тәтемә-

де, дип уйлады Хөсәен. Баш әйләнүе узды, ләкин колаклары әле һаман шаулап тора, Хөсәеннең кәефе бик начар иде бүген. Ләкин эшләнәсе эш башкарылмый кала алмый, ул бүген үзе яраткан лекторның лекциясен, әлбәттә, тыңларга тиеш, аннан Михаил Җаковны күреп сөйләшергә кирәк. Кичәге вакыйга уйланырлык — Тукай тирәсендә сырпаланып, дусларча кыланып йөргән Исхак исемле егет үз-үзен үтергән. Бу тикмәгә генә була торган хәл түгел. Димәк, димәк...

Хөсәен чаен эчеп чыгып китәргә әзерләнде, төймәләрен каптыра-каптыра башта хатыны янына керде. Аптыравына каршы Хәдичә уяу, күзләрен зур итеп ачкан хәлдә түшәмгә карап ята иде.

— Син уяндыңдамы, хәерле иртә. Мин киттем. Бүген эшем күп. Тиз генә кайта алмам. Борчылма, — диде Хөсәен.

— Туктале, — диде Хәдичә һаман түшәмгә караган килеш. Аның тавышы коры, салкын яңгырый иде. — Син минем укуның соңгы көннәре икәнен беләсең бит?

— Беләм, мин бик шат, Хәдичә.

— Шатланырга ашыкма, канатым.

Хөсәен сүзнең нинди юнәлеш аласын сизенеп, мыек астыннан гына әрнеп елмайды.

— Нигә алай дисең?

— Без синең белән киләчәк тормышыбыз турында бер генә кат сөйләшмәдек. Мин барысына да түзеп яшәдем. Шәһәрдән шәһәргә куылып, сөрелеп аз йөрмәдек, адәм мәсхәрәсе булып фәкыйрь тормышларны аз кичермәдек, торган урыннарыбызны, яткан түшәкләребезне полиция бер генә тапкыр эт абзарына әйләндереп туздырмады. Алай да түзим, дидем, никах укытып чыккан ирем хакына түзим, дидем. Инде чыдамым калмады. Хәер, күптән калмаган иде инде, ләкин барысына да нокта куярга вакыт җитмәгән иде әле. Менә хәзер ул вакытка санаулы көннәр генә калды. Мин имтиханны бирәм, диплом алам һәм сиңа катгый рәвештә ультиматум белдерәм: әгәр син минем белән ирле-хатынлы булып яшәүне дәвам иттерергә телисең икән, революцион эшеңне ташлыйсың. Менә минем әйтәсе сүзем.

Хөсәен, сүзнең тиз генә бетмәячәген сизенеп, карават янына урындыкны тартып китерде, аннан утыргач:

— Хәдичә, — диде тыныч кына, — син бу сүзләрне миңа беренче тапкыр гына әйтмисең. Минем өчен бу яңалык түгел. Мин дә бер үк сүзләрне кабатларга тиеш булам. Син бик түземле һәм батыр хатын. Әгәр син минем идеалларымны үз иткән булсаң, бу кичерешләр сине әз генә дә куркытмас иде.

— Мин сиңа башта ышандым, онытмагансыңдыр, сиңа ярдәм дә иткәләдем. Ләкин соңыннан күзләрем ачылды, синең идеалларыңның комнан ишелгән нәрсә икәнен ачык күрә башладым. Хыял алар барысы да. Аларның адәм баласын кайгы-хәсрәткә, утка салудан башка берни дә бирә алмаганлыгын аңладым мин.

— Синең күзләрең ачылмады, киресенчә, йомылды алар, Хәдичә, син беренче дәһшәттән соң ук акылыңны җуйдың, идеалларыңны саттың, аларны тук тормыш, обыватель хыялындагы җәннәткә алыштырдың.

— Юк, мин синең һәм барлык большевикларның идеаллары нигезсез бернәрсә икәнлегенә төшендем, Хөсәен.

— Ләкин син моны бер генә аргумент белән дә исбат итә алмыйсың бит.

— Алам, — диде Хәдичә, гасабиланып, яткан урыныннан күтәрелде. Аның йомры күкрәкләре ярым ялангач, чәчләре тузган, йөзе ачудан агарынган иде. — Әйт, кешечә яшәргә имканият барында ничек итеп акны карадан аера белми торган надан, вәхши эшчеләр, сасы мужик-

лар бәхете өчен газаплы тормыш кичерергә була? Пролетариат, пролетариат имеш! Әйтер идем инде... калсын.

— Син безнең дошманнар җырын җырлый башлагансың, Хәдичә. Онытма: искиткеч гүзәл шәһәрләр, искиткеч машиналар, күперләр, пароходлар син вәхши дип атаган эшчеләр кулы белән эшләнгән, син һәркөнне иртә торгач та ашый башлаган икмәкне син сасы дип атаган мужиклар үстергән. Син минем дусларыма тел тидермә. Әгәр инде аларның культуралары түбән икән, монда инде гаеп патша строенда.

— Инде синең, мин — интернационалист дип, татар халкын ук оныгуыңны мин беркайчан да гафу итә алмаячакмын. Ничек итеп руслар кубызына шул дәрәҗәдә биергә мөмкин?

— Минә монысы инде акны карадан аерырга теләмәгән милләтчеләр җыры. Нигә, син рус кешеләренең яхшылыгын бер дә күрмәдеңмени моңарчы? Оренбурда авырып ятканда сине Анфиса Петровна үз кызыдай якын күреп карамадымени? Бәлки сиңа минем рус дусларым төрлечә яхшылык күрсәтергә әзер тормаганнардыр? Син акны карадан аерырга өйрән. Юк, валлаһи, мин синең гади генә нәрсәләрне дә аңламавыңа хәйран калам. Ышанмыйм, ышанмыйм. Мин барган юлның иң дөрес икәнлегеп күрмәвеңә ышанмыйм, шуңа күрә өметемне дә өзмим синнән, Хәдичә. Имтиханнарыңны бир, ял ит, тынычлан, аннан без синең белән бу турыда әйбәтләп сөйләшербез. Ә минем барыр юлым үзгәрмәячәк, аны син, акыллым, белеп тор!

Хөсәен урыныннан торды, бүреген киеп чыгарга җыенды. Хәдичә һаман шулай түшәмгә текәлеп ята иде.

— Мин сүземне әйттем,— диде ул ишетелер-ишетелмәс кенә тавыш белән.— Суфиян янына китә аласың.

— Мин дә әйттем,— диде Хөсәен, күрше бүлмәдәге дәфтәрләрен алып ишеккә таба юнәлде. Тагы Хәдичә янына керде.

— Ә Суфия турында тыныч була аласың. Ул Фәхрелислам Агеевка кияүгә чыга.

Хөсәен үзен никадәр тыныч тотарга тырышмасын, дулкынлануын баса алмады. Баскычтан төшкәндә ул егылмас өчен, гомерендә бәлки беренче тапкырдыр, таянсага тотынгалады. Аска төшеп җиткәч кенә аңа почтальон очрады. Хат тоттырды. Хөсәен соңыннан укырга дип хатны кесәсенә салды һәм әле генә булып узган бәхәсне күңеленнән кабат кичерә-кичерә китеп барды.

Карт профессорның Рим хокукы турындагы лекциясе артык озак тоелды аңа. Ул, әледән-әле лекциядән аерылып, уйларына бата, әле Хәдичә турында, әле үзен-үзе үтергән җасус Исхак турында уйлана иде. Күңелсез уйларын аралап, бер сәбәпсез диярлек аның күз алдына зифа буйлы Суфия килеп баса иде. Озакламый туйлары була аларның. Кызның ризалык бирер алдыннан нинди тетрәнүләр, икеләнүләр уздыруын Хөсәен аңлый. Бәхетле булсын.

Явка квартиры Суконный бистәсендә йозаклар төзәтүче карт өендә иде. Хөсәен «барабыз» яллап, урәчәле чанага кырын яткан хәлдә, Балык базарыннан шунда таба китте.

Хөсәен нәкъ вакытында килеп керсә дә, группа башлыгы монда күренми иде әле. Бу Хөсәенне тәшвишкә салды. Бәлки мин соңга калганмындыр, дип борчылды Хөсәен. Бәлки теге Исхак үләр алдыннан язган хатындагы провокатор өлгеррәк булып чыккандыр. Алай дисәң, Хөсәенгә ул-бу булмады ич. Исхак ачык итеп бер провокатор хатынның группа житәкчеләре исемлеген, аларның адресын охранкага тапшырган булуын үзенең үлем алдыннан язган хатында хәбәр иткән бит, ә ул исемлектә Хөсәеннең дә барлыгы язылган.

Хөсәен Исхакка шиге төшкән көнне үк Мәхмүт Алиевны күрде. Дуслаш, бел, диде,ниндирәк кеше ул. Мәхмүт моңа бик кулай кеше иде.

Мәзин малае, үзе дә муллалык итәргә җыена, мөнбәрдән революцион идеяләр тарату турында хыяллана, җитмәсә үзе җитез, зирәк, сөйкемле егет. Ә барысыннан да битәр, Хөсәеннең иң ышанычлы яшь ярдәмчесе. Очраклы рәвештә шулай килеп чыга ки, Мәхмүт беркөнне Исхак «дусты» янына керсә, аның үле гәүдәсен һәм өстәлдә язып калдырган хатын таба. Мәхмүт ашыгып хат юллары аша күз йөртә һәм аны сундук яшереп куя, күршеләрен чакырып кертә, полициягә хәбәр итә. Һәм шул ук көнне хатны Хөсәенгә китереп бирә. Хөсәен тетрәнгән кеше кулы белән «Төкерәм мин сезнең дөньягызга» дип язылган хат юлларын укып тирән уйга калды. Аскарак болай дип өстәлгән иде: «Һич югында бер ярдәмем тисен, сак булыгыз, Хөсәен әфәнде, сезнең большевиклар арасында Минна Сафир атлы бер провокатор хатын бар, озакламый сезнең барыгызны да кулга алачаклар. Ул тулы исемлек һәм адреслар китерергә сүз биргән. Исхак».

Хөсәеннең Жаковка тапшырасы хәбәре шул хат турында иде. Һичшиксез бу хатта чын дөреслек язылган булырга тиеш. Кеше үзен үлемгә хөкем иткәч, бары дөреслекне генә сөйли, бу какшамас кагыйдә.

Тик, кызганычка каршы, Хөсәен Жаковны күрә алмады. Бер сәгатькә якын иске йозаклар, ачкычлар белән тулы верстак янында Михаилны көтеп утырганнан соң, хатның ни турыда икәнлеген язып картка бирергә мәҗбүр булды, һәм мөмкин кадәр тизрәк Жаковның өенә барып хатны тапшырырга кушты.

Урамга чыкканда Хөсәен үзен бөтенләй хәлсез итеп тойды. Чатта торган «барабыз» чанасына көч-хәл белән барып ауды. Юк, болай шаярма әле син минем белән, диде ул үз-үзенә, хәлсезлегенә мөрәҗәгать итеп, — мин андыйлардан түгел, бик тиз генә якалый алмассың. Ул «барабыз»чы белән сөйләшеп барды, шаярткан булды. Агай Шәле авылыннан икән. Ул һәр елны кыр эшләре беткәч Казанга шулай акча эшләргә килә икән.

— Юкса яшәр амал юк,— диде агай,— болай ичмаса чимьяне ач үлемнән саклап калып була.

Кабан күле аша чыгып, Екатерининская урамына керделәр. Почмакта Хөсәеннең яшьлеге үткән мансардлы өй күренеп калды. Бу өйдә инде хәзер бөтенләй ят кешеләр яшиләр. Якын, туган өй ничектер ятлар кулына эләккән кадерле бала кебек кызганыч иде.

Юл артык озак һәм җайсыз тоелды Хөсәенгә. Әмма барабызчы агай белән гәпләшә торгач кәефе бераз яхшыргандай булды.

Фәрхетдин белән алар өйрәнелгән урын — Яңа бистәдәге Мәхмүтләр өендә очрашырга тиешләр иде. Мәхмүт аны күңелсез бер кыяфәттә каршы алды. Фәрхетдиннең кереп чыкканлыгын, әмма тоткарлана алмавын, чөнки Әлмәттән баласы турында бик күңелсез хәбәр алуын, хәзер үк шунда китәчәген хәбәр итте. Имеш-мимешләргә караганда, Гыйззәтулла чәчәктән үлгән, ди.

— Я, хода, — дип куйды Хөсәен, — нинди бәхетсез көн булды бүген. Иртәдән үк башланган күңелсезлек һаман дәвам итә. — Ул ачынып көлемсерәде,— әллә, мин әйтәм, унөченче числоның бәхетсез көн булуы турында дөрес әйтәләрме?.. — Ул Мәхмүтнең кызларныкы кебек чибәр, яшь йөзенә карап торды. — Әллә нинди көн булды бүген, Мәхмүт энем.

Аулак бүлмәгә кергәч, Мәхмүт:

— Теге кәгазьне дә тиешле кешегә тапшыра алмадыңмы? — дип сорады.

— Миндә ул, мә, яшереп куй син аны.

Хөсәен Жаковка элемтәче карт аша бу турыда хәбәр итәргә мәҗбүр булганлыгын әйтте. Ничектер әле һаман колаклар шаулый иде. Әйтерсең лә колак янына телеграмм баганасы утырткannar, әйтерсең лә шуның чыбыклары зыңлап тора. Хөсәен сәгатенә карап алды.

— Һо,— диде урыныннан кубып,— минем бит әле Гафурга кереп чыгасым бар. Без анда Гафур, Мөхәтдин белән очрашырга тиеш.

Мәхмүт тә урыныннан торды.

— Тыныч кына утыр, Хөсәен абый, хәзер ат җигәм. Безнең ат белән генә элдертербез.

— Әйбәт булыр иде, — диде Хөсәен тынычлана төшеп. Берничә минуттан соң инде алар Плэтән урамы буенча Екатерининскаяга таба баралар иде.

— Синең бер дә кәеф юк ахры, Хөсәен абый, — диде дилбегә тоткан Мәхмүт. — Үзең турында да кайгыртырга кирәк әзерәк.

— Кәеф минем менә дигән, ни сөйлисең син. Тиктомалдан авыруга сабышып өйдә ятыйммыни?

Мәхмүт Хөсәеннең бөтенләй суырылып калган ап-ак йөзенә мәгънәле бер караш ташлау белән генә чикләнде. Калган юлны алар сөйләшми уздылар. Көтепханә һәм нәшрият вазифаларын үтәүче «Гасыр»да Хөсәен бик күптән инде Галимҗан Сәйфетдинев белән бергә китап чыгарырга хыялланып йөри иде. Бүген шул турыда сөйләшергә сүз куешканнар иде.

Бер катлы китапханә бинасы Захарьевский белән Евангелистлар урамы почмагында иде. Шуның янына җитүгә, Мәхмүт кара юрганы чаптырып килгән шәпкә ишек янында ук туктатты. Хөсәен чанадан төшкәч, Мәхмүтнең көтеп торыйммы дип соравына җавап бирмәде. Аның сак, хәлсез атлавын күреп, егет уйга калды. «Гасыр»га түгел, ә бәлки докторга илтергә кирәк булгандыр аны дигән уй башыннан үтте. Һәм ул китмәскә булды. Атны ишегалдына кертеп бәйләде дә, Хөсәен артыннан ашыкты.

Ул кергәндә Хөсәен социал-демократларга аерата якын мөнәсәбәттә булган нашир Борһан Шәрәф белән өстәл янына баскан килеш сөйләшеп тора иде. Күрше бүлмәдән ашыгып Галиәсгар Камал, Гафур Коләхметов һәм тагы берничә кеше чыкты. Хөсәеннең тавышын ишетеп, аның белән күрешергә ашыгулары иде ахры. Өстәл артында юан гәүдәле кыска мыеклы Борһан гына утыра. Башкалар, баскан килеш, соңгы вакыйгалар турында сүзгә керештеләр.

— Туктагыз, дуслар, без Борһан әфәнде белән эш турындагы сүзне бетерик әле, — диде Хөсәен көлемсерәп, — яңалыклар соңыннан. Кайда соң әле минем язган проспект кәгазем? — дип ул кесәләрен актара башлады. Иртә белән өйдән чыгып барышлый үзенә тапшырылган хат пальто кесәсеннән бүтән кәгазьләргә ияреп килеп чыкты. Бөтенләй онытып җибәргән иде ул аны.

Хөсәен конвертны ертмый булдыра алмады. Хат Хөсәенгә таныш булмаган кул белән язылган иде. «Хөсәен әфәнде, гафу үтенәм, әмма сезне кисәтүемне үземнең инсаният бурычым дип саныйм, — диелгән иде хатта.— Сезнең хатыныгыз Хәдичә ханым, сезгә карата хыянәтче генә түгел, ул сезне үтерүче дә. Миңа аның сезне агулап үтерергә җыенуы мәгълүм. Сак булыгыз». Хөсәеннең күз аллары караңгыланып китте, йөзе тагы да ныграк агарды. «Кемнең провокациясе бу? Тагы шул Җәгъфәрме?» дигән уй аның башыннан яшен тизлегендә узды. Аның йөзендәге үзгәрешне бүтәннәр дә искәреп алдылар. Мәхмүт тиз генә стена буеннан Хөсәенгә урындык китерде, Хөсәеннең йөзе качкан, ләкин ул һаман әле елмаерга тырыша иде. Әкрен генә:

— Утырырга кушмыйлар бит, — диде. Ул шул сүзләрне әйтүгә, тирә-юньдәге һич моңарчы булмаган гүләүгә хәйран калып, иптәшләренә карап чыкты. Ләкин аларның йөзендә аптырау аша инде дәр аңлашылмаган дәһшәттән башка берни дә юк иде. Гүләү арткаsuccessfully-арта барып, бөтен өйне тутырып тоташ үкерүгә әйләнде. Хөсәен тез буыннарының кинәт мамыктай йомшарып китүен тойды. Шул ук мизгелдә бул-

мә эчен үлем тынлыгы басты. Хөсәен янәшәдә торган Мәхмүт белән Гафурның кулына киселгән агачтай авып төште. Барысы да дәррәү кубып аны әйләндереп алдылар. Кемдер: «Докторга, докторга!» — дип кычкырды, тавышка күрше бүлмәдәгеләр дә йөгерешеп керделәр. Ләкин Хөсәен хәзер ярдәмгә мохтаҗ түгел иде инде...

## 41

Казан үзенең шалтыравык трамвайлары, «барабыз»лары, шау-шулы Балык, Печән базарлары, мәчет-чиркәүләре белән Тукайны сагынып каршы алгандай булса да, шагыйрь көткәннәрне әзерләп куймаган иде. Тукай, нәкъ Өчиледә ниятләнгәнчә, тыныч кына бер бүлмәгә урнашты, хуҗабикә бик сөйкемле күренгән иде башта. Мәгәр ул ата ялкау, ашны тәмсез, артык тозлы я тозсыз итеп әзерли торган, җитмәсә явыз бер хатын булып чыкты. Караватт алып куярга вәгъдә иткән булса да, вәгъдәсен үтәмәде, Тукайга, үзе әйтмешли, буш бутылкадай, идәндә аунарга туры киле.

Башка түзәрлек чама юк иде. Ул алдан түләп куйган задаткасын да алмыйча бу квартирдан качты, зур урамнарның берсендәге «Свет» кунакханәсенә урнашты. Бүлмә искиткеч җиһазлы, затлы күренә иде. Ул ялтырап торган паркет идәннәр, өстенә яшел постау ябылган язу өстәле, комод, кием шкафлары, бармак калынлыгы пыяладан коелган түгәрәк көзге дисеңме. Тукай бик куанган иде. Тик шатлыгы озакка бармады. Беренче төнне үк Тукай тагын бәхетсезлеккә юлыгуын аңлады. Бүлмәдә күселәр патшалыгы хөкем сөрә иде. Алар төнлә идән астыннан чыгалар да, дөнья бетереп бүлмә буйлап йөгерешеп йөриләр.

Тукайның йокысы качты, тагы кәефсезлек башланды. Кергән шәпкә артык игътибар итмәгән иде, бөтенләй салкын икән бу номер, хәтта сулыш беленә, җылыткычлары боз кебек.

Бизгәк тә озак көттермәде, күптәнге таныш буларак, тагы шагыйрьне калтырата башлады. Ютәл көчәйде, үпкә үз алдына гыжлап тора иде хәзер.

Габдулланы озак вакытлардан бирле югалтып торган дус-ишләре аңа тиз арада моннан күчеп китәргә киңәш бирделәр. Ләкин кая барасың тагы? Кая барсаң да кара сакалың үзеңнән калмый сөйрәлә. Тукай түзде. Озакламый җылы яз да үзенең купшы фаэтонында килеп җитәр, тәрәзәләрдән кояш нурлары сибелер, стеналарда ап-ак йөгерек шәүләләр биешә башлар. Зарар юк, түзәрмен, Печән базарына күчеп тә әллә ни бәхет-сәгадәткә ирешә алмам, дип уйлады шагыйрь.

Ул хәзер иртә торып юыну белән, муенына шарф чорнап, аягына киез итекләр киеп, иңнәренә пальтосын сала да шул кыяфәттә бүлмәсендә көнен уздыра. Әз генә кәефе булса да язарга утыра, шигырен, чәчмәсен яза. Әйтерсең лә аның вакыты бик чикле, әйтерсең лә әзерләнгән темаларын язмый калу куркынычы бар.

Ул шигырь артыннан шигырь язды. «Уклар» журналына үзенең Казанга кайту маҗаралары турында көлкеле итеп озын бер фельетон бирде. Ләкин сәламәтлеге көннән-көн начарлана барды.

Ул ундүртенче март көнне үзен аерата начар хис итеп уянды. Тәне уттай яна, үзе туңдыра, сулыш алуы ифрат авыр иде. Тукай юрган астыннан чыгарга батырчылык итә алмыйча, номер хадимәсе кергәнче кузгалмыйча ятты. Бераздан чәй китертте.

Көтмәгәндә-уйламаганда Габдулла Кариев күренде. Бу иске дусның хәзер килеп чыгуы шатлыклы да шул ук вакыт сәер дә иде. Чөнки Тукай Карыйның авыру йокмагае дип шикләнүен сизенә, моның өчен аңа чын күңеленнән рәнҗи иде. Әле Кариев күренгәч, ул җиңел сулап куйды, шигем дөрескә чыкмады, дип куанды.

Карыйның йөзе артык борчулы иде. Күзләренең кызарган булуы да Тукайның игътибарыннан читтә калмады.

— Ни булды? — диде Тукай башын калкытып. Кариев аның янына ук килеп иелде, тотлыга төшеп:

— Бик күңелсез хәбәр алып килдем бит әле мин сиңа, Апуш,— диде. — Безнең Хөсәен вафат булган.

— Хөсәен?! — Тукай берни дә аңламаган хәлдә юрганын читкә атып бәрде. — кайсы Хөсәен?

— Ямашев, — диде Кариев. Ул хәлсезләнеп утыргычка чүкте. Хөсәеннең ничек һәм кайда үлүе турында сөйли башлады.

— Я рабби, — диде Тукай. Ул үз-үзен белештермәстән, салкын идәнгә яланаяк баскан килеш, ашык-пошык киенә башлады. Аның өчен хәзер Габдулла Кариев алып килгән кайгылы хәбәрдән башка берни дә юк иде дөньяда. Кинәт ул бөтен гәүдәсенең тәкатьсез итеп калтыравын тойды. Таш чәйнектән стаканга су агызып эчте, ләкин ул да суынып өлгергән иде инде. Тукай кием элгеченнән алып пальтосын иңенә салды да Кариевның каршысына килеп утырды. Кариев күз яшьләрен мул агызып тавышсыз гына җылый иде.

«Һич булмаса җыларга иде, — дип уйлады Тукай, — бәлки җиңелрәк булыр иде». Ләкин ул җылый алмый иде. Ул инде күптән җылауны оныткан иде, котчыккыч газаплы тормыш яшьтән үк аның бәгырен ташка әверелдергән. Ул эчтән генә тирән хәсрәт кичереп дустына карап утырды. Үзенең дә бер елдан соң үләчәген, Хөсәен белән янәшә күмеләчәген, җеназасында халык бөтен бистәне басып китәчәген башына да китерә алмый иде әле.

— Җеназасы кайчан?

— Иртәгә, ахры. Әле ул анатомическида.

— Мотлакан барам.

Кариев әрнеп елмаеп куйды.

— Кайда инде сиңа, бу хәлеңдә. Ичмаса аңа багышлап берәр сүз әйт, каләм тибрәт.

Кариев хаклы иде. Тукай олы дустын күмүдә катнаша алмады. Ул сыкранып үзенең салкын номерында ятты һәм Хөсәен Ямашевка багышлап бер шигырь иҗат итте. Бер ай да узмагандыр, «Йолдыз» һәм «Ялт-Йолт»та аның кадерле дустына багышланган шигыре басылып чыкты.

Көч белән бергә гүзәллекне җыйган диңгез кеби,
Ул иде өстен вә кул җитмәс, кеше, йолдыз кеби.
Әүлияларның барын бер-бер китерсәм каршыма,
Күрмәмен дип уйлыймын бер якты йөз ул йөз кеби.
Көчле, көчсез, ярлы, бай булды һаман да бер аңар,
Һәр караш та ул иде чын «керпегеннән гөл тамар».
Үтте тормыш пычрагын гәүһәр кеби вөҗдан белән,
Аз гына кер кунганын да кай җиреннән кем табар?
Ул көрәште һәм явыз эшкә җәза бирде көлеп,
Үткен акылы шул көлешкә пакь көмештән юл булып.
Ул көрәште, язда елмайган кояш төсле бәләнд [1];
Карны, бозны ул ничек эртә көлеп һәм нур коеп.
Күрмәде гами [2], табигый, буш куыклар атмагач,
Һәм кәмиттә бер батыр да җирдә еглып ятмагач.
Бармыни бездә гомумән чын кеше кадрен белү?!
Без аны кайдан белик, мескен үлеп аңлатмагач?!

## 42

Мулланур Вахитов Хөсәеннең вафат булу хәбәрен алгач, бермәл өнсез калып торды. Юк, һич ышанасы килми иде шундый якын, шат кү-

[1] Бәләнд — бөек булып.
[2] Гами — надан кешеләр, толпа.

целле, көләч, олы мәйдандашының үлеменә. Ләкин акка кара белән язылган телеграмма бу фаҗиганы раслаган. Суфияның, кирәгендә ифрат җитди, кирәгендә көләч Суфияның мондый нәрсәләр белән шаяртмавын ул ачык аңлый иде. Мулланур тиз генә дусты Шәриф Манатовка китте. Алар бу авыр хәбәрне бергәләп кичерделәр. Шәриф исә шундук Петербургтагы барлык татар яшьләренә бу хәбәрне җиткерик, диде. Һәм, чыннан да, алар бу көнне үзләре укый торган психоневрологический институтның бер кабинетына башкалада укып ятучы татар-башкорт яшьләрен җыеп киңәш иттеләр. Нишләргә? Бүген үк кичектермәстән берәребезне Казанга җибәрергә кирәк, бәлки ул әле Хөсәенне соңгы тапкыр күреп кала алыр, бәлки әле ул аны соңгы юлга озатырга өлгерер, дигән карарга килделәр. Җирәбә Мулланурга төште. Студент халкы, барлы-юклы акчасын салышып, билетлык җыйдылар һәм институтның президенты рөхсәте белән Мулланурны ашыгыч рәвештә Казанга озаттылар.

Кызганычка каршы, Мәскәүдән кузгалып киткән Себер поезды шул кадәр әкрен кыймылдады, һәрбер станциядә, һәрбер разъезд һәм полустанкада шул кадәр озак тукталып барды, Мулланур Хөсәеннең җеназасына өлгермәү куркынычын бик тиз аңлады. Ул угаланды, үзен кая куярга белмичә тамбурга чыгып, ачык ишектән язгы күкселлек кергән карлы басуларга карап, гасабиланып барды.

Ул Казанга җиткәндә Хөсәеннең җеназасына бер тәүлек вакыт узган иде инде. Мулланур Московский урамында яшәүче энисе Өммегөлсем белән күрешеп, аның битеннән үпте дә, чәй дә эчеп тормыйча, кичке караңгы төшүенә карамастан, өйдән чыгып китте.

Ул үзенә телеграмма җибәргән Суфияны күрергә дип Пороховой бистәсенә китте. Юл буенча тагы Хөсәен турында, аның һич көтмәгәндә серле рәвештә үлеме турында уйланды. Ниһаять, менә ул бер катлы, агачтан салынган тимер түбәле мәктәп бинасы. Мулланур, извозчик чанасыннан төшеп, акчаны тиз генә бабайның кытыршы учына төртте дә ашыгып капкадан керде.

Аны Гафур каршы алды һәм кулыннан тотып диярлек олы бүлмәгә алып керде. Ак эскәтер ябылган өстәл тирәсендә Суфия, аның булачак ире — куе бөдрә чәчле, күперенке мыеклы Фәхрелислам Агеев һәм Мулланур танымаган, йөзендә тирән яра эзе булган тагы бер егет утыра иде.

Мулланур Фәхрелисламны «Эльислах», «Әхбар», «Кояш» газеталарында һәм «Мәктәп», «Аң» журналларында басылган мәкаләләре, хикәяләре буенча җиденче елдан ук белә иде. Ул туй булачагын ишетеп, котлау телеграммасы да җибәргән иде инде. Ләкин янагында җөй эзе булган егетне ул танымады. Фәрхетдин, дип Гафур таныштыргач кына ничектер исенә төшкәндәй булды. Очрашу бик күптән булган иде ахры. Мулланур бу егетне бишенче елны беренче маевкада күргәнлеген бераздан соң гына хәтеренә төшерде.

— Мин, кызганычка каршы, соңга калдым... — дип ул ак эскәтерле өстәл янына утырды.

— Шулай шул, — диде Гафур күңелсез генә. — Алай да рәхмәт, һич югында Хөсәеннең әле иңмәгән кабере белән хушлашып китәрсең.

— Ничек алай килеп чыкты соң? — дип сорады Мулланур. Гафур зур моңлы күзләрен Суфияга төбәде.

— Ничек булуын сиңа менә безнең доктор әйтеп бирер инде.

Суфия күңелсез генә сүз башлады. Ул Хөсәеннең унөченче мартта «Гасыр» китапханәсендә булуын, шунда сөйләшеп торганда кинәт авып вафат булуын үзе ишеткән кадәренчә сөйләп бирде.

— Хикмәт шунда тагы, — дип өстәде Гафур, — аның кулында бер хат табылган, ниндидер нәмәгълүм кеше: «Сине хатының агулап үтерәчәк», дип язган аңа.

Суфия абыйсын бүлдерде:

— Барысы да провокация. Дошманнары аны чыгырыннан чыгарыр өчен шулай эшләгәннәр. Мин үзем, үз теләгем белән патолого-анатомик тикшерүдә катнаштым. Хөсәен абыйның гәүдәсен профессор Иванов үзе ярып карады. Мин ассистент булдым. Бернинди агулану юк. Әлбәттә, бу дошман провокациясе.

— Шул хат аркасында үлгәндер дисезме Хөсәен абыйны? Мин моңа ышанмыйм, — диде Мулланур.

— Моңа беркем дә ышанмый. Белсәгез иде, аның организмы шулкадәр тузган. Искиткеч! Ничек йөргән ул шул йөрәк, шул үпкә белән? Шаккаттым мин вскрытие вакытында. Үзе бит һич сынатмас иде. Ачык йөз, көр күңел белән каршы ала иде кешене.

Хөсәенне бик зурлап Яңа бистә зиратына күмгәннәр. Озата баручыларның ифрат күп булуын, каберстанда митинг үткәрүләрен, андыймондый тәртипсезлекләр килеп чыкмасын өчен, полициянең ябырылып килүен Гафур да, Фәхрелислам да, Фәрхетдин дә бер-берсен бүлдерәбүлдерә сөйләделәр.

— Алар саклык чараларын күрсәләр, без дә йоклап ятмадык, — диде Фәрхетдин, — Алафузов заводларыннан да, Крестовниковтан да безнең агай-эне, баштан ук сүз куешып, гел митинг оештыручылар тирәсендә булды, фиргәвеннәрне бик якын җибәрмәдек.

Мулланурның Фәрхетдин белән болай якыннан торып сөйләшкәне юк иде әле. «Ярый торган егет икән бу», дип уйлады Вахитов.

— Сез Алафузов заводыннанмы?

Фәрхетдин өчен Гафур әйтте.

— Безнең Фәрхетдин Идел аша күпер сала.

— Анысы ярый, Мәскәүдән Казанга туры поезд булмавы бик җайсыз. Ә ничегрәк соң андагы эшчеләр?

— Һәркайдагыча, Мулланур иптәш.

— Нинди дә булса... эш алып барыламы соң?

Бу юлы да аның өчен Гафур әйтте.

— Безнең Фәрхетдин андагы татар эшчеләренең башында тора инде. Ул сөргеннән тәмам чыныгып кайтты.

Әйе, Мулланур «Урал» газетасы хәлләрен, андагы вакыйгаларны ишеткән иде. Аңа Хөсәен үзе Фәрхетдиннең җавапка тартылу вакытларында нык торуын да сөйләгән иде.

— Кессонда эшләүчеләрнең хезмәтләре бик авыр, — дип куйды Фәрхетдин. Кешеләр унике сәгать су астында, юештә интегәләр. Алган акчалары чыпчык томшыгы кадәр...

Фәхрелислам да сүзгә кушылды.

— Үзегезнең хәлләр ничек соң, Фәрхетдин дус. Сезнең улыгыз белән эш ничек булып бетте?

Фәрхетдиннең йөзенә кызыллык йөгерде. Әйтерсең лә аның иң авырткан җиренә кагылдылар.

— Улым савыккан, — дип куйды ул авыр сулап, — тик берни барып чыкмады. Тегеләр начальствоны гына түгел, мулланы да сатып алганнар. Мәчет кенәгәсен урлаганнар.

Мулланур берни дә аңламыйча хуҗаларга карады. Гафур хәлне аңлатып биргәч, Мулланур, тыела алмыйча, сукранып алды.

— Мин аптырадым инде, егетләр, — диде Фәрхетдин. — Барысыннан да көчле нәрсә — акча, байлык. Ул теләсә ни эшли ала торган, алла кодрәтен дә әйләндереп сала торган нәрсә икән.

Бүлмәдәгеләр Фәрхетдиннең артык ярсып китүен тоеп, сүзне икенчегә бордылар. Суфия Мулланурдан Петербург хәлләрен сораша башлады. Мулланур исә Суфия укуын тәмамлап киткәннән соң булган яңалыкларны сөйләргә керешге.

— Габдулла Тукаев бик каты авырый, җеназада да катнаша алма-

ды. Ишетүемчә, мәрхүм Хөсәенне бик зурлап, мәңге истә калырлык бер шигырь язган, — диде Гафур, сүз Казан хәлләренә күчкәч.

— Галимҗан Ибраһимов үзенең «Яшь йөрәкләр» исемле романын төгәлләгән, — диде Фәхрелислам. — Ул бирешми, гыйльми эшне дә, әдәби хезмәтне дә бик нык алып бара.

— Ә сез, Гафур абый, хәзер нинди әсәр язасыз?

— Мин нәрсә, — дип куйды күңелсез генә елмаеп Гафур. — Минем хәзер кул-аяк богауда. Укытучылыкны да ташларга туры килер ахры. Соңгы елымны укытам.

Күңелсез тынлык булып торды. Мулланур Гафурның сүзләрен дөрес аңлады. Аның һәр адымын тикшереп, һәр барган җирен, очрашкан бер кешесен охранкага җиткереп торалар иде.

— Шулай да бирешмик әле, Гафур абый, — диде Мулланур, — без Хөсәен Ямашев эшен нинди генә шартларда да дәвам иттерергә тиешле кешеләр. Хәзер илдә революцион күтәренкелек башланды. Мин, мәсәлән, хәзер берничек тә бирешмәскә тиешбез, дип уйлыйм. Бу — Хөсәен Ямашев өчен иң бөек һәйкәл булыр.

— Анысы шулай, бирешергә безнең хакыбыз юк. Хәтта кул-аяк богауда булса да.

— Карагыз әле, Галимҗан Сәйфетдинев Казандамы соң хәзер?

— Безнең Гассанмы? О, ул, — диде Гафур, — ул митингта бик ялкынлы речь сөйләде. Өзлексез мәкаләләр яза, большевистик вакытлы матбугат белән даими бәйләнештә тора. Хөсәеннең үлемен ул да ифрат авыр кичерде. Син аны, Мулланур, күрми китмә. Аның әле сиңа поручениелары да булыр дип уйлыйм.

Алар мәрхүм Хөсәенне әледән-әле искә алып, бик озак сөйләшеп утырдылар. Мулланур иртәгә иртүк зиратта булырга, аннан инде шәһәрдә күрәсе кешеләрен күреп, туган-тумачалары белән күрешеп чыкканнан соң, Петербургка юл тотарга булды. Ул хуҗалар белән саубуллашып урамга чыкты. Аңа Фәрхетдин дә иярде. Пороховой урамнарында сыбызгы март бураны хуҗалык итә иде. Мулланурлар «барабыз» эзләп тә, таба алмагач, әкренләп кенә Устьега таба киттеләр. Тәгаен анда трамвай булырга тиеш иде. Башта сүзсез генә атладылар.

— Җил сызгыра, — диде Мулланур тынлыкны бозып.

— Ул Хөсәен абый өчен җылый, — диде Фәрхетдин.

Алар бу минутта икесе дә бер уйда, күңелләрендә якты эз калдырган Хөсәен Ямашев турында уйлыйлар иде.

*1981*

## Нәби Дәүли

### Ветеран йоклый алмый

Җиңү көне,
Халык тантанасы.
Яз төренгән янар комачка.
Җир чәчәкләр тезгән күкрәгенә,
Йөз балкытып карый кояшка.

Сиңа, миңа — шатлык,
Ләкин әле
Сагышлар да яши күңелдә.
Солдатларның сызлый яралары
Менә шушы бәйрәм көнне дә.

Карт ветеран
Әле авырып ята,
Ул ишетә урам шауларын.
Күз алдында күргән кебек була,
Батальоннар узып барганын.

Йөгереп кенә
Чыгып китәр иде,
Аякларның көче калмаган.
Бер җилкәсен пуля тишеп үткән,
Кулына да агач ялгаган.

Ята солдат,
Уйлар килә, китә,
Истәлекләр кайта ерактан.
Кайчагында алар моңландырган,
Дуслар кебек кайчак юаткан...

Ә күршедә
Яшьләр күңел ача,
Аларга да бәйрәм бу көнне.
Бабалары өчен тост әйтергә
Әллә алар хаклы түгелме?

Тост әйтәләр
Җиңү хөрмәтенә,
Кычкыралар: «Ур-ра, ур-ра!»— дип.

Ә ветеран уйлый эчтән генә:
«Яшь әтәчләр шундый була»,— дип.

Ачуланмый,
Уйнап, көлеп әйтә,
Сүзгә сүзнең җае килгәндә.
— Бу шельмалар китап битләреннән
Җавап таба сорау биргәндә.

Сугышны да
Алар белә булыр,
Кинофильм карап экранда.
Космонавт та булып китәләрдер,
Төшләрендә рәхәт очканда.

Шулай була бирсен,
Гаеп түгел,
Туп атканын төштә күрүләр.
Сугышларның авыр тарихында —
Җитеп торыр безнең белемнәр...

Яшьләр бии,
Идән дер селкенә,
Ә ветеран тыныч елмая.
Ә хатыны аның ярсып-ярсып
Тыз-быз килеп яман зарлана.

— Нигә шаулый,
Шушы дуамаллар
Килеп чыккан каян—шайтаннар?
— Тавышлама үзең күңел бозып,
Шайтан түгел алар — шаяннар.

— Әллә кереп,
Йолкып кулларыннан,
Гитарларын тартып аласы...
Аласы да, идән уртасында
Шап иттереп бәреп ярасы...

— Юк, кирәкми,—
Диде карт ветеран, —
Җыр ишетсәм сызлау туктала.
Без җырны да азат итәр өчен
Үлә-үлә кердек утларга.

Биесеннәр,
Тимә син аларга,
Биюләр дә безгә кирәкле.
Сугышта да бию тыелмады,
Йөрәкләргә ялкын үрләтте.

Шулай, җаный,
Бер дә борчылма син,
Яшьлек шулай бизи заманны,
Матур итеп, гөрләп биюләрнең
Беркемгә дә тими зарары.

Әрләшергә язык
Мондый көндә,
Калдырып тор иске зарларны.
Балаларның шундый шатлыклары
Төзәтә бит минем ярамны...

Бүлмә тынды.
Яшьләр таралдылар,
Кечке утлар сүнде йортларда.
Ай сакларга чыкты йолдызларын,
Шәһәр инде ятты йокларга.

Ә ветеран
Һаман йоклый алмый,
Озакламас, инде таң атар.
Сызланудан түгел, шатланудан
Кайчагында елый солдатлар.

## Сораулар һәм җаваплар

— Кайда сезнең
Ташкын төсле кара толым?—
Сорау бирдем
Ап-ак чәчле аналарга.
— Ташкын төсле кара толым,—
Диде алар,—
Балаларда, балаларда.

— Кайда сезнең
Янып торган утлы күзләр?—
Сорау бирдем
Зарлы-моңлы аналарга.
— Янып торган утлы күзләр, —
Диде алар,—
Балаларда, балаларда.

— Кайда сезнең
Энҗе төсле тешләрегез? —
Сорау бирдем
Уй кичергән аналарга.
— Энҗе төсле тешләребез,—
Диде алар,—
Балаларда, балаларда.

— Кайда сезнең
Нечкә билләр, зифа буйлар? —
Сорау бирдем
Шат елмайган аналарга.
— Нечкә билләр, зифа буйлар,—
Диде алар,—
Балаларда, балаларда.

— Кайда сезнең
Назлы шаян чакларыгыз? —
Сорау бирдем

Ялгыз калган аналарга.
— Серле кичләр, айлы төннәр,—
Диде алар,—
Балаларда, балаларда.

— Кайда сезнең
Шатлыгыгыз, җырларыгыз? —
Сорау бирдем
Кайгы белгән аналарга.
— Шатлыгыбыз, җырларыбыз,—
Диде алар,—
Балаларда, балаларда.

...Иң ахырда
Бар бит әле соңгы сүзем,
Сорау бирәм
Буйга җиткән балаларга:
— Рәхмәт,— диеп,— яшәү өчен,
Әйтәсезме,
Әйтәсезме аналарга?

##Ерактарак тор әле син...

Бала сөя якты ут нурларын,
Курка белми әле ялкыннан.
Ләкин белә кемнең кем булганын —
Бала курка күзләр явыннан.
Ерактарак тор әле син,
Ерактарак,
Ап-ак, ап-ак бишек яныннан.

Микроб кына әле явыз түгел,
Йогышлырак бар бит «авырулар».
Кайсылары тәнгә сала тимгел,
Кайсылары җанга ябырылган.
Ерактарак тор әле син,
Ерактарак,
Ап-ак, ап-ак бишек яныннан.

Эчеп-исереп, тартып-сасып йөрсәң,
Син зарарлы тирә-юньгә дә.
Бала белән чәчәк — бер нәселдән,
Кем аларны саклар янудан?
Ерактарак тор әле син,
Ерактарак,
Ап-ак, ап-ак бишек яныннан.

Кулларыңны юып агартсаң да,
Хакың бармы бала кочарга?
Минем балам, диеп мактансаң да,
Саф булмасаң намус ягыннан,
Ерактарак тор әле син,
Ерактарак
Ап-ак, ап-ак бишек яныннан.

Елмаюны битлек итеп кисәң,
Сизми калмас бала йөрәге.
Уенчык дип таш кисәге бирсәң,
Ятлар белән син бер кавымнан.
Арактарак тор әле син,
Арактарак,
Ап-ак, ап-ак бишек янынннан.

Ул бишектә үсеп килә кеше,
Синең «зәхмәт» аңа йокмасын.
Йөзләрендә аның таңнар төсе,
Киләчәккә исеме язылган.
Арактарак тор әле син,
Арактарак,
Ап-ак, ап-ак бишек яныннан.

●

Килде болыт,
Каплап алды тирә-якны,
Яңгыр яуды, яшен атты.
Кырда арыш
Буен сузып җиргә ятты.

Кем коткарыр
Бу кайгыдан бире килеп?
Кем булышыр кулын биреп?
Авыр бөртек
Башакларны тора иеп.
Һаваларга
Тургай кинәт очып менде,
— Мин коткарам сине, диде.
Нәни кошчык
Матур җырлый белә иде.

Баш күтәреп
Тыңлый-тыңлый шушы җырны,
Арыш аягүрә торды.
Кояш аны
Нуры белән терәп куйды.

Кемдер бәлки
Миңа текәп шат күзләрен,
— Хакмы, дияр, бу сүзләрең?
Юк, мин белмим
Табигатьнең бу серләрен...

●

Шигырьне алырга
Кешенең үзеннән:
Шатлыклы күзеннән,
Кайгылы йөзеннән.

Хәтта,
Яшь тамчысыннан,
Хәтта,
Сагышның ачысыннан,
Моңнарның татлысыннан.
Шигырьне алырга,
Әлбәттә —
мәхәббәттән,
нәфрәттән,
Әлбәттә —
йөрәктән.
Әлбәттә —
туудан,
яшәүдән,
үлемнән.
Шигырьне алырга
Кешенең үзеннән.
Әлбәттә,—
кешегә бирергә!

1981

Газиз Кашапов

# СОЛДАТ ИРТӘ ИР БУЛА

ЛИРИК-ДРАМАТИК ХРОНИКА

## Барыр юлың еракмы?

### I



Барысы да, җәй уртасында яуган кар сыман, көтелмәгәндә килеп чыкты.

Әле кайчан гына рядовой Гамил Салихов бу яклардан еракта, гранит кыяларга сыенып утырган хәрби гарнизонда — укыту подразделениесендә иде. Беркөн ашханәдә, төшке аш вакытында, курсантлар арасында «чыгарылыш була икән: техниканы яхшы билгегә тапшырып, өченче классны белгеч дигән исем алучыларны частьларга озаталар, кече командирларны алырга килүчеләр дә бар икән инде» дигән хәбәр яшен тизлеге белән таралды. Берничәләре моңа, сөйләмәгез юкны дигәндәй, бөтенләй үк игътибар бирмәде — ишеттеләр дә оныттылар. Икенчеләре, инде кырыс тәртипкә буйсынырга мәҗбүр булып, башта яшь солдат курсын үткәндә, аннары биредә, күптөрле хәрби белемнәр өйрәнүдән ялыга башлаганнары:

— Китәбез, егетләр! Китәбез бит,— диешеп, бер-берсе белән киңәш табыш итә башладылар.

Әйе, халык бик белеп әйткән: утсыз төтен булмый...

Төшке аштан соң казармаларга кайтып ярты сәгать чамасы ял иткәч тә, кичен нарядка баручылардан калганнарга, казарма алдына чыгып тезелергә куштылар. Алар техника янына китеп барды.

Биек такта койма артында урнашкан аларның «хуҗалыгы». Анда курсантлардан бүтән беркем дә керә алмый. Бөтен тирә-юнь чип-чиста итеп җыештырылган. Ник бер җирдә хәтта ялгыш кына килеп төшкән чүп-чар яки кәгазь кисәге күренсен. Мәйдан үзе артык зур түгел. Уртада бер төштә солдат шинеле сыман соргылт яшел төстәге олы-олы җиһазлар тезелешеп тора. Курсантлар, капка төбендәге махсус җиһазландырылган урында перекур ясап, офицерлар килгәнен көтә башладылар. Озакламый алар да килеп житте. Курсантлар, тиз-тиз таралышып, һәркайсы үзенең системасы янына кереп утырды. Ул арада дөп-дөп итеп дизельләр эшли башлады.

Салихов инде бу хезмәтне яратып өлгергән иде. Аның системасы арада иң мөһимнәрдән санала. Бөтен подразделение нормативларны ник әллә күпмегә арттырып үтәмәсен, әгәр Гамилгә тапшырылган система төгәл эшләмәсә... Ул үзенең тартма-блокларын яхшы үзләштерде. Андагы һәр үткәргечнең ничек эшләгәнен һәм нинди хәлдә икәнлеген бик җентекләп өйрәнде ул. Менә хәзер дә ул, шунда килеп кергәч беренче эш итеп тартмаларны сөртеп чыкты: тузан-фәлән кунган булмасын!

Офицерлар арасында иң кечкенә буйлы, әле җәен генә килгән лейтенант кергәндә Салихов инде «шкафларга» беркетелгән җыелма өстәлне күтәреп, кирәкле схемаларны җәеп куйган иде. Теге яки бу команда үтә торган «юл»ны тагын бер кат тикшереп, имитацияли. Лейтенант, янәшәдәге әйләнмәле урындыкка килеп утырды да:

— Я, иптәш курсант, күрсәтегез әле сәләтегезне. Безнең тырышлыкның җимешләрен. Бер шарт: мине монда юк, сугышчан эш бара дип санагыз. Вакытны үзем күзәтермен,— диде.

Курсант, схемалар китабын ябып, портфельгә салып куйды да, борылып ишеккә таба юнәлде. Хәзер лейтенант аңа башваткыч бирәчәк. Курсант әнә шуны «чишеп» системаны сугышчан эшкә җайларга тиеш. Билгеле, лейтенант кулындагы секундомер бу арада инде текелди башлаган иде. Һәр мизгел санаулы...

Аз гына ял итеп алган арада егет үзенең каенлы-наратлы туган якларын, күптән түгел әле биредә күргән-белгәннәрен искә төшереп утырды.

Кич якынлашып килә. Май аеның соңгы көннәре булуга карамастан, төннәрен һәм иртәләрен әле шактый суык. Гарнизоннан чыгып, әнә теге йөзьяшәр нарат агачлары арасына керсәң... анда әле эреп бетмәгән кар өемнәре еш очрый.

Үткән шимбә көнне старшина берничә курсантны әнә теге киртләч-киртләч таш кыя итәгендәге каенлыкка себерке кисәргә алып барды. Шул мәһабәт наратлар арасындагы аланлыкта, солдатлар сафына кетмәгәндә килеп кергән кызлар шикелле булып, вак каеннар үсә. Ә каенлык уртасыннан бормаланып-бормаланып тау елгасы агып чыга да каядыр еракка-еракка китеп югала. Анда кечкенә генә чишмә тибә икән. Тешләрне сындырырдай салкын, үтә күренмәле саф су гранит ташлар арасыннан ирекка омтыла, вак ташларны шомарта-шомарта үз эзен сала — озын юлга чыга, зур елга белән кушылырга ашыга. Аннары алар бергәләшеп диңгез дулкыннары кочагына ташлана...

Гамил, яңа гына яфракка бөреләнгән каен ботакларын кисәргә батырчылык итмичә, бер ары барып, бер бире килеп йөргәләде. Берсеннән-берсе сылу, берсеннән-берсе зифа ап-ак шәмдәй кәүсәле каеннарның кайсысын йолыккалый башларга кыймыйча, аптырап калган егетне старшина:

— Курсант Салихов! Әллә урман күргәнегез юкмы? Бүтән чакта тагын килерсез. Увольнительный язып бирермен. Ә хәзер кушканны үтәгез. Лирикага бирелеп торырга вакыт юк,— дип кисәтте.

Курсант шуннан соң гына читтәрәк үсеп утырган бер бөкре, ак кабыгына караганда кара тузы күбрәк булган бер каенны ботарлый башлады. Старшина кайтырга дип чакырганда ул инде дүрт-биш себерке бәйләп юлга чыгып килә иде. Бүтәннәр исә кочак-кочак сындырганнар, көч-хәл белән җыештырып азапланалар. Старшина, Салихов ягына кырын-кырын карап куйса да, башка вакытларда һәр нәрсәне үрнәк башкарганы өчен булса кирәк, бу юлы дәшмичә калды...

...Ишектә тагын лейтенант күренде. Ул курсантны чакыра иде. Тагын берничә минуттан, Салихов үзенә тапшырылган системадагы шкафлар-

ны тикшереп чыкты, барлык тумблерларны да таләп ителгәнчә куйды да тагын эшкә кереште. Секундомер угы ничек кенә ашыгып йөгерсә дә курсантка бирелгән вакытны санап чыгарга өлгерә алмады.

Икенче көнне, иртәнге развод вакытында Гамилләр взводы алдына подразделение командиры килеп басты. Шактый тулы гәүдәле, чигәләре чалара башлаган, ләкин әле шактый җитез хәрәкәтле подполковник биш курсантның фамилиясен әйтеп, аларга саф алдына чыгарга кушты. Аннары укыту подразделениесе командирының әлеге биш курсантка ефрейтор званиесе бирелү турында приказын укыды. Шуннан соң батарея командирына калган курсантларны көндәлек эш урыннарына таратырга рөхсәт итте. Һәм каршысында басып торучыларга:

— Бөркетләр, без бүген подразделениенең иң яхшы курсантларын сугышчан частьларга озатырга тиешбез. Сез барасы җирдә махсус хәзерлекле белгечләр җитешми. Без, үзара киңәшкәннән соң, сезнең бишегезгә путевка бирергә булдык. Сынатмассыз дип ышанабыз. Хәзер үк штабка барыгыз. Анда сезне көтәләр,— дип сүзен бетерде.

Курсантлар, мондый кискен үзгәрешкә исләре китеп, кузгалыргамы, кузгалмаскамы диебрәк торганда подполковник, нәрсәнедер исенә төшергән сыман: — Бу карарга каршы килүчеләр юктыр бит, әллә бармы, егетләр? — дип сорау өстәде.

Бөркетләр дип мактаганнан соң, белемнәрен сугышчан эштә кулланырга, илебезнең һава чикләре сагына басарга атлыгучы егетләр, ничек каршы килсеннәр ди инде?!.

Подполковник ел саен күз җитү белән, чираттагы чакырылыш башлангач та, үзе әйткәнчә, яшь бөркетләрне шулай сайлап алып кайта иде. Ул аларны хәрби тормышның иң беренче, ләкин иң кирәкле серләренә төшендерә, өйрәтә, әле мыеклары да чыгарга өлгермәгән егетләрдән менә дигән белгечләр, кече командирлар әзерли. Һәм, бер көнне, менә бүгенгедәй итеп, үзе үстергән «бөркетләргә» путевка бирә, сугышчан эшкә озата. Һәр чыгарылыштан соң карт солдатның йөрәге ямансылап йөри. Нәрсәдер җитешмәгән кебек була.

Подполковникны инде урап ук алган курсантлар, үзләренең яшьлеге аркасында, әлбәттә, боларны тирәнтен үк аңламыйлардыр да әле. Шулай да алар карт солдатны калдырып китәргә ашыкмадылар. Аңа рәхмәт сүзләре әйттеләр. Бераздан исә подполковник аларга текәлеп карап, бөтенләй гади, йомшак тавыш белән:

— Сезгә, бөркетләр, барыгызга да хәерле юл,— диде.— Старшина янына кереп погоннарыгызны алыштырып чыгарсыз.

Тагын ун-унбиш минуттан киемнәре ятышлы, өр-яңа погонлы ефрейторлар бәләкәй сафка тезелеп штаб бинасына таба атладылар.

Кече командирларны алырга килгән вәкил — капитан Сергеев исемлек белән танышып чыккан икән. Ул укыту подразделениесеннән китәчәк барлык курсантларны туплап сөйләшеп алды да аларны юлга җыенырга таратты. Кич белән бу төркем китәргә тиеш иде. Капитан Сергеев үзе политработник икән. Ул кече командирлар арасындагы партия членлыгына кандидатлар белән аерым да сөйләште. Андыйлар өчәү иде. Шулардан партгруппа оештырды. Бурыч: төрле подразделениеләрдән яңа гына җыелган кешеләрне оештыру һәм хезмәт урынына «ЧП»сыз барып җитү. Ефрейтор Салихов капитанның вакытлы ярдәмчесе итеп билгеләнде.

Кече командирлар төркеме шул ук төнне, инде ияләшкән казармалары, үзләштергән кораллары, бу якларның кырыс табигате, дуслары

һәм командирлары белән хушлашып, пассажир поездына утырып озын юлга кузгалды.

Солдат хезмәте үз законнары белән дәвам итә. Иртәме, кичме, көндезме яки төнләме, «кирәк» дигән бер сүз аны җылы урыныннан, ияләшкән торагыннан аерып ала да, тиеш һәм кирәк булган яңа җиргә җибәрә. «Без нәкъ менә шуның өчен, туып-үскән авылларыбыз һәм шәһәрләребездән килеп, өстебезгә соры шинель кидек тә» дип уйлап куйды ефрейтор Гамил, әле соңгы утлар күздән югалгач та, поезд тәрәзәсенә маңгаен куеп, гранит кыяларга караган килеш. Кайтарылып төшәм-төшәм дип торган гранит ташлар өстендәге тоньк яктылык каядыр еракка, әлегәчә күрелмәгән якларга таба ашыга сыман иде.

Станциягә төнлә килеп җиттеләр. Тар перрон чуар халатлы, аллыгөлле рәсемнәр төшерелгән кәшимир шәл бәйләгән хатын-кызлар, җәйге төннең бөркүлегенә дә карамастан, башларына сарык тиресеннән тегелгән дәү-дәү тәлпәкләр кигән ир-атлар белән тулы иде. Иң гаҗәбе шул: араларында хәтта тунлылары да бар... Кече командирлар төркемен, сафка тезеп, капитан Сергеев ниндидер киң мәйданга алып чыкты. Анда тимер рәшәткәләр белән уратылган бакчада тирә-якка су тамчылары чәчрәтеп фонтан сиптереп тора, теге баштарак каршылаучы машиналар тора иде. Биредә һава бераз салкынчарак, шуңа сулыш алуы җиңел, иркенрәк. Шоферлар машиналары янына чыгып басты. Алар киң читле эшләпә, ачык якалы, алдан каптырылмалы гимнастерка, балаклары манжетлы чалбар һәм аякларына ботинка кигәннәр. Мондый форма яңа килүчеләрне гаҗәпләндерде. Вокзал тирәсендәге эскәмияләрдә поезд көтеп утыручылар исә пилоткаларын кырын салган, тор-гызма якаларын барлык сәдәфләренә дә эләктергән, җилкәләренә түгәрәкләп төрелгән шинель аскан солдатларга сәерсенеп карыйлар иде.

Вокзал алдындагы эңгер-меңгерне көчле нурлары белән яктыртып, скверга «газик» килеп керде. Аннан солдатлар шикелле үк ачык якалы гимнастерка кигән, кара кырпулы фуражкасын кулына тоткан мәһабәт гәүдәле полковник чыкты. Капитан Сергеев сафтагыларга:

— Смирно! Равнение на — средину! — дип кычкырды да, уң кулын чигәсенә куеп, тигез, нык адымнар белән полковникка таба китте. Тегесе кулындагы фуражкасын ашыгып киде һәм, капитанга таба өч-дүрт адым атларга өлгерде. Вокзал алды мәйданында хәзерге минутта басып торган барлык солдатларга да әлеге команданың катнашы булуга да карамастан, машина тирәсендәгеләр ягыннан «кәттә командир» дигән тавыш ишетелде. Ефрейтор Салихов «монда дисциплина бик үк катыдан түгел, ахрысы, «смирно» командасыннан соң да сөйләшәләр» дип уйлап куйды. Укыту подразделениесендә болай булмый торган иде. Җитмәсә тагы «кәттә»... Партизаннар диярсең.

Рапортны кабул итеп, полковник сафтагыларга якынрак килде, мәйдандагыларны сискәндерерлек калын тавыш белән:

— Исәнмесез, иптәш сугышчылар,— диде.

Сафтагылар дәррәү:

— ...дравие жел... тов... ниик! — дип исәнләштеләр.

Аларның тавышы бер-ике секундтан вокзал тирәләреннән әйләнеп кайтты да: — ...һник,— дип өстәп куйды.

Аннан соң полковник кече командирларны хәрби округка килүләре белән тәбрикләде һәм, сүзне озын-озакка сузып тормыйча, Сергеевка:

— Иптәш капитан! Егетләрне Алтухов хуҗалыгына илтеп урнаштырыгыз. Үзегез иртәгә иртүк штабка килерсез,— дип, машиналарга урнаша башларга рөхсәт бирде.

Юлга кузгалып ике-өч йөз метр җир китәргә өлгермәде, яңа килгәннәрнең исен китәреп каядыр, бөтен тирә-юньне көндезгедәй итеп яктырт-

кан куәтле прожектор кабынды. Аның Киез каз юлы кебек киң сибелгән нурлары салмак кына килеп машиналарны капшап алды да көтмәгәндә сүнде. Дөнья, әйтерсең, баягыдан да карангырак булып калды, егетләр беравык берни күрмичә бардылар. Ил чигенең якынлыгы солдатлар күңеленә анлашылмый торган серлелек өстәде. Калган юлны сөйләшмичә үттеләр.

Көньякның иртәнге кояш нурлары казарма алдындагы асфальт мәйданда рәт-рәт тезеп куелган койкаларда йоклап ятучы солдатларның йөзенә төште. Егетләр одеалларын аяк очына тибәреп, я булмаса бөтенләй асфальтка ташлап йоклыйлар. Плац өсте инде шактый гына кызарга да өлгергән.

Ефрейтор Салихов торып утырды, тирә-як белән таныша башлады. Полковник әйткән Алтухов хуҗалыгы тулысынча күз алдында иде. Киртләч-киртләч тау сыртлары ап-ачык булып күренә. Хуҗалыкны җирдән өелгән вал, мондагыча әйтсәк, дувал уратып алган. Урта бер җирдә казарма. Аның теге башында, аз гына читтәрәк — тагын бер таш бина.

Ефрейтор таш бинадан бире таба килүче капитанны күреп койка аркасына элеп куйган чалбарына үрелде. Сергеев ефрейторны чакырып кул изәде. Салихов чалбардан гына килеш капитан янына йөгерде. Кул биреп исәнләштеләр.

— Хәерле иртә, иптәш Салихов. Яңа җирдә ничек йокладыгыз? Сезнең монда полный камфорт. Болай кайчан ял итәр идегез әле? — диде ул аннары ярым шаяртып.

— Бик әйбәт йокладык, иптәш капитан. Бер нәрсә дә борчымады. Оҗмах монда. Җылы. Кояш...

— Шулаен шулай... ләкин ул оҗмах үзен танытыр әле, ефрейтор...

— Күнегербез, иптәш капитан!

— Иптәш ефрейтор, мин штабка китәм. Сез минем урынга каласыз. Биредәге старшина белән танышыгыз. Егетләрне ашатыгыз-эчертегез— сез биредә азык-төлек тәэминатына куелган. Аннары өс-башларыгызны тәртипкә китерегез. Яңа климатка күнегү-җайлашу өчен сезгә бер көн вакыт бирелә,— диде капитан китәргә борыла башлап.

— Без монда озак булабызмы соң, иптәш капитан?

— Күп түгел. Сезне бүген үк таратырга тиешләр.

— Аңлашылды, иптәш капитан.

— Әйе, ефрейтор, әгәр кайбер иптәшләрне алырга мин кайтканчы килсәләр,— диде ул мәйданда йоклап ятучыларга күрсәтеп,— озатып җибәрерсез.

— Есть, иптәш капитан...

— Үтәгез, ефрейтор.

Капитан штаб бинасы янындагы күләгәдә торган «газик»ка таба китте.

Мондый «анархия» бирегә кичә килүчеләрнең төшенә дә кермәгән иде. Күрегез инде. Кояш төшлеккә җитеп килә, түзә алмаслык кыздыра, ә егетләргә торыгыз дип команда биргән кеше юк. Дөрес, ефрейтор, ашка чакырып команда бирде бирүен, егетләр әле ашыйсы килми диешкәч, артык кыстап тормады. Ни әйтсәң дә үзебезнең иш, артык бимазаламый... Бу «анархия»нең командирлар тарафыннан бирелгән климатлашу көне икәнен белмиләр иде алар.

Бераздан йокы туйды. Кояшның шәфкатьсез кыздыруы егетләрне әлсерәтте. Алар койка өсләренә җаймалардан чыбылдык корырга мәҗбүр булдылар,— димәк, көньяк «оҗмах»ын сизә башладылар. Кояш һаман кыздырганнан-кыздыра бара. Асфальтка кул тидереп булмый.

Монда ничек яшиләр икән соң? Ләкин яшиләр ич. Әнә солдатлар, берни булмагандай, физик хәзерлек белән шөгыльләнә.

Төшке ашка биш-алты кеше генә барды. Калганнары салкынча душ астыннан чыгарга теләмәде. Ләкин барганнары да рәтләп ашамады.— Аннан-моннан гына капкаладылар да тизрәк душка, күләгәгә ашыктылар. Әлсерәү соңгы чиккә җитеп килә иде инде.

Ниһаять, баш өстенә мәңге төшмәскә менеп кунаклагандай торган утлы шар түбәнәйгәннән түбәнәя барып ерактагы тау сырты артына төшеп югалды. Егетләр, иркен сулап, өс-башларын тәртипкә китерергә тотындылар.

Чүл тынлыгын ярып, шлагбаум янына килеп туктаган машина гудогы ишетелде. Мәйдан сизелерлек җанланды. Димәк, аларны алырга килделәр. Плац янындагы ике УАЗдан офицерлар төшеп өс-башларыннан юл тузанын кага башладылар.

Группаның өлкәне буларак, ефрейтор Салихов алга чыкты. Ул башына пилотка кигән, гимнастерка якаларын каптырган, чалбарын менә дигән итеп үтүкләп өлгергән иде. Офицерлар белән устав кушканча исәнләште. Тегеләре:

— Я, егетләр, Россия бөркетләре, безнең «ташкент» сезгә ошыймы? Куырылмадыгызмы әле? — дип көлешә-көлешә хәл-әхвәл сораштылар. Арада берсе үзе дә укыту подразделениесендә булган икән — тегесенмонысын сораштыра башлады. Икенче офицер күкрәк кесәсеннән блокнот чыгарды да, кирәкле битне тапты.

— Наговицын, Савельев, Владимиров, Саенко,— дип укыды. Аннары, җыелганнарын күзәтеп чыккач: — Менә, иптәш ефрейтор, шуларны сезнең хәер-фатихагыз белән без үзебезгә алып китәр идек,— дип өстәде ул шаяртып. Ә ефрейторның янына ук килеп ул: — Капитан Сергеев сезгә сәлам әйтте. Менә шушы исемлекне сезнең галиҗәнапләргә тапшырырга кушты,— диде.

Фамилияләре әйтелгәннәр, «анархия» бетте, егетләр, хезмәт башлана диешеп, «мөлкәт»ләрен җыйдылар да, иптәшләре белән саубуллашып, УАЗларга барып утырдылар.

Тагын бераздан мәйданда ефрейтор Салихов белән Воронеж егете Аксенов икәү генә калды. Алар да урыннарын тиз генә җыеп старшинага тапшырдылар. Плац уртасындагы өстәл янында аларга диңгез флоты формасы кигән майор: — Сез безнең дивизионга билгеләндегез. Мин — командир, менә бу капитан — штаб начальнигы була. Җыеныгыз. Озакламый китәбез,— диде.

«Климатлашу» өчен бирелгән бер көн шулай узды. Иртәгә егетләрне яңа хезмәт, яңа урын, яңа иптәшләр көтә.

Ефрейтор Салихов белән Аксенов яңа подразделение казармасына кергәндә төн уртасы инде узган иде. Солдатларның йокыга иң зирәкләре дә онытылып оеган чак. Казарма эчендә караңгы. Дневальный тумбочкасы өстендә генә тонык, зәңгәрсу яктылык күренә. Штаб начальнигын күрүгә, тумбочка өстенә башын салып йокымсыраган дневальный сикереп торды. «Миңа нинди җәза бирәсез инде?» дигән сыман, күзләрен мелт-мелт иттереп алды да гаҗәеп бер акцент белән:

— Урток капитан,— дип тагын нәрсәдер әйтергә җыенды. Ләкин капитан аны үзе бүлдерде:

— Алиҗанов, кадерлем. Яланбаш хәрби кулын чигәсенә куеп честь бирергә тиеш түгел дип күпме әйтергә мөмкин? — диде ул.

Алиҗанов уртачадан озынрак буйлы, чандыр, ләкин чыныккан сөякле, кысынкы күзле үзбәк егете булып чыкты. Аның гимнастеркасы, күренеп тора, кимендә бер-ике размерга кечкенә. Җиңнәре терсәгенә җитә язган, бил каешы астыннан гимнастерка итәге нибары ике-өч бармак киңлегендә генә күренеп тора. Панамасы белән — яңа егетләр ин-

де кин кырлы эшләпәнең шулай аталганын беләләр иде — телефон аппаратын каплап куйган.

— Виновный, катта виновный, урток капитан,— диде Алиҗанов, ниһаять, үзбәк һәм рус телләрен бергә буташтырып.

— Что, что вы говорите, Алижанов?

— Дневальный үзенең гаебен таный, гафу итүегезне үтенә, иптәш капитан, — дип сүзгә кушылды ефрейтор.

— Ә сез үзбәкчә беләсезмени, ефрейтор?

— Мин татар, иптәш капитан. Безнең телләребез охшаш.

— Бик шәп бит әле бу, ефрейтор,— дип шатланды капитан.— Безгә быел пополнение Үзбәкстаннан килде, барысы да кышлак егетләре. Баштарак эшләр бөтенләй труба иде. Хәзер инде ярыйсы гына сөйләшәләр. Аңлашабыз. Русча сөйләшергә ярыйсы тиз өйрәнәләр. Шулай бит, Алижанов?

— Хак сүз, урток капитан.

— Ну вот... Ярый, ярый, менә яшь командирлар үзегезне тәртипкә өйрәтерләр әле... — диде капитан һәм бераз дәшми торгач:— Хезмәткә яңа гына чакырылганнар күп. Дисциплина ягы да аксый. Анысына әле түзәргә дә була, тик менә техниканы белмәү аптырата. Дежурный кайда, Алимҗан? — дип сорады.

— Спит лежал, урток капитан...

Капитан ишек өстендәге сәгатькә, аннан кулындагысына күз төшереп алды да:

— Ярый, Алимҗан... Менә бу икe егетне каравылдагылар койкасына яткырыгыз. Иртән старшинага җиткерегез: — Сезгә үлчәве ярардай киемнәр табып бирсен. Төшендегезме? Ә дежурный иртүк минем янга килсен. Хәзер барып аны уятыгыз,— дип казармадан чыгып китте.

— Подъ — ЕОМ!

Бу команда кайда гына яңгырамасын йоклап яткан солдатны мизгел арасында уята. Әгәр шуннан соң да юрган астында уянмаганга салышып ятучы бар икән — ялган. Ике сәгать ярым элек кенә яткан ефрейтор Салихов белән рядовой Аксенов «подъемны» ишетүгә сикерешеп тордылар да кабаланмыйча, ләкин җитез, өлгер хәрәкәтләр белән киенә башладылар. Ә старшина тавышы әле һаман колак төбендә яңгырап торды. Чөнки тавыш дисәң дә тавыш! Башларын одеал астыннан чыгарырга ашыкмаучылар бар әле. Монда сугышчыларны урыныннан тиз торырга, яшен тизлеге белән киенергә бер «тревога» командасы гына мәҗбүр итә ала микән әллә?

Ишектә тәбәнәгрәк буйлы, аршин җилкәле, цирк көрәшчесен хәтерләткән бер кеше күренде. Ул чалбардан гына әле. Аягында — йомшак тапочкалар... Әкәмәт. Ул йокы бүлмәсенең ачык ишегенә барып тагы бер кат: «Подъ — ЕОМ!» дип үкерде дә, егетләр каршына килеп:

— Таныш булыйк, братцы, дивизион старшинасы — ефрейтор Щербак,— диде. Аннары: — Сез ник йокламыйсыз? Юлдан килгәннәр ял итә алалар иде... — дип өстәде.

Дневальный янынннан ишеккә таба берничә кеше чыкты. Отделение командирлары иде. Йокыдан аннары торып чыгучыларның барысы берьюлы яңа килүчеләрне күреп алдылар, алар янына килеп сорашатаныша башладылар. Шул вакыт казарма болдырында дежур офицер күренде. Ул:

— Щербак, тезелергә команда бирегез. 6.30 да — кросска хәзерләнергә! — диде.

Иртәнге алты. Кояш инде ярыйсы ук кыздыра башлаган. Ләкин төнлә җир өсте бераз суынып өлгергән, сулыш алуы рәхәт әле. Еракта-еракта ком чүленә урнашкан бу гарнизонда үзенә генә хас тәртип,

аерым кагыйдәләр яши иде булса кирәк. Моны ике яңа егет тә сизә башлады. Старшина — ефрейтор Щербак тезелергә команда бирде. Кайсы якка басарга белмичә аптырап торган егетләргә сул флангка таба кулын изәп күрсәтте. Колонна дувал аша чыккач акрынлап тарала башлады. Әле анда, әле монда үсеп утырган чәнечкеле үлән тирәләренә икешәр-өчәр сугышчы җыелды. Кайсылары арырак китте. Берикесе әнә инде папирос төтәтә.

Командирның мәһабәт гәүдәсен ефрейтор Салихов ерактан ук күреп алды. Ул җиңел трикодан иде. Майор килеп җиткәндә барысы да олы юлга чыга торган сукмак тирәсенә тупланганнар иде. Салихов, «яңа урында хезмәт итә башлауның беренче көнендә сынатмаска кирәк» дигән сыман, Александрга күз кысып алды. Әлек бер подразделениедә хезмәт итмәгәч Сашаның ничек йөгергәнлеген белми иде ул.

— Шагом — марш! Тагын бераздан: — Бегом — марш! — дигән команда ишетелде.

Сафтагылар урыннан дәррәү ыргылды. Мондагыларга җиңелрәк — алар ботинкадан. Саша белән Гамил моны тиз төшенделәр. Ләкин бит «туктагыз әле, егетләр, чур, итекләрне салыйк» дип тора алмыйсың... Урыннан тыгыз бер төркем булып кузгалган сугышчылар ике-өч йөз метр узу белән сузыла башладылар. Өч километр ара озын дистанция түгел түгелен, әмма аны йөгереп узуның хикмәтен белергә кирәк: башта җиңел адымнар белән кузгаласың, аннары акрынлап күкрәк астына нәрсәдер тыгыла башлый. Сулыш алуы кыенлаша, һава җитми, чигәләр кыса башлый. Тәмәке тартучыларга бу икеләтә кыен. Билгеле, монда спортчылар темпы таләп ителми, ләкин вакыт чикләре барыбер бар.

Аксенов башта Гамил белән янәшә барды да ярты юлга җитәр-житмәс әкренләп артка калды. Ул иптәшенә «Син йөгер. Мин өчледән уза алмыйм»,— дип кычкыргач, Гамил авыр сулый-сулый йөгергән сугышчыларны берәм-берәм куып житеп уза башлады. Озакламый ефрейтор алдында ике-өч кеше генә калды. Әнә, инде шлагбаумның аклы-каралы киртәсе дә күренә — димәк, финиш якынлаша. Алдагыларны куып житәргә кирәк. Ефрейтор бер-ике тапкыр тирән сулыш алды да алга ыргылды. Бу аның ярышларда куллана торган хәлиткеч алымы иде. Алдан җиңел адымнар белән командир йөгерә иде. Адымлабрак баруына карасаң, болай йөгерергә тиеш тә түгел кебек. Салихов та командир барышына ярашып бераз ял итеп алды да, финишка егерме биш-утыз метр калгач, баягы ыргылышын кабатлады. Яңа килгән ефрейтордан мондый елдамлыкны көтмәгән майор бирешмәскә ничек кенә тырышса да өлгерә алмады, Салихов финиш сызыгын ике адымга алдан узды.

Кроссны секундомер белән күзәткән капитан Гаврилов кайтканда ефрейторга:

— Булдырдың, якташ. Командирның мин-минлегенә шәп суктың. Хәзер атна саен кросс булачагын көт тә тор,— дип күз кысты. Аннары чувашча: — Молодец, якташ, шулай кирәк, —дип өстәде.

— Сез, иптәш капитан, минем чувашча аңлаганны каян беләсез? — дип гаҗәпләнде Салихов.

— Безнең райондагы татарлар барысы да чувашча, ә чувашлар татарча белә, иптәш ефрейтор.

— Сез Татарстаннанмы?

— Әйе. Сезнеке авыл пелән пезнеке ара нибары биш километр.

— Биредә якташны очратырмын дип һич уйламаган идем...

— Пер татар егете дә бар әле. Биектау районыннан. Полный интернационал пиредә.

Аларны командир куып житте.

— Ә син, ефрейтор, командирны узарга да курыкмадың?

— Шуңа да спорт бит инде ул, иптәш майор. Ярыш.

— Молодец, ефрейтор. Кичә сезнең документларыгызны караган

идек. Укыту подразделениесендә дә яхшы укуыгыз, җәмәгать эшләрендә актив катнашуыгыз өчен ун көнлек ял биргән булганнар икән. Так вот. Мин сезнең ял итеп килүегезгә каршы түгелмен. Сез инде монда да аңа лаек икәнлегезне күрсәтә башладыгыз, ефрейтор. Бүген үк документларын тутырып бирегез, капитан!

Ефрейтор казармага чаклы сөйләшә алмас булып, хыял канатларында очып кайтты.

## Зур түгел солдат йөрәге

### I

Авыл өендә кара толымнарын мендәр өстеннән идәнгә салындырып төшергән бер яшь хатын үксеп-үксеп елый. Бер килә башласа, килә дә килә икән ул — өсте-өстенә, актарылып-актарылып килә кеше башына төрле кайгы-сагышлар. Бәлки шатлыклар да шулай килә торгандыр, тик алар күңелдә тирән эз калдырмыйча, җәйге матур көн шикелле көлемсерәп үтә китә. Кайгылары, нинди булса карарга килә алмыйча азапланган көннәре күңеленнән китми аның. Күңелнең әллә кайсы җирендә ничәмә-ничә төрле газаплы сорау туа. Аның җаваплары ник сирәк табыла икән соң? Аннары, ул җавапларның дөреслеген, еллар үткәч үкенмәслек икәнен каян белергә дә, ничек итеп ялгышмаска кирәк? Әгәр сиңа нибары унтугыз яшь, җилкәңдә исә нибары унъеллык мәктәптә күргән-белгән, татыган йөк кенә булса, иң дөрес карарны ничек итеп табарга соң? Өстәвенә унтугыз яшьлек кеше киң дөньяны бөтенләй күрмәгән, эти-әнисенең җылы кочагында иркәләнеп үскән кыз булса? Әгәр моннан бер ел чамасы элек ул кыз җаны сөйгән егеткә ата-анасының рөхсәтеннән башка кияүгә чыккан булса? Армия хезмәтен тутырып кайткан икенче берәү исә көн саен гармунын моңландырып аның капка төбеннән узып торса? Әгәр?.. Әгәр?!

Мендәр түзә. Күз яшьләре таммаган урын калмаса да түзә. Ичмаса бу толымнары да җан көйдереп бормаланып яталар... Ул ярата иде бит аларны. Юләр димәсәң дә юләр инде — шушы толымнарны я муенына урап, я битенә салып ята иде бит. Кеше ишетмәгән һәм күрмәгән әллә нинди үлән исләре килә дип әйтә иде. Шушы толымнар хуш исен трактор мае арасыннан да тоям ди иде. Ярата иде...

Иде. Нигә иде?! Ул аны һаман да ярата бит. Киткәненә елга якын вакыт узды, ә хатлары көн саен килә дә килә. Азга гына да онытмый күрәсең. Үзем дә яхшы инде, соңгы вакытта бөтенләй язмый башладым. Атнага бер хат килсә, алмадым, тегә-бу дип акланып булыр иде ичмасам. Юк, көн саен язып тора. Берсен алмасаң, икенчесен аласың. Почтага тиктомалдан, күрәләтә яла ягып булмый лабаса. Җитмәсә почтасы кем бит әле? Аның әнисенең сердәше — ахирәте. Югалтамы соң аның хатларын. Кар яуса да, яңгыр яуса да йөгерә-атлый килеп җитә. Таш яуса да килер иде кебек...

Ник кенә соң, ник кенә чыкты ул аңа? Армиягә китеп барасын белә иде бит. Китмиме соң? Әле ничек кенә китә? Әти военком белән беркие елга калдырып торыгыз әле, менә диган тракторчы бит ул дип, сөйләшеп караган иде әнә... Шуны ишетү белән оборона министрына хат язып салды. Армия дигәндә... Минем толымнарымны чынлап сагынмый күрәсең?!. Менә хәзер йөре айт-двага басып...

Мин монда аны көтеп урамга да чыкмыйча ятарга тиешмени инде?

Кадалгыры толымнар, нишләп һаман күз алдында бөтереләсез соң әле? Ачуымны бик китерсәгез, иртәгә үк кисеп-кисеп алырмын.

Юк, ул армиягә киткәндә «толымнарыңны кисә күрмә, кистерәсе булма!» — дип, ничәмә-ничә кабатлады. Яратам бит мин аны. Авылда аңардан да матур һәм житезрәк егет юк иде бит... Ник бу хәтле телгәләнәм соң әле мин?!. Вазыйхның гармун тавышын ишетмәгәндә күңелем тыныч. Гармунын уйнатып урамнан шул кәкре аяк уза башласа, йөрәккәем күкрәгемнән сикереп чыгып качардай була. Буе да аныкыннан тәбәнәк бит юкса, чәчләре дә сап-сары. И ходаем, ни генә кылыйм соң? Кичә кич тагын озата килде. Аз гына боргалап та тормый ичмаса: ташла Гамилне, миңа чык, ди. Чыкмасаң, барыбер урлап китәм, ди. Әйтерсең, минем ир хатыны икәнемне бөтенләй белми...

Гармунын култык астына кыстырып яныма килеп басса, үзем дә әллә нишләп китәм шул... Кичә кич салкынча иде. Гармунын миңа тоттырды да, пинжәген жилкәмә салды, куллары... Ходаем, ник соң әле мин гел Вазыйхны уйлыйм, ә аны — үз иремне кайчакта көннәр буе исемә дә кертеп чыгармыйм? Ниткән эш бу? Әти, аңардан битәр әни Вазыйх яклы шул. «Чыкма шул коммун Гариф кызы Сәгадәтбану малаена, көт Вазыйх кайтканны» дип, юкка гына сөйләмәде әни былтыр.

Нигә соң алар Гамилне хупламадылар? Әти белән дә еш кына бәрелешә иде шул. Колхоз житәкчесе белән югарыдан торыбрак сөйләшә иде. Әллә ниткән хаталар, гаепләр табып район газетасына язып торды. Авыл кешеләре дә «кияүең..., юк, ирең кайтсын да әтиеңне алыштырабыз» дигән була кайбер юньсезләре. Техникум бетергән дигәч тә... Әти, күрәсең, бу сүзләрне ишеткәндер? Ишетмичә! Куштаннар юк мени? Кайсыларын күрсәм, күңел болгана башлый...

Урамның теге башындагы инеш буенда көмеш телләренең моңына яшь йөрәкнең әллә кайсы почмагында яшеренеп яткан юксыну сагышларын кушып гармун уйный башладылар.

Тәнзилә үз-үзен кая куярга белмичә, бүген булмаса иртәгә хәл ителергә тиешле нәрсәләргә һаман җавап таба алмыйча аптырады. Гармун моңының иң беренче авазлары ишетелүгә башын мендәре астына яшерде, юрганы белән томаланып ятты. Гармун тавышы ишетелмәс булды. Хәзерге көйләр дә никтер йөрәк-бәгырьләрне телем-телем кискәли торган була башлады. Бу композиторларын әйтер идем...

Шундый уй-кичерешләр белән бимазаланган Тәнзилә бераз тынычлап йокыга талгандай булды. Ләкин тәнгә сихәт биреп, йөрәккә ял өсти, күңелне юата торган тирән йокы түгел иде бу. Аны төшендә дә шул ук уйлар эзәрлекләде.

...Имеш, Гамил әле аңа өйләнмәгән. Ләкин алар күптән инде сөйләшеп, яратышып йөриләр. Гамил ярәшергә кыстый. Тәнзилә бөтенләй үк каршы да түгел кебек, ләкин нигәдер аз-маз икеләнә сыман. Гамилне, кирәк булгач, колхоз автомобиленә шофер итеп күчерсәннәр иде. Тәнзилә, имеш, Гамилнең туганнан туган апасы белән инеш буендагы тугайда йөри. Тугай чишмәсе янында Гамил машинасы тора, имеш тә, кызлар йөгерә-атлый шул машина янына килделәр. Шоферы каядыр киткән. Кая китсен, су коена торгандыр, диде Гамилнең апасы. Кызлар аны-моны уйлап тормастан кабинага күтәрелделәр. Шофер урынына Тәнзилә менеп утырды, Гамилнең апасы теге якка, янәшә урнашты. Алай иттеләр: машина урыныннан кузгалмый гына бит. Аста күренеп торган ике педальгә ике аягы белән берьюлы басып, чукмар башлы күчергечне ачуланып тарткан иде, машина үкереп артка таба кузгалып китте. Анда, Тәнзилә белгәннән бирле, жиде бала колачы белән генә иңнәрлек карт һәм юан тал үсеп утыра. Машина нәкъ шул талга таба бара. Кай жиренә басып туктатырга соң моны, ходаем? Ләкин соң инде. Машина үкерә-үкерә барып әрҗәсе белән талның калын кәүсәсенә барып төртелде. Тәнзилә исә, азаплана торгач, аның нәрсәсенәдер басты, кай жирендер төртте: машина тагы бер үкерүдә алга ыргылды. Ин-

де хәзер Тәнзилә машинаны иллә дә шәп йөртә, имеш. Ул аны искиткеч бер осталык белән ярның читеннән үк бөрып алды да тыкрык буйлап авыл эченә таба элдертте. Машина яр читеннән мәтәлә язып борылганны дөньясын онытып су коенган Гамил дә күреп калды, колач салып бу як ярга йөзә башлады... Ул арада Тәнзилә авыл урамнары буйлап, бөтен кешенең исен китәреп, йөрепме йөри иде. Правление тәрәзәсеннән карап торучы атасы аңа кеше башы хәтле зур йодрыгын изәп калды. Шуңардан шүрләде дә Тәнзилә, машинаны күршедәге чуваш авылына таба борды. Олы юл шул якта иде. Озакламый тегермән буасы күренде. Буа озын-озын, ләкин тар иде. Көзгедән этисенең машинасына утырган Гамилнең куа килүен күреп алган Тәнзилә читкә борылырга, туктарга уйлап та карамады. Аннан... ничек туктатырга соң бу аждаһа кебек җикеренеп барган нәмәрсәне? Тәнзилә шулай уйларга өлгермәде, машина буа өстеннән суга сикерде. Күпмедер мизгел бушлыкта асылынып торганнан соң, ул суга чумып ук китте. Тәнзилә инде күптән рульне җибәрде, аякларын педальләрдән алды. Ул инде хуҗасы кебек үк үзсүзле машинаның бер генә нәрсәсенә дә кагылмый. Ләкин ул һаман кая бара соң? Ачык тәрәзәдән кергән су янында утырган кызны — Гамилнең апасын каядыр өскә алып менеп китте, Тәнзилә бер үзе калды. Агым аны да кыса. Менә инде ул авыз-борынны томалый. Тын алып булмый. Кыз әллә кая, су асты патшалыгына чума. Әкияттәге шикелле. Патша малае шулай чумган бит... Ләкин Тәнзилә патша малае чумган тирәнлеккә үк төшеп җиталми. Аның толымнарыннан ниндидер көч тарта. Тәнзилә баштан сизелер-сизелмәс кенә, аннары тизрәк-тизрәк өскә таба йөзә. Кемнеңдер көчле, ышанычлы кулы аны өскә әйди. Кыз өскә чыгып җиткәч, күк йөзе зәңгәрлеген күргәч тә аңын югалта. Әмма үзе барысын да белеп, ишетеп ята, имеш. Әнә этисенең тавышы. Кеше алдында ук бәргәләп ташламаса ярар иде, дип уйлап куя Тәнзилә. Этисен аның янына җибәрмиләр. Болай булгач, аңа эләкмәс, ахры. Ул арада кемдер аның кулларын бер күтәрә, бер төшерә башлый. Ясалма сулыш алдыралар инде, ди, кыз. Ниһаять, кыз тирән сулыш ала. Күкрәгенә салынып төшкән толымнарын кемдер рәтләбрәк куя. Тәнзилә куркып кына бер күзен ача. Керфекләр арасыннан гына карый. «Булды, егетләр, булды. Үтте.» диләр. Тәнзилә тавыш иясен таный. Гамил бу, аның тавышы. Тәнзиләгә рәхәт, бик рәхәт. Аның авыр уйлары берьюлы онытылды. Бөтенесе ап-ачык, имеш. Вазыйфка да җавап бирергә кирәкми. Гамил янәшәдә. Гармун тавышы ишетелми...

Тәнзилә аңына килә алмыйча әле тагын байтак вакыт азапланды. Нинди саташу соң бу? Аның күкрәгендә ниндидер авыр нәрсә бар? Аның чәч толымнарын кемдер сыйпый түгелме соң? Әллә һаман төш күрәме? Нишләп төш булсын ди? Әнә ич кызыл әтәч ишегалдында гайрәт чәчеп йөри. Әнисе тавыкларны чакыра. Тәнзилә тәмам исенә килде кебек. Күкрәгендә кемнеңдер башын күрде. Куркуыннан ни әйтергә белми телсез калды. Аннары яткан җирендә әкрен генә өскә таба шуышты. Баш уянып китте, күтәрелеп Тәнзиләгә карады. Аның күзләре шундый таныш, шундый ягымлы, шундый шатлыклы күзләр иде... Тәнзилә, үз-үзен белештермичә, Гамилен каты кочаклап алды, үксеп-үксеп, сулкылдап-сулкылдап еларга кереште. Алар шулай кочаклашкан хәлдә йоклап киттеләр, өсләренә ябучы да булмады...

Иртәнге унберенче сәгатьтә кызын уятырга дип керсә, Тәнзилә әнисенең исе китте, акылы бетте. Ул беравык тын алгач кына:

— Бәрәч, Гамил кияү, син түгелме соң бу? Ходаем, акылымнан гына яздырма, акылымнан гына яздыра күрмә,— дип кабатлый-кабатлый ишектән арты белән чыгып барганда бусагага абынып чүт кенә имгәнмәде...

## 2

Мирбат абзый бу көннәрдә уракка төшү хәстәрен күреп мең дә бер шөгыль белән йөри иде. Бер китсә, китә бит ул. Моңарчы шаулап-гөрләп барган эшләр быел нишләптер тыгыла башлады.

Язгы ташу вакытында Габделҗан тракторы белән суга төшеп үлде. Тикшерүчеләргә тракторчы елганың аръягында калган тракторын бу яктагы паркка үз белдеге белән алып чыкмакчы булган дип әйттеләр.

Моның белән берьюлы ике куян аттылар. Беренчедән, тракторчының үлемендә колхоз председателенең гаебе юк, икенчедән, тракторчы үзе дә гаепле түгел, чөнки яхшы ният белән эшләгән: кар эреп, җир кипшенә башлагач та кыр эшләрен башларга трактор кирәк булыр, дип фикерләгән. Әгәр дә трактор хәтле трактор теге якта утырып калса, күпер салынып беткәнче тик торган булыр иде, янәсе. Ләкин Мирбат абзый үзенең вөҗданы алдында болай килештереп алдаша алмый, чөнки белә: ул гаепле. Тракторчы Габделҗан иртән иртүк правлениегә килеп керде дә елгада су күтәрелгәнен әйтте. Су бозны да күтәргән иде. Ә боз белән күпер субайларының да күтәрелү ихтималы бар. «Субайлар тирәсендәге бозны ватарга, бәкеләр ясарга кирәк, Мирбат абзый» дип тракторчы моңарчы да председательне берничә мәртәбә кисәткән иде. «Йомырка тавыкны өйрәтми» дип мыгырдады ул чагында председатель. Ә боз чабарга нәрәт бирмәде, исеннән чыкты. Шуңа карамастан, тракторны «хет күтәреп» чыгарга кушты. Кем белгән бит бер буй субайлары күтәрелгәнне — «ДТ» килеп кергәч, күпер янтаеп трактор суга чумган... Габделҗанның баласына, ата-анасына пенсия билгеләделәр. Шуның белән бетте. Инде урак өсте борын төбендә, ә трактор әле дә булса ремонтланмаган, паркта тора, тракторчылар җитми. Өч кешене укырга җибәргәннәр иде җибәрүен, алар кайчан бетереп кайтыр әле?

Кичә райком бюросында шелтә чәпәп җибәрделәр. Гомердә булмаганны. Мирбат абзыйның колаклары гына түгел, үзе әйтмешли, бөерләренә хәтле кызаргандыр. Кызармыйни, борын аслары әле генә кипкән «малайлар» алдында шулай хур итеп җибәрсеннәр әле. Аның бит әле беренче секретаре да шулар яклы. Институт, техникум бетерәләр дә үзләрен әллә кемгә санап йөри башлыйлар. Ата-баба күрмәгән-ишетмәгән ысуллар белән иген игәргә исәплиләр. Эх, Александр Васильевич беренче чакта шәп иде. Мине ике сүздән аңлый торган иде ул. Аның урынына рәтләп мыек та чыкмаган берәүне китерделәр. Обкомда инструктор иде бугай. Яшь булса да эшне коры тота. Алай-болайга урын калдыра торганнардан түгел. Әнә районга килер-килмәс борын ничә председательне алмаштырды. Яшьләрне куя. Әйдә куй, куй. Ни эш кырганыгызны күрербез. Яз көне тракторчы Габделҗан үлгән чакта ул булса, баш беткән дә беткән иде. Болай да сораштыргалады әле. Хәзер онытты, ахрысы. Черт дери, шул «ДТ»га кемне генә куярга, тагын бер тракторчыны каян гына табарга соң? Бригадир белән механик эш арасында ремонтлаган булалар да бит. Алардан башка бүтән эш бармый...

Мирбат абзый тамак ялгап алырга шундый уйлар белән кайтты. Капкадан керүгә каршысына хатыны Фәндәрия атылып килеп чыкты. Картая гына да белми, ичмасам. Күр син аны, ничек җил-җил йөри, яшь килен диярсең. Авыл кешеләре «безнең председатель Мирбат абый түгел, аның хатыны Фәндәрия баш безгә» дип, юкка гына сөйләмиләрдер күрәсең. Кайда, нинди эш килеп чыкса да тыгылып-тыкшынып, колак итеп чәйни башлый. Дөрес, Мирбат абзый аның сүзләренә колак салмый салуын, тик барыбер көне-төне тугылап-тукып торсалар — кермичә булмый... Күр син аны, күр әле, черт дери, болдырдан ничек төште, ике генә атлады. Тагын нәрсә булган моңа?

Ул арада Фәндәрия йөгереп барып зур капканы япты да Мирбат

абзый янына ашыкты. Ул килеп җиткәндә генә Мирбат абзый, ат муены астыннан икенче якка чыгып, нәрсәдер эшләгән булып кайнаша башлады. Фәндәрия дә эчендәге серен кычкырып әйтергә базмыйча — күршеләрнең ишетүе бар! — ире ягына чыкты. Ниһаять, аның янына ук килеп, авызына керердәй булып, баядан бирле телен кычыттырып торган серен әйтеп салды.

— Кияү кайткан!

Мирбат абзый бераз аптырап калды. Хәбәрнең мәгънәсе аңа тиз генә барып җитмәде бугай.

— Нинди кияү? Нишләп... кайткан? — дип, үзе бөтенләй мәгънәсез сорау биреп куйды.

— И-и-и. Моның кадәр дә булыр икән. Соң, алланың факыры, синен унбиш киявең бармыни? Гамил кайткан.

— Соң әллә кайчан шулай диләр аны. Соң? Кайтса ни булган. Бетереп кайтканмы?

Мирбат абзыйның йөзе кинәт яктырып китте. Ул ирексездән елмаеп:

— Вәт молодец, черт дери, вәт молодец,— дип куйды. Аннары тагын бер мәртәбә.— Вәт молодец, малай актыгы, теле усал булса да кирәк чакта кайтып күренде. Ул бит минә дигән икенче класслы шофер да, тракторчы да. Теге тракторны ремонтларга кеше булды, черт дери,— дип эчтән генә үзе өчен дә өстәде. Аннары хатынын сискәндереп җилкәсенә сугып алды.

Мондый акыл сатудан миңгерәп калган Фәндәриянең күз аллары караңгыланып китте, ул төкрекләрен чәчрәтеп, иренең авызына керердәй булып очына ук башлады:

— Шул тракторларың белән кадалып беткәндә дә хатының, балаң турында уйламассың ахры син, алланың факыры. Шул апара мичкәсе белән чәчәктәй гомеремне заяга уздырдым, ходаем?

«Апара мичкәсе» — Мирбат абзыйга этисеннән калган кушамат. Ул хатынын тынычландырудан бигрәк, күрше-күлән ишетмәсен дип, Фәндәриясен барып кочаклаган булды.

Аннары тагын үз тугызын тугызлап сорап куйды:

— Озакка кайтканмы?

— Белмим. Мин аның белән сөйләшмәдем әле. Ул төнлә кайткан да кызыңның кочагына кереп чумган. Шул урам як тәрәзәне кадакла дип ничә әйттем — тыңламадың алланың факыры.

Фәндәриянең кирәкле-кирәкмәс урында әйтә торган «алланың факыры» авылдашларының җиңел теленнән аның үзенә кушамат булып ябышкан иде. Үзе юкта авыл кешеләре аны нәкъ шулай дип атыйлар да. Хәтта Мирбат абзый да колхозчылар арасында «теге алланың факыры» дип ычкындыргалый иде. Хәзер дә ул авызын ерып:

— Соң, алланың факыры, нәрсә булган дим. Керсә бит ярәшмәгән кызың янына кермәгән, үзенең закунный хатыны белән ята дисең әнә,— диде.

Фәндәрия мондый ваемсызлыкка түзалмыйча әйтеп салды:

— Соң, кичәгенәк югары оч Вазыйхы килгән иде бит. Ул бит безнең Тәнзиләне сорап йөри. Мин сиңа ничә әйттем, ходаем. Булса да булыр икән «алланың фа...» — шул урында Фәндәрия сүзен кырт кисте:

— Теләсәң нишләт, үзең риза булып кызыңны шул үксез бозаугa бирдеңме, хәзер инде үзең аерып ал.

Мирбат абзый да бу хәтлесенә түзә алмый иде.

— Соң, «алланың факыры», акылыңдамы син, юкмы? Бер биргән кызны нишләп аерырга, ди. Ире аерса, бер хәл иде... Алар бит әнә ал да гөл тордылар. Кияү армиягә киткәч, кызың маена чыдый алмыйча иләсләнә башлаган икән, анда синең гаеп. Аның колагына җыен юкбарны көне-төне син тукыйсың. Җиттеме сиңа, наконец, юкмы,— дип

дулап китте Мирбат абзый,— син минем җилекне аз киптермәдең бит инде... черт дери. Аерылышу белән уйнарга яратсаң, менә үзеңне...

Биек болдырда Гамил белән Тәнзилә күренде. Алар элеккечә үк кулга кул тотынышып, җилкәләренә озын сөлгеләр салып су буена юынырга төшеп баралар иде.

Ире ныклап дулый башлауга болай да «шып» булган Фәндәрия кияве белән кызы күренгәч, бөтенләй «мескен» булып калды. Кулын алъяпкыч астында гына уйнатып, ул иренә «тукта инде, тукта» дип ишарәләде. Аннары кырын-кырын гына баскалап келәткә кереп китте. Гамил исә бабасының соңгы «монолог»ын ишетсә дә, берни булмагандай:

— Нихәл, бабай, исән генә йөреп, колхозны җиңеп буламы? — дип ике куллап күреште, бабасының атын туарышырга тотынды. Тәнзилә әнисе артыннан келәткә кереп китте. Мирбат абзый, киявенең күзләренә карамаскарак тырышып, тарантас тирәсендә эшен бетерде.

— Ничего, кияү, бара. Сынатырга исәп юк әлегә.

Аннары Гамилнең таза-нык тәненә карап:

— Син соң ничек болай, кияү, кайтып килергә уйладың? Отпуск бирделәрме дисәм... — дип сорады.

Үзе күз кырыйлары белән, каш астыннан гына карап киявенең йөзен күзәтте: ишеткәнме, юкмы? Бераздан кияве өйгә чакырды. Ләкин утыз елга якын колхоз председателе булып йөргән бу кеше сүздә дә үз эшеннән озын-озак аерылып тора алмады:

— Син, Гамил кияү, иллә-мәгәр бик вакытлы кайттың әле. Ишеткән булсаң, Габделҗан быел күпердән елгага төшеп һәлак булды бит... Тракторны ремонтлап бетерә алмадык. Үзең беләсең,— урак өсте җитә,— дип зарын сөйли башлады. Гамил аның тел төбен аңлап:

— Ярый, бабай, булышырмын, ләкин мин нибары ун көнгә кайттым, аннары тракторда кем эшләр? — диде.

Председатель шатланып:

— Аннары күз күрер, кияү. Һич булмаса вакытлыча бригадирыбыз Зиннәтулла утырыр.

Кияү белән Тәнзилә су буена төшеп киттеләр.

### 3

Сәгать ярымнан Мирбат абзый белән Гамил келәт артындагы гаражда кайнаша башладылар. Анда Мирбат абзыйның былтыр алып куйган «Урал» мотоциклы тора иде. Ул үзе гомер буе диярлек трактор, машина йөртүчеләргә кызыгып яшәде. Тик колхозның менә дигән «Москвич»ы булса да авыл арасында ат җигеп йөрүен ташламады. Районга чыксалар, станциягә эш төшсә генә, анда да ерак юлга вакыт күп китә дип, шоферын чакырта торган иде. Былтыр бер мәл җенләнеп алган иде бу «Урал»ны. Тик Фәндәриясе буран туздырып матайга «запрет» салды. Җае чыккан саен «апара мичкәсе» дип ычкындыргаласа да, үз иренең бәясен бик яхшы белә иде ул. «Гомергә ат дилбегәсеннән башка нәрсә белән идарә иткәнең юк, матасилка хәтле матасилкага утырып мине тол калдырырга уйлыйсың бугай», дип Мирбат абзыйның авызын тиз томалады Фәндәрия.

Усал хатынның әлеге сүзләре Мирбат абзыйның мин-минлегенә каты сукты. Шул көнне үк председатель машина йөртергә өйрәнә башлады һәм, дөрестән дә, һәлакәт ясый язды. Былтыргы тайгак бер көнне Коры елга чокырына чак кына төшми калды. Бәхеткә каршы, телеграмм баганасы бу очракта «олы юлга маяк» кына түгел, председатель белән шоферының гомерен, колхоз машинасын саклап калучы терәк тә булды. «Москвич»ны төзәткәч, бик ялынып сорагач, өр-яңа «УАЗ» бирделәр.

Баягынак, Мирбат абзый сорагач, ире тапмасын дип яшергән гараж ачкычын эзли-эзли тирләп-пешкән Фәндәрия, кинәт исенә төшеп булса кирәк, иренә арты белән борылды да әллә кай төшеннән алып бирде. Иренең, бер үлемнән калгач, уңны-сулны, чокыр-чакырны карап йөрисен беләә иде. Җитмәсә, быел яз, Фәндәриянең хурлыклы сүзләрен аяк астына таптап Чистайга барып имтихан тотты, машина йөртергә хокук алып кайтты Мирбат. Тегесе ык-мык килә башласа, сүзсез-нисез генә кесәсенә тыгыла да шуны алып күз алдында уйнаткалый иде ул.

Әмма «үксез бозау»ның матасилкага утырганын күргәч, Фәндәрия кара көеп, ни кылырга, кая барып бәрелергә белмичә озак йөрде. Тик Мирбат абзый аның ни кыланганын күрмәде, ишетмәде. Кияү бу «нечкәлекләрнең» берсен дә шулай ук белми иде, әлбәттә.

Менә хәзер ул матайны гараждан чыгарды, анысын-монысын карады, маен-бензинын салды да бабасын бишеккә утыртып машина-трактор паркына китте.

Гамил белән мотоциклда барганда Мирбат абзыйның түбәсе күккә тия иде кебек. Ни әйтсәң дә үз кияве, авылда ярыйсы гына абруйлы кеше бит.

— Яшь кеше син,— диде ул,— җитмәсә нибары ун көнгә ялга кайткан ефрейтор. Әйдә, трактор төзәтеп арыгач, биленне яздырган арада шул матайга утыр да теләсәң кай тарафка чап — күрәсе кешеңне күр, барасы җиреңә бар!

Хәйләкәр Мирбат абзый, киявенә яхшылык эшләгән булып, тагын ике куянны берьюлы ата, үзенең сөекле кызын да онытмый иде: атланганы мотоцикл булгач, Тәнзиләсе янына кайтмыйча кая барсын ди ул?!

Гамилне күрү белән механизаторлар аның тирәсенә җыелдылар.

— Солдат кайткан! Күрегез әле, егетләр, китеп өлгермәде, инде отпускы да биргәннәр. Званиесы бар: ефрейтор! — диештеләр.

Мирбат абзый, мотоцикл бишегеннән төшә-төшә:

— Зиннәтулла күренсә, әйтерсез. Гамил «ДТ»ны ремонтлый башласын,— диде. Аннары Гамилгә: — Син, кияү, өс-башыңны да алыштырып кил, бу киемнәреңне пычрату ярамас, складтан комбинезон алырсың. Ремонтны тизрәк тотарга тырыш,— дип өстәде.

Председательнең «уазик» торган гараж янына таба китеп барганын карап калган механизаторлар «чәнечкеләрен» сибәргә дә күп сорамады:

— Күр, Гамил кайткач ничек сайрый. Телендә кияү дә кияү генә. Алла факырың ишетсә... телеңне тиз тешләтер...

— Ну, малай, Гамил, эшнең нәкъ өстенә кайтып төштең.

— Отпускыны нәрсә өчен бирделәр? Әллә шпиун тоттыңмы?

Арада берсе — Фәндәриянең чыбык очы, күңелле очрашу озаккарак сузылды дигәндәй:

— Берәрсе телеграмм суккандыр әле... — дип куйды.

Барлык механизаторлар авыл хәбәрләрен бөтен нечкәлекләре белән беләләр иде, нишләптер, берьюлы тынып калдылар. Гамил телеграмм турында әйтүче Мәннәфкә якын ук килеп, гимнастеркасын төзәтә-төзәтә:

— Я, Мәннәф, сүзеңне әйтеп, очлап бетер. Ник туктадың? — диде.

Мәннәф, башкаларга кырын-кырын карап, бер-ике адым артка чигенде:

— Нәрсә, «әйтеп бетер?» Мин генәме әллә? Әнә барысы да беләләр Тәнзиләңнең югары оч Вазыйх белән чуалганын. Машинасына утыртып киткәнен күрүчеләр бар...

Ул сүзен әйтеп бетерергә өлгермәде, механизаторларның берсе артыннан килеп аяк куйды, икенчесе Гамил белән Мәннәф арасыннан узган булып Мәннәфне этеп җибәрде. Теге мәтәлчек атып тәгәрәп китте.

Аңа торырга булышкан булып икенче бер егет теш арасыннан гына:
— Телеңне тый, Мәннәф,— дип пышылдады.

Ләкин соң иде инде. Эшләнәсе эш эшләнде, әйтеләсе пычрак сүз әйтелде. Әмма Гамилнең армиягә киткәнче бергә эшләгән механизатор дуслары Мәннәф сүзләрен көлкегә борырга җай таптылар. Гадәттә яшь-җилкенчәкне еларга җиткәнче үртәргә яратучы Гәрәйсәет абзый:

— Гамил бит ул синең андый сүзеңә карап акылын югалта торган кеше түгел, Мәннәфетдин туган,— диде. Аннары: — Уен сүзнең дә, егетләр, чамасы була. Уеннан уймак чыкмасын диебрәк шаяртырга кирәк. Әйдәгез, баламутлар, лафетлар янына! — дип өстәде дә чалбар балакларын кыштырдатып китеп барды.

Мәннәф сүзләре, бая бабасыннан ишеткәннәр белән бергә кушылып, Гамилнең күңел кылларын чеметеп-чеметеп алды. Ләкин ул сер бирмәскә тырышты. Складтан комбинезон алып килде дә завсклад һәм механик Насыйбулла белән «ДТ»га кирәкле нәрсәләрне барлый, исемләген төзи башлады. Запчастьлар складта икән. Шулай булгач, «ДТ» дүрт-биш көннән сафка басарга тиеш, дип карар иттеләр.

Ефрейтор Салихов җиң сызганып эшкә кереште.

4

Кияве Гамилне Фәндәрия яратмады. Моның җитди сәбәпләре бар иде.

Сугыш вакытында булды бу хәл. Ул чагында яңа гына унсигез яшь тулып узган Фәндәрия белән Гамилнең әнисе Сәгадәтбануны урман кисәргә җибәрделәр. Авылдан унбишләп хатын-кыз һәм аларга баш булып Фәхразый карт китте.

Фәндәрия авылда үскән кыз булса да шуклыгы, торма теллеге, яшьлегенә хас булмаган хәйләкәрлеге белән аерылып тора иде. Сугышның икенче елы, фронттан көн саен берсеннән-берсе авыррак хәбәрләр килеп тора. Урман кисәргә китүчеләрнең күбесе ирләрен сугышка озатып, икесе инде «публик»[1] алганнар иде. Ул хатыннар авыл Советына чакыртып урман кисәргә җибәрәбез дигәч тә каршы сүз әйтмәделәр. Нәрсә әйтәсең? Ирләребез китеп сугышта башларын куйдылар, без егерме биш яшьтән гомерлек тол калдык дисеннәрме? Алар өстенә генә төшмәгән бит кара кайгы. Башкаларны да әллә кайда калдырып читләтеп йөрми лә ул. Әнә Сәгадәтбану авыл Советында: «унбер айлык балам җитмеш яшьлек карчык кулында кала», дип авызын ачмакчы булган иде. Кая ул? Персидәтел Чәпәк Нәсыйх шундый итеп акырды, Сәгадәтбану авызын ник ачканына үкенде һәм бик тиз күнде.

Фәхразый карт үзе алтмыштан узган булса да таза сөякле ир-ат иде әле. Аның яшендәгеләр мобилизациягә эләкмәсәләр дә, алай-болай сугышка алып куймасыннар дип, хәстәрен күрде ул. Сугыш башланганның икенче көнендә колхозның типсә тимер өзәрдәй егетләрен һәм ирләрен сугышка озаткан чакта, үзчире тотып егылды Фәхразый карт. Авыз-борыныннан күбекләр атылып чыкты, селәгәйләре чәчрәде... Сугышка китүчеләр атларына менеп утырган җирдән Фәхразыйны кызганып кире төштеләр... «Нервлары кара кайгыга чыдамаган» диештеләр Фәхразыйның узганын белеп җиткермәгән кайберәүләр.

Көз көне военкоматтан язу килде. Оборона корылмалары эшенә кешеләр чакырыла иде. Фәхразый карт районга сугышка китүчеләрдән дә болайрак һаваланып барды. Күрегез, янәсе... илне сакларга үз теләгебез белән китәбез. Военкомат янына халык җыелып беткәч, теге мес-

---

[1] Үлем хәбәре.

кеннең үзчире тота башлады. Сырхавы барлыкка язу китерергә кушканнар. Илтмиме соң Фәхразый, илтә. Җир астыннан табып илтә. Әмма җир астыннан түгел, ир-атлар сугышка китеп беткәч персидәтел итеп куелган Чәпәк Нәсыйхтан пичәт суктырып алды. Кайчандыр юллары кисешкән аларның дип сөйләделәр. Шул дөрес булды бугай.

Фәхразый картның узган юлында кара таплар шактый булган.

Ул авылда кара эчлелек, кинәлелек белән даны чыккан мәзин гаиләсендә дүртенче бала булып туа. Дүрт-биш ел мәдрәсәдә сабак өйрәнеп йөргәч тә, андагы тәртипсезлекләренә түзәр әмәле калмагач, атасы аны авылдагы кибетенә, приказчик ярдәмчесе итеп кайтара. Фәхразый анда да озак тукталмый, кассадан акча урлаганда тотылып, атасы алдына баса. Оренбургтагы апасы янына җибәрәләр, алар да ике елдан артык түзми. Шул арада Фәхразый егет булып өлгерә. Беренче бөтендөнья сугышы башланыр алдыннан өйләнеп башка чыга. Дөрес, аны да сугышка алалар. Ләкин, Казандагы бер бай туганнарының тырышлыгы белән, рота мулласы итеп урнаштыралар. Анда да озак тукталмый, сугышка алып китәчәкләр дигән хәбәр тарала башлау белән, Фәхразый җаен китереп, әлеге үзчирен күрсәтә. Тикшергәндәй итәләр дә «кәҗә билеты» тоттырып кайталар.

Атасы Моксыйн егерме беренче елны — ләкин ачлыктан түгел — гүр иясе була. Фәхразыйның ярыйсы гына таза хуҗалыгы була, атасы үлгәнгә артык кайгырмый. Дөрес, гражданнар сугышы чорында Фәхразый кайдадыр югалып йөри. Ләкин, балыкта ит юк, кошта сөт юк, дигәндәй, анда да кинәндермәгәндер күрәсең. Кайта да, үз өенә бикләнеп яши башлый. Аннары... утыз беренче елның язында, һич көтмәгәндә, Фәхразыйның йорт-җиреннән көл-күмер генә кала. «Үзе ут төрткән» дип сөйлиләр сөйләвен. Ләкин район милициясенә алып китеп ике-өч көн тотканнан соң аны өенә кайтырга кушып чыгаралар икән. Авыл кулакларыннан арыну башланганда Фәхразый күрше авылдан иске каралты-кура юнәтеп кайнаша. Озакламый ул карт биясе белән кырыкмыш таен җитәкләп колхоз йортына китерә, гариза яза. Кешедән узып бернәрсә дә эшләми Фәхразый, ләкин арттагыларга да иш булмый. Шулай итеп еллар уза, элек кылган кыңгыр эшләр онытыла бара. Фәхразыйның өч улы үсеп җитә дә читкә китеп урнашалар. Ниһаять, сугыш башлана... Һәм урман кисәргә бармау исәбе дә була аның. Тик районнан хатын-кызларга башлык итеп ир җенесеннән кемне дә булса табыгыз, тапмасагыз үзегез барыгыз дигәч, персидәтел бу сүзләрне Фәхразыйга да җиткергәч, язмышын артык сынатмаска була. Башлык булып бару үзе үк начар түгел ләбаса. Алма кебек кызлар, хатыннар бара, утызга да җитмәгәннәр... Фәхразый картның сәламәтлеге һәм дәрманы турында тулы мәгълүматлы карчыгы аның мутлыгына юл ачыласын белә белүен, ләкин дәшми. Хәзерге заманда телеңне тыебрак яшәү яхшы, дип уйлый күрәсең. Һәм ялгышмый. Ире сау-сәламәт килеш кайтып төшә.

Урман кисәргә җыелган халык аз булмый. Ләкин бер колхоздан килгән кешеләр үзләре бер бригада булып эшлиләр. Асылда хатын-кызлар эшли, әлбәттә. Фәхразый карт әллә ниткән нәрәтләр, кәгазьләр белән йөри. Отчетлар язган була, карточкага биргән азык-төлекне кайтара. Бер җирдә кисәсе урман бетеп, егерме биш чакрым чамасы ары күчкәч тә урман кисүчеләрне авыл мәктәбенә урнаштыралар. Фәхразый карт сынатмый — үз бригадасына җылы бүлмә эләктерә. Бер класс бүлмәсенең артында икенче, тагы да кечерәк, чолан кебегрәк бүлмә бар икән. Шунда кереп оя кора ул. Нәчәлнек кеше бит! Шуннан соң ул үз азгынлыгына азык эзли башлый да инде. Әлегрәк тә хатыннарның кылларын чиерткәләп йөргән бабаң, инде бөтенләй йөгәнсезләнә.

Беренче корбаны итеп Сәгадәтбануны сайлый ул. Бу хатын аның күңелен күптән кытыклап йөргән икән. Авылда чакта да ул узып китсә

чекерәеп карап кала, таныш-белеш ирләр алдында булса, бер-ике чәнечкеле сүз әйтә, һе-һе-һе дип, көлгәндәй кыланган була.

Урман кисүчеләр иртәнге ашны таң белән ашагандай булып чыгалар да шуның белән кичкә хәтле эшлиләр. Дөрес, көндезге өчләр тирәсендә үзләре белән алып килгән икмәкне иске чиләктә кайнаган су өстендә «яңартып» учак көлендә пешкән бәрәңге белән тамак ялгап алалар. Кичен исә бөтен бригадага аш пешерелә — аны көн саен берәү иртәрәк кайтып өлгертеп куя торган була.

Дежур көнне бүлмәләренә кайтып керү белән күңеле шомлана башлый Сәгадәтбануның. Авылдан хәбәр әсәре дә юк, ичмасам. Аның бит почтасы да «йөриме — йөри» генә ул чакта. Хатлар айга якын килә. Улы Гамил ни хәлләрдә икән? Сәгадәтбану, бәрәңге алырга дип, шундый уйлар белән Фәхразый карт «кантурына» керә. Һәм... кечкенә бүлмә ишеген ачып җибәрүгә, аның борынын ярып аракы исе килеп бәрелә. Аннары шактый кызмача карт үзе күренә. Сәгадәтбану күңеле нигә шомланганны шул секундта ук сизеп ала да артка чигенә. Ләкин Фәхразый карт аның юлына аркылы төшеп:

— Сәгадәтбану наныем, кешеләр туңып урман кискәндә син менә монда кайттың. Әле тагы ике сәгать эшлисе бар. Телисеңме мин сине пастаянный дежур итеп куям, ә? — ди дә, кулын Сәгадәтбануның җилкәсенә куя.

— Ал кулыңны, кагылма, Фәхразый абзый. —Хатын чыгарга җай эзли иде. Ләкин тар бүлмә ишегендә Фәхразыйның кызарган күзләре ялтырый.

— Нигә, Сәгадәтбану? Ирләрегез барыбер сугыштан кайтмас. Күрәсең әнә, мимеч ничек килә. Без кискән утын белән танкыларга каршы торып булмый, наный. Әйдә, кил, икәү генә сөйләшик тә... беркем белмәс...

Бу кабәхәтлеккә башта аптырап кала Сәгадәтбану. Аннары, Фәхразый картның тырпайган куллары күкрәгенә үрелә башлагач, кулындагы кастрюле белән бар көченә кизәнеп тегенең битенә суга да, карт битен тотып иелгән арада, «кантур»дан чыгып та китә.

Авылдашлары кайтканда Сәгадәтбануның ашы пешмәгән була, ә үзе болдырда туңып, елап утыра икән. Хатыннар, бер нәрсә сорамыйча да, эшнең нәрсәдә икәнлеген төшенәләр. Алар, бөтенесе бергә кереп картның якасына ябышалар. Хатыннарга кул сузмаска ант иттереп, аны «кантурына» кертеп биклиләр. Иртәгә үк начальствога әйтергә булалар. Моны ишетеп торган Фәхразый хәвефкә төшә, ялына-ялвара башлый... Киң күңелле авылдашлары аны бу бәладән дә коткара. Тагын бер ай чамасы тыныч кына эшлиләр. Ниһаять, кичке ашны пешерергә Фәндәрия йөри башлый. Хатыннар баштарак моңа игътибар итмәсәләр дә, тора-бара хәл кискенләшә. Фәндәрия эшкә килгәч ашаган ашын, эчкән суын — барысын бергә коса башлый. Бите-башы үзгәрә. Хатыннар моның нәрсәдән икәнен бик төгәл чамалыйлар. Ә бит Фәхразый карт аңа чыбык очы тиешле кеше. Шуңа күрә дә хатыннар Фәндәрияне шикләнмичә җибәрә иделәр. Ә көннәрдән бер көнне Фәндәрия эшкә чыкмый: авырыйм дип, урында ятып калды. Була торган хәл. Ләкин кичен кайткач хатыннар хушсыз калалар: Фәндәрия кыймылдый да алмыйча кан эчендә ята...

Шул ук көнне Фәхразый карт югарыдан килгән кешеләр алдында үзчире тотып егыла. Аңа авылга кайтып китәргә рөхсәт кәгазе бирәләр. Бригадир булып Сәгадәтбану кала.

Игезәк балалар кебек бер-берсенә охшаш салкын көннәр үтә тора. Урманда да яз сулышы аңкый башлый. Көннәр җылына. Фәндәрия акрынлап булса да терелеп аякка баса. Аның өчен иң күп кайгырткан кеше Сәгадәтбану булса да, ни хикмәттер, Фәндәриянең үз «җан саксызына» яман нәфрәт белән каравы ачыктан-ачык сизелә. Ләкин авыл-

га кайтканда ул элеккеге кебек үк шук-шаян, шундый ук торма телле кыз була. Шул араларда ук яраланган Мирбат та сугыштан бөтенләйгә кайтып төшә. Тагын ике-өч атнадан Мирбат белән Фәндәриянең туйлары була.

...Еллар үтә бирә. Сәгадәтбану егерме биш яшендә ничек тол калса, шулай гомер уздырды. Аннары, МТСлар бетерелгәннең өченче елында, атна-ун көн генә чирләп ятты да, дөнья белән хушлашты.

Кызы Тәнзиләнең Сәгадәтбану малаена ябышып чыгуы турында хәбәр Фәндәрияне җеннәрен чыгарып кабарындырды. Үзен-үзе кая куярга белмичә күтәрелеп бәрелде ул. Килешү аңа үлем кәгазенә кул кую сыманрак бер нәрсә булып тоелды. «Ни звирлегем бар, шуны, үз кызымның кемгә чыгасын белмичә калдым», дип көне-төне тиргәде үзен. Беркөнне чишмәгә барганда нәкъ шулай чәпчи башлагач та, теге вакытта бергә урман кисәргә баручы, Сәгадәтбану кебек үк сугыштан соң тол яшәп гомер уздырган Гөлгенә аңа:

— Ни чуртыма болай гайрәт чәчәсең әле, Фәндәрия? Кызың үзеңнән уздырды, тик аның эше чистарак, сөйгәненә ябышып чыкты,— дигәч, мәрткә үк китеп кайтты сыман ул, чишмә янында бүтән кеше булмаганга мең шөкер кылып өенә ашыкты... Ләкин ант итеп сүз бирде:

— Шул коммун Гариф кызы Сәгадәтбану малае белән үз багалмамны яшәтсәмме, яшәтсәмме — исемем Фәндәрия булмасын,— диде.

## 5

Гамил трактор янында караңгы төшеп болтлар, шөрепләр күренми башлаганчы кайнашты. Аннары ачкычларын җыеп тартмага тутырды, юынды-чистарынды да бүрәнә өстенә утырып тәмәке кабызды. Ни әйтсәң дә, күңеле тыныч түгел иде аның. Беркөнге ике кешедән ишеткән бер-берсе белән бәйләнешле агулы сүзләр тынгылык бирмиләр иде. Тәнзилә белән өйләнешергә сөйләшкән чакта алар: гайбәт сүзләреңә ышанмаска, булганнарны яшермәскә! дип сүз куешканнар иде. Тәнзилә белән ачыктан-ачык сөйләшергә кирәк. Ул яшермәс.

Менә ул тагын мотоцикл кабызды. Аның әллә ничә ат көчле моторыннан чыккан тонык тырылдавы ерак-еракларга ишетелеп таралды. Фаралары да көчле якты сибә. Трактор яныннан әйләнеп узды да, кунак-ефрейтор авыл ягына борылды. Ферма яныннан үтеп Озын күпер буена килеп төште, бераздан Тәнзиләләр урамына барып керде. Фара уты егерме йортлы урамны буеннан буена диярлек яктыртты.

Бүрәнәләр өстенә утырган яшьләр туры бәргән бу яктылыктан кинәт чагылган күзләрен бер мәл томалап торды. Гамил алар янына килеп мотоциклының руль терсәген сул яккарак авыштырып куйды, ләкин утын бөтенләй сүндермәде — якынга төшә торганын калдырды. Кунакка кайткан авылдашлары белән бөтенесе берьюлы исәнләштеләр. Гамил исә барысына да кул биреп чыкты.

— Менә ичмасам, Гамил!

— Танымассың да...

— Генерал...

— Син, малай, бик тиз кайттың әле, әллә куып җибәрделәрме?

— Кусалар, лычка бирәләр ди.

— Артеллирис. Эмблемаларын күр: аркылы-торкылы ике көпшә...

— Белдең дә, нишләп «артеллирис» булсын — артиллерист диген.

— Әйдә, малай, сөйлә әле, ничек ефрейтор ясыйлар икән, ә? Кызыктыр анда — Армиядә...

Гамилнең карашы бүрәнәләр өстендә ике рәтле гармунын кысып утырган Вазыйхка төште. Армиягә киткәнче дус иделәр. Дөрес, Вазыйх алданрак китте. Ул өч яшькә олырак иде. Аның күрешергә төшмәвен-

нән үк баягы сүзләрнең күпмедер күләмдә дөрес икәнлегенә ышанды Гамил.

Ул егетләр белән тагы берәр «солдатский»ны тартты да мотоциклын кабызып тормыйча гына Тәнзиләләр капкасы төбенә илтеп туктатты. Ут бар, димәк, Тәнзилә өйдә.

Гамил өйгә кергәндә Фәндәрия апаның котыруы соңгы чиккә җиткән чак булып чыкты. Ул өстәл кырындагы урындыкка чәч толымнарын салындырып-туздырып утырган кызына җикеренеп-җикеренеп кычкыра. Тәнзилә ишек ачылган тавышка күтәрелеп тә карамады. Гамил барысын да аңлады. Ул ныклы адымнар белән Тәнзиләсе янына килде.

— Ни булды, Тәнзилә?

Тәнзилә дәшмәде. Аның җилкәләре сизелерлек калтырый иде.

— Ни булды, дим,.Тә...

Гамил сүзен әйтеп бетерә алмады. Әбисе Фәндәриянең теш арасыннан ыжгырып чыккан берсеннән-берсе агулырак, кеше ышанмаслык нәфрәт белән әйткән сүзләрен ишетте.

— Нәрсә булдымы, һәй... Нәрсә дә булмады... алланың фа... Нәрсә дә булмады. Син кияү кеше менә армиядә фрәйтер булып йөрисең... Без монда син кайтканчы киңәштек-сөйләштек тә, үзебезнең кызыбызны аерырга, синнән алырга булдык. Менә шул. Ә бу — җир бит, шуны белә торып, кичә сине кочагына керткән. Син инде нитмә, канәт, күңеленә авыр алма, кит чыгып. Кайту белән үк әйтербез дигән идек тә, Мирбат бабаң... Мирбат абзыеңны беләсең бит: колхоз эшенә кушканда гына акыра белә. Ә Тәнзиләнең яратып йөргән кешесе дә бар...

Гамил усаллыгыннан кара көйгән, әллә кайчангы, Гамилнең әнисе Сәгадәтбану алдындагы гына түгел, ире, кызы алдындагы гаебеннән дә арына алмыйча буылып йөргән хатынның ачулануын Тәнзиләсе алдына тезләнгән килеш тыңлады. Борынгы заман кыргыйлыгын күрсәтеп дулаган бу хатынга бер сүз әйтә алмады ул. Бары тик бугазына килеп тыгылган каты төерне йотып җибәргәч кенә, Тәнзиләсенең битен каплаган кулларын тотып:

— Бу ни дигән сүз, Тәнзилә? Зинһар, аңлат? — диде.

Тәнзилә тагын дәшмәде, тик сулкылдавы гына көчәя төште.

— Тәнзилә дим, Тәнзилә... Әйдә чыгабыз моннан! Урамга. Анда аңлашырбыз... Бу тынчуда сулавы кыен.

— Чыга ди, чыкмыйчарак торсын әле. Бер тапкыр чыкты инде...

Бу хатын белән сүз көрәштерүдән файда юк иде, билгеле. Гамил Тәнзиләсенең һаман шулай утыруын, аңа таба омтылыш ясамавын күреп дәшмәде, борылды да тышка, урамга, иркенгә ашыкты. Биек болдырдан ишегалдына атылып төште дә ул мотоцикл рычагына типте. Двигатель ярты әйләнештән үк кабынып китте. Кай арада, ничек менеп атланганын үзе дә белеп өлгермәгән Гамил, мотоциклның утын-ниен кабызып тормыйча, урамга килеп чыкты. Капкадан чыкканда сикерүдән, я бәрелүдән булса кирәк, фара уты кабынды һәм шул яктыда Гамил үзенең көндәше Вазыйхны күрде. Ул өй каршындагы кечкенә бакчага кереп, өйдәгеләрнең сүзләрен тыңлап торган, күрәсең, мотоцикл тавышы ишетелүгә урамга чыгарга исәпләгән, ләкин рәшәткәгә балагы эләгеп ычкына алмыйча азаплана иде. Фара яктыртып җибәргәч тә ул бар ачуы белән тагын бер тартылды һәм шул тартылудан чалбар балагы шарылдап ертылды да Вазыйх үзе урамга, ә гармуны бакча ягына мәтәлде. Гамил мотоциклының бишек тәгәрмәче белән Вазыйхны әз генә бәрдереп узып китте. Иркенгә чыккач күкрәген тутырып сулыш алды. Аннары газ биргечне ахыр чигенәчә борып, мотоциклын үкертә-үкертә дулап аргы якка — урманга таба юл алды. Анда ул, бөтен дөньясын онытып, катып калган карашын һавадагы йолдызларга текәгән килеш, урман читендәге аланлыкта шактый озак ятты. Күңеле тулы әйтеп бе-

тергесез сагыш, үпкә, ямансылау, юксыну-көенеч, моң-зар, рәнҗү-ризасызлык, шелтә һәм каргыш иде аның.

Төн таңга авыша башлагач, урман тирәсе салкынчаланып китте. Юк, өшемәде Гамил. Аның җаны өши иде. Ә бит ул бу караңгы бушлыкка шул салкынлыктан качып япа-ялгызы килде. Тирә-як инде якындагы агачлар да күренмәслек булып караңгыланды. Таң алды караңгылыгы төште бугай. Гамил ни эшләргә тиеш иде соң? Беренче уй — моннан тизрәк китү уе булды һәм шул минутта документлары белән юл кәгазьләренең чемоданда икәне кылт итеп исенә төште. Аннан соң бу мотоцикл — аны да урман буенда калдырып китеп булмый. Яшьтән үк тимер-томырны яратып, юлда очраган тутык тимер кисәген дә алмыйча калдырырга яратмаган механизатор кеше ничек итеп мотоцикл хәтле мотоциклны урман буенда ташлап калдырсын?!. Аннары тагы трактор-ны да сүтеп ташлады бит әле. Ә колхозда эшкә кушылмаган бер генә механизатор да юк. Әгәр Гамил аны шул көенчә ташлап китсә, авылдашлары ни әйтер? Карчык-корчыклар көтү куа башлаганчы паркка кайтырга кирәк. Аннан соң... Аннан соң Гамил Тәнзиләнең фикерен дә ишетмәде бит әле. Аның белән тагы бер сөйләшергә тиеш ул... Ләкин паркка кайту өчен авыл аша мотоциклын тырылдатып узарга кирәк. Көтү куучылар күзенә чалынмыйча узу һич мөмкин түгел. Аннары бөтен авыл, чынын-гайбәтен бергә кушып, «чебеннән фил» ясарга керешәчәк.

Гамил мотоциклын кабызды да урман буендагы юл белән күрше чуваш авылына төште, аннан тегә яктагы урманга менде һәм тагы урман буйлап барып авыл кырыенда урнашкан отрядка кайтып керде. Ул, трактор янына туктап тәмәке кабыза башлауга, кемнеңдер тавышын ишетеп артка борылды.

— Иртәләгәнсең бит, солдат?

Гамил каравылчыга нәрсә әйтергә белмичә аптырап калды. Дөресен әйтеп булмый, ә алдашасы килми иде аның.

— Ишеттек, ишеттек, Гамил, әбиең Фәндәриянең шашынуларын. Төнлә Мирбат абзый монда кереп чыкты. Сине эзләп йөри иде. Мотоциклы белән кая да булса бәрелеп әрәм булмаса ярар иде дип борчылды... Ярар, әйдә бергәләп бер төтенлик әле.

Гамил белгәннән бирле каравылда торучы бу абзыйның исемен берәү дә төгәл әйтә алмый иде. Олысы да, кечесе дә кушаматы белән — Букай абзый дип йөртә. Кыен минутларда янәшәндә сердәшең булмагач, менә шушы абзый кебек эчкерсез бер кеше белән тәмәке тартсаң да күңел бушана, күрәсең. Тагын бераздан Гамилнең күкрәгенә тыгызланып тулган дуең азрак йомшарды.

Ул ял срогын бетермичә авылдан китмәскә булды.

6

Тәнзилә әллә нишләп югалып калды. Гамил кайтып төшкәч тә бер мәлгә бөтен дөньясын онытты. Әнисенең сүзләре бөтенләй истән чыкты. Вазыйх белән сөйләшкәннәр дә әллә кая китеп югалды. Болай үзе Гамилне яратып чыкты кебек, югыйсә. Әле бит ул армиягә киткәчтән дә озак вакытлар юксынды, кемнедер эзләде аның йөрәге. Тапты... Тәнзилә үзе түгел, әнисе Фәндәрия эзләп тапты. Яшь хатынның күңеле йомшарган, ялгызлыкны кичерә алмыйча азапланган бер вакытны Вазыйх армиядән кайтып төште дә өздерә-өздерә гармун суза башлады. Ямансулаган күңел әллә генә нишләде шунда. Җитмәсә, Тәнзилә яшьтән үк әнисеннән куркып, аңа каршы килергә кыймыйча үсте. Ул әнисен яратудан битәр, аның күз карашыннан, әтисе чыгып киткәч тә «яшәргә» өйрәтүләреннән курка иде. Теге вакытта әнисен тыңламыйча Гамилгә

чыкты чыгуын, ләкин Тәнзиләнең аннан соң ишеткәннәрен беркем дә белми. Гаеп Тәнзиләнең әнисендә генә түгел, үзендә дә бар. Аның иркәләнеп үскән җаны һаман үзен назлар кеше эзли торды. Вазыйх әйткән матур сүзләрнең барсы да язып барылса, алар инде әллә кайчан калын бер китап булырлык җыелгандыр. Өстәвенә тагын гармун уйнаулары... Тәнзиләгә багышлап көй чыгарам дип йөри. Әлегә җырның сүзләрен генә килештереп яза алмыйча интегә икән.

Менә бүген дә, әнисе тавыш кубарып Гамилне чыгарып җибәргәч тә, Тәнзилә үз бүлмәсенә кереп киткән иде. Гамилнең мотоцикл тавышы да тынып бетмәгән килеш, капка төбендә Вазыйхның гармуны сайрый башлады. Тәнзилә, аны ишетмәскә тырышып, башын юрганы белән томалады да урынына чумды. Ул нишләргә дә белми иде: еларгамы, елмаергамы?

Гармун озак уйнады. Тәнзилә инде урынында җылынып йокыга китә башлаган иде. Юк шул, аның әнисенең исеме Фәндәрия бит. Кайдан гына уйлап тапканнардыр?!. Авылда гына түгел, районда да андыйның ишетелгәне юк. Гармун тавышы ишетелүгә ул кызы янына керде һәм, берни булмагандай, аңа бик тәфсилләп көйләрне аңлата, шуңа кушып үзенең истәлекләрен сөйли башлады. Аннары Тәнзилә бүлмәсенең тәрәзәсен ачып куйды. Сулышка җиңелрәк булсын янәсе. Бер хәйләгә икенчесенең очын ничек шулай тиз ялгап өлгерә диген син аны?!.

Әнисе чыгып киткәч тә озак йоклый алмады Тәнзилә. Үзенә нинди таләп куелуын, әнисе аңардан нәрсә теләгәнен төшенә иде ул. Ләкин аңа тагын карышырга, сүзен тыңламаска көч юк иде аңарда. Иртәгә, әгәр дә Гамилне күрсә, аерылышу турында сүз кузгатырга тиеш була түгелме соң ул. Ә бит күңелнең ерак түрендә Гамилгә булган җылы хисләр яши әле. Тәнзилә алар турында уйламаска тырышты — бөтен җаны-тәне белән, бар көчен җигеп тырышты. Ләкин ул хисләрдән һич кенә дә арына алмады. Уйлары белән булашып ята-ята йокыга китте. Тик тынычлап йоклый алмады. Әледән-әле Гамиле белән саташты. Әле аның тракторы, әле машинасы өскә килә, «таптыйм-таптыйм» дип үкерә сыман иде...

Авыл урамнары күптән инде тынып калган. Аны бары аргы урам башындагы инеш буенда моңаеп йөргән гармун тавышы гына боза иде. Аның нәрсә сөйләгәнен кем дә аңлый алдымы икән?

## 7

Тагын дүрт көннән трактор җыелып бетте. Кирәкле запчастьлар булса да ныклап тотынып ремонтлаучы табылмаганга гына үги бала сыман читтә басып торган ул. Кичтән Гамил тракторга май һәм ягулык салды. Барлык узеллар да кабат күздән кичерелде. Тоташтыру муфтасының эше катлаулырак иде, анысына механик Насыйб та булышып китте. Аннары двигательне кабызып яхшылап обкатка ясады. Кыскасы, иртән тракторны йөртеп карарга гына кирәк иде. Фәндәрия программасы буенча эшләнгән теге «концерт» турында механизаторларның берсе дә искә төшермәде. Гамил дә онытырга тырышты — иртә таңнан алып кичен күз бәйләгәнче эшләве зур ярдәм булды аңа. Дөрес, эт этлеген итмәсә, эче авырта дигәндәй, Мәннәф бер килеп чәнечкеләр кадаган итте итүен... Ләкин Гамилнең ачулы карашын күрүгә ул да читкә борылырга ашыкты.

Иртә белән килгәч тә ашыкмады Гамил. Урында килеш моторны озак эшләтте. Чөнки белә: ашыгып кузгалудан файда юк. Шулай итеп сәгать сигез җитте. Тракторчылар бригадиры Зиннәтулла белән механик Насыйб абзый тагын килеп тракторның йөрәген врачлар шикелле тыңлап карадылар. Барысының да сүзе бер булды: двигатель яхшы

эшли иде. Димәк, йөртеп тә карарга кирәк. Гамил, тирә-якта таралып яткан бар нәрсәне җыештырып бер якка куйды да, кабинага менеп утырды. Ул дулкынлана иде. Ни әйтсәң дә, элек ул тракторда эшләгән чакта, мондый җаваплы эшләрне Гаделҗан башкара иде.

Гамил хәзер дә аның хәрәкәтләрен тәртип буенча искә төшереп нәкъ шулай кабатларга тырышты. Рычагларны тарткалап карады, тоташтыру муфтасы тәбәлдерегенә баскалады. Алар, ремонттан соң һәрвакыттагыча, бераз гына булса да я ниндидер каршылык күрсәтеп, я чтрекләнеп буйсыналар, тартылалар, аска басылалар, әмма кире җибәргәч тә үз урыннарында ыспай гына торып калалар иде. Димәк, кузгалырга ярый. Гамил тәбәлдереккә йомшак кына итеп басты да күчергеч рычагны беренче тизлеккә куйды. Газ биргәч, мотор гайрәтләнебрәк эшли башлады, трактор калтыранып алды, аннары, егет ихтыярына буйсынып, кузгалыйммы-юкмы дигән кебек, акрын гына, теләр-теләмәс кенә алга таба китте. Гусеницалар, шомарганлыктан, шыгырдап келтери иде. Трактор торган җирдән берничә адымда яткан, әллә каян килеп дигәндәй аунаган бу урында бүрәнә бүкән өстенә менде дә бөтен тәне белән калтыранып дөп итеп төште. Бүкән яртылаш җиргә сеңеп калды. Гамил үзен битәрләп алды: «Юлны яхшылап чистартмаганмын шайтан алгыры...» Икенче мизгелдә әлегә чаклы булган барлык хәрәкәтләр, вакыйгалар берьюлы онытылды. Трактор алгы тәгәрмәчләрен салдырып бүкәннәр өстенә утыртылган автомобильгә таба бара иде. Гамил, өйрәнелгән гадәт буенча, муфта тәбәлдерегенә китереп басты. Тәбәлдерек... бернинди каршылык күрсәтмичә аска батты. Бу хәл секундның уннанмыдыр, йөздәнмедер бер өлешендә Гамилнең мисен ниндидер шикле аптыраш энәсе чәнчеп алды кебек. Барысы да кирәгенчә тәртиптә иде бит! Гамил борылу рычагын искиткеч тизлек белән үзенә таба тартты. Рычаг каршылыксыз-нисез аның ике тез арасына килеп керде. Егет тагын бер тапкыр муфта тәбәлдерегенә басты, әмма ул электәге хәлендә — аска баткан килеш тора иде. Болар барысы да санаулы секундлар эчендә булуга карамастан, Гамилнең маңгаена салкын тир бәреп чыкты. Баягы мизгел эшне хәл итте. Газ биргечне иң түбән билгесенә төшереп куйгач та хәрәкәтен дәвам иткән трактор каршыдагы машинага барып бәрелде. Машинаны бүкәннәр өстеннән этеп төшерде дә дрык итеп туктап калды һәм мотор сүнде. Гамил кабинадан атылып чыкты да машина астына ташланды. Анда... алгы күпер астында Вазыйх ята иде. Гамил ашыгып шунда керде, Вазыйхның култыксасыннан алып тартып карады. Ләкин... автомобильнең алгы өлеше аның аяклары өстенә төшеп баскан иде... Гамил хәлнең хикмәтен аңлады. Һәм көчсезләгеннән, башын учлары белән кысып, җиргә утырды.

Механизаторлар аны өстерәп чыгарып бер читкәрәк бастырдылар. Вазыйхны коткару чарасын күрү башланды: домкрат җайлаган арада ук, кемнәрдер озын киртә астына баягы бүкәнне куеп машина алдын күтәрергә азапландылар. Ике-өч минут үткәндерме-юкмы, Вазыйхны да тартып алдылар. Аның аяклары изелгән, авыз-борыныннан кан килгән, йөзе чиста дәфтәр бите кебек агарган. Кайсысыдыр: «Исән бит, егетләр! Тизрәк больницага озатырга кирәк. Ярый әле жир йомшак, ату бөтенләй изгән булыр иде...» — диде.

...Гамил баскан урынында озак торды. Аңа беркем сүз әйтмәде, нигә алай дип сораучы булмады. Вазыйхны район үзәгенә, больницага алып китүче механик Насыйб абзый, үз алдына сөйләгән сыман, «Бәхетен, энем... Машина астында бүкән калган, юкса бөтенләй сыткан булыр иде...» — дип кемнедер тынычландыргандай итте.

Вазыйх белән Гамил арасын барысы да белә иде. Трактор янына берәү дә якын бармады. Дөрес, Мәннәф бер мәртәбә «трактор кабинасына күз салыйк әле, ни дә булса ачыкланмасмы, егетләр» дип өзгәләнеп карады каравын. Ләкин башкалар аңа: — Нәрсәң калган анда? Әнә

районнан тиешле кешеләр килер дә карар, син кысылма! — дигәнне ишеткәч, бик тиз авыз йомды.

Мондый чакта тегеләй дә болай дип төрлечә фараз кылу, юраулар бик күп була. Бүген нишләптер механизаторлар арасында ул-бу әйтүче булмады. Тик Гәрәйсәет абзый гына, гадәттәге шаяртуларын ташлап, үзалдына сөйләнеп йөрде:

— Эчем сизә, егетләр, монда нәрсәдер бар. Менә әйтте диярсез, бар монда штото. Нишләп Гамил тракторны туктатмады? Туктата алмаган ул. Нишләп борылмады? Күрә торып бәрдергән дисезме? Ну, шиш, Гамил андый малай түгел ул. Мин аны өстәл астында җәяү йөргән көннәреннән беләм...

Механизаторлар дәшмәде. Шулай итеп байтак вакыт узды. Төшкене ашарга кайтмадылар. Букай абзый ызбасы тирәсенә җыелышып, тәмәке төтәтеп, пошынып утырдылар да тагын техника янына таралдылар. Гәрәйсәет абзый тагын:

— Күрегез әле, егетләр. Безнең этрәткә генә мур суккан диярсең. Тагы бер егет әрәм булды. Өч ай эчендә икенче кеше бит... Бүген персидәтеле дә җәһәннәмгә олаккан, ичмасам. Тизрәк берәрсе кайтсын идеме? — дип сукранды-сукранды да, чыгырыннан чыгарга житешеп, чүкеч-ачкычларын җыештыра башлады: «Житәр пакамест, калдыкпостык бармакларны да караңгыда сугып өзәсем юк»,— дип эшен тәгәлләде. Аның артыннан бүтәннәр дә җыелып тәмәке төрделәр. Гәрәйсәет абзый күршесенә тәмәке кабызырга үрелгән җиреннән кинәт туктады да житмеш җиде катлы итеп сүгенә башлады:

— Соң, анаң тегеләй, атаң болай булгыры. Нишләп кирәкмәгән жиргә тыкшынасың син? — дип акырды ул, үзләре тәмәке төргән арада Гамил тракторында йөрүче Мәннәфкә.— Юк, тикмәгә генә җенем чыкмый минем бүген. Менә әйтте диярсез...

Гәрәйсәет абзый сүзен очлый алмады — авылның теге ягындагы тау башында Вазыйхны салып киткән машина күренде. Ул аргыяктан тузан туздырып төште дә авылга кереп күздән югалды. Биш-алты минут үтүгә исә атлар абзары артыннан килеп чыкты, парк капкасыннан керде, механизаторлар җыелган жиргә килеп туктады.

Аннан колхоз председателе Мирбат абзый белән механик Насыйб төште, алар артыннан кызыл кырпулы фуражкалар күренде. Милиция кешеләре механизаторлар белән исәнләштеләр дә, берәүгә дә парктан китмәскә кушып, Гамил тракторы янына киттеләр. Гамил алар артыннан иярде. Аның аяк атлавы авыр, башы түбән иелгән, калак сөякләре ничектер зураебрак калган сыман иде.

Гәрәйсәет абзый, егет бераз ерагайгач та: — Теләсәгез ни әйтегез, соңгы алты бармагымны кисәргә бирәм —ә дүрте сугышта, Украина далаларында калган иде — Гамил мондый эшкә белә торып бармас. Менә күпме вакыт беребез дә күтәрелеп аңа карамадык. Әйтерсең, ул безнең янда түгел иде. Милиция кешеләре килеп төшкәч тә исем киттечигә чәчләренә ак суккан бит егетнең... — дип сөйләнеп калды.

Күпләр моны ишетмәде, ләкин Гәрәйсәет абзыйның сүзләре хак иде. Бизмән күтәрерлекме соң ул авариядән соң узган берничә сәгать эчендә Гамил кичергәннәр. Юк, үзенә ул-бу булыр дип кайгырмады егет, алай түгел. Ул Вазыйх язмышы, аның исән-саулыгы өчен кайгырды. Алар бит бергә уйнап үскән малайлар. Гамил, чыннан да бүгенге һәр адымын, барлык хәрәкәтләрен, иртән килгәч тә трактор янында кылган эшләрен ничәнче тапкыр барлап чыкты. Барысы да дөрес иде. Тоташтыру муфтасын кичә Насыйб абзый белән бергә эләктерделәр. Борылу рычагларын үзе тоташтырды. Нишләп соң шуларның берәрсе кинәт кенә эшләмәс булды икән? Бу сорауны ул үзенә-үзе бәлки инде меңенче тапкыр кабатлыйдыр. Ни өчен муфта тәбәлдерәге аска төште дә батты? Ныгытты, ныгытты бит ул аны! Кузгалып киткәндә үк бит әле тизлекне

тоташтырды. Башта беренче, аннары икенче тизлеккә күчерде. Вазыйх машинасына чаклы сигез-тугыз адым ара бар иде. Әлбәттә, борылып өлгерергә була... Ә менә Гамил тракторын бора алмады. Рычагны үзенә тартканда ук аның гадәттәгедән җиңелрәк килүен тойды. Шул аның аңына тиз генә барып җитмәде? Трактор хәтле трактор белән мондый могҗиза була димени? Юк, монда нәрсәдер бар?! Дөрес, Гамил борылу рычагын тарткач та бераз югалып, каушап калды. Ләкин бу шул хәтле тиз һәм көтмәгәндә булды. Шушы мизгел әнә эшне дә хәл итте... Ичмасам, Вазыйх турында берәр сүз әйтсеннәр иде. Ник барысы да авызларына су капкан кебек йөриләр соң? Әйе, Гамил белән сөйләшергә ярамыйдыр... Ни әйтсәң дә, нинди генә сәбәпләр эзләсәң дә син гаепле, Гамил. Син таптаттың, икенчедән... бөтен авыл белә, көнләштең.

Милиционерлар, РТСтан килгән тагы берәү трактор тирәсендә озак кайнаштылар. Кабинага да күтәрелделәр, трактор астына да төштеләр. Ләкин аларның нәрсә язганы, нәрсә караганы Гамилне бөтенләй кызыксындырмый иде. Ул, җаен туры китереп, Насыйб абзыйдан: «Вазыйх ни хәлдә?» — дип сорады. Механик, каш астыннан гына карап: — Җаны тәнендә әле,— диде. Бу кырыс өч сүз Гамилдә ниндидер өмет уятты. Ә аңардан сорауны иң соңыннан, барлык механизаторлардан сораштырып бетергәч кенә алдылар.

8

Ул, милиционерлар утырган бүлмәгә кереп, тик ике генә сүз әйтте:
— Гаепле мин...
Ян тәрәзә янында утырган Мирбат абзыйга бу ошамады.
— Гаепле икәнеңне болай да беләбез, син... син... нишләп шуны эшләдең, кияү... энем, нишләп?

Гамил бүлмәдәгеләргә: Мирбат белән Насыйб абзыйга, милиционерларга тагы бер күтәрелеп карады, ләкин бүтән сүз әйтергә теле әйләнмәде. Сорау алу гаҗәп тиз бетте. Күрәсең, мәсьәлә ачык булган. Язган беркетмәләренең һәр бите астына Гамилдән һәм Мирбат абзый белән механиктан кул куйдырдылар да, милиция вәкилләре Гамилне алып районга киттеләр.

Машина авыл уртасындагы Гаделҗан төшеп үлгән зур күперне узган чакта чишмәдән кайтып баручы Тәнзилә күренде. Ул, Гамилнең машинада икәнлеген күргәч тә, җилкәсендә көянтә-чиләк барын онытып бер адым ясады. Чиләкләр дөпелдәп җиргә төште дә су тузанлы туфракка түгелде...

Икенче көнне иртүк милиция бүлегенә районның хәрби комиссары килеп керде. Кичәге милиционерларның берсе Гамилне алып чыкты. Ефрейтор, каршысында торган подполковникны күргәч тә, күнегелгән гадәте буенча, бил каешын рәтләмәкче иде дә куллары бил турысында гимнастеркага, әйтерсең, ябышкан хәлдә хәрәкәтсез калды, күзләре идәнгә төбәлде.
— Исәнмесез, иптәш ефрейтор?
— Исәнмесез...

Янәшәдә басып торган әлеге милиционер подполковникка мөрәҗәгать итепме, әллә үзалдына гынамы, әйтеп куйды:
— Гражданин...
Подполковник тиз генә аңа карап алды да, янә ефрейторга борылып:
— Ничек булды соң бу эш, иптәш Салихов? — диде.
Ул Гамилнең чаларган чигә чәчләрен күргән иде инде. Шуңадырмы, әллә үзенең шактый еллар хәрби хезмәттә төрлесен күргән йөрәгенә

каршы кила алмыйчамы, битараф кала алмады: «Ничек булды соң, ефрейтор?» — дип тагы бер кат сорап куйды.

Гамил аның тавышында кызгану төсмере барын сизеп, тамагына килчәдән бирле тыгылып торган төерне йотарга тырышып карады, ләкин булдыра алмады, аннары, подполковникның җавап көтеп торуын күргәч:

— Белмим, иптәш подполковник, белмим... — диде.

Хәрби комиссар, ефрейторны милиционер белән калдырып, икенче катка менә торган агач баскычка юнәлде. Андагы бүлмәдә милиция начальнигы утыра иде. Озакламый алар агач баскычны шыгырдатып икесе бергә түбән төштеләр. Милиция майоры кулындагы папканы подполковникка тоттырды да Гамил янәшәсендәге сержантка:

— Ефрейторның әйберләрен чыгарыгыз,— диде.

Сержант теләр-теләмәс кенә подвалга төшеп китте. Гамил, хәле хәл булуга карамастан, «күр син аның селкенүен, приказ үти бит» дип уйлап, армиядәге иптәшләрен искә төшереп алды. Сержант аңа бил каешын, кулъяулыгын, бер «Север» папиросын һәм бер кап шырпы кертеп бирде. Документлар юк иде. Гамил, каешын тиз генә каптырды да, подполковникка карап:

— Тартырга рөхсәт итегезче, иптәш подполковник,— диде.

— Әлбәттә, тартыгыз, тартыгыз, ефрейтор.

Хәрби комиссарның мөгамәләсе бөтенләй хәрбиләрчә түгел сыман тоелды Гамилгә.

Алар хәрби комиссариатка киттеләр. Милиция сержанты капка төбенә чыгып озатып калды. Шул ук көнне почта китергән самолет Салиховны Казанга алып китте. Хәрби Комендатураның дежурный ярдәмчесе аны самолет янына килеп каршы алды. Шулай итеп, китүләренә бер ел тулмас борын, Гамил янә Казанга килеп төшә.

Былтыр олы урамнар буйлап сигез рәтле сафта вокзалга узуларын хәтерләде Гамил. Ул чагында күңел күтәренке, һәр яңа көн яңа тәэсирләр өсти иде. Ә быел... Ефрейторны гауптвахтага керттеләр. Бил һәм чалбар каешын, милициядәге кебек үк, дежурный алып калды. Папирос белән шырпыга тимәделәр. Тартсын егет, йөрәген бастырсын, диделәр бугай. Кичкә хәтле аның янына керүче булмады. Бөтен яктан да биек таш дивар белән уратып алынган ишегалдына караңгы төшә башлагач кына килде дежурный. Ефрейторны ашарга чакырдылар. Дежурный, ефрейторның «ашыйсым килми» дигәнен үзенчә аңлап:

— Син, ефрейтор, кем әйтмешли, кандала үчен туннан алма, яме? Аша, тамагыңны туйдыр. Солдат башына нәрсә төшмәс,— диде. Бераз выктан ул тагын әйләнеп керде: — Ишеткәнең бармы, ефрейтор, хәрби хезмәттә булып кайткан агайлар нәрсә диләр? — дип сорады. Гамилнең җавап бирмәсен аңлагач үзе үк әйтте: «Солдат иртә ир була!» диләр алар, туган. Так что, әйдә — аша, тук бул. Гел болай тормас, үзгәрер әле хәлләр...

Ефрейтор дежурныйның сүзен тыңлады, бик үк теләмәсә дә ашады-эчте. Тарихи истәлекләре, театрлары, парк-бакчалары белән әллә кайчаннан Гамилнең күңелен җәлеп иткән шәһәр өстенә караңгы төште. Ә тыштa бөркү иде.

Ефрейтор ирексездән үзе берничә көн генә хезмәт иткән дивизионны искә төшерде. Анда ничекләр икән? Бәлки сугышчан дежурга баскан-нардыр. Аларга, әлбәттә, ефрейтор Салиховның «җинаяте» турында хәбәр итәрләр. Ул кәгазьне капитан Гаврилов алыр, аннары командирга җиткерер. Ә бит алар яңа килгән кече командирларга шат иделәр. Капитан Сергеев та белер. Укыту подразделениесенә дә язып җибәрерләр...

Болай да тулышкан күңелне авылдагы хәлләр искә төшеп бөтенләй таштырды. Стенага ныгытып беркетелгән топчанга сузылып яткач

елыйсы килде егетнең. Энисе үлгәндәгечә итеп... Кыен вакытлар булмады түгел, булды, әмма моның кебеге... Күз яше кибәр ул, ләкин тамак төбендәге төер бетәрме? Авылдашлары аның турында ни уйлыйлар икән? Үч алучы, көнче диләрдерме? Юк. Ул үзенең Тәнзиләсен саклап калачагына ышана иде. Чөнки ярата иде ул аны. Ә яраткан кешеңә хыянәт итүләре... Ә Вазыйх... Алар бит бергә үстеләр. Вазыйхларның бәләкәй өйләрендә кышкы көннәрдә экиятләр сөйләшеп... Армиягә китәр алдыннан бергәләшеп кызлар янына йөрделәр... Шул чак Гамилнең хәтеренә күптәнге бер вакыйга килеп төште: сугыштан соңгы еллар. Гамилнең энисе калдык-постык икмәк кисәкләреннән сохари киптереп капчыкларга тутыра да ишегалдына асып куя иде. Гамил ашыйсы килгән саен кереп шуннан теләгән хәтле ала. Беркөнне Вазыйх белән бергә кайттылар. Икесенең дә яраулары килгән чак булган, күрәсең, бишмәт кесәләренә сохари тутырып тагын бозлавыкка китәләр. Шунда икесе дә кытыр-кытыр сохари кимерә, икесе дә уен кызыгыннан кетер-кетер көлешәләр... Инеш өстендәге бозга төшеп җиткәндә генә Вазыйх авызын тотып кычкырып елап җибәрде. Гамил берни аңламыйча аның тирәсендә бөтерелә. Бүтән малай-шалайлар да шунда җыелды. Көчкә тынычландырдылар Вазыйхны: «Ни булды, ник шар ярып үкердең?» Теге кат-кат ямаулы бияләен ачып күрсәтте: учында ике теш ята. Сохари кимергәндә сынганнар икән... Юк, ышанасы килми Гамилнең: «Ничек итеп хәзер шул Вазыйх минем белән инде ярәшкән Тәнзиләгә күңел төшерә алыр икән? Монда Тәнзиләнең энисе, Фәндәрия — Гамилнең аның турында «әби» дип уйлыйсы килмәде — боза эшне. Әйе, энкәй дөрес сөйләгән миңа, шул Фәндәриянең мәкерле планнары бу. Барыӣ шул гына!..»

Соңгы көннәрдәге кискен кичерешләрдән бераз бушаныпмы, әллә инде «ни булса да шул булыр, көтик әле, күз күрер» дипме, Гамил үзенең йокыга киткәнен сизмәде дә. Ул уянганда ишегалдындагы асфальтта яңгыр тамчылары шыбырдашып бии, һава салкынча иде. Кичәге бушану файдасызга булмаган икән: егет тынычланган, яхшылап фикер йөртү дәрәҗәсенә килгән.

Сәгать тугызлар тирәсендә хәрби прокуратурадан тикшерүче килде. Юридик институтны бетереп яңа гына эшли башлаган лейтенант. Һәр нәрсәне икешәр, өчәр кат сорашты, ачыклады да портфелендәге кәгазьләргә караштыргалап яңаларын язды. Ашыкмады. Ефрейтор Салихов «эше» аның үзалдына тикшерә торган беренче эш икәнен соңыннан беленде. Дөрес, Гамил моңа бөтенләй игътибар итмәде. Үзен гаепле саный. Җавапны ул бирергә тиеш. Ул инде хәтта теләсә нинди җәзаны алырга да әзер иде. «Гаепле икәнсең, җәзаңны ал. Эшең белән аклан», ди иде бит аңа энисе.

Лейтенант икенче көнне иртүк тикшерүне дәвам итәргә дип авылга китте. Ә ефрейтор гарнизон гауптвахтасында калырга, аның кайтканын көтәргә тиеш, диде...

## 9

Кара хәбәр тиз йөрер, дигән борынгылар.

Фәндәрия механизаторлар отрядындагы бәхетсезлекне шул сәгатьтә үк ишетте. Тыштан кайгырган булып күренергә тырышса да, эчтән шатланды. Теге уҗым бозавы Мәннәфне әйт әле син, тәки булдырган бит... Булдыра алмас дип юри котырткан иде. Ул чагында Фәндәрия эш болай зурга китәр, уеннан уймак чыгар, димәгән иде югыйсә. Ул бит Гамилне механизаторлар алдында көлкегә калдырырга гына теләде. Шуңа күрә Фәндәрия, үзенең кара ниятен яшереп: «берәр җирен ычкындыр, беркем сизмәслек-белмәслек итеп боз әле тракторын, Мәннәф,

кузгалып китсен дә туктата алмыйча йөрсен», диде. Малай чагыннан бирле Гамилне күрә алмыйча йөргән Мәннәф, Фәндәрия апасы якын итеп әйткәнчә — ужым бозавы, аны-моны уйлап тормыйча гына...

Эш болайга киткәч Мәннәф тизрәк Фәндәрия апасы янына кинәшкә, үзен тынычландырырга дип төшкән, хәбәр китергән «алла факыры». Фәндәрия исә булачак кияве — ул инде кияү итеп Вазыйхны саный иде — һәлакәткә эләккәнен ишеткәч тә артык борчылмады. Бермәл аптырап калгандай итте, ә чынлыкта исә үзенә җил-яңгыр тидермәү ягын карады, кырын эшенең зәхмәтсез булуын кайгыртты. Ярый ла бу ужым бозавы — Мәннәф куркуыннан ычкындырмаса...

— Син, Мәннәфетдин энем, бигрәк яман эш кырып ташлагансың икән, һай алла. Нишләп алай итәр булдың соң? — дип бөтенләй белмәгәндәй гаҗәпләнде ул. Моның белән бер очтан Мәннәфне куркытып, алай-болай теле кычытырга уйласа, гаепнең үзендә икәнлеген белсен дип киртә корып куйды. Шуңадыр, беренче сүзләрен үк, әле аңына килеп өлгермәгән Мәннәфне бөтенләй миңгерәтерлек итеп әйтергә тырышты.

— Карале, кара, кем Мәннәфетдин энем, тракторны син бозганны белсәләр, өтермән китәрсең бит, һай аллам, менә бит алла факыры...

Мәннәф, Фәндәрия апасының моңардан кырынрак йомышларын үтәгән кеше, аның теләсә нинди кабахәтлеккә барасын белгән булса да, мондый ук оятсызлыкны көтмәгән иде. Ул бары тик:

— Соң бит, ни бит, Фәндәрия апа, ни бит, мин бит... мин түгел бит... Син үзең шулай әйттең бит,— дигән булды, телен көч-хәл белән әйләндереп. Нишләптер, кинәт кенә теле тотлыга башлаган иде аның.

— һай алла, карале, карале бу алла факырына. Нәрсә сөйләп торган була тагын? Ни ди ул? — диде Фәндәрия исе киткән кеше кебек.— Син, Мәннәфетдин туган энем, тузга язмаганны лыгырдама. Нишләп мин шундый эшкә өйрәтим сине, үзем персидәтел хатыны була торып? Әллә трактор бозуның закунга сыймаганын белмимме? Телеңә салынып торма, белдеңме?! Син әллә бала-чагамы? Мин коега төш дисәм, син барып төшәрсеңме? Карале, кара, алланың факырына...

Фәндәрия апасының болай дулавыннан Мәннәф тәмам дөньясын югалткан булса да, хәлнең четереклелеген аңлады. Ник эшләдең дисәләр, егет башың белән: «Фәндәрия апа котыртты» димәссең бит инде. Моның актыгы, чынлап та, өтермә белән бетмәгәе. Киткәндә үк «тыны юк» диделәр бит Вазыйхның...

Фәндәрия исә моның белән генә калмады. Мәннәфне озатып җибәрүгә чиләк-көянтәсен алды да, көн уртасында, басмадан гына туры чыкмыйча, якын юлны ерак итеп, зур күпердән әйләнеп чишмә суына китте. Очраган бер хатын-кыз, карчык-корчык белән туктап аһ-ваһ килеп сөйләшеп торды. Гамил турында «армия хәтле армиядән шундый этлек эшләр өчен кайткан ахры, көнчелеге үзенә күрә генә түгел икән» дип кешеләргә «фикер» салды.

Кара хәбәрне ишеткәч Тәнзилә үз ягына керен бикләнде дә караватына капланды. Анасының әллә ничә мәртәбә ишек төбенә килгәнен ишетсә дә ачмады. Ул аңардан гел куркып яшәде. Кырын эшләрен белсә дә дәшмәде, түзде. Дөрес, әтисе өйдә чакта бик аптырамады. Ә соңгы елда, Гамил армиягә киткәч, анасының коткысына бирелеп карынында алтынчы ай яткан баласын харап итте: имеш, бала тагын булыр, алма кебек чагыңны юкка әрәм итмә... Ул анда, әрмедә теләсә кем белән... Бүгенге бәхетсезлектә дә анасының кулы уйнаганлыкны сизенә Тәнзилә. Дәлиле юк югын. Әмма әнисенең Мәннәфне чакырып пышын-пышын сөйләшүе күңелгә нииндидер шом салып калдырган иде кичә.

Тәнзилә хәзер үз күңелен үзе аңламый. Әллә нишләде түгелме соң ул? Яратып, бөтен егетләрдән дә өстенгә санаган Гамилен бөтен авыл алдында хур иттерде түгелме? Аның күңелендә хәзер нинди давыллар

юктыр... Аерым тору сынавын үтә алмады, ялгыз көннәрне кичерә алмады шул Тәнзилә. Ире алдында инде икеләтә гаепле бит ул. Нишләп соң Тәнзилә Вазыйх белән рәтләп сөйләшмәгән дә көенчә, анасының коткысына бирелеп үз өстенә яла алды. Нишләп соң ул Гамил белән бу йорттан чыгып китмәде? Нииишшшләәәп???



## 10

Гамилнең тормышындагы иң кара көннәр искиткеч акрын уздылар. Юк, җаваптан качарга җыенмый ул. Иртә белән эшкә килгәч үзенең һәр секунды һәм минуты һәлакәтнең сәбәбен ачыкларга мең дә беренче тапкыр тырышып, ничек үткәнен күзаллап интегә. Бер нәрсә аңа аеруча ачык: ул кичтән тоташтыру муфтасын да, тормоз рычагларын да үз куллары белән механик Насыйб абзый алдында җайлап куйды! Димәк, җавапны да ул, бары тик ул гына бирергә тиеш. Бу хакта икеләнеш юк.

Вазыйх... Ул ни хәлдә икән? Шуны гына беләсе иде дә бит. Тикшерүчесе дә кайтмый. Билгесезлектән яман нәрсә юктыр бу дөньяда. Бүген кич дежур офицердан больницага шалтыратуын үтенергә кирәк. Сөйләшсә, билгеле. Яхшылап төшендергәч аңлар, бәлки.

Көн искиткеч акрын узды. Гамил дежурныйдан сорап алган журналларның барысын да диярлек актарып өлгерде инде. «Знамя»дан хәтта бөтен бер повесть укыды. Ә көн һаман кичкә авышмый әле. Ничек кенә тыныч булырга тырышса да, күңелдәге уйлар өере басылмый.

Тәнзилә... Аның кара толымнары бөтерелеп күз алдында тора. Гамил бит аны егет була башлаганнан бирле яратып йөрде. Кызның да җавабы шулай иде. Мәннәфнең төрттерүләре, дөрес, солдат күңелен тырнамады түгел, тырнады. Һәм барысы да чын, дөрес булып чыкты бит. Теге көнне Тәнзилә энисенә каршы бер сүз әйтмәде — тораташ шикелле катты да калды. Андый түгел иде ул. Ни әйтсәң дә үзгәргән Тәнзилә. Элеккеге чаялыгы сүнгән, сөйгәне артыннан җир читенә барырга да риза түгел иде ул хәзер. Теге чакта тамчы да курыкмады һәм икеләнеп тормады ич — ябышты да чыкты. Ә армиягә нинди җылы хатлар язды?! Соңрак, сирәгәя башлаган хатларда, ниндидер әйтеп бетермәгәнлек сизелгәләде. Хатлар да, уйлар-хисләр дә аралаша-үзгәрә башлады: Гамилгә ябышып чыккан кыз, иженчесендә үпкә яки шелтә белдерүче кеше кулы... Димәк, аерылышып тору, аның колак төбендә энисенең бер сүзне тукуы аны үзгәрткән. Ә Гамил кайтып күренгәч ник үксеп-үксеп елады? «Күрешү шатлыгыннан» дип юрады Гамил. Күрәсең, юк, шатлык яшьләре булмаган алар.

## 11

Лейтенант Камил Шәйдуллин — хәрби прокуратура тикшерүчесе — икенче көнне иртүк районга китә алмады, тоткарланырга туры килде. Ефрейтор Салихов «эше» белән танышкач туган фикерләрен уртаклашырга, киңәш-табыш итәргә, берочтан рөхсәт сорарга дип подполковник янына кергән иде. Һич көтмәгәндә аңарда яңа бер уй калыкты. «Характеристикалар килгәнче күпме көтәргә туры киләчәк, әгәр ефрейтор элек хезмәт иткән урынга шалтыратып сөйләшсәң ничек булыр?» Подполковник та бу уйны хуплады. Лейтенантның тапталган сукмактан атламыйча, тикшерүләргә үзеннән кечкенә генә булса да яңалык кертергә тырышуы аны куандыра иде. Башкарасы тикшерүләргә, нинди булуына да карамастан, иҗади карарга омтылыш яшь хезмәткәрнең би-

тараф түгеллегенә бер дәлил. Димәк, университет студентлары арасыннан үзенә яңа хезмәткәр сайлаганда ялгышмаган ул.

Еракта гарнизон белән элемтәгә кереп сөйләшү, әле бер, әле икенче сәбәп табыла тору сәбәпле, озаккарак сузылды. Станциядәге кызларның тырышлыгы, ниһаять, җиңде ахырда. Алар кирәкле гарнизонны гына түгел, ефрейтор Салиховның командирының үзен дә эзләп таптылар. Укыту подразделениесе командиры белән сөйләшү тикшерүченең фикерен үзгәртте: «эш»кә тагын да җаваплырак, игътибарлырак карарга мәҗбүр итте. Чөнки гомерен меңләгән яшь солдатларны тәрбияләүгә багышлаган командир фикере белән исәпләшмәскә мөмкин түгел иде. Ә ул ефрейтор Салиховның гадел, эчкерсез кеше булуына аз гына да шикләнмәде. Эшнең асылын аңышкач та: «Мөмкин кадәр игътибарлы булыгыз, пожалуйста, кирәкле кәгазьләрне бүген үк җибәребез», диде.

...Лейтенант Шәйдуллин хәрби прокуратурадан чыкканда көн инде кичкә авышкан иде. Шулай да ул юлны кичектермәскә, самолет булмаса, Чистай автобусына утырып юлга чыгарга, ә аннан районга чаклы берәр машина тотарга ниятләде.

Менә ул зур тизлек белән алга ыргылган «Икарус»ның йомшак креслосында, битен ачык тәрәзәләрдән кергән йомшак җилгә куеп, басуларда өлгереп килгән арыш, бакчаларда җитешеп килгән кура җиләге һәм карлыганнарның борынны кытыклаган хуш исен иснәп бара. Күп тә үтми сөзәк үрләр арасыннан ялтырап-ялтырап борынгы Кама суы күренгәләп китә башлады, аннары мәгърур елганың бөтен киңлеге ачылып китте: Саескан тавы янындагы кичүгә җиттеләр. Паром палубасы кырыендагы култыксаларга тотынып елга өстендә кыелып-кыелып очкан акчарлакларны күзәтеп баручы лейтенант кинәт үз җилкәсенә кемнеңдер авыр кулы кагылганын тойды да борылып басты: алдында авызын колакларына җитәрдәй итеп елмайган кара кучкыл йөзле кешеләрне күрде.

— О, генацевале, дарагуй Камо, саулык-иминлекме?

— Савсем заммечательный егет бу.

— Танырлык та түгел...

Камил аларның барысын берьюлы таныды. Институт комсомол дружинасындагы дусты, зур җинаятьчегә каршы берүзе чыгып, тигезсез көрәштә һәлак булган Артем Айдиновның якташлары иде болар. Ике яр арасын сөйләшеп, хәл-әхвал сорашып уздылар.

Асфальт юлга чыккач автобус тизлекне тагын арттыра төште. Тагын арыш басуларының дулкыннары күренде, юл чатларында автобус көтеп торучылар күзгә чалынып-чалынып китте. Әйе, тормыш, бернинди чикләү-киртәләүләрне белмичә, үзенең әллә кай заманнардан килгән тәртибе белән дәвам итә иде. Камилнең йөгерек күңеле дә кинәт нигәдер үзенең шул тормышта үтелгән сукмагы буйлап узды. Мәктәптә укыганда ул үзенең зиһене, төгәл фәннәрне үзләштерүгә сәләте белән бүтәннәрдән сизелерлек аерылып тора иде. Унынчы класста инде таза, ныклы сөякле, киң җилкәле, зур башлы — аның баш киеме үлчәме алтмышлы иде — зәңгәр күзле бу егетнең фән кешесе, яисә берәр төрле конструктор-фәлән булачагын һәркем диярлек ачык белде сыман. Шуңа аның авиация институтына юл тотуы берәүне дә гаҗәпләндермәде. Алтын медальле егетне анда ике куллап каршы алдылар. Бәлки ул, чынлап та, космик заман очкычлары иҗат итүче бер галим булып җитлегер иде. Ләкин юлында аңа үзе кебек үк зирәк акыллы һәм сәләтле грузин егете Артем очрады. Беренче очрашудан ук аерылмас дус булып киттеләр. Укулары да бер группада, торулары да бер бүлмәдә. Шул ук Артем тырышлыгы белән Камил — дусты аны грузинчалап Камо дип йөртә иде — сугышчан комсомол дружинасына язылды, аннары аның иң активларының берсенә әйләнде. Шулай да аның үзе сайлаган юлдан

тайпылырга исәбе юк иде әле. Юк иде... Әмма бер кич, аның да беренче сәгате барысы берьюлы хәл итте, Камил Шәйдуллинның тормыш сукмагын бөтенләй икенче тарафка борды да җибәрде.

Ул кичне шәһәр урамнарында гадәттәгедән тынычрак иде. Тәртип бозулар, ярдәмгә чакырып шалтыратучылар бөтенләй булмады. Дружина штабы начальнигы Камил үз урынына Артемны калдырып тиз генә тулай торакка, онытылган китабын алырга кереп китте. Күп булса, унуникe минут торгандыр. Ләкин нәкъ шушы минутларның берсендә телефон шалтырый. Ярдәмгә чакыралар. Артем трубканы куя да, иптәшләре — беренче курс студентларына борчылмаска кушып, тәртип бозучының ялгыз икәнлеген әйтеп чыгып югала. Камил кергәндә ул юк иде. Тагын алты-җиде минут үттеме-юкмы, Камил, күңеле шөбһәләнә башлавын тоеп, өч-дүрт егет белән вакыйга булган урынга йөгерде. Җыелган халыкны аралап керсәләр... Артем кан эчендә ята, җинаятьчене узып баручы ир-атлар тоткан иде.

Курку белмәс батыр егетне соңгы юлга шәһәрдәге уналты институт һәм университет студентлары озатты. Ике-өч көннән сугышчан комсомол дружиналары икеләтә артты. Совет законнарын бозучыларга каршы көрәш аеруча кискенләште.

Дустының үлемен Камил аеруча тирән әрнү белән кичерде. Чөнки бу вакыйга булып узган урынга барырга Камил чираты иде бит. Өзгәләнде. Лекцияләрнең, яшь галимнәр башкара торган эшләрнең мәгънәсе кинәт югалгандай булды. Үзе берничә көн буе бүлмәсеннән чыкмыйча ятты да бер көнне иртүк каядыр китеп барды. Ә кичен ул үз иптәшләренә институттан китәчәген әйтте. Башта аңа ышанырга да, ышанмаска да белмәделәр, иптәшләре күз алдында декан исеменә гариза язылгач кына Камилнең шаярмавы аңлашылды. Деканатта да иң яхшы студентларның берсен тиз генә җибәрергә теләмәсләр иде, әлбәттә. Ләкин гариза янында республиканың эчке эшләр министрлыгыннан җибәрелгән документ та булгач карышмадылар. Шулай итеп, Камил Шәйдуллин университетның юридик факультетына күчте.

Районда лейтенант Шәйдуллин башта милиция бүлегендәге кыска гына, ләкин шактый кискен киңәшмәдә булды, аннары комсомолның район комитетында Салихов турында сөйләшеп чыкты. Аннары район газетасы редакциясенә кереп, армиягә киткәнче иң актив хәбәрчеләрнең берсе «Г. Салихов» язган мәкалә-хәбәрләр белән танышты. Тупланган мәгълүматларның барысы да ефрейтор файдасына иде. Дөресен әйткәндә, тикшерүче үзе дә актив егетләрне, кимчелекләрне күзгә карап, курыкмыйча әйтә белүчеләрне аеруча ярата. Андыйлар теләсә нинди катлаулы эшне дә намус белән башкара торган була. Шуңа күрә андыйларны бик үк өнәп бетермәүчеләр, җае килгәндә алардан үч алырга яратучылар барлыгына да шикләнми иде. Кем белә, бәлки бу очракта да шундыйрак хәлдер?!

Әмма тикшерүче шәхси хисләр, элек-электән килгән исбатлаулар белән генә, гәрчә, алар нихәтле көчле булсалар да, эш йөртә алмый, ул асылдагы фактларның үзәген аңларга, күрергә, теге яки бу «эш»нең гаеплесен генә түгел, аның сәбәпләрен дә ачып бирә торган дәлилләр табарга тиеш. Эше тикшерү астында торган кеше гаепле булса да, булмаса да ахырынача анык дәлилләр табу шарт.

Милиция бүлегендәге киңәшмәдә вакыйга урынына баручы иптәшләрнең кайбер хаталары да ачыкланды. Бәхеткә каршы, ул хаталар — тракторның техник төзеклеген тиешле белгечләр катнашында тулысынча тикшермәү — «эш»нең барышына йогынты ясый алмый иде. Чөнки тракторны авария булгандагы хәлендә сакларга кушылган, махсус кеше билгеләнгән булып чыкты.

Хәрби прокуратура тикшерүчесен, эчке эшләр бүлеге белән «Сельхозтехника» берләшмәсе вәкилләрен участок инспекторы Волков каршы

алды. Кирәкле кешеләрнең барысы да чакырылган, тиешле чаралар күрелгән иде.

Гамил Салихов төзәткән тракторны кабат карау бөтенләй көтелмәгән нәтиҗә бирде. Аның тоташтыру муфтасындагы терсәк белән тартучы рычагны бер-берсенә беркетүче бармак юк иде. Соңрак аны трактор торган урыннан таптылар. Бу хәл тикшерүчеләрне генә түгел, шундагы барлык механизаторларны да аптырашта калдырды. Чөнки бригадир Зиннәтулла белән механик Насыйб абзый беравыздан:

— Моның булуы һич мөмкин түгел. Салихов кирәкле детальләрне үз урыннарына безнең күз алдыбызда куйды,— диделәр. Алар икесе дә ышанычлы кеше. Өстәвенә механик тоташтыру муфтасын үз куллары белән көйләшкән дә иде.

Шулвакыт тикшерүчеләрдән бер читтәрәк торган каравылчы Букай агай кешеләрне этеп-төртеп төркем арасына керә башлады. Ул:

— Теләсәгез нишләгез, җәмәгать, гүр иясе булыр чагым җиткәндә генә җаныма гөнаһ алалмыйм, әйтәм, әйтәм булгач әйтәм,— диде.

Милиция вәкиле каравылчыга кырыс караш ташлады да, бүлдереп йөргәне өчен канәгатьсезлек белдергән шикеллерәк итеп:

— Ни булды? — дип Букай абзыйга төбәлде.

Гомере буена милиция кешеләре белән алыш-биреше булмаган агай мондый кырыслыктан кинәт таш стенага бәрелгәндәй тукталып калды.

— Ни булды дип, алай сүз кузгатып әйтерлек әллә ни булмады булуын да...

— Алайса ник тавыш куптарасыз?

Букай абзый, төркемдәгеләргә куе сары кашлары астыннан сөзеп карап чыкты да, катгый карарга килеп:

— Сүзем хак минем, шулай булгач нигә куркыйм ди. Иптәш следователь, менә шулай, беләсегез килсә, мин бирелдәге машиналар янында туже җаваплы кеше. Значится, нигә мине тыңламаска.

— Бик дөрес, агай, сөйләгез сүзегезне,— диде Шәйдуллин икеләнергә урын калдырмыйча.

— Теге көнне, закунный хатыны янынан әбисе Фәндәрия куып чыгаргач та, Гамил төне буе кайдадыр йөреп, таң атыр-атмас килеп эшкә ябышты. Соң, син соң, солдат, дим, әллә калхуз эше эшләргә дип кайттыңмы, дим. Теләр-теләмәс кенә елмая бу. Калхуз кем соң ул, ул бит без үзебез, Букай абзый, ди бу. Үз сүзендә торды бит тәки. Өч-дүрт көндә җыйды тракторны. Маладис егет ул, кулыннан эш килә.

Участок инспекторы Волков каравылчыны шул төштә бүлдереп:

— Соң Букай абзый, монда синең сүзләрнең дә ни катнашы бар? Авариягә кагылышлы сүзең булса әйт, булмаса...

— Һе, булмаса... Бар шул, энем, кем, Рәхимҗан, бар. Вәйт шулай, энем. Һе, беләсегез килсә шуфыр Вазыйх та, Гамил дә шушы уҗым бозавы Мәннәф аркылы харап булдылар.

— Ничек алай?

Төркемдәге механизаторлар барсы да аптырап-тынып калды.

— Ул төнне минем күңел тыныч булмады. Карап керәм дә яткан булам. Кеше дә юк, эт тә юк, дигәндәй. Таң беленгәч тә бер чыгуымда ә-ә-әнә теге баштагы комбайннар янында тимер чыңлаган тавыш килгән кебек булды да — шунда киттем. Җан иясе күренмәде. Җил-фәләндер дип уйладым. Әйләнеп килсәм, Гамил төзәткән трактор алдында Мәннәф тураеп маташа.

Букай агай янындагы бөтен кешеләргә тагын бер кат күтәрелеп, гаепле кеше сыман карап алды да тынып калды.

— Дәвам ит, абый.

— Дәвам ит дип, шул инде, бетте.

— Ничек бетте? Мәннәф нишли иде соң?

— Анысын белмим, мужыт нужасы булгандыр... Таң тишеге белән аның эшкә килгәне юк иде.

Мәннәф... Соңгы көннәрдә эшкә чыкмаган иде ул. Аны күпме эзләсәләр дә таба алмадылар. Сораштыра башлагач та теге көннән соң аны күрүче кеше юклыгы беленде. Өйләренә баручы участковойга «Урал ягындагы туган-тумачаларны күреп кайтам әле уракка төшкәнче дип китте», диделәр.

Гомердә читкә чыкмаган, хәтта армия хезмәтен дә Казанда гына үткәргән Мәннәфнең көтмәгәндә кунакка китеп баруы, тикмәгә генә түгел иде, билгеле.

Авыл кешеләре, бигрәк тә яшьләр белән сөйләшү Гамил Салиховның гаепсез икәнлегенә ышандыра барды. Фәндәрия тикшерүче алдында да үзенең киявенә карата нәфрәтен яшерә алмады, аны тегеләй-болай дип битәрләде, каралтырга тырышты. Асылда Гамилгә карата иң начар сүзләр әйтүче кешенең бер ул гына икәнлеге ачыкланды. Тәнзилә исә, елавыннан арына алмыйча, беркем белән дә юньләп сөйләшмәде. Тикшерүчегә дә «белмим, кешеләр өстенә, төгәл белмәгән килеш яла ягарга хакым юк, болай да җанымны этләр талый. Зинһар, бимазаламагыз мине», дип бетеренде.

Тагын бер көннән лейтенант Шәйдуллин хәрби прокурор өстәленә тиешле кәгазьләрне кертеп салды, тикшерү нәтиҗәләре белән таныштырды.

— Димәк, ефрейтор Салиховның эш-хәрәкәтләрендә җинаять составы юк,— дип нәтиҗә чыгарды лейтенантның күзләренә караган подполковник, талкыган җитен сыман ак чәчләрен артка сыйпап.

— Юк. Әлбәттә, юк, иптәш подполковник,— диде лейтенант тирән һәм катгый ышаныч белән.

— Шулай да теге тракторчыны табып, аның күрсәтмәләрен «эш»кә теркәмичә, тикшерүне төгәлләнде дип әйтергә хакыбыз юк бит, лейтенант.

— Дөрес, иптәш подполковник. Ләкин бит әле аны табасы бар. Ә гаепсез кеше безнең гауптвахтада утырсынмы?

— Ә ник анда тотарга аны? Частена кайтарып җибәрергә кирәк. Солдатның хезмәттә булуы яхшы, минемчә.

Лейтенант Шәйдуллин исә шуны гына көтә иде.

Подполковник яшь тикшерүчегә карап елмаеп куйды. Лейтенантның кеше җанлы икәнлеген белү аңа карата ышанычны тагын да арттыра, көчәйтә иде.

## Билләрендә сары каеш

### I

Ефрейтор канал аша салынган күпер төбендә машинадан сикереп төште дә, алдан әйләнеп шофер янына килде. Тегесе тәрәзәдән башын чыгарып аны көтә иде.

— Рәхмәт сиңа, дус кеше. Бик җилле йөртәсең машинаңны, хәвеф-хәтәргә очрый күрмә,— дип, күкрәк кесәсендәге кечкенә блокноты эченнән өчлек чыгарып шоферга сузды.

— Син што, ефрейтор. Нинди акча ди ул. Мин бит сине әйтер сүзем булганга гына көтәм: җирнең бигрәк «тишек» төшенә тап булгансың, хезмәтеңне исән-имин генә бетер дә өеңә юл ал...

Юлаучы җавап биреп өлгергәнче машина китеп тә барды. Ефрейтор Салихов аңа, «хәерле юл» дигәндәй, кул болгап калды.

Ефрейтор, портфелен бер кулыннан икенчесенә күчереп селти-селти, юл аша чыкты да сукмак-фәлән эзләп тормыйча гына канал кырыена төште. Башта кара кырпулы фуражкасын җирдән чыгып торган ниндидер тимер кисәгенә элеп куйды, аннары чишенде дә суга керде. Су чәчрәтә-чәчрәтә, пошкырына-пошкырына рәхәтләнеп коенды. Бераздан чыгып кайнар ком өстенә сузылып ятты, кулларын баш астына куеп югарыга, бер генә болыт әсәре дә күренмәгән күк йөзенә карады.

Һава эссе, бөркү. Сулыш алуы торган саен кыенлаша бара. Сирәк-мирәк кенә кайнар җил исеп киткәндәй була. Ул өзек-өзек килә дә битләрне сыйпап-сыйпап ала.

Гамилнең туган яктагы кырлар күкрәгендә ничәмә-ничә мәртәбә менә шулай, чалкан ятып зәңгәр күкләргә караганы, тургайлар җырын тыңлаганы бар. Анда да шундый күк йөзе, шул ук бер кояш. Ләкин мондагысының нурлары өтеп-өтеп ала торган аяусыз. Егет елмаеп куйды. Чөнки ул чынбарлыкта шуның нәкъ киресен кичерә әле. Туган яктагы кояш ныграк өтә, тәнен генә түгел, йөрәген яндыра иде.

Ул кояш та, туган кырлар да еракта хәзер, җырдагыча әйтсәң, «зәңгәр томаннар артында». Аннан киткәнгә дә ике айдан артыграк вакыт узды. Менә бүген беренче увольнительный алып шәһәргә барды.

Әмма, ничек кенә булмасын, барыбер сагындыра туган як. Гәрчә соңгы айлардагы вакыйгалар катлаулы, йөрәкне яралардай булсалар да җәрәхәтләр җөйләнеп тә бетмәгән бит әле. Ләкин балачагың, үсмер елларың узган, әниең җирләнгән төбәкне, беренче мәхәббәтең чәчәк аткан гөлбакчаны сагынмый һич мөмкин түгел иде.

И, хатын-кыз, дөньяның иң кадерле заты! Кешелек яралганнан бирле нинди генә шатлык-кайгылар, назлану-назлаулар, тирән хисләр, олы мәхәббәтләр тудырмадың син. Хәтәр алышларга ташлап, кемнәрне генә батыр итмәдең?! Ир-егетләр синең өчен күпме утларга керде дә суларга ташланды. Сине яклап һәм даулап нихәтле сугышлар-яулар купты, илләр, шәһәрләр, авыллар кырылды?! Ләкин син җирдә иң асыл зат булып һаман яшәдең, тагын күпме буын ир-егетләргә җан бирдең, тудырдың, иркәләп үстердең дә тагын яңа ялкыннарга ташладың. Иң бөек эшләргә рухландырган кебек, иң түбән җинаятьләргә дә этәрдең ир-егетләрне. Сине моңарчы кем дә булса тулысынча, ахырынача аңлый алдымы икән?!

Гамил баш астына салып яткан кулына ниндидер салкын, чиркандыргыч нәрсәнең тиеп китүеннән сискәнеп торып басты да әле генә үзе яткан урынга карады. Аның авырлыгыннан сизелер-сизелмәс уйсулык булып калган ком өстендә, борма-борма бөгәрләнеп, тимгелле, зур елан ята иде. Ефрейтор аңа исе китеп карап торды һәм бераздан аңлады: еланның чагар нияте булмаган, ул әнә теге куак төбендә, эссе комда иркәләнеп, җылынып яткан... Ә Гамил аның янәшәсендә, берни абайламыйча...

— Күр инде син аны, кеше бит еланны дошман итә, очраган бер җирдә үтерү ягын карый,— дип уйлады егет әле дә булса үзенә янаган куркынычны бөтенләе белән аңлап бетермичә, ирексездән. Аннары, еланны бер генә мизгелгә дә күздән югалтмыйча, саклык белән генә фуражкасын үрелеп алды, өс киемен, протфелен тиз-тиз эләктерде дә, киенеп тә тормыйча, яр өстенә күтәрелде. Сирәк-мирәк кенә үсеп утырган чәнечкеле үләннәр арасындагы аулак юлга чыкты. Үз подразделениесенә кадәр тагын өч-дүрт чакрым атлыйсы бар иде әле.

Кояшның кызу нурлары көзге яңгырлар чорында гына дымга туенган иксез-чиксез киң даладагы соңгы тамчыларны сыгып чыгарырга тырышкандай сибелә дә сибелә. Анда-санда үсеп утырган чәнечкеле дөя үләне, күрән, кәүсәләре яргаланып беткән саксаул куаклары шушы эссене, әйтерсең, бар дип тә белмичә, тереклек итә бирәләр. Беренче карашка бу тирәләрдә бер генә җан иясе дә юктыр кебек, ләкин бу бе-

ренче карашка гына шулай. Чүл үз законнары белән яши, тормышының үзенә генә хас агымы бар. Егетнең шул уйларын раслагандай, әнә аның аяк астыннан гына житез кәлтә атылып китте, баш өстендә, һич көтмәгәндә, тургай тавышы ишетелде...

Кайтып житәргә алты-жиде йөз адым калгач та позицияләр өстендә калкып торган антенналарның туктаусыз әйләнеп, иксез-чиксез күк йөзен тыңлауларына игътибар итте ефрейтор. Ул адымнарын тизләтте, атлаган уңайга гимнастеркасын төзәткәләде дә билен буып куйды, фуражкасын киде. Аның хәтеренә «отпускадан» соң беренче мәртәбә шушы юлдан кайтуы сеңеп калган иде. Ул чакта аңа, көтеп алган кебек, Саша Аксенов очрады. Капка төбендә постта тора икән. Алар чын дусларча, кочаклашып күрештеләр.

— Салихов, шайтан алгыры, ун көнлек ялга китеп күпме вакыт торып килдең. Туган яклардан китәсе килмәгәндер шул, ә? — диде Саша аның белән күрешә-күрешә.

— Саумы, кадерле дус, Саша. Син биредә тәмам үз кеше булып беткәнсең инде. Кайда син?

— Күрәсеңме, әнә ничек бөтереләләр?! Шунда.

— Шәп, малай, шәп әйләнәләр. Мине кая жибәрерләр икән, ишетмәдеңме?

— Соң, билгеле инде. Моңарчы ук өлкән оператор булган кешене.

Табигый ки, ефрейторның күңеле тыныч түгел иде. Ни әйтсәң дә ул биредә яңа кеше. Бәлки килеп житмәс борын ялга кайтарып жибәрүләренә дә үкенгәннәрдер әле. Аннары... тикшерү астында булган кешегә жаваплы урынны ышандырмаулары да мөмкин. Ләкин ул мондый уйларны кешегә ишеттереп әйтмәячәк иде.

— Ну, нилэр генә булып бетте соң, малай. Безгә комбат әйтте. Ышанырга да ышанмаска да белмәдек.

Икенче көнне иртәнге разводтан соң Салиховны штабка чакырдылар. Егетләр аңа «каушама» дип калды, ә Саша Аксенов штаб ишегенә кадәр озата барды.

Бүлмәдә өчәү — дивизион командиры майор Ховренко, капитан Гаврилов һәм яңа замполит Сергеев утыралар иде. Гамил кереп ишек төбенә басты да рапорт бирде. Аңа тартынмаска куштылар, авылда булган хәлләрне жентекләп сораштылар. Ефрейтор барысын да түкми-чәчми сөйләп бирде, бары тик Тәнзилә турында гына бер сүз дә әйтмәде. Командирлар бу хакта сүз кузгатмады. Ахырдан майор Ховренко үзенең басынкы тавышы белән:

— Быел безнең подразделение ерак полигонга, контроль атышларга барасы, шуңа күрә, сез, ефрейтор, махсус хәзерлекле белгеч буларак, безнең ышанычны акларга, яшь солдатларны өйрәтүдә, сугышчан хәзерлекне нигытуда мөмкин булган хәтле тырышырга тиешсез,— дип, ефрейторны эш урынына жибәрде...

Салиховның уйларын бүлдереп позицияләр өстендә буылып-буылып сирена улый башлады. Бераздан аның миләрне бораулап, күңелне әрнетердәй түбән тавышы тигезләнде, озын-озын гүләүгә күчте. Бу вакытта ефрейтор Салихов, олы-олы адымнар белән чәнечкеле дөя үләннәре аша сикерә-сикерә, позицияләр ягына таба йөгерә иде инде.

## 2

Киң җилкәле, табак битле, күптән түгел генә куе мыек жибәргән майор Ховренко Василий Степанович беренче карашка тупасрак, масаючан һәм эре күңеллерәк кеше кебек күренсә дә, чынлыкта, киң күңелле, уен-көлке яратучан, тәжрибәле командир иде. Ул бер көнне станциядәге күнегүләр тәгәлләнгәннән соң үзеннән бер читтәрәк һәм

түбәнрәк утыручы өлкән оператор Салиховка калырга кушты. Аңа бу егет беренче көннәрдән үк әллә кай ягы белән ошаган иде, шуңадырмы, аны һәрвакыт күз алдында тотты. Ефрейторны ялга җибәрүе дә һич көтмәгәндә булды. Ә инде Салихов вакытында кайтмый тоткарлангач үзен бераз гаепле санап йөрде: «Ашыгып җибәрмәгән булсак мәнә дигән солдат сафта калыр иде»,— дип уйлады ул. Соңгы көннәрдә егетнең бик уйчанланып, үзен ничектер сәер тотуын күргәч тә, йомыш табып, район үзәгенә увольнительный бирен җибәрде, шәһәрдәге истәлекле урыннарны, берочтан үзегезнең якташларны — татар бригадасы сугышчыларына куелган һәйкәлне дә күреп кайтырсың, диде.

— Син, күгәрченкәем, артык ямансылама әле болай,— диде майор, ефрейторның җилкәсеннән кагып. Кеше, җитмәсә ир-ат, бу дөньяда әллә нинди упкыннар кичәргә тиеш була. Тормыш юлында аның көтелмәгән тозаклар очрап бимазалый. Иң мөһиме, егетем, нинди очракта да кеше үзенең кешелеген югалтмаска, намусына тап төшермәскә тиеш. Әллә ниткән җинаятьчеләр дә, иртәме-соңгы, тормыш мәгънәсе хакында уйлана башлыйлар. Ләкин аларның кешелеге югалган, өметләре сүнгән, хыяллары канатсызланган, җинаять статьялары ятьмәсенә кереп чуалган була. Кайдадыр укыганым бар: кеше табигатьтән үсеп чыга. Ни өчен? Табигатьнең үзе белән көрәшеп яшәү, бер үк вакытта аны яклау һәм саклау, кыенлыклардан коткару өчен. Димәк, тормыш — көрәш ул. Һәркемгә төрлечә көрәшергә туры килә: үз-үзе белән, дошманнар белән, хәтта... дус-ише, туган-тумачалары белән... Синең башка да, дөресрәге, өлешеңә, шундыйрак бер бәла төшкән икән — сынатма, ир-егетләрчә түз, кичерә бел, түз. Минемчә, син төпле егет, шундый ук яхшы хәрби дә булачагыңа шигем юк. Кыскасы, сынаулардан сыгылма, хезмәт—иң шифалы дәва булыр сиңа. Дөрес, анысы, күңел яралары тиз генә төзәлми ул... Ялгышың — гомерлек сабак булсын. Бер кыйналган урынына кыйналмаган икене бирәләр диләрме әле. Вот шул, күгәрченкәй.

Ефрейтор баштарак командирның бу сүзләрне кистереп, нәкъ кирәкле урынына куеп, йомшак украин акценты белән тезеп китүенә башта артык игътибар итмәгән иде. Ләкин тәҗрибәле, өлкән кешенең аның хәленә шулай керүе күңелне кинәт йомшартып җибәрде. Егетне күптән азаплаган төер тамак төбенә үк килеп тыгылды кебек. Егетнең күзләренә яшь тулды, тик иреннәрен тешләп булса да түзде ул. Каршысындагы индикаторны кулындагы чүпрәк белән кат-кат сөртеп-сөртеп алгандай итте. Тагын бераздан, командирына рәхмәт әйтеп, китәргә рөхсәт сорады. Шулвакыт ефрейтор аның кул сыртындагы рәсемле язуларны күреп гаҗәпләнде. Ул әле командирның сугыштан соңгы елларда тәрбиячесез калып, урам малае булып йөргәнен, аннары балалар колониясендә тәрбияләнүен белми иде.

Соңгы вакытларда Василий Степанович Устав турында, солдат белән сержант, офицерлар арасындагы уставча мөнәсәбәтләр турында еш уйлана башлады. Уставча мөнәсәбәт... Кешеләр арасындагы барлык эшхәрәкәтләр, уй-тойгыларны шуңа сыйдырып буламы? Уставның кырыс пунктларына кереп бетмәгәннәрне ничек аңлатырга? Аның чиге кайда, кайчан, кайсы ноктадан башлана андый мөнәсәбәтләр. Кешеләр белән бергә эшләгәндә, яшәгәндә гел уставча гына мөнәсәбәттә калыргамы, юкмы? Чигенешләр, тайпылышлар да була бит. Уставка искиткеч акыллы, тирән мәгънәле, тәҗрибәдә күпме мәртәбәләр сыналган юллар язылган. Чөнки Устав куйган бурычлар, солдатлар һәм офицерлар өчен дә бер үк дәрәҗәдә, аның алдында һәркем бертигез җаваплы да, бурычлы да. Ул бурычларның бөтенесе дә бер максатка — туган Ватанның иминлеген сакларга әзер булуга юнәлтелгән. Ә Уставка сыймаган мөнәсәбәтләр нәрсәгә кайтып кала? Майор Ховренко уенча, ул гап-гади итеп әйтелгән бер сүздә дә булырга мөмкин. Әйтик, дорфарак бирелгән җавап, Устав таләп иткәнчә честь бирмәү, бер-береңә мөрәҗәгать ит-

кәндә кечкенә генә тыйнаксызлык — болар барысы да кешене кешә күңеленә кертәчәк сукмакта иң беренче адымнар бит. Менә әле генә солдатның күзләренә мөлдерәп яшь тулды, ул бөтен ихтыярын туплап тыелып калды, елмайды. Моның бит гыйбрәтле мәгънәсе бар. Нинди дә яман кичереш ачуын кабарткан, язмышына кул селтәүгә хәтле җиткерә аласы теге яки бу вакыйга кешене уйлап-нитеп тормыйча, теләсә нинди дорфалык кылырга да этәрер иде. Ә ир-егет, күңеле әрнеп елаган чакта иреннәрен тешләп тыелып кала икән, димәк, аның күңелендәге кешелек намусы сүнәсе-сүреләсе түгел. Димәк, бу кеше өчен, аның күңеле, тормыштагы урыны өчен көрәшергә — вакыт кызганмыйча һәм бернәрсәдән курыкмыйча көрәшергә кирәк. Авыр кайгы-сагыш, югалту, хыянәт, сынау өермәсе тулып дулаган күңел хәзер бушап, сафланып калган. Хәзер шул урынга игелек орлыгы салсаң, озакламый шуның шытымнарын күрәчәксең һәм ул яңа уңыш бирәчәк. Ә без күп очракта, көндәлек эш белән мавыгып яки үзебезнең битарафлыгыбыз аркасында, шундый орлык сибәргә онытабыз...

Дивизион чираттагы күнегүләр белән мәшгуль иде. Командир, арттагы күперчектә утырган килеш, барысын берьюлы күреп, барысына да тиешле күрсәтмәләрне биреп, шул ук вакытта шундагы бөтен операторларның да эш-хәрәкәтләрен күзәтеп барырга өлгерә. Аның алдындагы секундомер тиешле минутларны әле санап та өлгермәде. Системалар һәм расчетларның әзерлеге турында төрле яктан рапортлар ишетелә башлады. Майор Ховренко тревога игълан ителгәч тә атылып килеп кергән, үзенә тиешле барлык операцияләрне төгәл башкарган һәм ачык аңлаешлы тавыш белән командирга җиткерә барган ефрейторның киеренкелектән тирләп юешләнгән аркасына сугып:

— Молодец, ефрейтор, сынатмадың,— диде. Аннары, янәшәсендәге замполит белән батарея командирына мөрәҗәгать итеп:

— Минемчә, иптәшләр, ефрейтор үзенең өченче класслы белгеч икәнлеген раслап кына калмыйча, үз системасы белән бик яхшы идарә итә, безнең барлык таләпләрне үти ала. Бөтенесенә билгеләнгән вакыттан берничә минут алдарак өлгерә. Бу — әйтергә кирәк, беренче класслы белгеч нормативлары. Шулай булгач хәстәрләп, ефрейтор, озакламый имтихан бирергә.

Каршысындагы индикатор пыяласына төшерелгән масштаб сызыкларына карап утыручы ефрейтор мондый сүзләрдән әйләнмәле урындыгына сеңә төште, маңгаена бөрчек-бөрчек тир бөртекләре бәреп чыкты. Ә майор Ховренко баягыча ук дәвам итте.

— Сезнең, иптәш комбат, ефрейторны отделение командиры итеп билгеләү турындагы тәкъдимегез бик урынлы. Салиховка, белгеч буларак, безнең бер генә дәгъвабыз да юк. Сез моңа каршы түгелме, ефрейтор,— дип тагын бер кат үзенең көчле кулы белән Гамилнең аркасын шапылдатып какты.

Икенче көнне иртәнге развод вакытында, ефрейтор Салиховны саф алдына чыгарып приказ укыдылар. Күптән түгел генә хезмәтен тутырып кайтып киткән сержант Лушников урынына билгеләүне Салихов үзе ирешкән уңышлары өчен түгел, ә бәлки киләчәк хезмәтләренә өмет баглау дип, бик дөрес аңлады. Каршысындагы солдатларга каш астыннан гына карап торды. Аларның яртысы әле күптән түгел генә хезмәткә чакырылган егетләр иде. Шулай да ялга кайткач Салиховканиләр булганын беләләр. Алар ни әйтер? Күңелләре ефрейторны үзләренең командиры итеп танырмы? Ә Гамил үзе җаваплы вазифаларны үти алырмы? Хәзер нагрузка икеләтә артачак — аңа үзе өчен генә түгел, отделениедәге һәр солдат өчен дә җавап тотарга туры киләчәк иде. Егет уйлана һәм бу аны куандыра да иде.

Гамил көтте. Көн саен Тәнзиләдән хат-хәбәр көтте. Ләкин көннәр бер-бер артлы үтә торды, ә хат-хәбәр күренмәде. Ярый әле хезмәттәге мә-

шәкатьләр, командирларының ышанычы, яңа дуслар табылды Гамилгә. Аларның берсе — эчкерсез, хыялый романтик егет, Воронеж өлкәсеннән чакырылган Саша Аксенов иде. Ул хезмәтен тутыргач та комсомол путевкасы белән берәр гигант төзелешкә китәргә җыена, Гамилне дә шунда үзе белән китәргә чакыра иде. Үзбәк егете Олимҗан Алиҗанов та әйбәт дус булып чыкты. Ничектер алар беренче көннән үк гел бергә булдылар. Янәшә койкада йокладылар. Станциядә янәшә утырдылар. Русчаны белмәве үзәгенә үткән Олимҗан белгән нәрсәләрен дә авыр аңлата, көләрләр дип занятиеләрдә җавап бирүдән дә баш тарткалый иде. Гамил килгәч тә аның эшләре алга китте.

— Син, Гамилбой әкә,— яшьтәше Гамилгә ул олылап шулай дәшә торган булды,— алай бик бетеренмә әле. Ир бол, бөркет бол, түзем бол. Гозаллар табылар,— ди иде.

3

«Туры юл» колхозы председателе Мирбат Хәйретдинов райком бюросыннан чыкты да «уаз»ына кереп утырды, сәгатенә күз төшереп алды. Кәефе шәптән түгел иде. Булмаслык та шул: эшләр гадәттәгечә җайлы бармый. Әле анда, әле монда тәгәрмәчкә гел таяк тыгылып кына тора. Ә җитәкчелек аңардан яхшы эш таләп итә. Менә хәзер дә ул райком бюросы утырышыннан иртә белән генә киеп киткән күлмәге аркасына ябышканны тоеп чыкты. «Бер кыздырырга тотынсалар... элекке хезмәтләреңне исләренә дә кертеп чыгармыйлар».

Кайту ягына чыгып, үзәк урам очындагы ресторан яныннан узганда Мирбат абый түзмәде, машинасын юлдан читкә төшереп бастырды да, күңелне тынычландырып чыгыйм әле дип кереп китте. Залга борылмады. Буфетчы колхоз председательләре, баш бухгалтерларның барысын да яхшы белә иде. Хәтта кайсының нинди эчемлек капканын да хәтерли. Мирбат абзый ишектә күренеп юк сакалын сыпырган булып ике бармагын күрсәтүгә, суыткычтан коньякның молдавскиен алды да чәй чәшкәсенә салды. Зур тартмадан дүрт-биш «кара-ком» конфетын үрелеп алды һәм шуларның бөтенесен бергә прилавкага куйды. Мирбат абзый исә аларны тиз-тиз генә «үзләштереп» куйды. Ресторан болдырында алар автомобиль инспекциясе инспекторы Мясников белән очраштылар. Тегесе татар һәм чуваш телен бергә катыштырып, гадәтенчә:

— Мирпат апзый, «мунчага» килгәндә шоперыңны калдырмаска дип сөйләшкән идек, пугай,— диде болай да кысынкы күзләрен хәйләкәр кыскалап.

— Син, энекәш, беләсең бит, хәзер колхозда шоферлар алтын бәясенә йөри. Минекеләр тем более. Менә дигән комбайнчы да ул. Син, теге ни, энем, без бит синең әтиең белән бик дуслар идек. Беләсең. Ә син тагы бер шоферның правосын алгансың. Ашлык ташырга комачаулыйсың бит...

— Ансы вакытлыча, Мирпат апзый, тульке син теге ни, үзең карый төшеп йөр инте. Тагын алай-полай пула күрмә...

Машина йөртергә өйрәнгәндәге теге хәлне тәки ишеткән бит, шайтан алгыры, дип уйлады Мирбат абзый.

— Я, ярый, энекәш, Гергури, бик шаулама инде. Кирәк нәрсәң булса, килеп чыгарсың, буш итмәм.

— Шулай да, Мирпат апзый, акрын гына кайт...

Бер килмәсә килми инде ул. Район үзәкнең кырый урамыннан чыккач та елга аша зур күпер бар. Шуның уртасында Мирбат абзый, машинасы алдында нидер шәйләп, кинәт тормоз салды да машинасы күпергә аркылы басты. Күпер өстендә егыла-тора берәү каядыр барырга, күтәрелергә маташа иде. Машина астына кермәсәң, сиңа соң юл беткәнме

эллә, ананы корт чаккыры, дип Мирбат абзый гудокны туктаусыз кычкыртты. Ләкин теге бәндә борылып та карамады, көч-хәл белән күтәрелеп аякларына басты да ава-түнә юл уртасыннан атлавын белде.

Мирбат абзыйның бая тирләп юешләнгән күлмәге суыткычтан алган сыман бозлы кебек тоелды. Ул белгәнечә сүгенә-сүгенә машинасыннан төште дә әлеге кешенең якасыннан барып тотты.

— Сиңа нәрсә... нитиим, якты дөнья карангымы әллә? Башыңа, ата-бабаларың бүредән туган нәмәрсә, тай типтеме әллә? Тегесе якасыннан эләктергән кулдан ычкынырга омтылыш ясаган иде, кинәт, сөрлегеп китте. Мирбат абзыйны да үзе белән күпергә ега язды. Ачылыр-ачылмас күзләрен кыерсытучысына акайтып карады һәм... Мирбат абзыйны таныды. Бу — уракка төшәсе көннәр җиткәч тә комбайнын ташлап авылдан чыгып качкан Мәннәф иде. Ул Мирбат абзыйга кушаматын әйтеп эндәшмәкче иде дә, телен тыеп кала алды.

— Ә-ә-ә-әһәә, Мирбат абзый... Аппар... Әй лә, ни, җизни икән, во шәп. Син инде җизззни мине авылга апкайт инде... Шәһәрдә... анда ни бит, җизни, пашпырт кирәк. Эшшшшкә дә алмадылар... кая уууулл... Шуны алырга кайтышшшш. Уфффу.

Мирбат абзый исерек Мәннәфнең сүзләрен ишетсә дә, ни әйтергә теләгәнен аңласа да ачуланмады. Бердән, авылдашы, икенчедән, хатыны Фәндәриянең энесе тиешле кеше бит. Мәннәфне якасыннан тоткан килеш китерде дә арт ишекне ачып кабинага тыкты. Әйтергә теләгәненең калганын ул юлда бераз сулыш алырга туктагач сөйләп бетерде. Менә нәрсәләр ишетте Мирбат абзые аңардан:

— Син, җизни,— диде ул тотлыга-тотлыга,— мине качкынга саныйсың инде. Әйеме? Ярый, ярый, сана. Тик бит, җизни, ни бит, беләсеңме Мәннәфетдин авылдан ник качты? Белмисеңме? Һеє. Белмәячәксең дә. Потамышты белсәң дә белмәскә тиешсең. Минем шәһәрдә, вокзалларда өстерәлүем бик тә җиткән инде, бүтән алай йөрисем килми. Син нит инде, җизни, миңа пашпырт юнәтеп бир. Әйе, әйе. Бирерсең дә!.. Син предколхоз. Күпләр ужым бозавына санап, санга сукмый йөргән Мәннәфетдинеңне яхшы тыңла. Ишетмичә калдым димә аннары. Бел, Мирбат җизни, мин таптаттым. Гамилгә үч итеп таптаттым. Фәндәрия апаның кушуы буенча... Моторда теге бармакларны аз гына ләктереп калдырдым. Мин ул җинаятьче, ә сез, җизни, бер тиенлек гаебе булмаган Гамилне өтермәгә утырттыгыз. Мине гел шул, синең хатынның — алла факыры Фәндәрия апа котыртты. Тәнзиләне, диде, миңа...

Мирбат абзый шунда кинәт Мәннәфнең бугазыннан буып тотты да аны бераз күтәрә төшеп:

— Син, син, ни сөйләгәнеңне беләсеңме, сабакы?

Мәннәфнең болай да сулышы кысыла иде. Бугазыннан буып тоткач ул бөтенләй диярлек тончыкты, йөзе күгәрә башлады. Моны күреп Мирбат абзый тегенең инде пинжәк якасыннан тотып тагы бер селекте:

— Кем котыртты дидең?

— Фәндәрия апа — дип әйттем бит инде.

...Соңгы өч-дүрт айда Тәнзилә тәмам ябыкты. Элекке җор күңелле, шаян Тәнзилә юк инде. Күз төпләре тимгелле, карашы уйчан, салмак хәрәкәтле, ләкин кыз чагындагы гүзәллеген, зифалыгын саклап калган бер тол хатын бар авылда. Урак өстендә ул эшкә чыккалады, ә соңга таба урамда да чыгып күренмәс булды. Чыкса, очраган һәр кеше аңа төртеп күрсәтер дә:

— Менә ул — күрегез! Шуның аркасында лачын кебек ике егетебез хур булды,— дип битәрләрләр шикелле тоелды.

Авылда сүз әллә нинди әйләнеч юллар белән йөрми. Бер очтан чыгуга, икенче очка көне-сәгате белән диярлек барып җитә. Аларны Тәнзиләгә әнисе — Фәндәрия апа ташыды. Һәм ул аларны, үзеннән өстәп,

усал, кара эчле, тагын әллә нәрсәләр дип, гел Гамилне гаепләүгә әйләндерә иде. Аннары бөтен нәрсә буталып, һич аңламаслык булып бетте.

Менә этисе дә бүген районнан әллә нишләп, гомердә булмаганча шашып кайтты. Керде дә мич арасында, стенада эленеп торган, унике-шәрләп үргән каеш камчысын алып, башта бер сүз әйтмичә генә, Фәндәриясен сыдыргаларга тотынды. Тегесе, карышмакчы булып, бер-ике мәртәбә камчыны эләктереп караган иде дә... кая ул? Иренең ачудан чалышайган йөзен, котырынган күзләрен күргәч, карышуның файдасызлыгын аңлады һәм хәтта кычкырмады. Крепдешин күлмәк аша тәнне чәнчеп, чеметеп-чеметеп камчы төшкән саен ниндидер аңлашылмас авазлар чыгарып шыңшыды гына... Инде күпме гомер итеп бер тапкыр да кул күтәреп сукмаган хатынының кыланыш-капризларына дәшмичә түзгәннәрен чыгарды Мирбат. Хатыны ишетелер-ишетелмәс кенә сулкылдый башлагач, ул Тәнзиләгә таба борылды. Кызы аның күзләрендә мөлдерәгән бөртекләрне абайлады... Этисе исә аңа бер генә сүз әйтте: «Чыык!»

Тәнзилә, боерык көченә буйсынып, олы якка атлады. Әнисе янына килеп басты, күзләрен тутырып этисенә карады. Һәм шул караш Мирбат абзыйның күңелен тетрәндерде, сугарга дип кизәнгән камчысы һавада асылынып калды, сукмады.

Тагын ярты сәгать чамасы узуга, Мирбат абзый Фәндәрияне җилтерәтеп машинасына утыртты да районга алып китте.

— Гомер буе түзүемне, Фәхразый карт белән булган эшләреңне-кыланышларыңны белмәмешкә-күрмәмешкә салынуымны санга сукмыйча, маеңа чыдаша алмыйча кеше башын ашамакчы булгансың икән инде, әйдә, үзең түкми-чәчми генә кирәк җирдә сөйләп тә бир,— диде ул хатынына карышырлык урын калдырмыйча. Фәндәрия кинәт коелып төште, кыйнавыннан битәр булды бу сүзләр. Мирбат абзый, Фәндәриясенең гадәтләрен яхшы белгәнгә, районга баргач та сүзеннән кайтмасын дип, әлеге камчысын да калдырмады. Бу аның егерме ел бергә гомер иткән хатынына каршы беренче тапкыр күтәрелүе иде. Фәндәрия бит Мирбатны бернәрсә дә белми, муенына гомерлеккә камыт кигездем, үземә буйсындырдым, дип йөри иде. Белмәгән, белмәгән Фәндәрия Мирбатның тымызыклыгын. Тып-тын яткан «апара мичкәсе» әнә ничек күпереп чыкты! Күр, нинди давыл уйнатты.

## 4

Урып-җыю эшләре тәгалләнде. Силос салу, чөгендер алу кебек, соң башкарыла торган эшләр дә тәгалләнеп килә. Туңга сөрелгән мәйданнар күп инде. Быел уңыш шактый мул булды. Арыш, борчак һәм бодай җыйган чакларда көннәр искиткеч аяз һәм җылы торды. Әмма сентябрьнең актык көннәрендә, һич көтмәгәндә, һава чын-чынлап бозылып китте. Башта кара болытлар атна буена авыл тирәсендәге урман өсләрендә йөрде: килде дә яуды, килде дә коепмы койды. Аннары бер-ике көн аяз булып алды. Инде котылдык, калган эшләрне дә тиз арада бетерербез дип шөкер итеп торганда гына авылның төньягындагы тау, аның өстендәге урман артыннан әллә ниткән кургашындай авыр болытлар, берсен-берсе таптап узарга ашыккандай, авыл аркылы үздылар да икенче яктагы урманга кереп югала бардылар. Көннәр бөтенләй сүрәнләнде. Болытлар, теге гасыр ахырында төзелгән, инде күпме еллар буена карт-корыдан башка аяк басмаган мәчетнең биек манарасындагы айга тия язып агыла сыман иде. Кукуруз силослауны туктатып торырга туры килде. Аннары, Мирбат абзыйның гомердә беркем дә булдыра алмагандай сүгенеп йөрүенә түзә алмыйча, механиза-

торлар башта берәм-сәрән, ахырында бөтенесе кузгалып силослауга керештеләр. Машиналар басу буйлап түгел, әллә ничә ел тапталган юллардан да йөри алмыйлар иде, шуңа күрә «Беларусь»ны гына түгел, тар чылбырлы Т-40 лар да, колхозның үз осталары ашыгыч әмәлләгән арбаларны тагып ваклатылган массаны силос базларына ташый башладылар. Әкрен булса да эш бара торды. Күрше колхозлар яхшы һава көтеп яткан арада «Туры юл»ныкылар кукурузның эшен бетерделәр дә терлек азыгына дигән көнбагышның соңгы гектарларына төштеләр.

Шул көннәрнең берсендә райкомның беренче секретаре Василий Александрович Гнедой кайбер хуҗалыкларны йөреп чыгарга булды. Мирбат абзый хатыны Фәндәрияне райкомга алып килгән көннән бирле, аның «Туры юл» җитәкчеләрен күргәне дә, чакыртканы да юк иде. Тимер юл станциясенә үтеп барышлый булса да районның иң ерак почмагындагы ике урман арасында утырган бу колхозга кереп чыгарга теләде Василий Александрович. Юл өстендәге башка хуҗалыкларның эше белән ул яхшы таныш иде. Һәммәсе дә диярлек һава аязганны көтеп, колхоз малларын ашату-савудан бүтән эшләрне туктатканнар. Ә бит әле силос саласы, чөгендерне алып бетерәсе бар. Секретарьның «Туры юл»да да шул ук хәл булса, Мирбат абзыйны быелдан соң калдырырга ярамас дип, ачуы кубыбрак килә иде. Бу сәфәрендә карурманны чыгуга аркылы-торкылы ергаланып беткән буп-буш кукуруз басуын күреп ышанырга да, ышанмаска да белмичәрәк торды ул. Аннары колхозның фермалары кырында өсләре кышлыкка дип яхшылап ябылып куелган дүрт озын-озын базны күргәч район җитәкчесе түзмәде, горурланып үзалдына сөйләнеп куйды: менә бит ул безнең карт гвардия... Ну и ну, Мирбат абзый, җәй буена әрләгән өчен минем дә, һава көтеп яткан башка предларның да борыннарына чиерттең, карт төлке, дип сөйләнде. Ашыгып килеп вездеходына утыргач ул, шоферы авылга таба бора башлаганны күреп:

— Райүзәккә борыл, Шәйхетдин дус,— дип шоферның исен китәрде.— Күрәсең бит... Ну бу Мирбат абзыйны, кара син аны, карт төлкене, ә? Менә, энем Шәйхетдин, шулай эшли белгән кешене, яше алтмыштан узды дип кенә ничек итеп урыныннан төшерәсең ди, ә? — дип шофердан бигрәк үзенә кат-кат тукыды.

Тагын берничә сәгатьтән «сугышчан тревога» белән күтәрелгән колхоз председательләре һәм совхоз директорлары ашыгыч рәвештә райкомның утырышлар залына җыелдылар. Беришләре:

— Безнең Мирбат абзый, егетләр, тәмам чыгырыннан чыкты, исе дә китми утырыш-мутырышларга,— дип төрттергәндәй булды. Алар әле «урман шүрәлесе» Мирбат абзый турында алда ишетәселәрен белми иде.

Гадәттә тыныч, теләсә нинди тәртипсезлек-кимчелекне ахырына кадәр тыңлап бетерә, аннары салмак кына чыгыш ясап, сүзен барысының да җилегенә үткәрә белгән Василий Александрович Гнедой бу юлы үзүзен тыеп тора алмады. Беренче сүзләреннән үк әрләргә, «сафура бураннарын» туздырырга тотынды...

Мирбат абзый исә бу вакытта җылы өендә, хатыны һәм кызы, алар һәм үзе арасындагы мөнәсәбәтләрнең салкынлыгыннан җаны өшегәнгә өстәл артында, башын кулларына салып, хәмер капкалап утыра иде.

Бүген көнбагышны силоска урып бетерделәр. Механизаторларга «бахатой» оештырылды. Председатель шунда ук әз-мәз «җылынып» алды. Кайтуынча правлениегә кереп, бригадирларының баш-аяк каршы торуларына да карамастан, иртәгә бөтен халык — яше-карты, баласы-чагасы, мәктәп укучылары һәм укытучылар — эшкә яраклы һәммә кеше, чөгендер басуында булырга тиеш дип әмер биреп чыкты. Бу көнгәчә «Туры юл»да Мирбат абзый кушканны үтәми калган беркем дә булмады һәм булмас та. Шуңа күрә, соңгы айларда председательнең «җенләнү-

ләрен» яхшы күреп торган партбюро секретаре да «бу нарядны туктатып тор, Мирбат абзый» дип әйтергә базмады. Күренә ки, Мирбат абзый үзе өчен түгел, кешеләр өчен, колхоз өчен тырыша. Үзен кызганмый, бәйгедә яна торган ат шикелле.

Хәзер энә колхоз радиоузелыннан ул кушкан нарядны бирәләр.

Ә Мирбат абзый хәмер капкалап, уйланып утыра. Кичә кичкырын хатыны Фәндәрия белән кызы Тәнзилә ду килеп әйткәләштеләр. Аналы-кызлы түгел, әллә нинди базар хатыннары әйткәләшепме әйткәләшә диярсең. Аннары, әйтәсе сүзләрен тәмам әйтеп, түгеп-чәчеп бетергәч тә, икесе ике якта үкереште. Ниһаять, Мирбат абзыйның бердәнбере Тәнзилә үз бүлмәсеннән чыкты һәм, әтисеннән аз гына да оялмыйча, әйтепме әйтте:

— Әтекәем, бәгърем, зинһар, мине аңларга тырыш, яме. Мин синең йортыңда артык торалмыйм. Әни түгел, аждаһа синең хатының. Син аның бөтен кылганнарын белмисең әле. Син, әтием, кичер, мин... мин авылдан бөтенләйгә китәргә булдым. Нишләгәнемне үзем дә белмичә кылган хаталарыма, хыянәт дияргә телисез икән, хыянәтләремә түзеп, авылдашларым күзенә карап йөри алмыйм. Әгәр дә... әгәр дә җибәрмәсәң... белеп кал: мин законлы хатын, ир хатыны... Мине инештән, су төбеннән... Әтекәем, бәгърем...

Икенче кич инде Мирбат абзый әнә шул сүзләрнең ачысын юа. Хәмер белән...

Иртәгә иртүк бердәнбер кызы китәчәк. Мирбат абзый станциягә үзе илтеп куярга кушты, озатып җибәрергә булды... Хәзер исә Тәнзилә әйберләрен җыештыра, чемоданын тутыра, Фәндәрия үз ягында, кичәдән бирле бикләнеп ята, үксегәне генә ишетелгәләп китә. Ә Мирбат абзый бер гаепсезгә җанын өшетүчеләргә карап хәмер капкалап утыра иде...

## 5

Иртәгә ял көне. Төштән соң шәһәргә җыена башладылар. Унлап солдатка, тырыш хезмәтләре өчен рәхмәт әйтеп бер тәүлеклек ял бирделәр. Шефлар — университет студентлары — тантаналы кичәгә чакырганнар иде.

Гамил башта бармаска уйласа да, Олимҗан белән Саша бик кыстагач, килеште. Зур шәһәрнең сулышын тоеп кайтуы үзе ни тора, диештеләр дуслар.

Ярты юлга җиткәч тә машинаның бер-бер артлы ике көпчәге тишелде. Аларны салдырдылар, запастагы берне һәм икенчесен ямап яңадан куйдылар. Тиз-тиз эшләделәр кебек, әмма ярыйсы гына вакыт узды. Егерме-утыз километр узуга автомобиль тагын тормозларын чыңгырдатып юл читенә чыгып туктады. Егетләр инде нәрсә булды дип капитан Сергеевка карадылар.

— Болай ташбака адымнары белән барсак, иптәш капитан, университет кызлары бүгенге кичәне бездән башка гына уздырып җибәрәчәкләр бит.

— Ну, Гонибеда, машинаңны болай «караганыңны» белсәк, синең белән чыкмаган булыр идек,— диде солдатлар түземсезләнеп.

— Бу юлы, егетләр, көпчәк алыштырып кына китеп булмый. Әнә Гонибеда белән беда...

Дөрестән дә, Гонибеда рульгә башын куеп яткан иде. Солдатлар кабина ишеген ачып аны җиргә бастырдылар, теге исә эчен тотып өзгәләнә иде.

— Ни булды инде тагы, Гонибеда? Нәрсә генә ашадың бездән яшереп?

— Болай булсаң госпиталь, турыдан-туры «пулеметчик»лар ротасына җибәрәбез.

Гонибеда исә теш агартып торучыларга җен ачуы белән карады да, кызгандыргыч тавыш белән ант итте:

— Юууук, егетләр, бер нәрсә ашамадым, ей богу.

— Соң, ип-исән барган җиреңнән.

— Ни булса да булгандыр, егетләр. Может аппендициттыр? Яле машинага, салонга кертеп алыгыз,— дип туктатты шаяртып торучы солдатларны замполит.— Хәзер, хәзер, Гонибеда, доктор булмасак та аң гына чамалыйбыз без.

Гонибеда гимнастеркасын өскә күтәреп куйды, аннары каешын ычкындырып чалбарын бераз төшерде. Капитан аңа салмаска кушты. Теге исә теләсәң нишләргә риза: авырту гына бетсен... Капитан аның уң як бот төбеннәнрәк төштә эчenә дүрт бармагы белән басты да кискен генә җибәрде, кулын алды. Шофер авыртуга түзалмыйча:

— Ой-һой-һой,— дип куйды күзләрен йомып.

Капитан медицинаны солдатларның берсеннән дә артык белми иде әлбәттә. Ләкин аның карап торуга ышанычлы маташуы барысын да тынычландырды: замполит янәшәдә барында аптырыйсыңмы соң?

— Егетләр, шаяртырга урын юк. Мөгаен, аппендициттыр бу. Элек эчең болай авырткаладымы соң?

— Икеме, өчме мәртәбә шулай интектергән иде шул.

Замполит тагы да шөбһәгә төште. Солдатларга карап:

— Кайсыгыз шофер, я булмаса машина йөрткәне бар?

Әмма олы юлда, төрле-төрле автомобильләр кош шикелле очып торганда, авыру иптәшеңнең ыңгырашуын ишетә-ишетә зур тизлек белән барырга...

Замполит, егетләрнең дәшмәгәнен күреп:

— Ярый алайса, үзем утырам. Ну вакыт уза инде, егетләр, мин бик әкрен йөртәм. Безгә һәр минут кадерле бит,— дип кабина ишеген барып ачты.

Гамил тәҗрибәле шофер булуына да карамастан, бер карарга килә алмыйча тора иде. Теге сабак артык кыйммәткә төште. Ләкин бит,— дип уйлап алды ул замполитның рульгә утырырга җыенганын күреп,— тәҗрибәсез капитанның тагын да зуррак бәла китерүе, һәлакәт ясавы ихтимал.

Капитан машинаны кабызырга дип стартерны иләмсез үкертә башлаган иде инде.

— Иптәш капитан, рөхсәт итегез... Утырышыгыз, егетләр, тизрәк...— дип кычкырды Гамил үзе дә сизмәстән. Ике-өч километр арада алдагы машиналарны куып җитеп оста-оста узгалагач та, капитан Сергеев Гамилнең тәҗрибәле шофер икәнлегенә тәмам ышанды. Аннары, шоссеның ремонтлана торган төшен әйләнеп, чокыр-чакырлы җирне саклык белән узгач ефрейторга сорау бирде:

— Нишләп, иптәш Салихов, шофер икәнлегеңне моңарчы әйтмәдең?

Гамил шактый гына дәшми барганнан соң, капитанга карап алды да әйтте:

— Гафу итегез, иптәш капитан. Мин рульгә беркайчан да утырмаска дип ант иткән идем. Авылдагы теге вакыйгалардан соң.

Замполит егеткә карап алды да, авыр көрсенеп:

— Ихтимал, син хаклысыңдыр, Гамил,— дип куйды.

Шәһәр күренә башлагач, каршыда, җир астыннан үсеп чыккандай, көтмәгәндә, автоинспектор күренде. Гамил, әллә күрмичә, әллә туктарга өлгерә алмыйча, аны азрак узып киткәч кенә үзалдына сөйләнгәндәй: «Менә бит» дип, тормозга басты.

Инспектор белән капитан сөйләште, ул салон ишеген ачып, анда

ыңгырашкан Гонибеданы күрсәтте. Милиционер әллә ышанмады, әллә ышанып та шәһәрне белмәгән шофер больница эзләп йөрмәсен дипме, Гамилгә үз артыннан калмыйча барырга кушып, «матаен» кабызып алга төште. Ул хәрби госпитальне күрсәтер өчен барган икән.

Гонибеданы врачларга тапшырган арада милиционер Гамил янына килеп сөйләшеп торды.

— Молодец, оста йөрисең, шоферга укырга кирәк сиңа, ефрейтор,— дип мактады, кинәш бирде. Ефрейторның икенче класслы шофер икәнен ул каян белсен!

Университетта юбилей уңае белән оештырылган тантаналы кичә күптән башланган булып чыкты. Чыгып сөйләүчеләр алмашынган арада капитан Сергеев үз егетләрен, тавышланмаска кушып, актлар залына алып керде. Арткы рәттәге буш урыннарга утырыштылар. Оратор сүзен бетереп икенчесе чыкканчы алар янына кызлар йөгерешеп килделәр. Шефлар — дүртенче курс студентлары икән. Чәчәкле озын күлмәкләр кигән берсеннән-берсе матуррак кызлар исәнләшә-исәнләшә үк, солдатларны аралап урнаша башладылар. Гамил янәшәсенә озын кызыл күлмәгенең күкрәк турысына бизәкләр төшерелгән, чем-кара чәчләрен толымнарга үреп җилкәләренә салган, тулган ай шикелле түгәрәк йөзле, куе каш-керфекле төрекмән кызы утырды. Гүзәлләрнең дә гүзәле диярлек иде ул. Буй-сынына, елмаеп, иркәләп-назлап караган күзләренә сокланмаска мөмкин түгел. Гамил исәнләшүдән башка бер сүз дә әйтә алмас булып югалып калды кебек. Аның куллары, бармакларына карап күпме шулай утырыр, бу кыен хәлдән ничек котылган булыр иде, билгесез. Бәхеткә каршы, Олимҗан янәшәсендәге кыз ярдәмгә килде. Боларның сүз таба алмыйча утыруларын күреп:

— Ә сезнең, иптәш ефрейтор, исемегез ничек? — диде ул ниндидер шаян тон белән.

— Исемем Гамил, ләкин сезгә аны әйтүе кыендыр, мине...

— Нишләп кыен булсын? Менә минем яңа танышымның исеме дә русча түгел, ә мин әйтә алам ич — Олимҗан. Дөресме, Олимҗан? Кыз, җавап та көтеп тормыйча, сүзен дәвам итте:— Мин Төрекмәнстанда үстем, хәтта мәктәпне дә төрекмәнчә бетердем. Без университетта гарәп телен өйрәнәбез. Сезнең исемегез гарәпчәдән әйләндерсәң — эшләүче, хезмәт иясе, дәрәҗәле кеше дигән мәгънәне аңлата, дөресме, Сона? — дип, әле дус кызына карап тезепме тезде. Аннары тагын:— Бәй, сез әллә танышмадыгыздамы? — дип гаҗәпләнде.— Ягез әле, ягез, дуслар, танышыгыз. Рәсми төстә танышыгыз. Сона, нишләп болай утырасың? Әй, сезне, оялышкан булалар тагы...

Хәзер инде кул биреп танышуның кирәге калмаган иде. Зирәк арадашчы шуңа да карамастан үз сүзен дәвам итте: Гамил белән Сона кул бирешеп күрештеләр.

Кичәнең тантаналы өлеше бетте.

Тәнәфестән соң беренче каттагы иркен залда танецлар, уеннар буласы икән. Аңарчы студент кызлар шефларын үзләре укый торган аудиторияләр белән таныштырдылар.

Ничектер үзеннән-үзе шулай туры килде инде, Гамил күпме генә тырышмасын, башка солдатлар арасына кереп югала алмады. Барысының да инде пары бар. Хәтта, замполит үзе дә ялгыз түгел, группа старостасы — барысыннан да тәбәнәгрәк буйлы, бик сүзчән бер кыз белән ни турындадыр бәхәсләшә иде. Кыскасы, Сонаны калдыру тәрбиясезлек, әдәпсезлек булыр иде.

Залда оркестр авазлары яңгырый башлады.' Шеф кызлар солдатларны җилтерәтә-җилтерәтә залга алып төштеләр.

Гамил тагын кыен хәлгә әлакте: ул бии белмим дигәч, Сона нишләргә белмичә аптырап бер читтә калды. Аңа, дип уйлады Гамил, комсомол оешмасы поручение биргәндер инде... Әлеге дә баягы Хәлил бабай

таягы диләр иде Гамилләр авылында — Олимҗан Светланасы бу хәлдән котылу юлын тапты. Сона янына килде дә ул:

— Егетне әнә тегендәрәк, аулаграк якка алып китеп, биергә өйрәтергә кирәк, җаным,— диде. Светлана групкомсорг икән. Кичә беткәндә инде Гамил, Сонаның искиткеч тырышлыгы һәм түземлелеге белән, шактый шома бии дә башлаган иде.

Башта Сона алдында югалыбрак йөргән егет, тора-бара кыюланды. Русча-татарча-төрекмәнчә сүзләр теле ярдәм итте бугай... Соңыннан, юлда кайтканда да егетләр: Гамилнең эше уңмас иде дә бит, ул өч телдә берьюлы сөйләште,— дип көлештеләр.

Танцылардан соң яшьләр шәһәр урамнары буйлап шактый йөрделәр. Әллә нинди темалар табып әңгәмә-бәхәсләр куптардылар. Әдәбият һәм сәнгатькә кагылышлы сүз чыккан саен Гамил үзенең «надан»лыгыннан оялды, искиткеч күп нәрсәләрдән хәбәрдар булмавын тоеп, Сона алдында хур булмагаем дип коты алынып атлады. Ләкин кыз, ул уйлаганча, үзен Гамилдән өстен куярга уйлап та карамады. Озын керфекләрен сирпеп торган саен сихрилеге арта барган күзләре елмайды, аннары ягымлы, йомшак күкрәк тавышы белән я русча, я төрекмәнчә җавап бирде. Ә инде паркта аллеялар буйлап йөргәндә Гамилне үзе култыклап алды. Бөтен дөнья, тормыш тоташтан искиткеч матур, күкләр гел аяз торадыр төсле тоелды ул минутларда Гамилгә. Яшәве, менә шундый аңлы-белемле гүзәл кызлар белән зур шәһәр урамнарында йөрүе, бернинди борчуларсыз атлавы рәхәт тә иде соң!

Яшьлек, гашыйклар күңеле шикелле, әйтеп тә, аңлатып та бирә алмаслык гүзәл чак бит син. Син ул, Яшьлек, син булмасаң, кеше кичергән авырлыклар, җитди сынаулар, күңеленнән бер дә китмичә, аның гомер буе интектерер, газапланырга дучар итәр иде. Син ул, Яшьлек, яшәвебезне күркәм, кызыклы һәм тирән эчтәлекле итәсең. Син ул, Яшьлек — тормыш дәвамчысы. Син ул, Яшьлек, бөтен хыяллар, бөтен эшчәнлекләр һәм батырлыклар чыганагы. Син ул, Яшьлек — мәңгелек. Менә шуның өчен дә син, Яшьлек, җир йөзендә атом һәм нейтрон бомбалары шартлавын күрмичә яшәргә хаклысың!

## 6

Тәнзиләдән хат-хәбәр юк.

Почта килгән минутларны Гамил аеруча кыен кичерде, аеруча борчылды. Аннары читкә китеп баса яки бер-бер эш таба торган булды. Ләкин әле бер генә кешенең дә үз-үзеннән качып котыла алганы юк. Кая гына бармасын — күккә менсә дә, җир астына төшсә дә — кеше күңеле һәм йөрәгендәге яра эзләре юкка чыкмый. Солдатларның хат ташучы янына ашыгып-ашкынып баруларына, кайберәүләрнең шатлыклы хәбәрдән кинәт яктырып киткән йөзләрен, икенче берәүләрнең хат эчендәге хәбәрне бүтәннәр белән уртаклашканын күргәч тә тетрәнеп куя Гамил. Юк юкта үз фамилиясен дә кычкырганны көтә иде ул. Соңрак көтмәс булды, өметен өзде, күңелен җилкендермәскә тырышты.

Ә университет кичәсендә булып, Сона белән танышып кайткан көннән соң егетнең дөньясы кинәт яктырып китте кебек. Күңел түрендә сүнәр-сүнмәс кенә үрмәләгән хисләр уяна башлады. Нәрсә генә эшләсә дә яхшырак, тизрәк башкарасы килде. Егетләр белән сөйләшер сүзләре дә күбәйде. Станциядәге эшләрне нинди дер шат авазлы җырлар көйли-көйли, элекке белән чагыштыргысыз җиңеллек белән үти башлады.

Шул хатирәләр белән рухланып йөргәнгәмедер, хәтта вакыт агышы да тизләнде кебек.

Атышта беренче тапкыр катнашу Гамил өчен аеруча җаваплы, күп көч куюны, барлык эшләрнең тәртибен ялгышуларсыз белүне таләп ит-

кән имтихан әле. Ул моны яхшы төшенә. Вакыт белән һич исәпләшмичә, станциядә, сызым китаплары белән «җенләнеп» утырды. Көндезләрен башка операторлар белән шөгыльләнде, шкафларны, системаларны кабат-кабат тикшерде. Күнегү арты күнегүләр узды. Кайбер төннәрне хәтта төшендә дә кайсы тоташтыргычның кайсы төштә, командаларны нинди тәртиптә башкарачагын ап-ачык, кинодагы сыман күреп ята башлады.

Болытлы күңелне кояш булып яктырткан Сона хатирәләре балкышы да көчәйгәннән-көчәя барды. Тагын шәһәргә барасы, Сонаны күрәсе, аның белән сөйләшәсе, шәһәр урамнарыннан үтәсе гел килеп торды. Инде киләсе якшәмбе көнне увольнительный сорыйм дип тагын дә канатланыбрак йөргәндә, озакламый полигонга китәчәкләре билгеле булды. Киеренкелек тагын да артты, шәһәргә киту түгел, ял вакытын да кыскартырга туры килде. Көннәрне төнгә ялгап яши башладылар.

Әйләнә-тирәдә сихри бер күренеш иде. Очлы борыннарын югарыга калкытып торучы ракеталар ирексездән куандыра, күңелләрдә горурлык хисе уята. Шушы мәгърур көч-куәт янында басып тору, алар белән идарә итәргә өйрәнү — бу бит илең күрсәткән зур ышаныч.

Ефрейтор һавага чыккач та җир өстендә көнме, төнме икәнлеген аера алмыйча торды кебек. Чынлап та, моны төшенү бик үк җиңелдән түгел иде. Кояшны әллә кургаш болытлар, әллә тау тезмәләренә таба өерелеп килгән тузан баганалары томалаган иде. Аның сизелер-сизелмәс күренеп, зураеп тәгәрәвен чамаларга гына мөмкин. Ә бер мәлне тирә-юньдә бер нәрсә дә күренмәс булды, җир өстенә искиткеч бер тизлек белән караңгылык иңде, күк күкри, яшен яшьни башлады. Гамил бу күренештән хәйран калып:

— Безнең якларда, иптәш капитан, мондый чакта яңгыр ява, чиләкләп коя,— диде.

— Хәзер бит, ефрейтор, биредә дә менә чынлап та көчле яңгыр ява,— диде капитан. Гамилнең моңа ышанмыйча, яңгыр таммыймы дип, кулын тузан өермәсендә тотуын күргәч ул көлеп җибәрде. Аннары җитди итеп өстәде: — Әйе, гаҗәп тоеладыр сиңа, ефрейтор, ләкин чынлап та яңгыр коеп ява! Әмма дымы аның атмосфераның иң өске катлауларында калып, кояш нурларының чамасыз кызулыгыннан парга әверелә, җиргә кадәр төшеп җитә алмый. Ягъни үзенә күрә бер төрле «һава мендәре» хасил булып, дымны үзенә сеңдерә дияргә мөмкин. Монда, чүлләр илендә, бу яңгырны — «коры яңгыр» диләр. Без аны күрмибез, тоймыйбыз.

Гамил моңа бик гаҗәпсенде. Яңгыр таммый да, ә «коеп ява» имеш... Эченнән генә: Сонадан берәр төрле әдәбият сорарга булыр, университет китапханәсендә бардыр әле,— дип уйлап куйды. Бу уй аны шатландырды-канатландырды да. Чөнки шәһәргә бару өчен сәбәп кирәк. Сонага да шулай әйтергә мөмкин булачак.

Ефрейторны кабинага чакырдылар. Гамил ашыгып менде дә үз урынына барып утырды. Динамикларда операторлар һәм расчетлар биргән докладлар ишетелә.

— Дальность...

Гамил дә бер билгеле тәртип белән, ләкин хәлнең киеренкелегеннән бераз дулкынланып микрофонын алды. Эш арасында гына сәгатенә күз төшерде. Хәзер минутлар түгел, секундның һәр мизгеле исәптә.

Станциягә беренче тапкыр кергән кешегә хәтта тәртипсез ишетелгән шикелле тоелачак докладлар бертоташ булып яңгырый иде.

— Перрвый готов...

Ефрейтор да әзерлекне тәгәлләве турында рапорт бирде.

— Дивизион әзер!

Майор бөтен составка ишеттереп:

— Молодцы, бөркетләр! — диде.

Аңа берәү дә җавап кайтармады. Хәтта аңа әйтеп бетерергә дә ирек бирмичә, яңадан-яңа тавышлар ишетелде:

— Высота...

Бөтен бер дивизион, бер кешедәй булып, күтелмәгән «цель»не зур төгәллек белән каршыларга әзерләнә иде.

Ефрейтор индикатордагы сизелер-сизелмәс аксыл нокта-сызыкларга күз алмалары авырта башлаганчы текәлеп карады. Менә, менә... Болар «дошман» самолетларымы, яисә алар җибәргән «помех»лармы? Хәзер үк, инде әйтелгәнчә, секундның бер мизгеле эчендә Гамил әнә шуны, төп-төгәл, ялгышмыйча билгеләргә тиеш. Тиеш, тик.., нишләптер, ефрейторның тавышы ишетелми. Әллә ул «дошман» самолетларын «помех»лардан аералмыймы? Әлбәттә, тәҗрибәсезлек нәтиҗәсендә мондый чакта ялгышулар бик мөмкин. Тик бит әле хәзер «цель»нең кемнеке икәнлеге мәгълүм түгел. Импульслар бер төрле бит, сызыклардан гыйбарәт дип утырасыңмы?

Майор Ховренконың бөтен гәүдәсе урындыгы белән берга ефрейторга таба әйләнде. Ул ашыктырмады. Ләкин аның йөзендә түземсезлек чаткылары сизелә иде.

Олимҗан Гамилгә иң якын утырган кеше. Дусты аның аркасына орынып диярлек эшли. Ул да дустының зур сынау тотканын, киләчәк атышларга бару-бармавы, аның отделение командиры буларак язмышы хәл ителгәнне аңлый. Тик берничек тә ярдәм итәлми иде шул. Олимҗан, киеренкелекнең соң чиккә җитүен, иң соңгы мизгелләр узып барганны бөтен җаны-тәне белән сизеп кечерәеп калгандай булды. Кулындагы кечкенә штурвалын бар көченә кысты. Көчле тавыш аны кинәт чынбарлыкка кайтарды:

— Иптәш майор, «дошман» помехаларсыз килә.

Олимҗан аңлады. Бу Гамил доклады иде. Операторлар, сөйләшеп куйгандай бердәм кубып, тагын докладлар яудыра башладылар:

— Дальность...

— Первый готов!

Бу командалар һәм докладлар һич икеләнмәслек төгәл, ышанычлы иде. «Цель»ләр якынлашканнан якынлаша инде. Ракета җибәрү мизгеле җитеп килә. Солдатларның гына түгел, офицерларның да маңгайларына салкын тир тамчылары бәреп чыкты. Бөтен позицияләр өстендә майор Ховренко тавышы ишетелә башлады. Тагы берничә секундтан иң соңгысы — «пуск» командасы яңгыраячак.

Әмма... Майор Ховренко киеренкелектән кырысланган тавыш белән «отбой» командасын бирде.

Ефрейтор, кирәкле тоташтыргычларны күчерә-күчерә, маңгаендагы тир бөртекләрен җиңе белән сөртеп алды. Бурыч уңышлы башкарылды. «Дошман» үтмәде, «юк ителде». Әмма сугышчан обстановкада, әгәр дә син идарә пультында утырасың икән, тәҗрибәң бармы, син каушадыңмы-юкмы дип сорамаячаклар, әлбәттә...

7

Помгаклау утырышына кадәр кичке ашны ашап, душка кереп коеныпчыгарга өлгергән Гамил инде үз хәрәкәтләрен, ким дигәндә, йөз мәртәбә генә күз алдыннан кичергән иде. Душтан соң киенгәндә аның янына Алимҗанов килде.

— Син, Омилбой, беләсеңме нишләп ялгыштың,— диде.

— Әйт, Олимҗан...,

— Син, Омилбой, тойгы вә кичерешләрне тоймадың. Мөмкин кадәр

яхшырак кирәк дип ойладың. Төп гаебең ул түгел... Син, Омилбой, төрекмән кызы Сонаны сагынып утырдың мәллә...

Гамилнең бу сүзләрне ишеткәч исе китте. Гаҗәпләнүдән барлык арыганнары, ишетергә тиешле үгет-нәсихәт юкка чыкты. «Менә сиңа, мә! Олимҗан, минем халәтне үземнән яхшырак белә түгелме соң»,— дип үчекләде ул үз-үзен.

Димәк, Гамил оператор буларак, техниканы яхшы өйрәнсә, үзләштерсә дә, тәҗрибә тупларга, осталыкны тагын да арттырырга тиеш икән әле. Үзең белү, бөтен операторларны ишетү генә аз, обстановканы анализлый белергә дә кирәк. Операторларның бердәм, бер уй, бер хәрәкәт белән эшләвенә, ялгышларны үз вакытында ачыклый белүләренә дә ирешергә кирәк. Моның өчен укырга, хәрби училищега керергә кирәктер, әлбәттә... Капитан Сергеев бит, без сине, Гамил, озакламый партиягә алачакбыз дигән иде... Их, сынаттың, дус кеше, сынаттың.

— Хак сүзләрме, Олимбой?

— Хак сүзләр, әлбәттә, хак сүзләр, Олимҗан кадерлем.

Йомгаклау утырышында майор Ховренко ефрейторны аягүрә бастырды да:

— Салихов, бүгенге ялгышыгызга ничек карыйсыз? Кем гаепле? Аңлатма бирегез,— диде.

— Иптәш майор, гаеп миндә. Бары тик үзем гаеплемен.

— Нәрсәдә соң гаебегез?

— Беренчедән, иптәш майор, мин хәлнең кискенлеген аңлап бетерә алмадым.

— Дөрес... Ә икенчедән?

Гамилнең икеләнеп торуын күреп капитан Сергеев:

— Әйтеп бетерегез, Салихов. Сугышчан эшкә анализ ясаганда вактөяк булмаска тиеш,— диде.

— Икенчедән, хәлиткеч вакытта минем уйларым таркауланган, өлешчә читкә киткән иде. Гафу итегез, иптәш майор.

Командир бу юлы да Салихов биргән җаваплардан канәгать калды. Ул йомгаклау сүзендә барлык кимчелекләрне ачты, ефрейторга болай диде:

— Салихов үзен класслы специалист, сәләтле кече командир итеп танытты. Тиешле хәзерлек узса, менә дигән офицер булачак. Аның бүгенге ялгышына килсәк... Контроль атышлар вакытында ул аларны кабатламас дип ышанырга кирәк.

Ул сүзен очлап бетерә алмады. Бөтен тирә-юньне, ничәмә-ничә гасырлар буена тыныч яткан даланы, янәшәдәге тау тезмәләрен яңгыратып сирена уйнап җибәрде. Салихов штабтан атылып чыкты да, офицерларны узып, олы адымнар белән кургаш болытлардан арынган күк йөзен айкап утырган станциягә таба ыргылды.

Бөтен дивизион, аның бер сугышчысы ефрейтор Салихов һәм аның дуслары өчен иң җитди, иң катлаулы сынау башлана гына иде әле.

## 8

Позицияләр ягына таба бар көченә йөгерүчеләр футбол мәйданы өстенә төшәргә җыенучы вертолетны баштагы мәлдә күрмәделәр. Ләкин ят тавыш аларның игътибарын җәлеп итте. Сугышчыларның кайберләре тукталып калгандай булды. Салихов аларга:

— Алга, алга, иптәшләр, кичекмәстән алга! — диде дә үзе, үрнәк күрсәтеп, тагын да катырак йөгерә башлады. Аның артыннан башкалар да дәррәү кузгалып киттеләр.

Салихов отделениесе генә түгел, бүтәннәр дә тиешле вакытта үз

урыннарына килеп, хәзерлек эшләрен башкардылар, системаларны сугышчан хәлгә китерделәр.

Гамил дулкынлана, ләкин каушамый иде. Ул хәлиткеч имтихан сәгатьләре җиткәнне бөтен күңеле белән тойды. Яңәшәдәге солдатлар, бигрәк тә Олимҗан, аеруча бер җитдилек, җаваплылык сизеп үз вазифаларын тавыш-тынсыз гына башкара, һәммәсе ефрейторның һәр сүзен кичекмәстән үтиләр. Әле кайчан гына, үзен отделение командиры итеп билгеләгән көнне, ефрейтор Салихов «минем белән бер кашыктан ашап, бергә йоклап, бергә нарядка йөргән иптәшләр сүземне тыңлармы» дип икеләнебрәк уйлаган иде. Хәзер инде ул яңәшәдәгеләрнең җитди кыяфәтләренә карап үзенең ялгышканлыгын ачык аңлады. Соңгы айлардагы тырышлык, сугышчан бурычларны үтәүгә хәстәрләнүен, дисциплинаны ныгыту өчен барган социалистик ярышның нәтиҗәләре шәптән күренә.

Тирә-якта төгәл көйләнгән, инде ничәмә-ничә мәртәбә тикшерелгән аппаратураның салмак гөжләве ишетелеп тора, дизельләр дөп-дөп килә. Мәңгелек дала да инде боларның бөтенесенә күнегеп килә.

Ачык ишектә командир, аның артыннан әле таныш булмаган бер полковник күренде. Бу — яңалык иде. Димәк... Полковникның кырә-кырешкә үк командирларга биргән боерыгы ишетелде. Шул ук мизгелдә ул сүзләрнең мәгънәсе бөтен сугышчыларны кинәт җитдиләндерде, оператор Филимонов хәтта, каядыр җыенгандай, урыныннан торгандай итте, әмма тиз арада әйләнмәле урындыгына сеңде. Әлеге боерык буенча дивизион һич кичекмәстән өйрәнүләр барган районга китәргә тиеш иде.

Олимҗан шунда ук ефрейторга карап куйды. Бу карашның зур мәгънәсе бар иде. Моннан берничә көн элек кенә уздырылган бер күнегү вакытында ул:

— Безгә станцияне урыныннан күчерү нәрсәгә кирәк инде, юкка бимазалыйлар,— дип сукыранып алды. Бер дә генә «юкка» булмаган икән. Салихов исә бу берничә минут эчендә үзләре башкарырга тиешле эшләрне, барлык вак-төякләре белән күз алдыннан кичерергә өлгерде. Бераздан моның файдасы тиде...

Күк йөзен караңгы болытлар томалап алды, күзгә төртсәң күренмәслек төн җир өстенә ябырылып ятты. Каршы атлаган кешене аяктан егарга тырышып искәндәй көчле кайнар җил тынмады. Шулай да сугышчылар билгеләнгән вакытка станцияне юл хәленә китереп, күченү чорындагы барлык машакатьләрне җиңеп походка әзерләнделәр. Ял итәргә туры килмәде, шлагбаум алдында тезелгән колонна алдындагы «газик» кузгалып китте. Аның артыннан куәтле двигательләре белән үкерешә-үкерешә автомобильләр һәм тягачлар да билгесез караңгылык эченә кереп чумды.

Көндезге күнегүләр киеренкелегеннән, соңгы сәгатьләрдәге машакатьләрдән арыган солдатлар бераз тын алырга мөмкин дип уйлаганнар иде. Ләкин алар урыннарында җайлап утырырга өлгерер-өлгермәс борын, баягы полковник — арадашчы ихтыяры һәм әмере беләндер, күрәсең, дала уртасында каршы як — «яшелләр» разведкасы белән бәрелештеләр. Башта тиз генә котылырга уйласалар да, «яшел»ләр калышмадылар, ниндидер максат белән колонна артыннан баруларын дәвам иттеләр. Майор Ховренко, билгеле, «яшел»ләр разведкасын үз артыннан ияртеп бара алмый иде. Колонна бермәл туктап калды. Ул да түгел, алдагы автомобиль ягыннан:

— Ефрейтор Салиховны «Сокол-1» чакыра,— дигән боерык ишетелде. Гамил «бу ни бу?» дип уйлап алды да, үз урынына рядовой Алимҗановны калдырып, колонна буйлап алга таба йөгерде.

— Иптәш майор, ефрейтор Салихов сезнең боерык буенча килде.

Майорның йөз кылбәте моңарчы күргәндәгедән күп җитди, кырыс

иде. Шул ук мизгелдә командир машинасы артыннан килеп чыккан полковник күренде. Салихов кичекмәстән:

— Иптәш полковник, майорга мөрәҗәгать итәргә рөхсәтме? — дип әйтеп салды. Ефрейторның житезлеге, хатасын бик тиз аңлап, төзәтергә җөрьәт итүе полковникка ошады булса кирәк, ул аңа сынаулы караш төшереп алды да:

— Рәхим итегез, рәхим итегез, ефрейтор,— дип, ризалык бирде.

Майор Ховренко исә кулындагы «командирскиена» карап алды һәм ефрейторны кабинага чакырды. Анда тонык кына «тычкан уты» яна иде. Командир, итәгендәге планшетка кулындагы карандаш белән суккалап:

— Салихов, сезгә гаять житди задание йөкләнә. Сезнең отделение «яшел»ләр разведкасын кимендә бер сәгатькә тоткарларга, ә аннары төп колоннаны куып тотарга тиеш. Очрашу урыны — менә монда... исемендәге колхозның ындыр табагы янында. Аңлашылдымы?

— Так точно, иптәш майор.

— Ашыкмагыз, ефрейтор. Ә безнең колоннаны ничек итеп куып тотарга уйлыйсыз?..

Ефрейтор бу сораудан аптырап калды. Чынлап та, колоннаны җәяү куып тоту, житмәсә дошман разведкасын тоткарлап шактый вакыт үткәргәннән соң, бик четерекле мәсьәлә булачак иде. Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, «яшел»ләр дә бу далада җәяү йөрми торганнардыр.

Ховренко ефрейторның уйларын аңлады бугай, ул:

— Менә монда, иптәш ефрейтор,— дип карандашы белән планшеттагы картага төртеп күрсәтте,— сезне тягач көтәчәк. Нәкъ бер сәгать утыз биш минуттан сез аның янында булырга тиешсез.

— Үтәргә рөхсәт итегез, иптәш майор?

Командирның йөзендә сизелер-сизелмәс елмаю чагылып алды, ул Салиховка ышана иде.

— Үтәгез!

Салихов машинадан чыкты да артка, үз отделениесе калган якка йөгерде. Ул арада, командирның тавышсыз командасына буйсынып, колонна тагын кузгалып алга юл алы. Аның соңгы кызгылт утлары озакламый күздән югалды. Тирә-якта бары тик усал җил генә бөтерелә, кайдадыр гүләгән двигательләр тавышын ерагайганнан-ерагайта иде.

Отделение ефрейторның бер түгәрәккә җыеп, пышылдап биргән боерыгын җиренә житкереп үтәргә әзер иде. Шуңа күрә әле генә дивизион колоннасы узып киткән канал аша салынган күперне арканлау озакка сузылмады, егетләр кыр кәҗәләре сыман житезлек белән үз урыннарына таралыштылар. «Яшел»ләр разведкасын каршыларга әзерләнделәр. Хәзер исә ефрейторны бер генә нәрсә борчый, ул да булса, колонна артыннан эзәрлекләп килүче «яшел»ләрнең мондагы юлны гына түгел, тирә-юньне гомумән белү-белмәве ничек икән? Әгәр алар озакламый үзләренең каналга килеп төртеләселәрен белсәләр, аны нәкъ монда чыкмаулары бик ихтимал. Димәк, ул очракта аларны көтеп бирегә уздырган вакыт әрәмгә үтәчәк.

Сул яктан, Олимҗан көткән борылыштан, һич көтмәгәндә әллә нинди ят тавыш ишетелде. Чүл бүресенең улавы иде бу. Ефрейтор, үз янындагы Филимоновның өстенә иелә төшеп:

— Василь, тизрәк Алимжанов янына шуыш, икәүләшеп каршы тору җиңелрәк булыр,— диде.

Филимонов карагай-карагай күренеп торган чәнечкеле үлән куаклары арасыннан Алимжанов янына ашыкты. Кинәт ул яктан атыш тавышы да ишетелде. Ефрейтор моңа бик шатланды, чөнки «яшел»ләр разведкасы аларны читләтеп узмаган, димәк, алар монда бушка калмаганнар булып чыкты.

Санаулы минутлар тиз үтә. «Яшел»ләрнең әле бер, әле икенче як

тан әйләнеп узарга тырышып та, заслон аша үтәлмәячәкләрен төшенеп, тынычланып калган минутлары иде бу отделениенең. Гамил командирның вакыт турындагы кисәтүен исенә төшерде. Кулындагы сәгатен күзләренә якынайтып, җентекләбрәк караса — бер сәгать вакыт үтеп тә бара... Кичекмәстән кузгалырга, билгеләнгән урынга, үзләрен көтеп торган таягач янына ашыгырга кирәк иде. Шулай да, ефрейтор ашык-пошык китеп баруның файдасызлыгын төшенде. Берәм-берәм чигенергә, ара-тирә берәр тапкыр атып та калырга кирәк, дип уйлап алды ул. Аннары, бая сөйләшкәндәгечә, чүл бүресе тавышы белән Олимҗанны чакырды. Башта Филимоновның сугыш уенына мавыгып шуышып килгәне күренде, аннары Олимҗан да килеп җитте. Салихов аларга планны аңлатты, каналның теге ягына берәм-берәм чыгарга, анда башкаларны көтәргә кушты. Үзе уң флангтагыларны чакырырга шуышты.

Алар күпернең теге ягында очрашып юл читендәге канауның ике ягыннан бардылар-бардылар да, бергә кушылып, сул яктагы юлга чыктылар һәм тагын кинәт борылып төньякка таба киттеләр. Күпер ягыннан мотор тавышы ишетелә башлаганда алар инде еракта каралып торган каралтыларга таба бар көчкә йөгерәләр иде. Ярый әле, безнең тягачка утырып киткән тавыш «яшелләргә» ишетелмәячәк, дип уйлап алды Салихов, егетләр артыннан йөгерә-йөгерә, чөнки җил безгә каршы яктан исә, димәк, ул да безнең яклы иде.

Майор Ховренко гына түгел, арадашчы полковник та, заслонга җибәрелгән отделениедән канәгать иделәр.

Тагын бераздан кичә башланган көчле кайнар җил тынып калды. Артта, көнбатышта, төн куелыгы карала барып, көнчыгыш офык читләре сизелер-сизелмәс кенә болытлардан арына башлаганда, дивизион колоннасы зур тизлек белән билгеләнгән районга якынлашып килә иде инде.

Юлның соңгы ун-унбиш километрын Салихов белән Филимонов җилкәләре белән бер-берсенә терәлеп утырган килеш йоклап уздылар. Алар тягачның билгесез диварга төртелгәндәй кинәт туктап калуыннан түгел, ә бәлки моңарчы үзләре ишетмәгән, кыска, ләкин искиткеч аңлаешлы:

— Комплексны әйләндереп куярга! — дигән боерыктан уянып киттеләр.

Таң аткан, ерактагы офыктан яңа туган ай сыман булып кояш чыгып килә иде. Салкынча. Тирә-юнь тыныч, әйтерсең, төннең-төн буена көчле җилләр исмәгән дә, озын юллар үтелмәгән.

Әлеге боерыктан бөтен колонна берьюлы умарта күче шикелле хәрәкәткә килде: куәтле тягачлар үкерешә-үкерешә техниканы төрле якка тарата башлады, солдатлар юан-юан кабельләр сузалар, аннары ашыга-ашыга аларның озынча җәйпәк башларын бер-берсенә тоташтыралар, шунда ук күрер күздән яшерү чарасын да күрәләр иде. Әле анда, әле монда командирларның кыска, ләкин кискен, икеләнергә урын калдырмый торган өзек-өзек командалары ишетелеп торды. Һәммә нәрсә үз тәртибе белән, андый-мондый буталыш-фәләнсез бара — кыскасы, зур коллективның моңа күнүнәрне төнгә ялгап хәзерләнүе сизелеп, күренеп тора иде.

Салиховлар отделениесенә икеләтә киеренкелек белән эшләргә туры килде, чөнки алар командирның гына түгел, арадашчының да күз алдында, янәшәсендә кайнашалар. Күрәсең, яшьлегенә карамастан, чигәләренә чал суккан ефрейторның төнлә тапшырылган бурычны төгәл үтәве, хәзер дә аның каушавы һич сизелмәгән тавыш белән идарә итүе, аңа карата ышанычны тагын арттыргандыр. Полковникның әлегә бу отделение эше белән генә түгел, барлык дивизионның хәрәкәтеннән канәгать булуы сизелеп тора.

Шуңадырмы, ул, әледән-әле сәгатенә караштыргалап:

— Булдырасыз, булдырасыз, Василий Степанович. Дөресен әйтим, миңа болай ук булыр димәгәннәр иде. Иркенләп эшләгез, вакыты житкәч тә мин үземне сездерермен әле,— дип елмаеп куйды.

Ансы, әлбәттә, билгеле инде. Ләкин нинди генә командир үзенең жилкәсендә арадашчының сулышын тоеп йөргәндә тыныч, битараф күңел белән йөри алыр икән? Майор Ховренко исә андыйлардан түгел дә түгел инде.

Тагын күпмедер вакыт үтте. Ике тапкыр «һава» тревогасы бирелгәнне санамаганда, дивизионның хәзерләнүенә башка комачау булмады. Василий Степанович Ховренко озакламый үзенә тиешле урынга кереп утырды да станцияне әйләндерүчеләрнең доклад-рапортларына колак сала-сала иң соңгы, иң җаваплы имтиханга хәстәрләнә башлады.

Станцияне хәзерләү, аның барлык системаларын сугышчан атышка хәстәрләү тәгәлләнде, тикшереләсе урыннары тикшерелде, кешеләр үз урыннарына урнашып, хәлиткеч минутлар алдыннан тынып, ничектер басынкыланып калдылар. Капитан Сергеев һәм аның егетләре өчен бик тә кирәкле минутлар иде бу. Агитаторлар, кай арададыр, «сугышчан листок»лар чыгарып әлделәр. Анда ефрейтор Салихов отделениесенең төнге заданиене ничек үтәве турында язылган кыска мәкалә дә бар иде. «Кай арада өлгергәннәр дә кемнән сорашып белгәннәр соң болар» дип уйлады Гамил «сугышчан листок»ны күргәч.

Бары тик үзенә генә мәгълүм уйлар кичереп утыручы арадашчы сискәнеп китте, кулындагы сәгатенә карап-карап алды, аннары урыныннан торып арлы-бирле йөрештергәләп алды да майор Ховренко артында туктап операторларның эшен күзәтеп торды. «Моның болай дулкынлануы юкка гына түгелдер», дип уйлап алды Салихов. Икенче мизгелдә динамикта көчле, бераз калтыранган тавыш ишетелде:

— Вижу цель! Цель в воздухе!

Гамил алдындагы индикатор пыяласын күз карашы белән тишеп, бораулап чыгардай булып бер ноктага төбәлде. Радио белән идарә ителә торган «цель»-мишень иртәнге һава агымын ярып, сәгатенә мең километрга якын тизлек белән якынлаша иде. Аны «тотарга», кулдан ычкындырмаска кирәк. Ләкин экранда ни бу, ни? Анда ишеп-актарылып ябалак кар ява. Мондый экраннан бердәнбер дөрес «цельне» ничек табарга да ничек кенә ялгышмаска соң? Ә ялгышырга, беркөнгедәй хаталанырга ярамый иде. Моңа бүген беркемнең дә хакы юк, чөнки зур коллективның эше, намус эше, илне сакларга хәзерлеге тикшерелә.

Гамил алдындагы кечкенә штурвалны салмак кына, сизелер-сизелмәс кенә боргалый башлады, ниһаять, ул күренер-күренмәс бердәнбер дөрес «цель»не күреп алды. Ул чамасыз тиз якынлаша иде.

— Есть «цель»! — Гамилнең күзләренә әллә нинди яшь тулгандай булды. Бу горурлык та, кичергәннәре өчен әрнү дә, киләчәгенең яктылыгы өчен шатлану да иде.

Ләкин ул иртәрәк куанган икән әле. Байтактан бирле үзенең барлыгын «оныткан» кешеләрнең исенә төшерим әле дипме, арадашчы полковник:

— Төбәүче офицер сафтан чыкты. Сезнең карар, иптәш майор!— диде. Ефрейтор алдындагы «цель» бер читкә тайпылды, ул урынына сеңәрдәй булып китте.

— Ефрейтор Салихов! Төбәүче офицер вазифаларын үтәү сезгә тапшырыла. Үтәгез!

Арадашчы моннан да катлаулы, моннан да куркынычрак нәрсә уйлап таба алмый иде, билгеле. Ләкин бу хакта уйлап бер генә секундны да әрәм итәргә ярамый. Ефрейтор үзе «есть» дип әйтеп өлгергәнче урыннан торды да, һич көтмәгәндә «һәлак булган» тере офицерның са-

тышлы күзләренә карады. Аннары үзенкеннән зуррак, киңрәк индикатор каршына утырды. Монда аның өчен бер генә сер дә юк иде сыман. Тик күнегүләр вакытында эшләү бер нәрсә, ә бөтен бер подразделениенең язмышы кыл өстендә торганда...

Мизгелләр... Нинди күп мәгънәгә ия сез! Кеше дигәнең күз ачып йомган арада ниләр кыла ала? Бик күпне. Моңа төнге йокыларын, ару-талуларын онытып, дөньяда бары тик бер максат белән яшәүчеләр, ул да булса — туган илнең иминлеген сакларга баскан гап-гади ләкин, ай-һай, гади түгел! — солдатлар сәләтле. Моның өчен илен яраткан, аның идеалларына чиксез бирелгән кешеләр батырлыгы кирәк.

Күпме мизгел үткәндер, ә ефрейтор Салиховның башлангыч мәгълүматлары әзер иде инде. Ә өйрәнүләр барган районга кара гәүдәсенең эче үлем белән тулы «цель» якынлашканнан-якынлаша бара. Әнә ул инде атып төшерү зонасында. Салихов тирән итеп, озакка җитсен дип сулыш алды да, барлык кыюлыгын җыеп ракетаны җибәрергә рөхсәт сорады. Тагын берничә мизгел... Ләкин нинди мизгелләр алар? Кешеләр, илләрнең язмышын хәл итә торган мизгелләр түгелме соң?!

Тынлык, шомлы, җан тетрәткеч тынлык...

Җилкәләренә искиткеч авыр йөк күтәргән командир — майор Василий Степанович Ховренконың бер сүзе, бары тик бер генә сүзе кирәк. Менә ул:

— Пуск!

Тирә-як, мәңгелек дала, гөрселдәүләргә күмелә.

Ефрейтор Салихов алдындагы экранда, әле кайчан гына үз урынында тып-тыныч яткан ракета күренде. Ул инде иртәнге һава тыгызлыгын ярып язмышы хәл ителгән «цель»-мишеньгә таба ашкына һәм аны туктатырдай көч юк иде. Электр белән эретеп ябыштыручы кулындагы электродның икенче тимергә тиеп киткән чагындагыдай ялтырап чыккан чаткылар, ниһаять, төрле якка сибелде.

— «Цель» бәреп төшерелде!

Барча сугышчылар да, майор Ховренко үзе дә берьюлы урыннарыннан сикереп тордылар. Көчле «Ур-ррра!» тавышы ишетелде.

«Тагын бер сынау үтте. Ә алда тагын күпмесе көтә торгандыр әле»,— дип уйлап алды ефрейтор Салихов. Аның битендә ике бөртек көмеш тамчы тәгәри иде.

## Эпилог

Кояшлы көннәргә, шифалы яңгырларга туенган сусыл үләннәр үсеп җитеп бүген-иртәгә печәнгә төшәр чак иде. Урман читенә урнашкан авыл кыркапкасына, тузан туздыра-туздыра, зәгъфран төсендәге «Жигули» килеп керде. Ул, йомшак тирбәлә-тирбәлә, анда-санда тибенгәләп йөргән тавыкларны куркытып, авыл урамы буйлап үтте, инеш аша салынган күпер бүрәнәләрен дөбердәтеп «сапап» чыкты. Яшеллеккә күмелеп утырган мәктәп бинасы алдындагы бәйрәмчә киенгән кешеләр янына җитеп кинәт туктады. Машинадан җилкәләренә икешәр сызыклы һәм берәр зур йолдызлы погоннар таккан хәрби чыкты. Аннары, машинасының алдыннан әйләнеп узып, теге як ишекне ачты. Күкрәкләренә чигүле бизәкләр төшерелгән озын кызыл күлмәк кигән, чем-кара чәчләрен толымнарга үреп җилкәсенә салган, тулган ай шикелле йөзле ханым ямь-яшел чирәмгә төшеп басты. Арт ишектән ике кыз, алар артыннан кызыл йолдызлы пилоткасын кыңгыр салган, чем-кара чәчле малай төште.

Хәрби кеше үзенә таба килүчеләр ягына борылды. Алар арасында тагын ике хәрби-капитан бар иде. Алар майорга честь бирделәр, аннары тулы гәүдәле бер ханымны алга уздырдылар.

Майор — ул Гамил Салихов иде — укытучы апаларын кочаклап күреште, исәнлек-саулык сорашты. Аның читкәрәк борылганын сагалап торучы капитаннар, шул ук мизгелдә, майорны кочып алдылар, өчесе бергә арткарак чигенеп, чирәм өстенә аудылар.

Күкрәгенә чигүле бизәкләр төшерелгән озын кызыл күлмәкле ханым — Сона бераз иелә төшеп укытучының битеннән үпте.

Ниһаять, җирдә тәгәрәгән «олы нәниләр» сикерешеп тордылар.

Майор бер кулына таяк тоткан, аксабрак атлаган берәүгә төбәлде. Бу — Вазыйх иде. Ул — укытучы икән.

Читтәрәк тагын бер ханым тора: Тәнзилә. Аның буй-сыны әллә ни үзгәрмәгән — һаман электәгечә үк ыспай, зифа. Тик калын кара толымнар юк иде.

— Исәнлектәме, Тәнзилә?

— Ару гына әле, Гамил.

Алар башкаларның игътибар итүләрен сизмәделәр.

— Мирбат абзый ни хәлдә?

— Әтинең үлгәненә биш ел тула инде, Гамил.

— Гафу ит, Тәнзилә, ә Фәндәрия апа?

— Сау-сәламәт әле.

— Үзең кайда яшисең соң, Тәнзилә? Гаиләң исән-иминме?

— Юк, Гамил, мин ялгыз яшим. Еракта, Кыргыз якларында, ә син каян болай?

— Германиядән кайтыш.

Гамил төркемдәгеләргә борылып кемнедер эзләде. Аннары барып хатыны Сонаның кулыннан тотып бирерәк китерде дә:

— Таныш булыгыз, Сона! — диде.

Тәнзилә белән Сона кул биреп күрештеләр.

Шау чәчәктә утырган сиреньнәр җылы, йомшак җилдә салмак кына тирбәләләр, кайчандыр су сибеп үстерүчеләрне сәламлиләр, гүя берберләренә сыенып күрешергә омтылалар иде.

*1978-1979*

## Роберт Миңнуллин

# ЙОЛДЫЗЛАР АРАСЫНДА

### Йөрәк

Йөрәгемне учым белән
Кысып тоткан чакларда
Киңәш бирәсең — йөрәкне
Киләчәккә сакларга.

Сүзләрең хактыр, кадерлем,
Саклану кирәктер ул.
Сакланган йөрәк, әлбәттә,
Иң әйбәт йөрәктер ул.

Төреп кенә йөртер идем —
Саклап кына булмый ла!
Саклаган да булыр идем,
Бүген кирәк ул миңа!

Янсын йөрәк! Янсын дөрләп!
Тамсын, әйдә, каннары!
Миңа йөрәк бүген кирәк!
Киләчәккә — аннары...

*1980*

### Яз. Чәчү алды

Җиңел сулый дөнья. Бөртек үзен
Башак итеп күрә төшләрендә.
Ә язгы кыр яп-ялангач калган —
Дәрт ургыла калку түшләрендә.

Кыр ялангач әле. Ояла ул.
Ябынасы килә яшел җәймә.
Бу хәлдә ул басу түгел әле —
Җаны тарта аны яшел җәйгә.

Иң зур бәхет аңа — тыңлап яту
Тамырларның пышылдашуларын.
Иген бит ул ишетелеп үсә,
Җырга күмеп шушы басуларын.

Ә орлыклар — дәртле! Яз исеннән
Кытыклары киләдер аларның.
Сабаннарга вакыт ялтырарга.
Теше чыккан инде тырмаларның.

Җилләр әзер кояш нурларында
«Яшәү» дигән көйне башкарырга.

Яңгыр! Кояш! Ташламагыз җирне —
Иң изге эш тора башланырга!

*1981*

## Илеш сабантуе

Кыза гына, кыза сабантуе!
Алыш, ярыш, көрәш — биредә!
Ак сөлгеләр ята тыпырчынып
Илеш ирләренең билендә.

Атлар килә! Матур атлар килә,
Оныттырып бөтен уенны.
Ә атлары шундый зифа буйлы,
Ә атлары — аккош муенлы.

Атлар килә уйнап! Шул чагында
(Сизмичә дә хәтта калынды)
Ук шикелле очкан Җирән кашка
Борылмада кинәт абынды.

Өстендәге малай очып төште.
Торып басты. Елап җибәрде.
Авыртканнан түгел, гарьлегеннән,
Кызганганга күрә Җирәнне.

Кочаклашып елаштылар. Аннан
Икесе дә читкә атлады...
Чабыш дәвам итте. Очты гына
Сабантуйның калган атлары.

Онытылды шундук абынган ат.
Бер хакыйкать узды уемнан:
Шул ат кебек бик тиз онытыласың,
Төшеп калсаң әгәр уеннан.

Җиңәргә дә мөмкин иде бит ул.
Ай, кызганып куйдым мин атны.
Җиңүчеләр бизи сабантуйны,
Җиңүләре бизи ир-атны!

Абынса да кемдер, егылса да,
Җиңүчеләр һәрчак табыла.
Тик нишләмәк кирәк, бу дөньяда
Дүрт аяклы ат та абына.

*1980*

## Кара ташлар арасында...

Монда кара ташлар гына
Ята әнә таралып.
Ята алар йокымсырап,
Ята алар каралып.

Ята алар хәтерләтеп
Кемнеңдер бахырларын —
Ташка әвереләдерелгән
Әкият батырларын.

Я булмаса, кайчандыр бер
Йолдыз булгандыр алар...
Ташлар шомландыра мине,
Ташлар — уйландыралар.

Кара ташлар кара кошлар
Төсле ята тирәмдә.
Тик очмыйлар. Тамырлары,
Ахры, бик тә тирәндә.

Ташлар — кара! Ул ташлардан
Чәчелә кара нурлар.
Сүндермәсәң, ул нурлардан
Күңелләр каралырлар.

Сүндермәсәң, кара нурлар
Каралтырлар таң нурын...
Эзлим, эзлим, таба алмыйм
Кара ташлар тамырын.

*1981*

## Булмас аны ватып...

Бабайлар да күккә ашып торган
Манаралар корган.
Сары айлы кәрвансарайлары
Горур басып торган!

Тик җир белән тигезләгән барсын
Мәрхәмәтсез Вакыт.
Безгә балчык чүлмәк кенә калган —
Анысы да ватык.

Ул чүлмәкне кыйпылчыкларыннан
Җыйганнардыр көчкә.
Гап-гади буш чүлмәк. Гыйфрите дә,
Чурты да юк эчтә...

Бездән соң да чүлмәк калыр микән?
Ниләр эшләр Вакыт?!
Тик ул балчык булмас! Болай гына
Булмас аны ватып!

*1981*

## Аның моңы

Мин әткәйнең гармун уйнаганын
Еш ишетәм соңгы араларда.
Аның моңы тула — күптән инде
Төзәлгән дип йөргән яраларга.

Искә алам бик еш мин әткәйнең
Җырлый-җырлый гармун уйнаганын —
Бик беләсем килә шул гармунның
Уйнаганда ниләр уйлаганын...

Шадралары тулы моң булгандыр —
Үлә иде әткәй гармун диеп.
Гармунын да атап йөртә иде
Гармун диеп түгел, зар-моң диеп.

Ул Актаныш базарыннан аны
Алып кайткан иде сыер сатып.
Һәм уйнаган иде — күрекләре
Өзелерлек итеп — чыелдатып!

Әткәй дә юк инде, гармун да юк —
Тик моңнары калды сагынырга.
Ничә еллар инде сүрелмичә
Шул моң яши миндә сабыр гына.

Онытамлыйм һаман мин әткәйнең
Соңгы тапкыр уйнап җырлаганын.
Тик сүзләрен искә төшералмыйм —
Ни хакында иде җыры аның?

Моңы гына истә! Аның моңы
Күзләремнән тора түгелергә.
Ә сүзләре ул җырлаган җырның
Туып кына килә күңелемдә.

*1981*

## «ТУФАННЫ ОЗАТУ» ЦИКЛЫННАН

### Бөтенләйгә кайтырга...

Тын да алмый ята Туфан.
Уйлыйдырмы: кителә...
Китте Туфан. Соңгы тапкыр
Кагылгачтын битенә,

Әллә чын, әллә могҗиза —
Чымырдады кинәт тән:
Елмаеп җибәрде Туфан
Көтмәгәндә, кинәттән!

Җанланып китте күңелләр,
Йөрәкләр типте: Ту-фан...
Елмайды! Җәлилләр төсле
Елмаеп китте Туфан.

Китте... ләкин белеп китте
Кайтасын ул тагын да —
Тиз генә ничек сүнәсең,
Сүнмәс өчен кабын да!

Карагыз — Туфан йолдызы
Чыкты икән кай турга?!
Бөтенләйгә китте Туфан —
Бөтенләйгә кайтырга!

### «Кайсыгызның кулы җылы?»

Шагыйрьләр тын калган бүген,
Алар бүген барсы ятим.
Башын аска иеп баскан —
Бөек ятим Сибгат Хәким.

Каләмдәшләр, хәлегезне
Ничек кенә җиңеләйтим?
Соң ничекләр юатыйм да,
Юатырга ниләр әйтим?

Бик юатыр идем сезне —
Мин үзем дә бүген ятим.

Кайсыгызның кулы җылы?
Кем кодрәтле? Я, кем?! Я, кем?!

Юатырга җитәр иде
Тик бер җылы сүзе генә...

...Юк шул, хәзер юатала
Фәкать Туфан үзе генә!

## Башкорт шагыйре Нәҗар ага Нәҗмигә

Калдырып шигырьләреңне,
Агыйделне, Уфаңны,
Ишетүгә килеп җиттең,
Күрергә дип Туфанны.

Әйткән иде ул соңгы кат:
«Тагын кил — озак торма!»
Озакламадың, килдең син.
Бу юлы... озатырга.

Әнә ул — якты бер балкыш —
Бәхетле, якты Туфан!
Матурлык, сафлык, гаделлек,
Шигърият яклы Туфан!

Ул җанын шигърият белән
Алыштырды бүгеннән.
Ул шигърият исә мең кат
Гомерлерәк үлемнән.

Туфансыз калдык дисеңме?
Ник әле тынып калдык?
Хәят — Туфансыз, әмма без
Туфанлы булып калдык!..

Килдең генә, китәсең дә —
Гомер турында уйлап,
Туфанның мәңге суынмас
Шигырь юллары буйлап!

## Туфан васыяте

Илгә шагыйрь кирәк, шигырь кирәк!
Бу заманда язып була ансын.
Һәрбер батыр шагыйрь булмаса да,
Һәрбер шагыйрь батыр була алсын!

Мин ышанам сезгә! Ил туфрагын
Күз яшьләре белән чылатмассыз.
Татар шагыйрьләре сынатмады.
Энеләрем, сез дә сынатмассыз.

Күтәрерсез күккә Шигъриятне!
Канәгатьлек белән тынышмассыз.
Шигъриятлән өстен булыр өчен
Беркайчан да, беләм, тырышмассыз.

Шигъриятлән өстен булмый шагыйрь,
Шигырьдәшләрем лә, телдәшләрем.
Ватан, Халык, Шигырь өчен янып
Яшәсәгез, мин дә мең яшәрмен!

Мин яшимен әле — сезнең өчен.
Кем өчендер, бәлки, мин үләрмен...
Без — бертуган татар шагыйрьләре!
Мин ышанам сезгә, энеләрем!

*1981*

## Көз. Диңгез. Гөл

Эзәрлекле кар диңгезне,
Ялкынлана ак ялкын.
Табигатьтә бер генә төс —
Ак кар, ак ком, ак дулкын.

Кар эчендә ята елап
Диңгезнең көзге гөле —
Диңгезнең нечкә күңелле
Фирүзә күзле гөле.

Нәкъ безнең як гөле төсле!
Ул — Идел гөле бугай.
Бездә туып монда үскән
Гөл инде үле бугай?!

Юк, юк, җанлы! Ләкин ул гөл
Сулып бара, күр инде.
Ничек ярдәм итим аңа?
Өзеп алып керимме?

Өзәргә артык гүзәл шул —
Кулым бармас өзәргә.
Ә гөл сула... Ул мөлдерәп
Карый минем күзләргә.

Коткарыйк, диңгез, без аны,
Үги кызны-гөлеңне.
Әллә ул гөл сиңа бер дә
Жәл, кызганыч түгелме?

Бу хәлгә ничек түзәсең?
Күкрәгеңдә җан бармы?
Бик гайрәтле булсаң да, син
Әллә көчсез җанвармы?

Ничек ярдәм итим гөлгә?..
Тыя алмый үземне,
Учларыма алдым гөлне.
Өздем, өздем... өзелде.

Елмайды гөл сөенечтән,
Белсә дә ул үләсен.
Сулды учта... Гөл бәхете
Шулдыр инде, күрәсең.

*1980*

## Төнге диңгез. Маяк. Йолдызлар

Төнге диңгез! Ул чигенә
Безнең күз карашыннан.
Атлыйбыз, өч дәрвиш кебек [1],
Йолдызлар арасыннан.

Йолдызлар оча кочакка —
Ала өтеп учларны.
Без Казанны сагынабыз,
Хәтерлибез дусларны.

Искә алабыз Тукайны,
Ян Райнис «Нарат»ларын.
Һәм тынабыз. Исәп — күрү
Диңгездә таң атканын.

Сискәндереп куя кинәт
Йолдызлар өне безне.
Балкып-балкып куя маяк
Яктыртып төнебезне.

Яңа маяк. Тибә маяк.
Тибә диңгез йөрәге.
Маякка тарта күңелләр,
Төн булганга күрәме?

Кешеләрнең йөрәге дә
Нәкъ шулай яна ласа.
Туктый ул йөрәк булудан,
Яктыртып яналмаса.

Йөрәкләргә дәшә күңел —
Кешеләр йөрәгенә.
Ә тозлы җил, сүндерәм дип,
Маякка өрә генә!..

Борчуларны читкә куеп,
Хисләрне көчкә тыеп,
Җирдә яшәүнең олы бер
Бәхет икәнен тоеп,

Атлыйбыз Җир шары буйлап
Йолдызлар яктысында...
Галәм аяк астыбызга
Йолдызлар атты шунда!

*1980 Рига, Дубулты*

[1] Аяз Гыйләҗев, Рәдиф Гатауллин һәм шушы юлларның авторы

## Мәҗит Рәфиков

### Тол ана

Сугышта ул ирен югалтты.
Биш бала... Яшь түкми юатты.

Сыерын җигеп җир сөрде ул.
Биш туйга биш юрган сырды ул.

Янында оныклар һәр заман.
Тормышның җаныдыр ул һаман.

Кичергән, күтәргән. Зары юк.
Тезләң дә алдына, кулын үп!

### Шифаханәдә

Шифаларның шифасы да —
Кешегә Кеше икән,
Җәфаларның җәфасы да —
Кешегә Кеше икән.

### Казан тальяны

«Әпипәгә» Рейхстаг диварларын
биетеп кайткан Казан тальяны!
Бөтен музыкалар арасыннан
әллә кайдан таныйм мин аны.

Калды толлар, назсыз һәм үксезләр.
Азмы каза, кайгы күрелгән,
Ә ул һаман сүнмәс яшьлек дәрте
Булып яңгырый минем күңелдә.

### Тиңсездер бу дөнья

Тиңсездер бу якты дөнья,
тиңсез...

Беркем дә сине белмәгән,
үзең берни дә күрмәгән,
сөешү могҗизасы белән
бу дөньяга килгәнче,
бу тормышка тәпиләп бер кергәнче.
Бу шау-шулы дөнья
еллар вә гасырлар кичә килгән
синсез, синсез...
Бер төш кенә хәтле гомереңдә
күренгәнеңчә күрерләр,
беленгәнеңчә белерләр...
Килер бер көн,
бу шау-шулы дөнья
синсез, синсез кичә бирер
айлар вә елларны,
гасырларны...
Уйнап яшә,
уйлап яшә,
синнән биредә кемнәр калыр,
нилр калыр:
Кемнәр сине өзелепме искә алыр?
Каһәрләпме утка салыр...
Тиңсездер бу якты дөнья,
тиңсез!

## Яз

Исерттеме болын чәчәкләре,
Тилерттеме кошлар моң түгеп...
Яшь яфраклы ак каеннар белән
Кочаклашып йөрим мин бүген.

И кояшлы яшел бу дөньяны
Иң матур бер җырга саласы!
Мин үзем дә шушы кояш, кырлар,
Шушы су буйлары баласы.

## Очыш

Зәңгәрләнеп ята җирләр-сулар,
Болыт калды аста агарып.
Чал бөркетләр җитмәс биеклектән
Алып китте безне самолет.
Өстән карап, «Азамат»ны көйләп,
Алла кебек барам утырып.
Бу минутта гүя син — Гулливер,
Җирдәгеләр — барсы лилипут.
Бу илаһи очыш тантанасын
Безгә бүләк иткән зирәк ир
Сине белми... Ә син билет кына
Аласың да, әйдә, оча бир!
Гүзәллеген таты бу дөньяның,
Биеклек һәм тизлек ләззәтен —
Иҗатчылар рухы бөеклеген
Бераз гына аңлар сәгатең...
Трап килә. Әйдә тәпи-тәпи
Менә син дә гади лилипут...
Шушы лилипутлар арасында
Гулливерлар барын истә тот.

## Дифгат Сирай

# СОЛДАТ УЛЫМА ХАТЛАР

*
* *

Рәсемеңне кулга алган саен,
Бер вакыйга төшә исемә:
Май булгандыр, ахры, бар тирә-як
Чумган иде шомырт исенә.
Без базардан кайтып килә идек,
Күршедәге авыл аркылы.
Тәрәзәдән күреп, әниемне
Дәшеп алды таныш хатыны.
Кара тасма белән каймаланган
Рәсем сузды аңа моңаеп.
Синекедәй ыспай мыеклы, яшь
Солдат тора иде елмаеп...
Кырык биштә булган бу очрашу
Әле һаман чыкмый исемнән.
Бүген дә май. Бүген дә бит, әнә,
Шомыртлардан дөнья исергән.
Тәрәзәне киереп ачкан килеш,
Рәсемеңә карап утырам:
Көләч күзләр, керфек арасына
Әйтерсең лә балкып нур тулган.
Кулга алып шушы рәсемеңне
Күрсәтмәгән кешем бардырмы?
«Чибәр икән, күз тимәсен,— диләр, —
Карашлары бигрәк ягымлы...»
Шулай димен эчтән мин үзем дә,
Күз тиюнең беләм бәясен;
Иң соңгысы булсын иде җирдә
Кырык биштә күргән ул рәсем.

*
* *

Ал син, улым, минем автоматны,
Тәртип санын карап-тикшереп.
Күпме мишень ауды каршысында,
Дошман башы кебек тишелеп?!
Окоп комы, поход тузаннары
Шомарттылар ложа түтәсен.
Шул ложага терәп җилкәңне син,
Кирәк булса, сип ут көлтәсен...
Ал син, улым, минем автоматны,

Үзгәргәндер, беләм, яңадыр.
Күңеленңне ләкин төшермә син,
Тәртип саны барыбер калгандыр.
Шул санлысын сора командирдан,
«Әти кушты!» — диген, тартынма.
Каршы килмәс, антын үтәп киткән
Элеккеге солдат хакына.

*
* *

Декабрьда мин ант биргән идем,
Байрак үбеп — полк байрагын.
Ә декабрь туган аем да ул,
Иң гүзәле, димәк, айларның.
Ә син — январь улы! Кайсы айда
Үбәсеңне белмим байракны.
Кайчан гына ләкин үпсәң дә син,
Исеңдә тот, улым, һәрчакны:
Ирләр туа ике тапкыр, башта
Кеше булып туа, төпләнә.
Икенче кат солдат булып туа
Ант биргәндә — байрак үпкәндә.
Шул байракка тугрылыгы белән
Көчле итә илен ул, үзен.
...Ант биргәнгә инде чирек гасыр,
Яттан беләм ләкин һәр сүзен.

*
* *

Дусларым сорыйлар:
«Улыңнан хат бармы?
Кай якта — бик җылы,
Бик салкын яктамы?»
Танышлар сорыйлар:
«Улыңнан хат бармы?
Поварны, писарьмы,
Әллә соң сактамы?»
Күршеләр сорыйлар:
«Улыңнан хат бармы?
Сержантка укыймы,
Я гади солдатмы?»
Кызлар да сорыйлар:
«Улыңнан хат бармы?
Кайчанрак кайта ул,
Кайтамы, каламы?..»
Барысы да сорыйлар,
Сорыйлар тик сине.
Сорыйлар гүяки:
«Дөньялар иминме?»

*
* *

Тәгәрмәч өстендә үтте
Солдаттагы бар гомер.
Уйларымны шул көннәргә
Тәгәрәтим әле бер:
Иң беренче аяк бастым
Украина җиренә.
Изге җир ул: кан дәрьясы
Шаулап акты биредә.
Адымымның икенчесе
Калды Кавказ тавында.
Изге җир ул: ябрылмаган
Аңа күпме яу гына?!
Аннан юллар Казагыстан
Якларына ташлады.
Изге җир ул: ирек өчен
Меңнәр салган башларын.
Каберләрен күргән саен
Хәл белеп китә идем;
Чәчәк салып, солдатларча
Сәламләп үтә идем.
Тик Байкалга җиталмадым,
Ул якларны күрмәдем.
Синең белән китте ләкин
Шул якларга йөрәгем. —
Син минем солдат юлымны
Дәвам итәсең анда.
Изге җир ул: күпме ирләр
Йоклыйдыр сопкаларда?!
Каберләрен күргән саен
Хәлен белеп китә күр:
Чәчәк салып, солдатларча
Сәлам биреп үтә күр.

*
* *

«Хәрби һөнәрең нинди?» — дип
Юк әле сүз катканым.
Мин дә ничә еллар буе
Сер иттереп сакладым. —
Топограф идем. Хәзер дә
Сөйләп булмас барчасын.
Әйтәм бары йөргәнемне
Сөйрәп үлчәү тасмасын.
Сазга батып, суга чумып,
Ерып карын, ком-ташын,
Тупчыларга координатлар —
Ут ноктасы юллаштым.
Сиңа гына әйтәм моны,
Сер иттереп сиңа да.
Теләсәм дә, һөнәреңне
Сорамыймын шуңа да.
Әйтмәсеңне яхшы беләм,
Үзе чыгар бер «төртеп».

Улыңа гына әйтерсең,
Аңа да тик сер итеп.

*
* *

«Без, дигәнсең, бер взводта
Егерме берләп милләт».
Егерме берләп милләтнең
Берсе син инде, димәк.
Үзе бәхет шундый взвод
Сафында булу, беләм:
Очрашасың гүя кабат
Син үз гаиләң белән.
Һәрберсе дус, якын сиңа,
Чиге юк татулыкның.
...Үз взводымда күрдем мин
Ныклыгын чын дуслыкның.
«Ватанны уяу сакларга!» —
Антка кылып тугрылык,
Чыга идек походларга
Бердәм гаилә булып.
Мин сусасам, флягасын
Суза иде кабардин.
Ул арыса, юл капчыгын
Ала идем аннан мин...
«Без, дигәнсең, бер взводта
Егерме берләп милләт».
Егерме берләп милләтнең
Берсе — син, татар, димәк.
Ә татарлар беркайда да
Сынмады-сынатмады.
Балта астына ятса да,
Иле данын сатмады.
Кызыллык китерә күрмә
Син дә илнең йөзенә.
Истә тот әманәтемне,
Онытма бер сүзен дә.
Күңелеңнең сафлыгына
Ышанып калам, улым:
Пакь булса күңелең, ак булыр
Өеңә кайтыр юлың!

# УНБЕРЕНЧЕ БИШЬЕЛЛЫК: КЕШЕЛӘР ҺӘМ ЭШЛӘР

## Мансур Вәлиев

# СЕБЕР ЯЗМАЛАРЫ

## Сәяхәтләр турында берничә сүз



Яшермим, мин үзем алай сәяхәт ярата торган кеше түгел. Ни өчен, ни сәбәптән? Монысын да ачык кына әйтә алмыйм. Бәлки, вакыт ягы һәрчак кысан булгангадыр? Алда һәрвакыт ниндидер кичектергесез эш торгангадыр. Һәм еш кына кыюлык, тәвәккәллек җитмәгәнгәдер?

Ә бәлки, заманның шундый ыгы-зыгылы булуыннандыр бу — сәяхәтләрне яратмау? Болай да бик күп чабып йөрелә бит! Әзрәк кенә туктап, уйланып торырга да вакыт тими... Кызык кына каршылык та килеп чыга: син яшәгән тормышның агышы кызуланган саен, ул тыштан активлаша төшкән саен, үзеңнең өстәнрәк йөзүеңне сизү тойгысы һаман ныграк ачыклана бара, ул хис синең тормыштан алган шатлыкларыңа һаман кыюрак каршы төшә...

Күрәсең, замандашларның бик күбесен аптырата торган каршылыктыр бу. Кеше әле күп вакыт әнә шулай: үзенең күңеле белән тормышы арасында тәңгәллек табып бетерә алмыйдыр.

...Кеше чит якка киткәч, үзенең җирен-суын гына түгел, ә моңа кадәр үзе яшәгән, үзе ияләшкән бөтен мохитне сагына, бик нык кирәксенә икән бит!

Чыннан да, менә, билгеле бер урында үсемлек үсә. Ул бу урынның туфрагына, суына, һавасына, андагы төрле үзгәрешләргә мең, миллион еллар буена ияләшкән. Әлеге үсемлекнең һәр күзәнәге әнә шул җир, шул урын шартларына җайлашкан. Табигатьнең бөек гармониясе шулай итеп бик күп үсемлекләрне җир шарының төрле-төрле почмакларына чәчеп чыккан, аларга үз холыкларына туры килгән урыннарны биргән.

Уйлап карасак, адәм баласы да — табигатьнең бик нәзберек, бик сизгер бер үсентесе ләбаса! Ул да мең еллар буена билгеле бер шартларга, билгеле бер урын чынбарлыгына ияләнгән. Үсемлек сыман, ул да билгеле бер төрдәге туфракка, суга, һавага күнеккән. Ә тагын да мөһимрәге: ул җирдә аның белән, аның ата-бабасы белән бергә гомер иткән үз кешеләр була. Тормышы җир-суга һәм һавага бәйле булса, җаны әнә шул кешеләргә килеп тоташа аның!

Шуңа күрә, чит җиргә күчеп киткәннәрнең ничек җирсүен аңлату өчен, икенче туфракка илтеп утыртылган үсемлеккә күрсәтү генә җитми. Үсемлекләр җирсү дигән нәрсәнең җан газабына әйләнеп, кешене ничек тилмертүен белмиләр! Чөнки алар, биологик яктан караганда тере булсалар да, күңел, җан дигән бик әрнеткеч бер нәрсәне тоймыйлар!

Ерак Көнчыгышта хезмәт иткән чакта мин бик еш кына стенага эленгән зур карта — илебез картасы янына килә идем. Үземнең туып-үскән ягыма бик озак кына карап торгач, хәзер мин яшәп яткан җирем белән Казан арасын бармакларны суза-

сүзә, сәямләп үлчи идем. Нәкъ ун сәям чыга иде! Ун мең чакрым җир әнә шулай — кул бармаклары белән ун мәртәбә атлауга үтелә иде карта өстеннән.

Сагынган, җирсегән кешенең хыялы Ерак Көнчыгыштан әнә шулай — бер атлауда меңәр чакрым араны үтә-үтә Казанга таба кайта иде. Әллә шунлыктан, Казанга кайтып өлгәшкәч, ничә еллар буена минем аннан беркая да чыгасым килмәде. Еракка юл йөрүне, сәяхәтләрне артык яратмауның бер сәбәбе әллә әнә шуннан микән, дип уйлыйм мин еш кына.

Ләкин... Бик борынгы бер философның «Барысы да ага, барысы да үзгәрә» дигән сүзләрен бүген юкка гына еш кабатламыйлар, күрәсең. Телибезме, теләмибезме — дөнья безне барыбер үзгәртә, ахры. Сәяхәтләр, юл йөрүләргә карата минем мөнәсәбәт тә әкренләп үзгәрә, ахрысы...

## Себер каян башлана?

Минем өчен Себер каян, нәрсәдән башланды соң?

Мәскәү янындагы бер иҗат йортында Төмән язучысының Себер, андагы искиткеч зур эшләр турында сөйләвен тыңлауданмы? Ул сөйләгәндә Себернең бүгенге көннең алгы сызыгы икәнен аңлаудан һәм үзеңнең анда, алгы сызыкта булмавың өчен кыенсыну, уңайсызлануданмы?..

Алгы сызыкны күрәсе килү омтылышы миңа «Мәскәү — Төмән» поездына билет алдыртты. Себернең минем күңелдәге яшәеше шулай барлыкка килде.

Ә аның чынга ашуы салкын январь иртәсендә бик еракка юл тоткан поездның бер җылы купесына кереп урнашудан башланды. Юлдашларым да «алгы сызык»ның үз кешеләре булып чыкты: Халидә белән Нина иң ерак төньяктан башланып, Әлмәткә таба килүче Уренгой — Әлмәт газ үткәргече төзелешендә эшлиләр икән. Хәзер аларның Мәскәүдән кайтып килеше. Ял көнендә генә, Мәскәүне бик тә сагынганга гына барганнар алар башкалага!

...Чын Себер ул төньякның рәсми булмаган башкаласы Төмәнне күрүдән башлана бугай. Бүген Себергә, төньякка бәйләнгән барлык сүзләр ахыр чиктә шушы шәһәргә килеп тоташа. Ул — бүген Көнбатыш Себернең чиксез киңлекләренә, тирән байлыкларына үтеп керү өчен капка да, бу эшнең бөтен оештыру мәшәкатен үзенә туплаган зур үзәк тә.

Төмәннең тимер юл вокзалына килеп төшкәч тә, зур үзенчәлек сизәсең. Иң башта кешеләрнең, пассажирларның бик җылы киенгән, туннарга, калын шарфларга уралган булуы күзгә ташлана. Күбесенең аягында бары тик төньяк кешеләренә генә хас булган аяк киеме — унталар. Хатын-кызлар исә үзләренә болан тиресеннән читеккә охшаш бик матур аяк киеме тектерәләр икән. Кешеләрнең аркасында зур рюкзак, киң табанлы ау чаңгысы күтәргәннәр дә еш очрый. Ир-атларның барысы да диярлек сакал-мыектан.

Төньякның кече башкаласы Төмән урамында яланбаш йөрүче егетләр дә шактый. Январь аеның 30 градуслы салкынында бу, билгеле гаҗәпләндерә. Ә бераздан мин моның серен белдем. Төмәндә яланбаш йөрүче сакал-мыек баскан бу егетләр тагын да төньяктанрак — ерак Уренгойдан гына кайтканнар икән. Кырык биш, илле градуслы салкыннан кайтканнар! Алар Төмәнне үзләре өчен көньяк, җылы як дип саныйлар икән.

Аннары Төмән вокзалында тагын шул күзгә ташлана: кешеләр биредә Европаның зур шәһәрләрендәге сыман гел ашыгып, гел каударланып яшәмиләр. Зур эшләре булмау нәтиҗәсендә килеп чыга микән әллә ул — кешеләрнең әһәмиятсез вак-төяк өчен гомер буе ыгы-зыгы килеп яшәве?

Себер, төньяк әнә шулай күп төрле, күп яклы башлана икән ул кеше өчен.

## Сургут. Очучы бригадалар

Сургут — Төмәннән төньяктарак урнашкан шәһәр. Аңа Төмәннән чыгып киткән поезд бер тәүлеккә якын бара, ә «АН-24» самолеты ике сәгать оча. Себернең иң зур

елгасы Обь ярына урнашкан бу шәһәрне җай көне бик матур диләр. Мин килеп төшкәндә исә январь уртасы иде, урамнар буйлап салкын җил сызгырып йөри, буран уйный. Кешеләр, җилгә каршы бик нык бөгелеп, ничек тә булса алга барырга тырышалар.

Мондый көнне күрмәгән-белмәгән чит шәһәргә, бигрәк тә Сургут ише төньяк шәһәренә килеп төшү адәм баласы өчен бик үк рәхәт эш түгел, билгеле. Иге-чиге күренмәгән, вакыт-вакыт үзе дә күздән югалып китә торган урам буйлап, сәгатьләр буе якташ нефтьчеләрне эзләп йөрү шактый арытты. Ләкин мин аларны — Татарстаннан һәм Башкортстаннан килеп, Себер җирендә кара алтын чыгаручы кыю егетләрне барыбер табарга тиеш идем. Чөнки минем бу якларга килүем Себерне, төньякны күрү өчен генә түгел. Якташларымның биредә ничек эшләүләрен, ни рәвешле яшәүләрен дә беләсем килә.

Сургут шәһәрендәге күп оешмалар биш катлы таш йортларның ишегалларына, кечкенә-кечкенә вагоннарга урнашкан. Аларның күбесенә берниндн язу да кадакланмаган. Кайсының нинди оешма икәнен шунда эшләүчеләр үзләре генә белә, күрәсең. Ә эзләүче кешегә, әлбәттә, вагончыкларның һәрберсенә диярлек кереп: «Сез Татарстаннан, яисә Башкортстаннан түгелме?» дип сорап йөрергә генә кала.

Көн буе эзли торгач, үз якташларымны барыбер таптым бит! Алар Академик Губкин урамындагы вагоннарда булып чыктылар. Татарстан белән Башкортстан экспедицияләре биредә дә бер-берсеннән ерак урнашмаган икән. Аралары җәяүлегә ун гына минут!

Ләкин болары — Сургут урамнарын бетереп, мин көн буе эзләп тапкан бу вагоннар — безнең як нефтьчеләренең идарә итү штабы, конторасы гына. Үзләре исә Сургуттан йөзәр, йөз иллешәр чакрым ераклыкта — тайга эчендә эшлиләр икән... Тайгага, чын нефтьчеләр янына киткәнче, әйдәгез башта безнең яктан килгән бу экспедицияләр белән бераз танышып алыйк.

Сургут шәһәре тирәләрендә Башкортстаннан килгән өч экспедиция, Татарстанның бер экспедициясе эшли. Болар ни өчен оештырылган, нинди экспедицияләр соң?

Көнбатыш Себердә — ягъни Төмән өлкәсенең төньягында — нефть һәм газ ятмалары бик күп. Аларга тиң ятмаларның әле илебезнең бер төбәгендә дә табылганы юк иде. Күз алдына китерү өчен бер генә санны әйтеп үтик. Хәзер Төмән өлкәсендә көн саен бер миллион тонна нефть чыгарыла! Мондый саннар Татарстан кешеләре өчен яхшы таныш булырга тиеш. Бездә иң яхшы чыккан чагында елына 105 миллион тонна кара алтын табыла иде. Әле бу сан якын елларда бик нык үсәргә мөмкин. Чөнки хәзергә әле нефть Обь елгасы буенда гына чыгарыла. Бүтән урыннарга әле керү мөмкин түгел — тоташ сазлык, баткаклык. Ә Обь буйлап әзме-күпме юллар салынган, елга үзе дә җәй көне нефтьчеләргә шактый булышып кала: су юлы белән байтак кирәк-ярак алып киленә.

Партиябез Көнбатыш Себернең әнә шул байлыкларын тиз арада үзләштерүне бурыч итеп куйды. Хәзер илгә кирәкле нефтьнең иң күп өлеше менә шушы якта чыгарылырга тиеш. Әмма, Көнбатыш Себернең үзендә, бигрәк тә аның төньягында, халык аз яши. Нефтьче һөнәренә ия булганнар исә тагын да азрак. Ә җир асты байлыклары илгә кирәк!

Һәм җитмешенче елларның ахырларында шундый карар кабул ителә: Көнбатыш Себерне үзләштерүне илнең төрле республикаларына, өлкәләренә бурыч итеп куярга, алар нефтьчеләрнең экспедицияләрен оештырырга тиешләр.

Хәзер нефтьчеләр Сургут якларына илебезнең кайсы гына төбәгеннән очып килми. Алар үз бригадалары белән Татарстан белән Башкортстаннан да, Куйбышев һәм Саратов өлкәләреннән дә киләләр. Хәтта... хәтта биредә Кавказ белән Эстониядән дә нефтьчеләр утырган самолетлар оча!

Шулай итеп, Төмән өлкәсенең төньягында «очучы бригадалар» барлыкка килә. Алар 12 көн эшлиләр дә, самолетка утырып, өйләренә кайтып китәләр һәм өйдә шулай ук 12 көн ял итәләр. Аннары тагын самолет белән Себергә эшкә киләләр.

Бу ысулның өстенлекләре һәм кайбер уңайсыз яклары хакында нефтьчеләр арасында төрле сүзләр йөри. Күпләр 12 көн буе тырышып эшләү һәм аннары шуның кадәр үк ял итү — кеше өчен бик әйбәт дип саный. Һава хәленә бәйле сәбәпләр аркасында аэропортларда бушка вакыт сатудан зарланучылар да бар. Җитәкчеләр ара-

сында да бу ысул белән эшләүнең шактый җитешсезлекләрен күрәләр, чөнки ерак җир, биредә бик күп кирәк-ярак җитешми, еш кына төрле тоткарлыклар килеп чыга. Шуның өстенә, тагын эшчеләрнең ерак юл йөрүенә бәйле күренешләр дә килеп кушыла. Әмма, ничек кенә зарлансаң да, хәзергә әле бүтән чара юк. Бик күп нефтьчеләр өчен вахта-экспедиция ысулы белән — килеп-китеп эшләү әлегә бердәнбер юл булып кала.

Аэропортларда самолет күтәп торганда сез «махсус рейс» дигән сүзләр ишетсәгез, ул нефтьчеләр өчен билгеләнгән самолет булыр. Аэропортларда, утыз-кырыклап ир-атның юл капчыкларын барысын бергә өеп куеп, күңелле генә гәпләшеп торганын күрсәгез, алар Себергә юл тотучы нефтьчеләр үзләре булыр.

## Поселок

Сургут шәһәреннән төньякка таба чыгып китеп, йөз егерме чакрым юл үтсәң, бу якларда бердәнбер булган поселокка килеп керәсең. Ул — нефтьчеләр, төзүчеләр, гомумән, нефть эшенә әзме-күпме катнашы кергән кешеләр яши торган поселок. Бу поселок Обька коючы Пим дигән елга буена утырган, шуңа күрә ул да Пим дип йөртелә. Йортлары сиксән-туксаннан артмаса да, Пимның исеме илебезнең һәрбер картасына диярлек төшерелә. Ни өчен? Чөнки, әйткәнебезчә, якын-тирәдә аннан зуррак кына түгел, ә гомумән бүтән торак пунктлар юк дияргә була.

Сөйләүләренә караганда, элегрәк монда җирле халык — хантлар яшәгән. Әсоңгы елларда, бу якларда нефть чыгарыла башлагач, бихисап күп кешеләр, техника килгәч — җәнлекләр куркып тагын да ераккарак, тайганың эченәрәк киткәннәр. Алар артыннан әкренләп хантлар да күченгәннәр. Чөнки алар — аучылык белән көн итүче халык, аларга чын тайга, күп киек кирәк! Шулай итеп, Пим поселогы әкренләп килгән кешеләр кулына калган.

Поселокның тышкы күренеше үк анда кемнәр яшәвен бик яхшы сөйләп тора. Җыелма өйләр, тимер вагоннар, чана өстендәге өйләр, җиңелчә генә корып куелган коттеджлар — поселок урамыннан барганда син әнә шуларны күрәсең. Әмма һәрберсенең түбәсендә бик югарыга менгезеп куелган телевизор антеннасы чайкалып тора. Әнә шул колгалар монда, йөзләгән чакрымга тайга эченә киткән кешеләрне, Зур Җир белән бәйләп торалар.

Пим поселогы бик күп яктан үзенчәлекле. Монда күп өйләрдә төннәр буена ут сүнми. Чөнки нефть табу эше көнне-төнне белми, ул тоташ, бер өзлексез дәвам итә. Биредә диспетчерлык пунктлары көн-төн эшләп тора. Рацияләр тәүлекнең теләсә нинди вакытында илебезнең теләсә кайсы ноктасы белән элемтә тәэмин итә. Биредә көн-төн эшчеләр эштән кайта, көн-төн эшчеләр эшкә бара. Урамда төне буе машина, трактор тавышы тынып тормый.

Пим поселогы әнә шулай яши. Аның тормышында бүтән авылларга охшаган күренешләр дә күп, билгеле. Чөнки йөзләгән чакрым ераклыкта, тайга эчендә булса да, Пим барыбер кешеләр яши торган авыл бит. Шуңа күрә бүтән гадәти авылларга хас күренешләр Пим өчен дә ят түгел. Пим поселогы урамыннан да, егетләрнең күзен кызыктырып, зифа буйлы яшь кызлар үтә. Кичләрен егетләр, кызлар җыйналып клубка киногэ баралар. Биредә дә кешеләр бер-берсенә кунакка, кич утырырга йөрешәләр. Шимбә, якшәмбе көннәрне биредә дә заманча музыка ритмнары яңгырый...

Һәм тагын биредә бик еш кына яшь бала авазлары ишетелә... Биредә дә бәләкәй бала тартып йөрүче яшь әниләрне еш очратырга була. Ә ял көннәрне бик күпләр парлап-парлап урамнан үтә.

Ө поселокның икенче өлеше Пим елгасының аргы ягына урнашкан. Ул якта буровойлар, төп эш урыны. Шуңа күрә бөтен техника, барлык кирәк-яракны кышын тегендә күбрәк алып чыгып калырга тырышалар. Шулай итеп, поселок ике як ярдагы нефть катламнарын яулау өчен дә плацдарм булып хезмәт итә.

## Алдынгы бригадада

Бу якларга килеп эшләүче бораулау бригадалары арасында елның-елында алдынгылык казанучы бер коллектив бар. Ул — бораулау мастерлары Хәсип Билалович Мөхәммәдиев һәм Евгений Георгиевич Воронцов — икесе бергәләп җитәкли торган бригада. Үткән елда алар пландагы 50 мең метр урынына 60 мең 301 метр тау токымы бораулаганнар. Көнбатыш Себер, төньяк шартларында бу — бик әйбәт күрсәткеч!

Бригада моңа ничек ирешә икән соң? Шул сорауны ачыклау максаты белән яшь бораулау мастеры (аңа әле 30 гына яшь) Евгений Георгиевич Воронцовка мөрәҗәгать итәм.

— Минемчә, безнең эштә иң кирәге: бер-береңне аңлау, оешканлык, тупланганлык,— дип үз-үзе белән киңәшкәч, уйланган төслерәк башлап китә ул сүзен.— Хәзер бригада әкрен-әкрен әнә шуңа ирешеп килә сыман...

Әйе, мин бригада егетләрен эш вакытында да, эштән соң ял иткәндә дә күп күзәттем. Һәркайда шул күзгә ташлана — алар бер-берсен ярты сүздән аңлап яшиләр. Кайчан, нәрсә эшләргә кирәген алар күп чагында мастер әйтмичә дә белеп торалар, үзләре башлап эшлиләр.

Бораулаучы — бригададагы иң төп кочләрнең берсе. Аның тәҗрибәсе, белеме бик күп нәрсәне хәл итә. Бригаданың ел дәвамында күпме җир токымы бораулый алуы, планны үтәве яисә үти алмавы да иң элек бораулаучының осталыгына бәйле дияргә була. Чөнки ул вахта капитаны кебек. Бораулау процессын ул алып бара. Кайбер бик тәҗрибәле бораулаучылар, хәтта, алда нинди токымга эләгәчәкләрен һәм анда үзләрен нинди хәл көтәргә мөмкин икәнен аңлап эш итә, дип сөйлиләр. Алар авария булмасын өчен нинди саклану чарасы күрергә кирәклеген дә әйтәләр икән. Кайбер акыллы башларның бу кисәтүне санга сукмыйча: «Җир астында ни барын каян белә ул? Кереп күргәнме әллә!» — диебрәк эшләп, алдан тиешле чараны күрмичә, бик еш кына үкенгән чаклары да була икән.

Әхнәф Мөкимов — бу бригаданың яшь бораулаучысы. Ул әле егерме җиде генә яшьтә. Ләкин инде аның нефть эшендә эшли башлавына ун елдан артык. 1975 елда ул бораулаучылар курсын тәмамлаган, аннан соң Башкортстанда шактый гына җир бораулаган. Ә менә 1980 елның май аеннан бирле Әхнәф Мөкимов Себер җирендә. Хәзер ул бишенче разрядлы бораулаучы.

Бу якта эшләү Татарстан, Башкортстандагыдан бик нык аерыла. Биредә бөтенләй икенче шартлар. Кышын утыз биш-кырык градуслы салкын, көчле җил һәм күз ачкысыз бураннар. Әнә шундый һава шарты булганда да, бораулаучы егетләргә, берничә карамыйча, буровой баскычыннан югары күтәрелергә һәм вахтаны үз кулларына алырга туры килә.

Ә язын, җәен егетләрне шулай ук бик күп сынау көтә. Язын, Себер елгалары ташып скважиналарны су баса, эш бик катлаулана, бару-кайту да авырлаша. Җәй көне исә бу яклардагы иң зур дошман — черкиләр кузгала. Алар болыт кебек була дип сөйлиләр. Битлексез эшләү дә мөмкин түгел икән. Ләкин бригада егетләре Себернең мондый сынауларын уңышлы үткәннәр. Алар хәзер яңа шартларга ияләнеп киләләр инде.

Вахтадан соң, җылы вагонда сөйләшеп утырганда, Әхнәф миңа үзенең ничек итеп нефть эшенә кереп китүен сөйли, бергә эшләүче егетләрне бик җылы сүзләр белән искә ала. Мин үз алдымда үтә тыйнак, ләкин зур эш эшләүче яшь замандашым утырганын аңлап алам. Бригаданың күп егетләре сөйләшкәндә әнә шундый тәэсир калдыра. Аларның бер-берсенә карата булган ихтирамы да тыенкы елмаю яисә саран гына берәр сүз рәвешендә чагылып китә.

Бораулау барганда да егетләр аз сөйләшәләр. Бораулаучы Әхнәф идарә итү пульты янында тора, ә өч ярдәмчесе аңа ярдәм итә. Бөтен хәрәкәтләр тиз, төгәл һәм зур игътибар белән башкарыла. Бер караганда әллә ни катлаулыгы да юк кебек: күпмедер вакыт менә шулай кеше эшләгәнен күзәтеп, бөтен операцияләрне ятлап каласың да, шуннан соң син дә бораулаучы була алырсың кебек. Кайчагында, бигрәк тә егетләрнең җиңел генә эшләгәннәрен карап торганда, күңелдә шундыйрак уй да туып китә.

Шулай, халыкның «җиңелгә җен кебек» дигән сүзе бар бит. Ягъни, җиңел барган эшкә бөтен кеше ябышырга тели дигән сүз инде бу. Минем күңелгә килгән уй да эш җиңел тоелганга, ахры... Бераздан ниндидер, мин аңламаган катлаулылык килеп чыкты һәм егетләр, тиз генә нәрсәдер киңәшеп алдылар да, бөтенләй мин аңламаган эшкә тотындылар. Аны тиз арада көйләп тә куйдылар. Яңадан тигез ритм белән борауларга тотындылар...

Алар үзендә бик күп байлыклар яшеренеп яткан Себер җиренең ике мең ярым метр тирәнлегенә юл тота иделәр.

## Авария

Мин 317 нче буровойда төн кунарга калган идем. Сургутка кунакханәгә кайтып йөрү бик ерак — йөз километрдан артык. Күңелдә кичен нефтьчеләр белән тагын да ныграк танышып, алар турында тагын да күбрәк беләсе килү уе да бар иде.

Бу буровойда шулай ук алдынгы бригада эшли. Галимов һәм Әхмәтшин бригадасы. Сүз уңаеннан, бригадаларның ни өчен ике кеше фамилиясе белән йөртелүен дә ачыклап китик. Бусы да шул ук вахта-экспедиция ысулыннан килә. Кешеләр дә, мастерлар да алмашынып эшли дигән сүз бу. Мәсәлән, биредә бригаданың яртысы мастер Әхмәтшин җитәкчелегендә 12 көн эшләгәч, кайтып китә. Аны мастер Галимов кешеләре алыштыра. Шулай итеп, ике өлештән торган бер бригада килеп чыга. Бригада турында сүз чыкканда һәрвакыт ике мастерның да исеме рәттән телгә алына.

Ә хәзер буровойда Нур Галимҗанович Галимов кешеләре. Галимов үзе — бик тәҗрибәле бораулау мастеры. Ул бу эштә инде 30 ел эшли икән. 1980 елда бригада күрсәткечләр буенча Мөхәммәдиев-Воронцов бригадасыннан гына калышкан, 50 меңлек план 60 мең итеп үтәлгән. Галимовның үз эшен бик яхшы белүе аның һәр хәрәкәтеннән, һәр сүзеннән сизелеп тора. Аннан үз-үзенә нык ышану рухы бөркелеп тора.

Ул кичне Галимов миңа бригадасы, үзенең егетләре турында сөйләде, үзләренең Себер җирендә ничек итеп эшли башлауларын искә алды. «Бу егетләр белән җир җимертеп эшләп була!» — дип кенә әйтте ул, аларның барысына гомуми бәя биреп. Мин аның бу сүзләрендә үз солдатларына бик нык ышанган командир тавышын ишеттем.

Ул кичне буровойда килеп чыккан авария коллективны бик күп яктан сынады...

Мастер белән, бораулаучы һәм аның ярдәмчеләре белән сөйләшеп-танышып алганнан соң, мин будкада технолог Альберт Сәләхетдинов белән әңгәмә корып утыра идем. Авызына карап, дигәндәй, нефтьчеләр тормышыннан хикәятләр тыңлап утырам. Салкын Себер кичендә мондый әңгәмәче белән җылы будкада гәп кору — кайчак миңа иң кирәкле, иң кызыклы нәрсә кебек тә күренеп китә. Ни әйтсәң дә, тоньякта — 62 нче параллель тирәләрендә бит без!

Әмма тиздән, бик тиздән, Альбертка да, миңа да җылы будканы ташлап, буровойга китәргә туры килде.

Без мастер Галимовның үзебез утырган будкага килеп керүенә, аның йөзе ни кыяфәттә булуына башта бөтенләй игътибар да итмәдек. Ә ул исә, килеп кергән көйгә туп-туры рация янына үтте дә, аңа килеп җитәр-җитмәс, нәрсәдер исенә төшкәндәй, борылып тагын чыгып китте. Без аны сүзсез генә озатып, әңгәмәбезне дәвам иттек. Мастер үзенең гадәти йомышлары белән йөри дип уйладык. Ләкин озакламый мастер тагын килеп керде. Бу юлы ул үз бүлмәсенә үтте дә, бияләен салып, эскәмиягә куйды. Башыннан каскасын, бүреген салып атты. Минем янда утырган Альберт нәрсәдер сизенде ахры — тиз генә мастер янына чыгып китте. Мин аларның ни рәвешле аңлашканнарын күзәтергә өлгерми калдым. Колагыма мастерның бары тик бер генә сүзе килеп иреште...

— Колонна...

Альберт башта бу сүзнең нәрсә аңлатканына төшенергә теләгәндәй тып-тын торды. Аннары, аңлап алгач, миңа да барысын да төшендерә алырдай тавыш төсмере белән:

— О-о-ой...— диде. Һәм бераздан тагын шуны ук кабатлады — О-о-ой... Бик яман бит бу!..

Аның бу сүзләреннән соң, әйтерсең, мастер тагын нидер исенә төшерде — тиз генә башына киде дә, яңадан буровойга таба юнәлде.

Мин шунда ук Альбертка ябыштым.

— Нәрсә булды! Нинди хәл бу — аңлат әле!

Башта Альберт бик кыска итеп өч кенә сүз әйтте:

— Бу бик зур авария!

Соңыннан, Альбертның кат-кат аңлатуыннан мин шуны төшендем: бу — нефтьчеләр телендә «колонна очу» дип аталган зур авария икән. Ягъни, торбаларның өзелеп, забой төбенә төшеп китүе. Ике мең метр тирәнлеккә, аска төшеп китүе.

Авария кичке сигезләр тирәсендә булган иде. Иртәнге җиделәрдә үк төзәтелеп, эш бераз җайга салынган кебек булды. Шуңа хәтле, төн буена буровойда беркем дә йокы күрмәде.

Авария турында ишетү белән, иң башта баш инженер Варис Миңлебаевич килеп җитте. Мин аның турында нефтьчеләрдән «бик таләпчән, принципиаль» дигән сүзләр ишеткән идем. Әмма Варис Миңлебаевич кемне дә булса ачуланырга, битәрләргә керешмәде. Ул килеп төшү белән аварияне бик тиз арада ничек төзәтү юлын эзләргә тотынды. РИТС (Район инженер-технология службасы) начальнигы Николай Петрович та килеп җитте.

Төнге сәгать бер.

Төнге сәгать ике. Өч.

Варис Миңлебаевич һәм Николай Петрович ашыга-ашыга исәп-хисап ясыйлар, бу очракта иң кулай һәм иң ышанычлы булган, бердәнбер вариантны сайлыйлар. Хәзер аларга торбаларның ничә мең метрда икәнен төп-төгәл ачыклау һәм, шуны төгәл белгәч, торбаның башын табып алу, аны өстән төшкән яңа торбага ялгау кирәк. Күрәсезме — сүздә шактый җиңел чыга. Ә чынлыкта бу эш, мондый аварияне төзәтү бик ышанычлы итеп, зур герметик таләпләргә җавап бирерлек итеп башкарылырга тиеш. Шулай түгел икән, борауланган скважинаны кабул итмәячәкләр. Ничә атналык хезмәт бушка китәчәк!

Төне буе мин аларга — инженерларга карап, аларның ничек баш вата-вата уйлануын күзәтеп утырам. Бу вакытта алар миңа каядыр ерактагы космик корабның язмышын хәл итә торган, шул космик корабның ялгышын төзәтүче зур галимнәр булып күренә. Аларның акылы, аларның акыл көче әнә шул ерактагы корабны җиргә әйләндереп кайтарырга тиеш!

Чагыштыру булса да, бирелә арттыру юк, минемчә. Чөнки өзелеп төшеп киткән торбалар да бик еракта, тирәндә. Алар да әлегә кеше хөкеменә буйсынмыйлар. Чөнки аларны кеше кулына кайтару, үз урыннарына куя кирәк.

«Авария вакытында бары тик инженерларны гына күргәнсең», диярга мөмкиннәр. Юк, алай түгел. Без ул төнне буровойда да бик озак булдык. Будкадан буровойга хәтле ерак түгел — күп булса ике йөз метр. Ләкин бу авария нәкъ менә инженерлар ныклыгын сорый торган, аларның үз урыннарында ни дәрәҗәдә вәкаләтле булуын тикшергән очрак сыман тоелды. Һәм, минемчә, алар бу сынауны әйбәт үттеләр.

Соңыннан авария килеп чыккан әлеге скважинаның язмышы белән кызыксындым:

— Ничек соң, герметика буенча кабул иттеләрме?

Баш инженер тып-тыныч тон белән генә (әйтерсең, буровойда йокысыз үткән төн бөтенләй онытылган):

— Ә, аны әйтәсезме? Әйбәт булды, әйбәт кабул иттеләр аны,— диде.

## Рация янында

Әйе, нефтьчеләр тормышы — тынгысыз, бик тынгысыз. Ул көнне-төнне, шимбәне-якшәмбене белми. Монда тәүлек буена, тәүлекләр дәвамында өзлексез чыгып торган төрле-төрле мәсьәләләр хәл ителә. Бирелә чын мәгънәсендә Себерне, төньякны яулауның алгы сызыгы.

Нефтьчеләр тормышын фронтның алгы сызыгына иң ошаткан нәрсә ул — рацияләр. Рация. Ул һәрбер буровойдагы будкага куелган. Моның өстенә тагын посе-

локта һәм базада рация бар, шулай ук йөз чакрым ераклыктагы Сургутта рация эшли. Алар барысы да бер дулкынга, бер төрле ешлыкка көйләнгәннәр. Һәм бер рациядән бер кешенең сөйләшкәне бөтен барлык рация аппаратларында яңгырап ишетелеп тора.

Рация аша барган бу сөйләшүләрне кайчагында тәүлекләр буена барган оператив киңәшмәгә охшатырга мөмкин. Ләкин шунысы бар: кайчакта үз мәсьәләсе хәл ителү белән, ул кеше үзенең буровоена чыгып йөгерә, аның тавышын син инде тиз генә рациядә ишетмисең. Әйтерсең, бер командир үзенә задание ала да, шунда ук аны үтәр өчен китеп бара.

Кайчагында рация үзе дә байтак кына вакытка тынып кала. Мондый хәл, гадәттә, бөтен буровойларда да эш бик әйбәт барганда була. Ул чагында беркем дә рациягә якын килми — бары тик эшли генә. Рациядә, сигез сәгать үткән саен, сводка бирүчеләрнең тавышлары гына ишетелеп кала.

Нефтьчеләр тормышын белим, өйрәним дигән кешегә менә шушы рация янында басып торып та бик күп нечкәлекләрне белергә була икән. Бервакыт, рация аша сөйләшүләр вакытында, нинди генә нечкәлекләр килеп чыкмый!

Монда сөйләшүчеләрнең тавышы буенча кемгәдер карата булган хөрмәт, ихтирам да чагыла. Юк, һич тә аның эш урынына, дәрәҗәсенә карап түгел. Ә бергә эшләү дәверендә нык сыналган кешегә күрсәтелә торган ихтирам була ул.

Кайберәүләрне, бигрәк тә күрсәтмә генә биреп торучыларны өнәп бетермәү дә шактый ачык чагылып ала бу сөйләшүләрдә. Ләкин бервакытта да, кешеләрнең никадәр кенә ачулары килгән булса да, сөйләшү ямьсез юлга керми, билгеле бер чикне үтеп чыкмый. Нефтьчеләрнең рация аша сөйләшүләре үзенең культуралылыгы, берберенә карата ихтирамлылыгы белән, алар турындагы кайбер дөрес түгел күзаллауларны юкка чыгара.

Бирeдә бик еш кына теге яисә бу әдәби әсәр телгә алына. Кайчагында кешеләр бер-берсенә андагы герой сүзләре белән җавап бирәләр. Мәсәлән, бервакыт буровойдан мастер ниндидер ярдәм сорый. Ә диспетчер, тегенең түземлелеген сыныйм әле диган төсле:

— Ильф белән Петровны укыдыңмы? — ди.— Укымасаң, вәт, белеп тор, анда болай диелә: «Спасение утопающих — дело рук самих утопающих».

Билгеле, ахыр чиктә диспетчер теге мастерга ярдәм итә инде. Ләкин, шул ук вакытта, ул әлеге сүзләре белән: «Ә үзегезнең мөмкинлекләр турында ныклап уйлап карадыгызмы соң? Бәлки читтән ярдәм сорамыйча да эшләп буладыр ул эшне?» — дип кисәтә дә төсле... Чөнки, гел читтән ярдәм иткәнне көтеп кенә ятучылар да юк түгел бит әле.

Рация аша һәрчак иң ашыгыч, иң кирәкле мәсьәләләр хәл ителә. Кемгәдер бик тиз арада запчасть кирәк, кемгәдер торба китерүче машина ярты юлда батып калган — аны тартып чыгару сорала, бригададан кемгәдер бик ашыгыч телеграмма килгән — аны юлга озату кирәк, тагын ниндидер комиссия булачак, барлык буровойлар куркынычсызлык техникасы буенча әзерләнергә тиешләр. Һәм башкалар, бөтен бик күп төрле мәсьәләләр... Боларның барысы бергә — нефтьчеләр тормышы дип атала.

Рация аша сөйләшүләрне тыңлап торганда бик кызык сүзләр дә ишетәсең. Менә бер көнне буровойга Сургуттан конкурс буенча инженер, яшь кенә кыз килгән. Ул рация аша диспетчерга эндәшә: «Икенче буровойга барырга автобус кирәк иде».— ди. Моны диспетчер бик игътибар белән тыңлап тора да:

— Валя, җаным, бөтен аавтобусларымны алып бетерделәр бит. Менә берсе генә калды,— ди, аның бик тә хәленә кергән кеше тавышы белән.

Ә Валя моңа чын күңелдән ышанып, тагын дәшә рациядән:

— Соң, алайса, шунысын җибәр инде.

— Ярый, алайса, мин сиңа топ-тобус җибәрәм! Хәзер барып җитәр!

Бирeдә топ-тобус дигәннең нәрсә икәне күпләргә мәгълүм — ул, безнеңчә әйткәндә, тәпи-тәпи бару булып чыга инде.

Бөтен машинасы булмагач, диспетчер нәрсә бирә алсын тагын шуннан башка! Аның да хәлен аңлагыз, кызлар...

Дүрт көн буе миңа да диспетчер булып утырырга туры килде. ЦИТС — центральная инженерно-технологическая служба — диспетчеры булып. «131» дигән позывной

белән мин дә эфирга чыга идем һәм кайбер мәсьәләләрне хәл итәргә маташа идем. Чөнки, чын диспетчер үзе ялсыз бик озак эшләгән иде, аңа хәзер ял кирәк иде. Вакытым булудан файдаланып, мин дүрт көн диспетчер хезмәтен башкардым.

Бу эш шулай ук байтак кына мәшәкатьле. Аңа да көн-төн тынгылык юк. Монда утырганда минем үземә, мәсәлән, күп мәртәбәләр Сургут белән элемтәгә керергә туры килде. Чөнки күп белгечләр анда эшли. Тагын төнге сәгать икедә поселокта урнашкан бүтән оешма кешеләрен — тампонаж конторасы эшчеләрен йокыдан уятып, буровойга җибәрергә туры килде. Чөнки аларны бораулап бетерелгән әзер скважина көтә иде. Ә бу эшне һич тә иртәнгә чаклы сузарга ярамый!

Шулай итеп дүрт көн эчендә мин дә кайбер нәрсәләр хәл итәргә тырыштым. Соңга таба, икенче рациядәге бүтән диспетчерлар минем кем икәнлекне сизенделәр ахрысы, алар миңа «131» дип эндәшергә уңайсызланып, исемемне һәм әтинең исемен сорый башладылар. Сөйләшкәндә эндәшү өчен, ягъни.

Рация — үземнең алгы сызыкта булуым хакындагы иң якты бер истәлек булып калды...

## Хантлар

Бу тирәләрдә элек-электән яшәүче җирле халык — хантлар булган. Ләкин, алдарак әйтеп үткәнебезчә, алар хәзер еракка, тайга эченә күчеп киткәннәр. Мин поселок кешеләреннән: «хантларны ничек күрергә мөмкин соң?» — дип сорагач, күбесе: «Шул, үзләре янына, тайгага барсаң гына инде...» — дигән иде. Аларның мондый сүзләрен ишеткәч, өметем бөтенләй сүнде. Монда булып, бу якның төп халкын күрми китү, ничектер, иң кирәк нәрсәне очратмау кебегрәк тоела иде.

Әмма бәхетем бар икән — мин хантлар белән дә очраштым! Шулай беркөнне поселоктан, 310 нчы буровойга бармакчы булып, җәяүләп кенә чыгып киттем. Буровойга бару юлы бик матур урыннардан уза: иң башта, поселокны чыгу белән, шактый киң Пим елгасы аша үтәсең. Пим өстенә килеп кергәч, аның тирәсендәге матурлык тагын да ачыграк, тулырак күренә төсле. Ике як ярында ерак-еракларга сузылып киткән калын нарат урманы. Ул меңләгән еллар буена бер адәм заты күрми үсеп яткан мәгъруր Себер тайгасының төп сыйфатларын югалтмаган урман әле. Аның юан-юан наратлары бер урында инде Пим өстенә үк авышып төшкәннәр, ә икенче җирдә, мәхәббәтен аңлаткан гашыйк төсле, иелеп кенә торалар...

Пим бозында басып торганда, күңел нәкъ менә Себер җиренә генә хас киңлекне тоеп алгандай була. Самолетта Себер өстеннән очканда туган тойгы — иркенлек, чиксезлек тойгысы елга өстендә яңадан уяна. Шул вакытта үзеңне бу калын һәм игечиге күренмәгән урманнарда, бу киңлектә бер ялгызың гына итеп күрәсе килеп китә. Миндә уянган бу яңа тойгы — адәм баласына бик борынгыдан сеңеп калган, табигатьне тансыклау, аның белән бергә-бер булырга теләү хисе, ахрысы. Әнә шундый чакларда еш кына уйлап куясың: таш йортлардан әз генә ераккарак китеп торсаң да, мәңгелекнең нинди гүзәл хатирәләре яңара икән бит бездә. Тоташ таштан торган тормыш эчендә яшәп, без үзебезнең меңнәрчә еллар буена килгән күпме матурлыгыбызны онытып йөрибез икән бит...

Сукмак Пим өстеннән бара да аннары сөзәк ярга күтәрелә. Яр башына менгәч, бу сукмак, һич уйламаганда, машина юлына әйләнә. Чөнки поселок егетләре менә шушы ярга хәтле машина, трактор белән кайталар да, боз өстенә машина белән керергә ярамагач, транспортларын яр башында калдырып, җәяү генә атлыйлар. Янсә, бүтән йомыш белән поселокка килсәләр дә, машина шулай яр башында калып тора.

Менә Пим өстеннән ярга күтәрелеп, бераз карап тордым да әлеге машина юлы буйлап әкрен генә китеп бардым. Юл һаман яр кырыеннан ераклашмый, елгага терәлеп үк бара. Сул ягында — урман.

Шулай, табигатькә исем китеп барганда, кинәт ... нда нәрсәдер игътибарымны җәлеп итте. Мин текәлебрәк карадым һәм үземә таба чабып килгән боланнарны күреп алдым. Мин моңарчы зоопаркта гына күргән боланнар!

Аларны күрү белән мин, билгеле алга барудан туктадым. Үз урынымда баскан ки-

леш кенә, авызымны ачып дигәндәй, моңарчы бер дә күрмәгән бу хикмәтне күзәтеп тора башладым.

Боланнар миңа отыры якынлашты, якыная барды. Алар әллә ни зур хайван түгел икән үзләре, җирдән бер метр чамасы гына калку. Әмма бик тә җитез чабалар! Алты болан бер чананы һәм аңа утырган өч кешене минем күз алдыннан очыртып кына алып китте!

Чанага хантлар утырган иде. Алар ачык яшел төстәге, безнең яктагы плащка охшаганрак формадагы кием кигәннәр. Ул кием бихисап күп тәңкәләр белән бизәлгән, тәңкәләр арасыннан билгә асылган пычак та күренеп калды. Аякта, билгеле инде, җылы тиредән тегелгән җиңел аяк киеме. Ә иң кызыгы: менә шушы утыз градус салкынлы январь көнендә ир-ат хантлар яланбаш иделәр!

Ул вакытта минем күз алдыннан бер-бер артлы өч чана үтеп китте. Беренче чанада ир-атлар утырган һәм алар үз телләрендә кызып-кызып нәрсәдер сөйләшәләр иде. Шул арада кулларындагы озын таяк белән боланнарны да куалыйлар. Ә икенче чанада олырак яштәге хатын-кызлар иде. Алар әкрен генә ниндидер көй сузалар. Ул көй бик сузынкы, моңлы көй — аларның үз көйләре.

Хатын-кызлар киемендә дә бер кызык үзенчәлек бар икән: алар битләрен тоташтан диярлек кат-кат яулык белән каплаганнар. Ләкин ул яулыклар биттән алгарак чыгып тора һәм нәкъ күз турысында кечкенә генә тишек калдырылган. Соңыннан, кешеләрдән сорашкач, моны төрлечә аңлаттылар. Берәүләр: хатын-кыз чит ир-атка йөзен күрсәтмәсен өчен, диде. Икенчеләр исә: бу якларда бик көчле була торган җил битне кисмәсенгәдер, дип аңлатты. Бәлки икесе дә дөрестер.

Ә өченче чанада... Ә анысында бүтәннәр янәшәсендә яшь кенә бер хант кызы да утырып бара иде! Ул үзләренең тайга эчендәге ялгыз өйләреннән, урман уртасында бер үзләре генә гомер итүдән — поселокка таба, бу яклар өчен зур шәһәр кебек саналган поселокка таба бара иде!

Бу күренеш миңа бик мәгънәле тоелды. Һәм, гомумән, тайга уртасында көтелмәгәндә килеп чыккан хантлар белән бу очрашу минем өчен бер матур кино сыманрак булып калды. Чынлык белән хыял арасындагы бер күренеш булып.


Әмма шунысы да бар: мин хантларны тагын күрдем. Шул ук көнне, поселокка кире әйләнеп кайткач, яңадан очраттым мин аларны. Бөтенесе бергә, кибет каршындагы иркен генә бер урынга килеп тукталганнар иде. Боланнарның кайсысы яткан, кайсысы аяк өсте генә ял итә. Теге вакытта минем яннан узып киткәндә күрми калганмын ахры — хантларның үзләре белән кечкенә балалары да булган икән. Алар хәзер, ямь-яшелдән киендерелгән кечкенә курчаклар кебек, чанага бер менеп, бер төшеп, боланнарга нидер дәшкән булып кинәнеләр. Ә әти-әниләре кибеттә. Хантлар бирегә кирәк-ярак алып китәргә килгәннәр.

Ул арада каяндыр бик затлы, заманча киенгән эстон егетләре килеп чыкты (алар да поселокта тора) һәм черт-черт итеп хантларны, боланнарны фотога да төшерә башладылар. Көнбатыш республикадан килгән кешеләр өчен бу — бик кызык экзотика инде, билгеле! Алар фотога төшереп маташканда, якындагы борылмадан бик зур трактор да килеп чыкты. Эстон егете боланнар һәм хантлар янәшәсендә замана тракторын да төшереп алды. Икесе бер кадрга сыйгач, шактый кызык килеп чыга бит! Егерменче гасырның типик күренеше...

**Шәмси Хамматов,**
доцент, тарих фәннәре кандидаты

**Йосыф Закиров,**
партия, сугыш, хезмәт ветераны

# МУСА ҖӘЛИЛ ҺӘМ МӘСКӘҮ МАТБУГАТЫ



Шагыйрь-журналистның Мәскәүдә яшәү чорында иҗат иткән публицистик әсәрләре бүгенге җәмәгатьчелек өчен таныш түгел диярлек.

Мәскәүдә ВКП(б) Үзәк Комитетының татар-башкорт бюросы органы буларак чыккан «Эшче» (1918—1931) газетасында партия карарлары басыла, аның ленинчыл милли политикасы ана телендә пропагандалана һәм аңлатыла. Ул эшчеләр тормышын киң яктырта, культура, әдәбият, сәнгать мәсьәләләрен игътибар үзәгендә тота. Анда илебезнең эшче хәбәрчеләре, әдипләре, журналистлары, культура работниклары күп язышa. Муса Җәлил дә Мәскәү университетында укыган елларда «Эшче» газетасының танылган публицисты булып әверелә. Ул шулай ук ВЛКСМ Үзәк Комитеты органнары «Кечкенә иптәшләр», «Октябрь баласы», «Ударниклар» журналларын оештыручы, «Коммунист» газетасының төп терәге, җаваплы хезмәткәре була.

*
* *

Мәскәүдә 20 нче елларда һәм 30 нчы еллар башында татар телендә чыккан «Эшче», «Игенчеләр», «Коммунист» газеталары, «Фән һәм дин», «Кечкенә иптәшләр», «Октябрь баласы», «Яшь эшче» (соңыннан «Ударниклар») журналлары һәм башка милли матбугат органнары хезмәт ияләре, яшүсмерләр, яшьләр арасында партиябез һәм дәүләтебез политикасын пропагандалауга, культурабызны үстерүгә шактый өлеш керттеләр. М. Җәлил — шул матбугат битләрендә яшьләр, эшчеләр, ударниклар, иҗат кешеләре, партия һәм комсомол тормышы турында иң күп чыгыш ясаган журналистларның берсе.

1927 ел. Май аена милли комсомол җитәкче работникларының Мәскәүдә Бөтенсоюз киңәшмәсе билгеләнә. Шул уңайдан «Эшче» газетасы киңәшмәдә тикшереләчәк мәсьәләләр буенча фикер алышу оештыра. Комсомолның өяз комитеты инструкторы, ВЛКСМның Оренбург губерна комитеты члены М. Җәлил ул газетаның 1927 елгы 5 март санында «Читен мәсьәләләрнең берсе» дигән мәкалә бастыра. Ул яшәп килгән кыенлыкларны ачып бирә, кайбер комсомол оешмалары җитәкчеләренең яшьләрне тәрбияләүдә ялгыш караштa торуларын тәнкыйтьли. Комсомолның вак милләтләрдән

торган түбәнге оешмаларындагы эшне җанландыру максатыннан киңәшләр бирә, «түбәнге оешмалар өчен су белән ут урынына кирәк булган сукмакларны» билгели. Бу — М. Җәлилнең политик яктан үсүен, мөһим мәсьәләләргә дөрес бәя бирә белүен күрсәтә торган актуаль мәкалә.

1927 елда М. Җәлил башкалага килә, укый, эшли башлый. ВЛКСМ Үзәк Комитетының татар-башкорт бюросы члены буларак, аңа эшче-крестьян яшьләре, комсомол эшчәнлеген матбугатта яктырту вазифасы тапшырыла. Партия карарлары һәм директиваларына таянып, ул үз чыгышларында яшьләрне коммунизм рухында тәрбияләү, аларның белемен, квалификациясен күтәрү, социализм төзү һәм илнең оборона сәләтен ныгыту эшенә тарту бурычларын аеруча калку итеп күрсәтә.

Менә М. Җәлилнең Бөек Октябрь социалистик революциясенең 10 еллыгына карата язылган «Октябрь һәм эшче яшьләр» (1927 ел, 5 ноябрь саны) дигән мәкаләсе. Илебез хезмәт ияләре бу бөек бәйрәмне халык хуҗалыгының барлык тармакларында гаять зур уңышлар белән каршылый, совет кешеләренең көнкүреш шартлары яхшыра, 7 сәгатьлек эш көненә күчү тормышка аша, артта калган аграр илне индустриаль илгә әйләндерү өчен героик көрәш җәелә, дип күрсәтелә анда. Ул яшьләр өчен гомуми, югары, производство белеме бирү һәм сәламәтлек саклау өчен шартлар тую турында шатланып яза.

Коммунистлар партиясенең ярдәмчесе һәм резервы булган комсомолның социалистик җәмгыятьтә тоткан урыны турында фикер йөртеп, М. Җәлил аны Октябрьның яшьләргә биргән иң беренче һәм төп бүләге хөкүмәтебез «ныклыгын, яшәвен һәм үсешен үткен күзәтүче, пролетариат көрәшенә таза алмаш хәзерләүче таза армия» дип атый.

М. Җәлил, ил алдында торган бурычлардан чыгып, мәкаләсен түбәндәге сүзләр белән тәмамлый: «10 еллыктагы бурычларыбызның зурысы — илебезнең хуҗалык хәлен ныгыту, индустрияләштерү һәм шуның аркылы сугыш көчен күтәреп, дошманнарның һөҗүменә каршы хәзерләгән арттыру, илебездәге социализм төзелешенең тизләгән көчәйтү. Икенче — пролетариат яшьләренең революцион кузгалышын үстерү, чит ил көрәшчеләренә якынаю, комсомолның сафларын тыгызлау, эшче яшьләрнең бөтенесен һәм ярлы, урта крестьян яшьләренең киң катлавын оештыруга курс алу, комсомолның көндәлек эшенең сыйфатын күтәреп, илнә төзү бурычлары белән бәйләү.

Бу бурычлар, үткән ун елдагы шикелле, алдагы ун елда да, шиксез, уңышлы рәвештә тормышка ашарлар».

Бу чорда илне индустрияләштерү һәм, партиянең XV съезды карарлары нигезендә, авыл хуҗалыгын күмәкләштерү өчен киеренке көрәш бара. Шундый шартларда (1928 ел, май) комсомолның VIII съезды җыела. Съезд алдыннан, ул барган көннәрдә һәм съездан соң «Эшче» газетасында М. Җәлилнең алты мәкаләсе басылып чыга.

Газетаның 1928 елгы 8 апрель саны. М. Җәлил «Комсомолның VIII съезды алдыннан» дигән мәкаләсендә ВЛКСМның VII съездыннан соң үткән ике елда комсомолның эш йомгакларын, Ленин партиясе җитәкчелегендә киң катлау эшче-крестьян яшьләрен илдә социализм төзү эшенә тартуын, контрреволюцион троцкистик оппозициянең яшьләрне партиягә каршы куярга маташуын кискен рәвештә кире кагуын, комсомол сафларында пролетариат йогынтысының ныклыгын, аның большевистик идеяләр белән сугарылганлыгын, миллионнарча ВЛКСМ членнары һәм киң катлау яшьләрне илне саклау эшенә хәзерләүдә бик күп чаралар үткәрелүен аерып күрсәтә.

Татар-башкорт комсомол оешмаларының ике еллык эш йомгаклары турында М. Җәлил болай дип яза: «Эшче яшьләргә хезмәт белемен бирү, һөнәрләрен күтәрү, производство тормышына якынлаштыру, фабзавуч мәктәпләре челтәренә күбрәк алу юлында зур уңышларга ирешелде. Авыл яшьләре авылның общий сәяси эшләренә тартылдылар. Татар-башкорт комсомолы пролетариат культурасын төзү мәсьәләсендә дә катнашып, үзенең туры сүзен әйтте. Ул төрле калыпка төренеп, яшьләр һәм комсомол сафына йогынты ясарга омтылган дин агуларына каршы көрәште. Әдәбиятта булсын, аң-белем һәм агарту эшләрендә булсын, пролетариат идеологиясе гегемонлыгын булдыру теләгеннән тайпылулар белән кискен көрәшеп, үзенең сафыннан яңа эшче культура хезмәтчеләре, әдипләр, язучылар кадрын хәзерләде».

М. Җәлил ВЛКСМның VIII съездында катнашып, аның беренче утырышыннан «Комсомолның VIII съезды», «Яшь большевиклар» партиягә алмашка», йомгаклау

утырышыннан «Большевикларча таза тәнкыйть аркылы яңа җиңүләргә!» дигән репортажлар яза. Съезд карары яктылыгында М. Җәлил комсомол яшьләрне буржуаз идеологиягә йогынтысына каршы көрәшне кискенләштерергә чакыра, авыл хуҗалыгын коллективлаштыруда комсомол алдында торган төп бурычларны һәм чараларны аңлата.

Комсомолның VIII съездыннан соң «Бездә тәнкыйть», «Комсомол эшендә ирекле группалар методы», «Яшьләр арасында агарту эшләре» дигән баш мәкаләләрендә ул съезд карарларын пропагандалый, эштә булган җитешсезлекләрне ача, аларны бетерү өчен комсомол оешмаларында тәнкыйть җәелдерергә өнди, җитәкчелек эшендә сизелә башлаган формализмга каршы кискен көрәш алып барырга чакыра.

1929 ел тарихка «Бөек борылыш елы» дип кергән. «Бишьеллыкны — дүрт елда» дигән лозунг астында социалистик ярыш киң җәелә. Комсомол сафыннан беренче ударниклар килеп чыга. Социализм төзү өчен барган бу көрәш М. Җәлил мәкаләләрендә чагылыш таба, аларның тематикасы үзгәрә. «Производство фронтында комсомол», «Комсомол ярышка хәзерләнә» дигән мәкаләләрендә ул предприятиеләрдә брак чыгаруны бетерү, эшче яшьләр арасында төрле профессияләр буенча конкурслар үткәрү, аларның киң массасын социалистик ярышка тарту турында эшлекле сөйләшү алып бара.

1929 елның апрелендә совет җәмәгатьчелеге Галиәсгар Камалның 30 еллык иҗади бәйрәмен киң билгеләп үтә. Әдәбият һәм драматургия өлкәсендәге зур хезмәтләрен искә алып, Татарстан хөкүмәте Г. Камалга «Хезмәт батыры» дигән мактаулы исем бирә. Бу зур бәйрәм Мәскәүдә дә үткәрелә. Галиәсгар Камал иҗаты турында әдәбият түгәрәге һәм МАПП (Мәскәү пролетариат язучылары ассоциациясе) секциясенең берләшкән җыелышында Муса Җәлил доклад ясый.

М. Җәлил Мәскәүдәге эшчеләр коллективлары белән еш очраша. Ул «Урак-Чүкеч» заводы эшчеләре алдында чыгышлар ясый, предприятие турында «Эшче» газетасында яза. Аның «Бер өзеклек турында»гы хәбәрендә заводның тимерчыбык ясау цехында өзеклек килеп чыгуы, эшчеләрнең, бигрәк тә ударникларның тырышлыгы белән аның бетерелүе сурәтләнә.

«Эшче»дә М. Җәлилнең «Яшьләр өчен көрәш позициясендә» дигән мәкаләсе басыла. Ул XV Халыкара яшьләр көненә карата язылган. Бу көн яшьләрне коммунизм йогынтысы астына туплау өчен барган көрәш позицияләрен тикшерү көне булачак, ди ул. Халыкара яшьләр көнен сыйнфый дошманның астыртын чыгышларына каршы кискен көрәш, комсомолның сафларын ныгыту, социалистик ярышны киңәйтү, эштә булган җитешсезлекләрне бетерү, ашлык хәзерләү кампаниясенә әһәмиятне көчәйтү өндәмәләре белән үткәрергә кирәклек турында яза.

М. Җәлил яшьләрне марксизм-ленинизм тәгълиматы белән коралландыру хакында бик нык кайгырта. «Эшче»дә басылган «Революцион теория өчен походка» исемле алты бүлектән торган мәкаләсендә ул, партия күрсәтмәләрен пропагандалап, болай ди: «Революцион теориядән башка революцион практика булуы мөмкин түгел. Революцион теориядән башка, сыйнфый көрәшне теория ягыннан тирән аңлаудан башка комсомол үз сафында большевиклар, халыкара пролетариат революционерлары тәрбияли алмый» («Эшче», 1929, 15 сентябрь).

Социализм төзү фронтының нинди генә тармагын алсак та, без анда публицист М. Җәлилне күрәбез. Ул, ил белән бергә сулыш алып, чорның актуаль мәсьәләләрен күтәрә. «Авылда комсомол», «Большевизм темпы өчен көрәшкә», «Матур әдәбият — бишьеллык өчен көрәшкә», «Промышленность миллионлаган эшче көчләр сорый», «Октябрьның 14 еллыгына милли эшче-кадрлар», «Нефть планын ике ел ярымда тутырабыз» дигән мәкаләләре әнә шуны раслый.

Шагыйрь-журналист М. Җәлил Мәскәүдә яшәгән рус, башка милләт халыклары язучылары А. Фадеев, А. Жаров, А. Безыменский, М. Светлов, Э. Багрицкий һ. б. белән аралаша. М. Горький, В. Маяковский чыгышларын тыңлый. Әдипләр җыелышларында, пленумнарында катнаша һәм вакытлы матбугат өчен отчетлар, репортажлар яза.

Бөек пролетариат язучысы А. М. Горький әдәбиятчыларны заводлар тарихын язарга чакыра. Партия Үзәк Комитеты әдипнең бу инициативасын яхшы дип таба. М. Горький җитәкчелегендә 31 кеше составында «Заводлар тарихы»н төзү редколлегиясе раслана. «Правда» газетасының 1931 ел, 7 сентябрь санында М. Горькийның

«Фабрика һәм заводлар тарихы» исемле мәкаләсе басыла. «...Безгә,— дип яза М. Горький,— үзебезнең чынбарлыгыбызны һәрьяклап өйрәнергә кирәк, безгә барлык завод һәм фабрикаларыбызның йөзен, барлык предприятиеләрне, дәүләт төзелеше буенча барлык эшләрне белергә кирәк. Безгә үткәннән мирас булып калган һәрнәрсәне һәм 14 елда булдырылган, бүген булдырыла торган һәрнәрсәне бөртекләп, һәрьяклап белергә кирәк...

Эшчеләр завод булдырдылар, алар аның тарихын — үз эшләренең тарихын да язарга тиешләр».

М. Җәлилнең «Эшче» газетасында (1931 ел, 11 ноябрь) «Заводлар тарихын языйк» исемле күләмле мәкаләсе басыла. Анда ул РАППның (Россия пролетариат язучылары ассоциациясе) пленумында А. М. Горький чыгышының тарихи әһәмияткә ия булуын рухланып яза: «Пленум шунда ук Максим Горький куйган яңа, чиксез зур, җаваплы һәм тарихи бурыч тирәсенә бөтен пролетариат язучыларын мобилизовать итү турында үзенең кискен карарын чыгарды.

Максим Горький башлавы белән күтәрелгән бу данлыклы, зур җаваплы эш партия Үзәк Комитеты тарафыннан да зур игътибар белән каршы алынды. Үзәк Комитет заводларның тарихын язу турында бөтен эшчеләргә, гыйльми көчләргә, тарихчыларга, әдәбиятчыларга ачык юнәлеш биргән билгеле карарларны чыгарды»...

Заводлар тарихын язуның пролетариат матур әдәбиятында яңа сәхифә ачуын, бу мөһим эшнең киң катлау эшчеләр һәм ударниклар катнашы белән алып барылырга тиешлеген М. Җәлил яхшы аңлый. «Заводлар тарихын язу эшенә,— ди ул,— бөтен матур әдәбият фронты тартылырга тиеш. Ленинград, Мәскәү, Харьков язучылары бу походны башладылар. «Кызыл путиловец» һәм «Динамо» заводлары бу эшкә ныклап керештеләр. Татар пролетариат язучылары үзләренең сүзләрен әйтергә тиешләр».

«Эшче» газетасының «Әдәбият фронты» дигән сәхифәләрен оештыруда МАППның (Мәскәү пролетариат язучылары ассоциациясе) татар секциясе членнары М. Җәлил, Ш. Шәһрәтдинов, М. Крымов, Ш. Усманов, Ә. Ерикәй актив катнашалар. Аларның шигырьләре һәм мәкаләләре әнә шул сәхифәләрдә басыла. «Эшче»нең 1930 елгы 2 март санында татар секциясе членнарының фоторәсемнәре бирелә.

1929—1931 елларда «Эшче» газетасы битләрендә коммунист М. Җәлилнең «Без партия һәм комсомол чакырган фронтта», «Культура походын көчәйтү турында комсомоллар карары», «Революцион теория өчен походка» исемле публицистик язмалары, шулай ук халыкара яшьләр көненә багышланган, троцкизмга, солтангалиевчелеккә каршы кискен көрәш ачарга чакырган, театр һәм әдәбият мәсьәләләрен күтәргән шактый мәкалә, шигырь һәм рецензияләре чыккан.

1927—1929 елларда М. Җәлилнең «Игенчеләр» газетасында да берничә мәкалә һәм шигыре басылган. Алар арасында «Уңыш походына җырлар», «Урожай походы һәм кызлар», «Авылда комсомол» дигәннәре игътибарга лаек. Ил алдына зур яңа бурычлар — кулакларны бетерү һәм крестьяннарның төп массасын колхоз юлына күчерү проблемалары килеп баса. М. Җәлил әнә шул бурычларны аңлатуга үз иҗаты белән өлеш кертә.

Ул «Игенчеләр» газетасында (1929, 13 март) «Мостафа малае» имзасы белән «Уңыш походына җырлар» исемле шигъри мәкаләсен бастыра. Шулай ук ул авылда хатын-кызларның тоткан ролен күрсәтеп, «Игенчеләр» газетасында «Урожай походы һәм кызлар» дигән мәкалә чыгара. «Авыллардагы киң массаның зур бер өлеше — кызлар,— дип яза Җәлил.— Бездә кызлар хуҗалыкны төзү, яңарту кебек күмәк эшләрдә моңарчы бер дә батыр катнашмадылар. Комсомол походының үзәк бурычларының берсе — шушы артта калган татар-башкорт кызларын авыл хуҗалыгын төзү эшенә тарту, аларны походның алдынгы солдатлары итү булырга тиеш».

Бөек Октябрь революциясенең 12 еллыгына карата язылган «Авылда комсомол» дигән күләмле мәкаләсендә М. Җәлил партия директивалары нигезендә авыл комсомолы алдында торган бурычларны, аларны үтәү юлларын аңлата. Ул авыл комсомолларын колхоз төзелешендә инициатор, массаны оештыручы булырга, һәрвакыт килешмәүчән сыйнфый көрәш байрагы астында барырга, партиянең генераль линиясеннән тайпылуларга каршы кискен көрәшергә чакыра.

Муса Җәлил 1930—1932 елларда Мәскәүдә чыгып килгән ВЛКСМ Үзәк Комитe-

тының «Ударниклар» журналында да актив язышa. Ул аның редколлегия члены була. Аның бу журналда 15 тән артык шигырь, очерк һәм мәкаләсе басылган. 1930 елның 6 санында комсомолның IX съезды алдыннан «Большевизм темпы өчен көрәшкә!» дигән зур мәкаләсе чыккан. Сүз уңаеннан шуны да әйтеп үтик, «Эшче» газетасының 5 октябрь санында шул ук темага «Муса» имзасы белән баш мәкалә дә бирелә. Автор, ВКП(б) ҮК өндәмәсеннән һәм ВЛКСМ ҮК карарыннан чыгып, бишьеллык планны дүрт елда үтәү өчен көрәштә комсомол оешмалары алдында торган бурычларга тукталa, бишьеллыкның өченче елында сафка басачак промышленность гигантларын санап үтә.

Илне индустрияләштерү һәм авыл хуҗалыгын күмәкләштерү эше кискен сыйнфый көрәш шартларында барды. Сыйнфый дошман «безнең гигант эшебезгә аяк чалмакчы була. Бу көрәштә сыйнфый дошман чит ил буржуазиясе белән бәйләнештә булып, ил эчендә троцкизм калдыкларыннан һәм уң оппортунистлардан файдаланды,— дип яза М. Җәлил.— IX съездга хәзерлек — менә шул көрәштәге көчебезне барлау, сафларыбызның сугышчанлыгын тикшерү», бишьеллыкның өченче елын тулы уңышлар белән каршылау нигезендә барсын.

1930 ел илебез тарихында зур вакыйгаларга бай булды. Ул елны беренче зур тимер юл — Турксиб сафка басты. 17 июнь көнне Сталинград заводы конвейерыннан беренче трактор төште. Совет матбугатында бу әһәмиятле вакыйгага зур урын бирелә. Әдипләр, публицистлар партия җитәкчелегендә яулаган бөек җиңүгә мәдхия җырлыйлар. «Ударниклар» журналында (2 сан) М. Җәлилнең дә «Гигант өлгерде» дигән очеркы басыла. Автор Тракторстройда көннән-көн киң колач ала барган социалистик ярыш, эшчеләрнең удар бригадаларга берләшеп, кыен шартларга карамастан, планны күп мәртәбә арттырып үтәүләре, гади эшчеләр арасыннан намуслы, бөтен эштә алда баручы бригадирлар үсеп чыгуы турында шатланып яза.

Сталинград трактор заводы төзелү илебез авыл хуҗалыгын күмәкләштерүгә гаять зур йогынты ясый. Октябрь революциясе таңында «әле хыял гына» булган идея киң адымнар белән тормышка аша.

МАППның татар секциясе җитәкчесе буларак, М. Җәлил әдипләрне, шагыйрьләрне завод-фабрикаларда, эшче коллективларда ешрак булырга, алар тормышын чагылдырган әсәрләр язуга чакыра. Ул «Матур әдәбият — 5 еллык өчен көрәшкә!» дигән баш астында басылган бер мәкаләсендә («Ударниклар», 1930, 6 сан) ул шигъри юллар белән болай дип яза:

**Каләм —**
**Күмер бирсен, тимер бирсен,**
**Каләм —**
**Зур эшләргә җигелсен!**
**Һәр сугышта артка чиккән дошман,**
**Каләм сугышында да җиңелсен!**

Мәкалә МАППтагы татар секциясенең берләшкән утырышында партия Үзәк Комитетының өзеклекләр һәм бишьеллыкның өченче елына хәзерлек турындагы өндәмәсен һәм шул нигездә РАППның әдипләргә аталган ачык хатын тикшерү уңае белән язылган. Утырышта секция эшендәге җитешсезлекләр тәнкыйть ителә, аларны бетерү өчен төгәл чаралар билгеләнә. Секция җанлы газеталар, эшчеләр сәхнәсе өчен бишьеллыкка карата әдәби материаллар җыентыгы чыгару кирәклеген билгеләп үтә һәм татар эшчеләре күп булган завод-фабрикаларга әдәби бригадалар җибәрә. Подольскига механика заводына Урманов, Әюп Гарәй, М. Давыдов, «Урак-чүкеч» заводына — Әхмәт Ерикәй, Вил Садрый, Муса Җәлил, «Кызыл Богатырь» резина заводына — Шамил Усманов, М. Крымов, М. Максуд иптәшләр беркетелә һәм әдәби бригадалар эшкә керешәләр.

1932 елда башкалабыз Мәскәүдә метрополитен төзелә башлый. Бу төзелештә эшләү өчен илебезнең төрле почмакларыннан квалификацияле эшчеләр килә. Шулар арасында озак еллар буена Төньяк Кавказ, Закавказье тимер юлларында һ. б. җирләрдә эшләгән тоннель эшләре остасы Вәлиәхмәт Вахитов, моторчы Гыйлаҗ Шәмсетдинов, десятник Мингалиев һәм башка бик күп кадровый эшчеләр була.

Метрополитен төзелеше батырларының эшчәнлеге үзәк газета-журналларда, шул

исәптән «Ударниклар» журналында да чагылыш таба. Журналның соңгы 12 санында (ул 1932 елның декабрендә чыгудан туктый) «Туннель инструкторы Вахитов» дигән очерк басыла. М. Җәлил, гадәттән тыш вакыйгаларны үз күзе белән күреп, вакытлы матбугатка бирелә торган материалны «беренче кулдан» алу өчен Метростройның уникенче шахтасына, Вахитов эшләгән урынга бара. Вахитов революциягә кадәрге тормышның бөтен авырлыкларын татыган, үз тырышлыгы белән һөнәр алган атказанган эшче була. «Мин аны,— ди Муса Җәлил,— беренче күрү белән мондый күңелле, сабыр, эшкә җитез булуы ягыннан үлчәп исем киткән иде». В. Вахитов мәктәп бетереп, югары белем алган кеше түгел, ул — практик. Шахтада иң алдынгы активистлардан санала. Эш сәгатьләрендә генә түгел, эштән бушаган чакларда да үзенең шахтасын исеннән чыгармый. Яңа килгән эшчеләрне өйрәтә, мондагы эш процесслары белән таныштыра. Аны барлык эшчеләр якын күреп, дус итеп яраталар.

Автор үз героеның кешелеклелеген яратып сурәтли. Үзенә мөрәҗәгать итүчеләрне ул көлемсерәп, якты йөз, дустанә каршы ала, кешеләрнең белмәгән, төшенмәгән нәрсәләрен сабырлык белән аңлатып бирә. Муса Җәлил очерк героен безнең күз алдыбызга яшьләрне оста тәрбияләүче остаз итеп китереп бастыра.

*

* *

Егерменче еллар ахырында, утызынчы еллар башында Мәскәү үзәк татар матбугатының даими авторлары арасында Фәтхи Бурнаш, Фатих Сәйфи-Казанлы, Мәхмүд Максуд, Шиһап Шәһретдинов, Афзал Шамов, Шәйхи Маннур, Кави Нәҗми, Мансур Крымов, Әхмәт Ерикәй, Шамил Усманов, Салих Баттал, Гали Ильясов, Идрис Агишев, Нур Сәйфи, Гомәр Бәширов, Әминә Абдуллина, Гадел Кутуй, Ләбиб Гыйльми, Зәйнәп Бәширова, Вил Садрый, Габдрахман Минский, Гомәр Баязитов, Хәмит Мөҗәһитов, Мирза Давыдов, Афзал Таһиров, Гали Динмөхәммәтов, Әхмәт Фәйзи, Әсгать Айдар, Латыйф Хәмиди, Хәсән Хәйри, Максуд Сөндекле, Гариф Галиев һәм башка бик күп язучылар, шагыйрьләр, журналистлар, партия, комсомол, совет эшлеклеләре бар. Муса Җәлил исә Мәскәүдә чыккан татар вакытлы матбугатында иң актив публицистларның берсе булып танылa. Ул партия, комсомол, илебез, халкыбыз тормышындагы актуаль проблемаларны күтәрә. Аның 1927—1932 елларда гына «Эшче», «Игенчеләр» газеталарында, «Кечкенә иптәшләр», «Октябрь баласы», «Фән һәм дин», «Ударниклар» журналларында йөздән артык публицистик мәкаләсе, очерк, репортаж, җыелышлардан отчет, әдәби әсәрләргә, театр спектакльләренә рецензиясе һәм шигыре басыла.

М. Җәлил комсомол, партия вакытлы матбугаты органнарында ун елга якын эшли. Ул Мәскәү университетында уку чорында да җәмәгать эшен иҗат эшчәнлеге белән оста үреп алып бара, матбугатка, әдәбиятка сәләтле эшче яшьләрне тарта, әдипләр, шагыйрьләр, журналистлар арасында тәрбия эшләрен нәтиҗәле итеп оештыра белә.

Җәлил — Мәскәү эшчеләре белән иң актив аралашкан әдип, журналист. Совет индустриясе, төзелеш геройлары, эшчеләр тормышы турында татар совет вакытлы матбугатының очерк жанрына нигез салучыларның берсе дә ул иде. Муса Җәлилнең журналистик хезмәте хәзерге буын иҗат яшьләренә, матбугат, әдәбият фронтында эшләүчеләргә сүнмәс маяк булып балкый.

# УПКЫННАР АША



Качкынны курку билəп алды. Соңгы көчен җыеп, тау башына, урманга таба үрмәләргә кереште. «Әсирлектән котылдың! Син иректә!..» дигән уй аңа әйтеп бетергесез шатлык, ләззәт бирде. Әмма шунда ук күңеленең икенче бер почмагыннан: «Әгәр тотсалар?..» дигән шомлы уй калкып, аны тетрәндереп җибәрде. Бу хыянәтчел уйны башыннан куарга теләп, әсир юеш агачка ныграк сыенә төште. Һәм шунда ук йокыга китте.

...Матур җәй ае. Фельдшерлык дипломы алып, ул үзенең туган — Әлки якларына кайтты. Салман участок больницасында озак эшләргә туры килмәде, фин сугышы башланды, аны армиягә алдылар. Фронтка кергәндә яшь, бик яшь иде әле ул. Беренче яралыларны күрү, чатнаган салкыннарда беренче медицина ярдәме күрсәтүләрне аның беркайчан да онытасы юк. Кырык грәдуслы салкыннар. Кулдан салып, сугышчыларның ярасын бәйләргә, аларны ут астыннан алып чыгарга кирәк. Бер көнне алгы сызыкка күп тапкырлар барырга туры килде. Каты сугыш булды. Шунда ул яраланды, битләрен өшетте. Госпитальдән чыккач күп тә үтмәде, тагын да дәһшәтлерәк, тагын да куркынычрак сугыш аны һәм башка күп миллионлаган кешеләрне үзенең утлы кочагына алды. Львов янында ул фашист илбасарларының атакаларын кире кагуда катнашты. Авыр көннәр, үзәк өзгеч чигенү айлары... Яралылар күп, дару, транспорт җитми. Фашист «карчыгалары» яралылар өстенә өзлексез бомбалар ташлый, пулеметлардан ата.

Аларның частена Львов белән Киев арасындагы Старый Константинополь авылы янында дошманны тоткарларга боерык бирелде. Авыр, канлы сугыш башланды. Ике көндә Нигъмәт санитар белән бергә йөзгә якын яралы сугышчыны кораллары белән бергә алгы сызыктан алып чыкты, аларга беренче ярдәм күрсәтте һәм тылга озатты. Батырлыгы өчен аңа беренче бүләк — Сугышчан Кызыл Байрак ордены бирелде.

Уң флангтагы пулемет кинәт тынып калды. Нигъмәт, санитарны үзе белән алып, шунда шуышты. Расчет канга батып ята. Аларны плащ-палаткага салып сөйрәгәндә, Нигъмәтнең уң кул бармагын һәм уң аяк үкчәсен нидер яндырып узды. Авыр яраланган пулеметчыларга беренче ярдәм күрсәткәч кенә, ул үзенең сынган бармагын һәм яралы аягын бәйләде һәм яңадан алгы сызыкка юнәлде... Шул чак аның каршында утлы яктылык кабынды.

...Аркасы белән агачка бәрелүдән ул йокысыннан уянды. Һәм, куркынып, күзен ачты. Агач ботаклары арасыннан йөзенә туп-туры язгы кояш нурлары төшкән иде...

Ул үзенең кайдалыгын һәм урманга ничек килеп эләгүен аңламыйча торды.

Тавыш-тын ишетелми. Аның өчен иң мөһиме, кеше күзенә күренмичә генә, урман эченәрәк үтү. Анда партизаннар булмый калмас... Һәр кыштырдауга колак салып, кичкә кадәр байтак юл узды. Тиздән урман уртасындагы аланлыкта ялгыз бер йортка килеп чыкты.

Озак күзәтте Маханов бу йортны. Урманчы өе икән. Хуҗа Николай исемле. Хатыны аңа: «Коля, ашарга кер» дип кычкырды. Нигъмәтнең күңеленә: «Бу кеше партизаннарны белми калмас!» дигән уй килде. Шулай да ул урманчының ишеген шакырга батырчылык итмәде. Тоткынлыкка кабат эләгү куркыта, сабыр итәргә, сак булырга куша. Зур гына агачка поскан килеш тагын бер төн уздырды. Таң беленү белән ишектә йорт хуҗасы күренде. Нигъмәт аягына басты. Ул туңган, бөтен тәне калтырый иде. Апрель төне суык, үлеп ашыйсы килә.

«Ни булса, шул булыр...» дип, кесәсенә тыккан ташны капшады да, яшеренгән урыныннан чыгып, урманчы каршына атлады.

— Исәнмесез, Коля абый! — дип, сәламләде ул аны. Урманчы кинәт килеп чыккан чит кешене башыннан аягына кадәр күзеннән уздырды.— Миңа партизаннарга эләгәсе иде.

— Партизаннарны мин каян белим?

— Партизаннарны тапмасам, бетәм. Каян икәнемне күреп торасыз...— Нигъмәт юан агач артына посты.

— Әй, кая киттең?..— дигән тавыш ишетеп, сак кына үрелеп, ишегалдына күз салды. Хуҗа сөтле кружка белән икмәк кисәге тоткан иде.

— Мә, аша,— диде хуҗа. Ул Нигъмәтнең икмәкне зур-зур кабып, ашыгуын күзәтеп торды.

— Ашыкма. Тартып алмыйлар! Чәйнәргә кирәк.

Нигъмәт бүрәнәгә утырды, башын әйләндергеч хуш ис аңкып торган йомшак икмәкне озаграк чәйнәргә тырышты.

— Бик зур рәхмәт, Коля абый,— диде ул кружканы сузып.

— Нишләтим инде мин сине? Хәзергә миндә торып тор,— диде ул.— Тамагыңны эшләп түйдырырсың.

— Риза.

Урманчыда ул бер ай яшәде. Хәл керде, ныгыды. Бер көнне кичкә таба утын ярып ятканда, урманчы:

— Утыр әле,— дип сүз башлады.

Нигъмәт утыргач:

— Сиңа эшкә урнашырга кирәк,— диде.

— Кая?

— Коваль станциясенә.

— Мин шундагы лагерьдан качтым.

— Лагерьга бармассың. РОА га...

— Власов армиясенәме?!.— Ул, урыныннан сикереп торып, балтасын күтәрде дә, яра алмый азапланган ботаклы бүкәнгә китереп сукты. Бүкән шартлап икегә ярылды. Шуннан соң балтасын читкә атып бәрде дә, нәфрәт белән,— Юк! — диде.

— Син коралсыз. Ә коралсыз кеше кемгә кирәк?!

Әйе, коралсыз солдат кемгә кирәк?! 1943 елның язы гына иде әле. Сугышның тагын күпмегә сузылачагын кем белә? Нигъмәт башын тотып, яңадан бүрәнәгә утырды.

— Баш ватуның кирәге юк,— дип, урманчы аның аркасына кулын салды. Аннан:— Коралсыз син кемгә кирәк? — дип кабатлады.— Сине Чашкин дигән бер капитан белән таныштырырмын. Фельдшер итеп эшкә урнаштырыр.

Шуның белән сөйләшү бетте. Нигъмәт йокысыз, бик газаплы төн уздырды. «Партизаннарны эзләп караргамы?.. Аларны эзләгәндә, фашистлар кулына барып капсаң?.. Ә власовчылар шайкасына керү аннан җиңелрәкме?!.»

РОА капитаны Чашкин Махановны фельдшер итеп эшкә кабул итте һәм санитар сумкасы биреп, Коваль белән Брест-Литовский арасындагы Вежба станциясенә җибәрде. Эш авыр түгел: тимер юлны партизаннардан саклаучы РОА солдатларына медицина хезмәте күрсәтү.

Бер көнне ул тамак ялгап алырга солдат ашханәсенә керде. Кеше юк иде. Аның янына яшь кенә, зур зәңгәр күзле официантка килде.

— Сез каян! — диде ул ягымлы бер тавыш белән.

— Вакытыгыз бармы? Булса, утырыгыз әле.

— Хәзер, сезгә ашарга алып килим...

Озак та үтмәде, шактый ук итле аш белән, ботка алып килде. Аларны өстәлгә куйганнан соң, Нигъмәт каршына утырып, иягенә таянды да:

— Мин сезне тыңлыйм,— диде. Үзе ап-ак түгәрәк йөзле, кабарып торган алсу иренле, бәдрә чәчле.

Официантка яңа танышның беренче булып сүз башларга уңайсызлануын күреп:

— Мин мондагыларның барысын да беләм. Ә сезне хәтерләмим. Сер булмаса, чыннан да, сез каян килдегез? — диде.

— Мин, үзебезнекеләрне эзлим... Монда безнекеләр бардыр. Шулаймы?

— Һай, белмим шул...— диде кыз. Аннан ул яңа танышның әле генә ачык, шат йөзенә борчу йөгерүен күреп, дәвам итте: — Шулай да мин аны белән сөйләшеп карармын. Ул урманда өш була. Гөмбә җыярга йөри ул.

Сөйләшә торгач, Маханов Катяның ата-анасы Вежба станциясе янындагы хуторда яшәвен, әтисенең итекче булып немецларда эшләвен белде.

...Вежба станциясендә ул Катяның ата-анасы торган йортны эзләп тапты. Әмма өйгә кермәде, буш вакыты булган саен читтән генә күзәтте. Ул инде Катяның атасын да, анасын да белә иде.

Бер көнне Нигъмәт санитар сумкасын асып, кич белән тимер юл буйлап кайтып килгәндә, шпаллар янында гына бер кешенең егылып ятуын күрде. Катяның атасы иде ул. Нигъмәт аңа басарга булышты. Итекченең авызыннан аракы исе аңкый иде. Көч-хәл белән басып тора. Хәзер Катяның өенә керергә, аның анасы белән сөйләшергә сәбәп бар. Исерекнең кулын җилкәсенә салып, аны өенә алып китте. Исерек таза, үзе кычкыра, җырлый... Аз гына бушатты исә — барып мәтәлә. Хуҗа хатын ботын чабып:

— Ай, дуңгыз!.. Тагын эчкән...— дип кычкырып җибәрде. Ул Нигъмәтне озата чыкты.

— Сез гафу итегез инде,— диде ул.— Кайчак ул шулай...

— Зарар юк. Андый хәл кемдә булмый...

Инде китәргә дип җыенган Нигъмәт кинәт туктап калды.

— Әллә берәр нәрсә булдымы?..

— Юк, юк! Тик менә...

Хатыны өйгә кергәч, итекче көлеп куйды.

— Кечкенә генә булса да, көчле икән, хәерсез. Провокатор булуы да бар...

Нигъмәт эшкә кереште. 11 нче казачий полкта фельдшер булып хезмәт иткән Петяны очратты. Ул аның белән бергә әсирлектә булган иде. Шунда Петя РОАга язылган.

— Бер киңәш бар иде.

— Нинди?

— Качарга уең юкмы?..

— Кая?

— Партизаннарга.

Петяның күзләре очкынланып китте.

— Кайчан? — Ул Махановның кулын каты итеп кысып алды.

— Әмма корал кирәк.

— Корал?! ...Анысы була! — диде Петя.— Артскладта минем дустым эшли. Попов. Складны фрицлар саклый. «Салырга» яраталар. Бер-ике литр аракы, я берәр литр спирт булса, алар салган арада, йөге белән алып чык, күрүче булмас.

— Синең ышанычлы кешеләрең юкмы?

— Ничәү кирәк?

— Ышанычлы булсыннар.

Нигъмәт Севастополь морягы Силкинны эзләп китте. Ул да, әсирлектән качкач, ниндидер юллар белән РОАга килеп урнашкан. Тәмугъ газапларын кичергән кешегә качу турында ничек әйтми калырга кирәк?!.

Нигъмәт сүз кузгату белән ул:

— Кайчан? — дип сорады.

— Бүген.

— Ә мин?..

— Теләсәң...

Маханов сүзен әйтеп бетерә алмады, Силкин аны кечкенә баладай җилтерәтеп баш очына күтәрде дә акрын гына җиргә төшерде.

— Гомердә онытмам!

Алар кичкә кадәр киңәштеләр. Билгеләнгән вакытта артскладка барганда лейтенант Попов немец сакчыларын инде сыйларга керешкән иде.

— Мәҗлесегез түгәрәк булсын! — дип, Маханов сумкасыннан тагын өч шешә аракы чыгарды.

— Гут, гут...— дип, сары тешләрен ыржайтты немец ефрейторы.— Әйдә! — Ул стаканга аракы салып, эчәргә ишарә итте.

Маханов бер-ике йотты да, буылып йөткерергә кереште.

— Менә болай кирәк,— дип, фашист ярты стакан аракыны авызына аударды. Маханов, исе киткән булып:

— Күрми дә калдым! — диде.

Әмма эш алар уйлаганча барып чыкмады. Складтан корал алып чыгып, биек койма аша сикергәндә, атыш тавышлары яңгырады. Немец сакчылары эчеп утырганда, кинәт кенә аларга алмаш килгән. Постларын калдырып, эчәргә киткән фашистлар урынына икенчеләре баскан.

Петя белән Силкин, өчәр автомат күтәреп, складтан чыгып киләләр иде. Петя шунда ук автоматларын җиргә ташлады да качып баручы төркем артыннан ташланды. Маханов та аңа ияргән иде, караңгырак урында моряк аны кулыннан тотып, җиргә сузып салды.

— Ят! Тыныңны чыгарма!..— дип боерды.

Фашистлар ата-ата качучыларны куа киттеләр. Шуны гына көткән Силкин, дустының кулыннан тотып:

— Киттек! — диде. Һәм, сикереп торып, капма-каршы якка сикерде. Маханов аңа ияртде. Коймага җитәрәк, моряк песи кебек җитез генә итеп бензин цистернасына үрмәләп менде дә, аның капкачын ачып, шырпы сызып ыргытты. Аннан икенчесе, өченчесе...

Шуннан соң булган вакыйгаларны ике мәртәбә Советлар Союзы Герое, СССР Верховный Советы депутаты, Украина Коммунистлар партиясенең Чернигов һәм Волынский обкомы секретаре, Чернигов-Волынский партизан отрядлары берләшмәсе командиры А. Федоровның «Последняя зима» дигән китабыннан алынган юллар белән дәвам итәбез.

«Көз көне Стоходтагы партизан заставасы безнең штабка немец формасындагы ике кешене тотып китерде. Киемнәрендә кем булулары турындагы билгеләре юк иде. Икесе дә русча сөйләшә. Заставада ук алар үзләренең РОАдан — хыянәтче Власов туплаган «рус азат итү армиясе»ннән качуларын әйттеләр.

Штабта сорау вакытында өлкән власовчы үзен Федор Прокофьевич Силкин дип атады, 34 яшьтә, Севастопольдә соңгы көнгә кадәр оборонада торган укчы дивизия капитаны. Силкинның күкрәге киң, ашыкмаучан, йөзе гадәти русларныкына охшаган. Икенче качак — тәз гәүдәле, нык мускуллы, кара чәчлесе — үзен татар, Негмеат (автор аны шулай атый) Хәбибуллович Маханов дип әйтте. 23 яшендә, лейтенант. Аңа:

— Сез качкан полк хәзер кайда тора? — дигән сорау бирдек.

— Брестта.

— Ә полктагы кешеләрнең настроениесе ничек?

— Барысының да Федор белән минеке кебек. Үз ирекләре белән түгел... Барысы да партизаннар ягына чыгарга шат булырлар иде!

Безнең якка чыгучыларның сүзләрен бик ныклап тикшерергә кирәк иде. Әмма без хәзергә бер нәрсәне — Силкин белән Махановның Севастополь оборонасында катнашуларының дәреслеген генә тикшерә ала идек.

Штабка Устин Дроздовны чакыртып алдык. Тәз буйлы, яшь кенә капитан килеп керде. Салам төсендәге, дулкынланып торган чәчләре пилоткасы астыннан чыккан. Бер ел буе Дроздов Севастопольне геройларча саклаучылар сафында булды.

Ул төгәл тикшерү сораулары яудыра башлагач, мөгаен Силкин белән Маханов бик нык гаҗәпләнгән булырлар.

— Инкермада кайсы дивизия оборона тотты? Диңгез пехотасының җиденче бригадасы Сапун-тауның кайсы ягында торды? Җиденче бригада белән кем командалык итте? Ә сигезенче белән кем? Козацкий бухтага соңгы тапкыр совет корабле кайчан керде? Ул ничек атала иде?..

Тиз һәм төгәл җаваплар бирелде.

— Севастопольчеләр! — дип, Дроздов ышанычлы рәвештә йомгак ясады».

Китап авторы А. Федоров Махановны севастопольче дип санап ялгыша. Сорау алганда җавапны Силкин бирә. Ә партизаннар исә аларның икесе дә бер частьта хезмәт иткән дип уйлый. Чынында исә Маханов Севастопольдә бөтенләй булмый. Киев янында барган авыр сугышлардан соң, ул хезмәт иткән дивизия Днепропетровскига чигенә. Днепр елгасына килеп җиткәндә, күпер шартлатыла. Бик күп яралылар белән бергә Маханов елганың аръягында кала. Ярдәм күрсәтеп, яралыларны елга аша алып чыгуны оештыра. Шуннан соң бу дивизия Сталинградка ялга җибәрелә. Шушында Маханов танк бригадасы составына кертелә һәм Харьков юнәлешендәге һөҗүмдә катнаша. Фашистларны алар байтак куалар. Әмма күп тә үтми бу бригада

чолганышта кала. Снаряд кыйпылчыгы тиеп, Нигъмәт яралана. Егерме ике көн кыр госпиталендә ятканнан соң, алар фашистлар әсирлегенә эләгәләр. Аннан мәсхәрәле тоткынлык юлы башлана... Белоцерковь, Днепропетровск, Владимироволынск, Кэвальдәге әсирлек лагерьлары... Ирекә омтылулар, качу, тотылу, кыйналу һәм карцерлар... Берсе дә калмый.

Боларны партизаннарга ул хәзер бер ничек итеп тә исбат итә алмый. Документлары юк. Ул Силкин сөйләгәннәргә кушылудан да уңай чара тапмый. Севастопольчедиләр икән, дисеннәр. Силкин аны белә һәм аңа ышана. Хәзер ул партизаннар ышанычын яуларга тиеш. Аның күңеле саф.

Партизан отрядлары берләшмәсе командиры Алексей Федорович Махановның кичерешләрен аңлады булса кирәк:

— «РОА солдатлары партизаннар ягына чыгарга шат булырлар иде» дип, үзегез әйттегез бит. Шулай булгач, аларның бу уйларын тормышка ашырырга булышу — безнең бурычыбыз!

Икенче көнне таң беленү белән капитан Дроздов җитәкчелегендәге отряд шушы ниятне үтәргә дип юлга кузгала.

Төн уртасында уникe разведчик хутордан өч километр арада туктыйлар. Дроздов планшетыннан сургычланган конверт чыгарды.

Чернигов-Волынский партизан отрядлары берләшмәсе командиры Алексей Федорович Федоровны Брестта торучы полкның барлык власовчылары да партизаннар ягына чыгарга теләүләре турындагы хәбәр бик нык кызыксындыра. Бу полк белән полковник Черкасский командалык итә. Аның нинди кеше икәнен Маханов та, Силкин да әйтә алмый. Шулай да Федоров аны коюны булдырмый калу һәм ялгыш юлга баскан сугышчыларга Ватан каршындагы гаепләрен йолу мөмкинлеге ачу максаты белән Черкасскийга хат җибәрергә булды. Ул үзенә бирелгән хокуклар нигезендә совет ягына чыгучыларның барысына да, шул җөмләдән полк командирына да амнистия вәгъдә итте. Сөйләшүләр алып бару өчен үзенең вәкиле итеп Дроздовны билгеләде. Менә шул хат Нигъмәт кулында. Ул, кеше күзенә күренүдән шикләнеп, хуторга җиткәч, урамга кермичә, бакча артыннан китте. Ниһаять, киртә аша үтеп, Катяның ата-анасы торган йортка якынлашты, тәрәзә чиертте.

— Кем бар анда?..

— Мин, Нигъмәт...

Маханов, песидәй тавыш-тынсыз атлап, өйгә керде.

— Нигъмәт!.. Ни булды?..— дип пышылдады Катяның әнисе калтыранган тавыш белән.

— Сезгә бик зур үтенеч бар! Шушы хатны Катяга илтеп бирергә кирәк иде.— Маханов эчке кесәсеннән сургычланган конверт чыгарды.— Ә Катя аны полк командиры Черкасскийга бирергә һәм аннан җавап алып кайтырга тиеш.

Кешеләр торып, урамда хәрәкәт башлангач, Катяның әнисе юлга кузгалды. һәм караңгы төшкәндә генә арып-талып кайтып керде. Өйалдындагы чиләктән чүмеч белән салкын су алып эчте дә:

— Катя хатны бирә алмады,— диде.— Полковник тирәсендә кеше күп, ничек бирәсең? Катя «Җае белән үзем бирермен», диде. Сиңа күп итеп сәлам әйтте.

Бер көн узды, ике, өченче көн дә үтеп бара. Ә Катядан бернинди хәбәр-хәтер юк. «Хатка җавап алмыйча, отрядка кире әйләнеп кайтыргамы әллә?» дигән уй сагать саен кочәя барды. Әмма моңа: «Максат — җавап алу! Бу бит йөзләгән, меңләгән кеше тормышына бәйле!» дигән фикер каршы төште. «Бу хәлдән ничек итеп чыгарга?.. Беренче сугышчан бурычны җиренә җиткереп ничек үтәргә?» дип караңгы чормада баш ватып ятканда, акрын гына ишек кактылар...

Бу — Катя иде.

Чормадан сикереп төшүен Нигъмәт сизми дә калды. Ул кызны әләктереп, өйгә алып керде.

— Җавап булдымы?..

— Юк.

Бераз тынычлангач, ул сөйләп бирде: полковник Черкасскийны ул бары тик бүген көндезге аш вакытында гына очраткан. Ашап бетергәннән соң, табак-савыт җый-

гандә, өстәлгә конвертны салган. Полк командиры гаҗәпләнеп официанткага карап ала да, конвертны ачып, хатны укый.

— Җавапны кичке аш вакытында бирерсез,— дип пышылдый аңа кыз һәм бүлмәдән чыгып китә.

Кичкә кадәр кыз «менә-менә кулга алырлар!» дип, кая басканын белми ут йотып йөри. Кичке аш вакыты җитә. Әмма ул-бу сизелми. Черкасский кичке ашка килгәч, Катяга:

— Хәзер үк күз алдымнан ычкын! Эзең булмасын! Юкса...— дип бармак яный.

Кыз ашханәдән чыга да алдын-артын карамыйча өенә йөгерә.

— Аларның килеп чыгулары бар! — дип йомгак ясады кыз.

— Син, кызым, бар. Сиңа калырга һич тә ярамый,— диде ана уйчан гына.— Мин бара алмыйм. Әтиең дә больницада ята. Аны ничек калдырып китәсең?..

— Әни!— дип, кыз анасының муенына сарылды.

— Юк, кызым! Үгетләмә!

— Кулга алсалар?..

— Минем гаебем юк. Хат турында мин берни белмим.

Кыз белән егет бусагага җиткәч, ана Махановның кулын кысып тотты.

— Зинһар, Нигъмәт, Катяга күз-колак була күр! — диде ул ялварулы тавыш белән.

— Борчылмагыз, Марина түти! Борчылмагыз! — диде егет.

Дроздов Нигъмәтне озак еллар күрешми торган үзенең иң якын туганын очраткандай кочагына алды.

— Я, ничек?..— диде ул, Махановны күкрәгенә кыскан килеш.

— Черкасскийга ышаныч юк. Ул хайван.

— Нәрсә, риза булмадымы?..

— Юк. Тулырак итеп, әнә, Катя сөйләр,— диде Нигъмәт читтәрәк басып торган кызны күрсәтеп.

Базага кайткач, Дроздов берләшмә командиры генерал Федоровтан Маханов белән Силкинны үзенең отрядында калдыруын үтенде. Шулай итеп, Нигъмәт разведчик булып китте. Бер үк вакытта фельдшерлык вазифасын да үтәде. Аңа бик күп куркыныч заданиеларны үтәүдә катнашырга туры килде. Кулыннан бер генә көнгә дә коралын төшермәде. Ярты елдан регуляр Совет Армиясенә кушылдылар. Дошманны куа-куа Нигъмәт Кенигсбергка кадәр барып җитте, аны алуда катнашты. Ә аннан Ерак Көнчыгыш... Япон самурайларын җиңүдә күрсәткән батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнде.

Язмыш упкыннары аша үтеп, ул, ниһаять, үзенең туган якларына кайту бәхетенә ирешә. Җиң сызганып халыкның сәламәтлеген саклау эшенә басты. Монда да ул үзенең көчен, энергиясен бирде. Еллар бер-бер артлы уза тора. Хезмәтләре өчен Нигъмәт «Сәламәтлек саклау отличнигы» дигән исемгә лаек булды.

Көннәрнең берсендә Маханов «Советская Татария» газетасының 1963 елның 3 нче ноябрь санында Алексей Федоровның «Последняя зима» дигән китабыннан үзе турында, «Севастопольчеләр» дигән өзек укып, чиксез дулкынланды. Һәм элекке командирына шунда ук хат язып салды.

«Кадерле Алексей Федорович! Егерме ел аерылып торганнан соң сезне сәламләргә мин бик шатмын. Минем иптәшләрем Силкин һәм Катяның язмышы турында сез нәрсә дә булса белмисезме?

Мин Татарстанның Яңа Салман авылында яшим һәм сугышка кадәр эшләгән участок больницасында фельдшер булып эшлим. Кулыгызны нык кысып, Нигъмәт Маханов».

Озак та үтмәде, Нигъмәт җавап телеграммасы алды.

«Кадерле Нигъмәт Маханов!

Немец-фашист илбасарларына каршы көрәштә коралдаш иптәшем буларак, минем Яңа ел алды тәбрикләвемне кабул ит!

Нык сәламәтлек һәм медицина эшчәнлегендә уңышлар телим. Совет кешеләре өчен партизаннар бик күп нәрсә эшләделәр. Шундый ук партизан ялкынын һәм совет кешесенә карата мәхәббәтне авыл хуҗалыгы эшчәннәрен, бөек халкыбызның улларын һәм кызларын дәвалауда куллан.

Генерал-майор Алексей Федорович Федоров. Ике мәртәбә Советлар Союзы Герое, партизан отрядлары берләшмәсенең элекке командиры».

**ФӘЛӘХ НАСЫЙРОВ.**

Фәрваз Миңнуллин

# ЗАМАН ҺӘМ ПОВЕСТЬ

Соңгы елларда илебез тормышында булып узган үзгәрешләр һәм яңарышлар язучыларга бай материал бирде. Яңа проблемалар һәм темалар, өр-яңа мәсьәләләр күбәйде. Күп булулары өстенә, аларның байтагына кичекмәстән җавап та бирергә кирәк иде. Шулай итеп, тормышның ашыгыч һәм актуаль мәсьәләләрен хәл итәргә кулай жанрларның берсе — повесть бермә-бер активлашты.

1980 елда дөнья күргән ундүрт повестька нигезләнеп прозабызның бүгенге хәле хакында нинди фикер әйтергә, нинди нәтиҗә ясарга мөмкин? Иң элек, прозабыз таза, нык җирлектә, дөрес юнәлештә үсә, дип әйтә алабыз. Аннары, әдәбиятның тематик колачы киңәя, идея һәм сәнгатьчә камиллеге үсә бара, аның бүгенге чынбарлык, халыкның бүгенге тормышы белән бәйләнеше тирәнәйде, дияргә була. Бер ел эчендә дөнья күргән повестьларны игътибар белән күздән кичерсәк, алар арасында без производство һәм авыл хуҗалыгы мәсьәләләренә багышланганнарын, хәрби-патриотик һәм тарихи-революцион жанрга караганнарын, археологлар һәм милиция хезмәткәрләре хакындагыларын, Ватан сугышы турындагыларын да очратырбыз. Шулай да бүгенге повестьларның зур күпчелеген КПСС Үзәк Комитетының «Идеология, политик-тәрбия эшен тагын да яхшырту турында»гы мәгълүм карары белән аваздаш әсәрләр, башкача әйткәндә, әхлак мәсьәләләренә багышланган әсәрләр тәшкил итә. Хәер, бу узган ел гына башланган нәрсә түгел икән. Әлеге карар белән ныклап танышкач, мин бер нәрсәгә сөенеп һәм гаҗәпләнеп калдым! Баксаң, соңгы еллар татар прозасының иң матур үрнәкләре нәкъ менә әхлак мәсьәләләренә багышланганнар, нәкъ менә партия карары белән аваздаш икәннәр бит: Ә. Еникинең «Тынычлану» хикәясен, А. Гыйләҗев, Ә. Баянов, М. Юныс, Х. Сарьян, Г. Рәхим повестьларын, я булмаса Г. Бәшировның «Җидегән чишмә» һәм А. Расихның «Сынау» романнарын алып карагыз. Һәммәсе әхлак мәсьәләләренә багышланган әсәрләр. Әйтерсең, безнең прозаиклар шундый карар чыгасын алдан белеп, көтеп торганнар. Бик күңелле хәл бу! Язучыларыбызның ил, халык мәнфәгатьләрен кайгыртып яшәүләре, партия, халык белән бергә яшәүләре хакында сөйли торган факт бу!

Ләкин икенче бер нәрсә борчый: без әдәбиятта эшче темасы көчәеп килә дип мактанып йөри идек — узган ел эшче темасына, производство мәсьәләләренә багышланган повестьлар аз язылган. Кулга тотарлык бердәнбер әсәр — Фәрит Гыйльметдиновның «Елганың борылган төшендә» исемле повесте («Казан утлары», 9 сан).

Яңа гына техникум бетергән Фәнис исемле бер егетне нефть скважиналарына капиталь ремонт ясау белән шөгыльләнә торган бригадага эшкә җибәрәләр. Төрле холыклы, төрле язмышлы кешеләр, сәер һәм төксе табигатьле, авыр холыклы бригадир... Яшь егет беренче тапкыр кырыс чынбарлык, реаль тормыш белән очраша... Әмма җебеп һәм югалып калмый. Тормышның беренче сынауларын уңышлы үтә, беренче адымнарын дөрес атлый. Әсәр әнә шул егет турында, аның характеры формалашуы, ир-егет һәм чын нефтьче булып өлгерә баруы турында. Автор яза торган материалын белә, кешеләрне белә, Фәниснең тормыштагы беренче мөстәкыйль адым-

нарын ышандырырлык итеп бирә алган. Заманча язылган кыска һәм җыйнак повесть, җылы юмор белән сугарылган әйбәт повесть.

«Җәза» повесте («Казан утлары», 3 сан), «Бер ананың биш улы» кебек үк, Хәсән Сарьянның җитди әсәре. Мәзин малае Нуриман герман сугышыннан алдынгы карашлы большевик, чын көрәшче булып кайта. Әтисенең кеше талап җыйган малын ярлыларга өләшә, эшче-крестьян властена бирә. Шул рәвешчә, ата белән ул сыйнфый көрәшнең ике ягына басалар, килешмәс дошманга әйләнәләр. Авылның иң ярлы катлавыннан чыккан, гомер буе кеше малына кызыгып яшәгән Баһау исә, байларга, кулакларга сатылып, кеше үтерүчегә әйләнә... Повестьның үзәген Нуриман белән Баһау арасындагы конфликт билгели, әсәр баштан ахырга кадәр сыйнфый көрәш вакыйгаларына багышланган.

Чыннан да, бер уйласаң кызык бит: бай малае кызыллар ягында, хәерче Баһау байларны яклый, байларга хезмәт итә. Әдипләр тарафыннан тормышны әтрафлы һәм эзлекле төстә үзләштерүнең бер үзенчәлеге бу. Ул шуннан гыйбарәт: әдәбият һәр теманы акрынлап үзләштерә, башта акны ак, караны кара дип яза. Эшче — революция ягында, капиталист — контрреволюция ягында. Иң дөресе шулай, иң типигы шулай, шулай булырга тиеш! Күп сурәтли, күп өйрәнә торгач, бер заман язучылар дөньяның шактый катлаулы булуын, аның ак белән кара төсләрдән генә тормаганын аңлый башлыйлар, ярым тоннарны эзләргә тотыналар. Шулай большевикка гашыйк мулла кызлары, байлар кубызына биюче ярлылар, ярлы халыкка теләктәшлек итүче муллалар, большевикларга кушылган мәзин малайлары пәйда була. Х. Сарьян повестендагы Нуриман белән Баһау образларына мин әнә шул яктан килеп карыйм. Тик бу мәсьәләдә чик-чама, сыйнфый акыл, аек караш булырга тиеш. Юкса, бөтенләй буталып бетәргә мөмкин...

Тәнкыйтьче Ф. Галимуллин «Җәза»ны бөтен җире килгән, һәр яктан камил әсәр дип бәяләү ягында. Дөрес, повестьның баштагы өлешләре бик әйбәт тәэсир калдыра. Ахырга таба исә аның «мамыгы», «йоны» кими башлый, ул ит кунмаган ябык малны, бетоны салынмаган арматураны хәтерләтә башлый. Әмма монда авторның гаебе юк. Гаепче — үлем. «Җәза»— Х. Сарьянның пөхтәләп эшләп бетерергә өлгерә алмый калган әсәре.

Б. Камаловның «Актуган Гапсаттары» дигән повестена кагылып, тәнкыйтьче Ф. Галимуллин мондый фикер белдергән иде. «Б. Камаловның «Актуган Гапсаттары» исемле повестен укыгач, күз алдына кызыклы гына образ килеп баса. Сиксән яшькә җиткән Гапсаттар гомерен мәгънәле итеп уздыра, ил гаме белән яши... Менә ул колхозның беренче тимерчесе, яңа тормыш төзүдә актив катнашканы өчен, кулак ярчекнәре тарафыннан һөҗүмгә дучар була. Бөек Ватан сугышы елларында көнне төнгә ялгап фронт өчен эшли, улы һәлак булгач, кулына корал тотып, ут эченә китә. Әле һаман да актив иҗтимагый эшчәнлек белән яши...»

Мин тәнкыйтьче белән бу мәсьәләдә килешәм. Гапсаттар карт миңа да ошады. Чыннан да, тормышның ачысын-төчесен күп күргән, нык үзәкле карт, хәтердә кала торган образ. Дөрес, бер дә кабатланмаган, әр-яңа образ түгел, безнең әдәбиятта мондый картлар булгалады... Аннары повестьның сюжет-композициясе шактый таркау, буталып-чорналып беткән. Ныклап торып уйлап, югары таләпләр ноктасыннан чыгып якын килсәң, ул — повесть та түгел әле, ә бәлки ике табаклы гап-гади озын бер хикәя.

Үзара сөйләшкәндә, Адлер Тимергалинны без яратып татарның бердәнбер фантасты дип йөртәбез. Беркадәр үзгәрткәч, бу сүзләрне Мөгъсүм Насыйбуллинга карата да кулланып була. Иҗат юлын суд һәм тикшерү органнарында эшләүче кешеләр турында очерклардан башлап, ул тора-бара детектив һәм документаль повестьлар язуга күчте. Бүгенгесе көндә шушы өлкәдә иң күп һәм нәтиҗәле эшләүче язучыларыбызның берсе М. Насыйбуллин тырышлык һәм үҗәтлек белән әдәби осталык серләрен өйрәнеп килә. Елдан-ел аның каләме чарлана, иҗади колачы киңәя бара. Авторның «Ярканат» исемле яңа повесте да шул хакта сөйли.

Бер сәүдә конторасының кассасын басып, илле мең сумга якын акча урлыйлар. Сирәк була торган, гадәттән тыш шушы вакыйгага ике шәһәрнең милиция һәм прокуратура хезмәткәрләрен аякка бастыра... Әсәрдә сүз әнә шул хакта — югалган акчаны эзләү һәм табу турында бара. Повестьны уку дәвамында без милиция хезмәткәрлә-

ренең, суд һәм тикшеру органнарында эшләүче кешеләрнең авыр һәм тынгысыз хезмәте белән танышабыз, җинаятьчеләр даирәсе, тегеге яки бу рәвешле җинаятькә катнашкан кешеләр белән очрашабыз. Билгеле, караклар тотыла... Авторның төп игътибары милиция һәм прокуратура кешеләренең осталыгын күрсәтүгә — аларның ничек итеп каракларның эзенә төшүләрен, ничек итеп аларны фаш итүләрен тасвирлауга бирелгән. Бу хакта ул белеп, җентекләп һәм тәфсилләп яза. «Ярканат» повестен укыган һәр кеше: «Безнең җәмгыятьтә ачылмый торган җинаятьләр, тотылмый торган караклар юк икән», дигән нәтиҗәгә киләчәк. Әсәрнең төп кыйммәте шунда дип уйлыйм. Аннары, закон сагында торучылар кырыс, гадел хөкемдар булып кына түгел, тәрбиячеләр буларак та ачылалар.

М. Насыйбуллин тормышта очраган җинаять күренешләренең сәбәпләре һәм социаль тамырлары турында уйлана. Бу кадәресе — күркәм сыйфат. Бу кадәресе — аның гади детектив жанрдан психологик прозага күчәргә омтылуы турында сөйли торган факт. Әмма җинаятьчелекнең социаль тамырларын ачыклау мәсьәләсендә кайчак ашыга төшә кебек. Әйтик, укучы төп җинаятьчеләрне һәм каракларны — кияүгә чыга алмаган карт кыз Нина Игнатюк белән еллар буе фатирсыз тилмергән Зайцевны вакыт-вакыт кызганып куя икән, бу — авторның ашыга төшүе, акцентлар хакында тиешенчә уйлап бетермәве хакында сөйли.

Узган ел Кояш Тимбикова безне «Таңкәле тау» исемле яңа повесте белән шатландырды. Шатландырды дим, чөнки ул — авторның моңарчы язган әсәрләре арасында иң уңышлысы. Аннары, «Таңкәле тау»— безнең әдәбиятның тематик чикләрен киңәйтә торган әсәр, хәтерем ялгышмаса, археологлар хакында язылган төүге әсәрләрнең берсе.

Атаклы профессор Хәй Фәләхи яшь археолог Харрас җитәкләгән экспедициянең эшен перспективасыз дип таба, казыну-эзләнү эшләрен туктатырга куша. Харрас бик яхшы аңлый: хикмәт перспектива булмауда түгел. Ул тапкан, ул туплаган археологик материаллар Идел буе болгарлары белән Азов буе болгарлары арасында бәйләнеш булуын раслый. Бу исә — профессор Хәй Фәләхинең еллар буе алга сөреп килгән тезисларын юкка чыгару дигән сүз. Хикмәт әнә шунда. Профессор шуннан курка... Яшь археолог Харрас та бирешергә теләми. Шулай шәкерт белән остаз арасында конфликт башлана. Повестьның үзегендә шул конфликт ята. Ул конфликтка берәзлексез яңа кешеләр килеп кушыла тора. Повесть кызыклы һәм үзенчәлекле кешеләре, гыйбрәтле һәм мавыктыргыч эпизодлары белән истә кала.

Археологлар турында әсәр язу өчен автор күп материал туплаган. Ләкин шул материалны ныклап кулга ала, эзлекле тәртипкә сала алмаган. Сөгъдия карчык һәм журналист Карачурина язмышы, Акъяр шәһәре һәм Таңкәле тау хакындагы легендаривалтьләрне алыгыз... Ахыр чиктә боларның һәркайсы аерым-аерым повесть була алыр иде.

Мәхәббәт темасына караган әсәрләрне Ибраһим Салаховның «Мәхәббәт картаямы?» исемле повестеннан башлау җайлырак булыр төсле. Ярым истәлек характериндагы, шактый сентименталь һәм традицион стильдәге бер повесть бу. Кырыс тормыш бер-берләрен үлеп яраткан ике яшь йөрәкне аера: Ильясны көтмәгәндә армияга эшкә җибәрәләр, Газизә Казанда кала. Күпме генә эзләсәләр дә, соңыннан бер-берләрен очрата алмыйлар. Арага сугыш килеп керә, тормышның башка катлаулы хәлләре комачаулый. Шулай гомер уза. Газизә иргә чыга, Ильяс өйләнә... һәм картаеп, олыгаеп беткәч, кабат очрашалар. Баксаң, әле һаман бер-берләрен яратышалар икән, хисләр сүрелмәгән, мәхәббәт картаймаган икән... Повестьта сүз әнә шул хакта бара. «Мәхәббәт картаямы?»— соңарып килә торган, беркайчан да сүнми-сүрелми торган мәхәббәт турындагы повесть. И. Салахов тагын бер кат мәхәббәт хисенең мәңгелек булуын раслый.

Мәдинә Маликованың «Кояш күпере» исемле повесте да мәхәббәт турында. Әсәр композицион тезеклеге, әдәби бөтенлеге белән аерылып тора. Әсәр беренче җөмләләре белән үк геройлар язмышына тирән кызыксыну уята. Кем ул Тәбрия? Аның үлеме райбашкарма председателен нигә шундый кара кайгыга сала?.. Әсәр геройлары безнең игътибарны биләп ала, без аларның кем булуларын, тормышларын, язмышларын белергә ашыгабыз. Әнә шундый кызыксыну уятканнан соң гына автор серле йомгакны акрынлап сүтәргә керешә. Күз алдына Тәбрия һәм Гадил, аларның

тормышы, аяныч мәхәббәтләре, повестьтагы башка геройларның тормышлары ачыла бара. Әйткәнемчә, әсәр зур кызыксыну белән укыла. Вакыйгалар сөйләнеп беткәндә, образлар нигездә ачыла, мәсьәләләр чишелеп бетә дияргә була.

Шул ук вакытта, мавыктыргыч вакыйга артыннан куып, автор геройларның эш-хәрәкәтләрен дәлилләүгә тиешле игътибар биреп җиткерми. Әсәрнең материалы авторга тормыш, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр, мәхәббәт хисенең көче турында зуррак, киңрәк гомумиләштерүләр ясарга да мөмкинлек бирә. Миңа калса, М. Маликова ул мөмкинлекләрдән тиешенчә файдаланмаган...

Узган ел дөнья күргән янә бер мәхәббәт повесте — Әхсән Баяновның «Аргы яр» исемле әсәре. Кызыклы һәм үзенчәлекле әсәр, алда телгә алган ике повестьның берсенә дә охшамаган әсәр...

Билгеле булганча, Ә. Баянов прозага шигырьдән килде. Шуңа күрә аның роман-повестьларында шигърият белән проза, прозаның кырыс реализмы белән поэзиянең шартлы алымнары чиратлашып килә. Ә. Баянов прозасы фикергә, фәлсәфи уйлануларга бай. Шуның өстенә ул — эзләнүчән һәм тынгысыз прозаик. Ул яңа темалар һәм яңа проблемалар эзли, яңа формалар һәм яңа алымнар эзли. Ул ихлас тон белән «пикантный» хәлләр турында сөйләргә ярата, еш кына четрекле мәсьәләләр күтәрә. Шуларның һәммәсе өстенә, геройларның прототиплары тиз танырлык була. Ә. Баянов — күпертергә һәм арттырырга маһир кеше. Ул урталыкны яратмый. Аның геройлары кырт икегә бүленгән булыр. Начарлары — беткәнче начар, уңае — һәммә кешедән югары, өстен булыр. Реаль тормышта андый геройларны очратуы кыен. Аның каравы, тормышта сирәк очрый торган шундый геройлар ярдәмендә язучы реаль мәсьәләләр күтәрә. Аны даими төстә дөньяның һәм җирнең иминлеге борчый, ул кеше һәм табигать, аларның мөнәсәбәте турында уйлана. Ә. Баянов үз әсәрләре өчен отышлы ситуацияләр таба, роман-повестьларының сюжет-композициясен оста итеп кора белә. Аның проза әсәрләре тиз агучан, киеренке вакыйгаларга корылган була. Шуларның һәммәсе күпмедер дәрәҗәдә авторның «Аргы яр» исемле повестенда да сизелә.

«Аргы яр» — мәхәббәтнең үзеннән дә бигрәк, аның фәлсәфәсе турындагы повесть. Ул ике геройның — Нажар белән Гөлчәчәкнең — күңел дуэтлары формасында язылган. Әсәрне укыганда, без аларның үзләре һәм дуслары белән, алар арасындагы интим мөнәсәбәтләр, аларның уй-фикерләре, дөньяга карашлары белән танышабыз.

Нажар — шактый тәкәббер һәм һавалы кеше. Дөнья мине эштә, хыялда һәм мәхәббәттә алдады дип, каш-күз җимереп, йодрык төйнәп йөри торган кеше. Хөр һәм ирекле булырга, җаны ни тели шуны эшләргә ярата торган кеше. Нажар тормышяшәеш, сөю-сөюшү турында фәлсәфә сатарга ярата. Арада мондые да бар: «Рөхсәт ителгәннең аръягында, тыелган белән ике арада иң ләззәтле сөенечләр җанны иркәли ул». Мин философ түгел. Бу мәсьәләдә автор белән дә, герой белән дә аяк терәп бәхәсләшүе кыен. Шулай да фикеремне белдереп үтми уза алмыйм: сәеррәк фәлсәфә...

Әсәрдә Гөлчәчәк тормышы аеруча тулы һәм эзлекле сурәтләнгән. Катлаулы язмышлы, аяныч язмышлы кыз. Күбәләк кебек чәчәктән-чәчәккә кунып йөри торгач, тәмам саташып һәм буталып беткән кыз бала. Үзе Нажарны ярата, ди. Шул ук вакытта Шамилне дә оныта алмый, Радик һәм Ришат белән дә араны өзми. Аяныч язмышлы кыз.

Гөлчәчәк белән Нажар ике сөер кеше — очрашалар, күңел ачалар, сөешәләр, каргашалар, гаепләшәләр һәм... аерылышалар. Нәкъ халык җырындагыча: «Бер болганмый су да тонмый, болганмый булмый әле...»

Су бер тонар, ә күңел нишләр?!. Ә. Баянов мавыгып укыла торган әсәр язган. Үзенчәлекле һәм кызыклы образлар иҗат иткән. Шулай да мәхәббәт кебек мәңгелек теманың социаль аспектын, иҗтимагый ягын күләгәдәрәк калдырган шикелле. Бүген, интим хисләр җитди һәм актуаль бер мәсьәләгә әйләнеп барганда, язучының бу мәсьәләләргә карашы төплерәк, тирәнрәк булганы яхшы.

Укучылар арасында «Без — 41 нче ел балалары», «Фронтовиклар», «Кеше китә — җыры кала» кебек роман-повестьлары белән танылган язучы М. Мәһдиев иҗатында «Ут чәчәге» үзенчәлекле урын алып тора. Үзенең һәр әсәрендә диярлек ул сугыш

алып килгән авырлыклар һәм корбаннар турында сөйли, халыкның психикасында һәм рухи дөньясында сугыш тудырган үзгәрешләр турында уйлана. Язучының күпчелек әсәрләрендә колхоз һәм хәрби тема, фронт һәм тыл тормышы үзара керешеп һәм бәйләнеп баралар, чиратлашып киләләр. Бу — аның әсәрләренең бер үзенчәлеге. Ләкин өстә яткан, һәркемгә күренеп торган үзенчәлеге. Ул сугышка хәтле һәм сугыш елларындагы авыл, сугыштан соңгы авыл турында яза. Игътибар иткәнегез бармы икән, сугышка хәтле авыл белән сугыштан соңгы авыл арасында җир белән күк аермасы. Сугыш авылны гүя ике чорга, ике дәвергә бүлеп куя. Сугыш авыл кешеләренең самимилеген һәм ихласлыгын, авылның авыллыгын киметә төсле. М. Мәһдиев әсәрләрен укыганда, еш кына авылның элеккесен, сугышка хәтлесен ныграк сагынасың. Ул әдәбиятка татар авылының кабатланмас үзенчәлеген һәм гореф-гадәтләрен алып килде. М. Мәһдиев сугышка хәтле һәм сугыш чорындагы авыл турында, сугышның авылга булган йогынтысы турында кабатланмаган яңа сүз, үз сүзен әйтә алды. Күпмедер дәрәҗәдә бу нәрсә «Ут чәчәге» повестена да хас...

«Ут чәчәге»— төбендә сугыш темасына багышланган, хәрби кешеләр турындагы повесть. Башка әсәрләреннән аермалы буларак, «Ут чәчәге»— бер герой, баштан ахырга кадәр үзәк герой тормышын сурәтләүгә багышланган әсәр. Бу яктан ул авторның барлык әсәрләреннән нык аерылып тора. Әмма ни генә булмасын, «Ут чәчәге» барыбер Мөхәммәт Мәһдиев әсәре. Бу — һәр адымда сизелә, барыннан да бигрәк әсәрнең темасында, материалында, авторның үзе сайлаган материалга булган мөнәсәбәтендә сизелә.

Фронтовик, солдат — аның өчен кадерле, хөрмәтле кеше. Кешенең бәясен ул аның фронтта, хәрби хезмәттә булу-булмавыннан чыгып билгели. Аның әсәрләрендәге фронтовиклар — ифрат гадел һәм принципиаль кешеләр, халык, ил мәнфәгатьләрен кайгыртып яшәүче олы җанлы кешеләр. «Фронтовиклар» романындагы Гата һәм Рушадлар, «Кеше китә — җыры кала» повестендагы Тимерханнар, без сүз алып бара торган «Ут чәчәге» әсәрендәге Асаф Рәимов — әнә шундыйлар.

Асафның яшьлеге зур вакыйгалар барган чорга туры килә. Ул башыннан ахырына кадәр Бөек Ватан сугышында катнаша, фронтның алгы сызыгында йөреп һәм гомерен куркыныч астына куеп, күп батырлыклар күрсәтә, кешелек җәмгыятен фашизм афәтеннән саклап калырга булыша. Бүлектән бүлеккә образ үсә, эреләнә — монументальләшә бара.

Сугыштан соңгы авыр елларда без аның белән өйрәнү отрядларында, хәрби училище һәм хәрби академияләрдә очрашабыз. Ул бик тырышып белемен күтәрә, вакытын һәм көчен кызганмыйча, яшь буынга хәрби-патриотик тәрбия бирә. Олыгаеп, отставкага чыккач та шул эшенә турылыклы булып кала.

Дөрес, повестьта Асаф Рәимовтан тыш та байтак образлар бар. Язучы аларның да үз йөзен, үзләренә генә хас сыйфатларын таба алган. Сылу белән Гаделия, Габделнур белән Гафур һәм Минҗан карт образлары — әнә шундыйлар. Аннан соң, әсәрдә гаҗәеп матур итеп сурәтләнгән табигать күренешләре күп, сугышка хәтле булган тыныч һәм имин заманнар, сугыш чоры авылының кырыс күренешләре оста итеп бирелгән.

Шулай да әсәрнең барлык бүлекләре дә бер югарылыкта язылган дип булмый. Минем үземә аның беренче өлеше, Сылулар, Габделнурлар катнашкан өлеше ныграк ошады. Ахырга таба повесть сүлпәнәя һәм сүрелә төшә. Ничектер сузыла, ялкыта башлый. Асафның өйрәнү отрядларындагы тормышы, военкоматтагы эшчәнлеге игътибарны әллә ни җәлеп итми. Баштагы җылылык, романтика кими. Гафур белән бәйле маҗаралар, хәтта күп санлы үлем-китемнәр дә әсәрдәге киеренкелекне кире кайтара алмый. Шуңа да карамастан, повесть укучылар тарафыннан да, тәнкыйть тарафыннан да югары бәя алды. Сәбәбен сорарсыз. Сәбәбе — әсәрнең беркайчан да онытылмый торган кызыклы һәм көлкеле эпизодларга, матур күренешләргә, истә кала торган, үзенчәлекле һәм колоритлы образларга бай булуында. Аннары, баштан ахырга кадәр үзәк герой тормышын сурәтләгән, традицион стильдә язылган повесть булуында. Мондый характердагы әсәрне М. Мәһдиевнең беренче тапкыр язуы.

Разил Вәлиевнең «Яшисе килә!» исемле повесте реаль кеше турындагы документаль әсәр. Ул хәрби хезмәт вазифаларын башкарганда батырлык күрсәткәне өчен үлгәннән соң медаль белән бүләкләнгән якташыбыз Рәфкать Миргазизов турында.

Мондый әсәр язуның үз кыенлыклары бар. Герой тормышына караган фактларны әллә ни үзгәртеп булмый, хыялга һәм фантазиягә җирлек тарая. Шуңа да карамастан, Р. Вәлиев үз өстенә алган кыен эшне, нигездә, уңышлы башкарып чыккан, якты дөньяда нибары унтугыз ел яшәп гомерен мәңгеләштереп калдырган замандашыбызның күркәм образын тудыра алган. Тагын да ачыклабрак әйткәндә, тәрбияви һәм эмоциональ яктан зур тәэсир көченә ия булган файдалы әсәр язган.

Безнең язучылар күбрәк үзләре күргәнне язарга яраталар. Бу табигый хәл. Күргәнне-белгәнне, кичергәнне язу җиңелрәк. Ләкин һәммәбез дә күргәнне-кичергәнне генә яза башласак, татар әдәбиятының офыклары, тематик чикләре нык тараер иде. Шуңа күрә язучыларга, алга конкрет максат куеп, актив рәвештә тормышны өйрәнергә туры килә. Р. Вәлиевнең «Яшисе килә!» повесте әнә шулай язылган.

Татар әдәбиятының хатын-кыз образларыннан гомер-гомергә бәхете булды. Артык еракка китмичә, соңгы 60—70 ел вакытны күз алдына китерегез. Олы юлдагы телеграф баганалары кебек, безнең әдәбиятта буйдан-буйга үзенчәлекле һәм мәлаем хатын-кыз образлары тезелеп бара: Ф. Әмирханның Хәяты, Г. Ибраһимовның Карлыгач Сылуы һәм Ш. Камалның Газизәсе, Г. Кутуйның Галиясе, Г. Бәшировның Нәфисәсе, М. Әмирнең Миңлекамалы, Р. Төхфәтуллинның Гөлзифасы, Ә. Еникинең Акъәбие һәм Гөләндәм туташы. Узган ел шулар янына А. Гыйләҗевның Бибинур карчыгы өстәлде.

Ташлыяр буендагы Аксыргак авылына Җиһангир Сәфәргалин дигән яшь председатель килә. Авыл халкын шатландырып һәм куандырып, гаҗәпләндереп һәм сөендереп күп төрле изге эшләр эшли-эшли дә, кәтмәгәндә үлеп китә. Моңа иң кайгырган, иң нык әрнегән кеше Бибинур карчык була. Җиһангир үлеме белән Бибинур карчыкның соңгы таянычы, соңгы өмете киселә. Дөрес, Җиһангир турында истәлек булып ул утырттырган яшел бакча, бакча янында буа, почта һәм мәгърур һәйкәл кала. Бибинур карчык һәр көн буе шул бакчага төшеп утыра, буа шавын тыңлый-тыңлый узган гомерен күз алдына китерә, истәлекләр дәрьясына чума.

Гыйбрәтле һәм мәгънәле тормыш юлы уза Бибинур карчык. Ил белән, халык белән, Аксыргак белән уртак язмыш кичерә Бибинур карчык. Ул гомер буе ил өчен, кеше өчен, башкалар өчен яши. Шул аны бәхетле итә, шул аңа җан тынычлыгы китерә. Бибинур язмышы — яшьлекләре колхоз төзү елларына, иң көчле һәм дәртле чаклары авыр сугыш елларына туры килгән хатыннар язмышы. Бибинур язмышы — безнең әниләр язмышы! Авыр язмыш, гыйбрәтле язмыш, бәхетсез язмыш, бәхетле язмыш...

Дөрес, буа шавын тыңлап, үткәннәрне искә төшерү өчен генә йөрми буа янына карчык. Буа янында тагын әле почта бар. Бибинур үзе үстергән балаларыннан күчтәнәч, посылка димим, һич югы хат-хәбәр көтә.

«Җомга көн, кич белән»— 1980 елның иң уңышлы һәм зур резонанс уяткан, шул ук вакытта капма-каршы фикерләр уяткан әсәре. Повестьның төп уңышы — Бибинур карчык образы.

Ниһаять, тагы бер повесть — Гариф Ахуновның «Йолдызлар калка»сы. Автор үзе әйтмешли, гадәти булмаган повесть, язучылар тормышы, язучылык хезмәте турындагы повесть.

Китап төрле зурлыктагы җиде бүлектән тора. Бүлекләр, хронологик тәртиптә килеп, автор тормышының сабый чактан алып бүгенге көннәргә хәтле булган тормышын нурли.

«Юл башы» дип исемләнгән беренче бүлек, мәсәлән, булачак язучының сабый чагы, мәктәп еллары һәм педучилище чоры, беренче укытучылары, матурлык дөньясына — иҗатка тәүге адымнары турында. Алга таба без Г. Ахуновның студентлык еллары һәм иптәшләре белән танышабыз, иҗат газаплары янына мәхәббәт газаплары килеп өстәлә... Менә ул «Совет әдәбияты» журналында эшли башлый, язучылар даирәсенә керә, әдәби хәрәкәткә катнаша, гражданин һәм язучы булып формалаша. Дүртенче бүлектән Әлмәт чоры башлана. Әлмәттәге әдәби кичләр, шул әдәби кичләрнең башта әдәби берләшмә булып оешулары, аннары Татарстан язучыларының Әлмәттәге бүлеген ачу... Повестьның соңгы бүлекләре Ч. Айтматов һәм М. Кәримнәрнең юбилейлары уңае белән язылган. Язучы әлеге юбилейлар вакытында алган тәэсир-

ләре белән уртаклаша, язучы һәм халык, язучының халык алдындагы җаваплылыгы турында уйлана. Әсәр белән танышканда, безнең күз алдына Г. Ахуновның 50 еллык тормыш юлы килеп баса, без аның бик күп әсәрләренең язылу һәм басылу тарихы белән, иҗат шатлыклары һәм иҗат газаплары белән танышабыз. Ул безгә әдәби иҗат эшенең үзенчәлекле якларын, күп кенә хасиятләрен ачып бирә. Бу повестенда Г. Ахунов прозаик буларак кына түгел, сәнгать әсәрләрен нечкә сиземли торган тәнкыйтьче буларак та ачыла. Бу — әсәрне бермә-бер кызыклы итә.

«Йолдызлар калка» повестен укыганда, без 50—70 елларда республикада барган әдәби хәрәкәт, шул хәрәкәтнең уртасында кайнаган мәдәният кешеләре: язучылар, журналистлар, тәнкыйтьчеләр, режиссерлар белән танышабыз. Алар кырыклап кеше. Автор һәр кешенең үзенә генә хас сөйләү рәвешен, гадәтләрен бирә алган. Шуңа күрә аларның һәммәсе диярлек җанлы булып күз алдына килә, истә кала. Бусы — әйбәт. Шуның белән бергә, Г. Ахунов, кеше һәм художник буларак, аларның һәркайсына үз мөнәсәбәтен белдерә. Аларның берсүзсез кабул итәрдәйләре күп, килешмәстәйләре дә бар... Г. Ахунов яшьләрне усаллыкка, әсәрләрен дөньяга чыгару өчен көрәшергә, талашырга өйрәтә. Әмма, талашу һәм көрәшү өчен, яшь авторның таланты, ныклы әдәби-эстетик карашлары, иҗат принциплары булырга тиеш, дип тә өстәсә, нур өстенә нур булыр иде...

Сәнгать әсәренә дөрес бәя бирү — кыен эш. Һәр сәнгать әсәре тере бер организм, яңа бер дөнья. Һәр әсәргә бер генә ачкыч, үз ачкычын табарга кирәк. Әгәр кемдер синең әсәреңне аңламаган, аңа бердәнбер ачкычны таба алмаган икән — моның өчен ул кешегә үпкәләргә, аңардан дошман ясарга ярамый. Аннары, тар мәҗлесләрдә генә сөйләнә торган сүзләрнең һәммәсен киң массаларга җиткерә бару да мәҗбүри түгелдер шикелле. Саный башлагач, тагын бер кимчелеген әйтим: повесть озынгарак сузылган. «Намус» романының сурәтләү чаралары, Муса Җәлил һәм аның архивы, Мәскәү тормышы турындагы өлешләрне кыса төшәргә мөмкин. Тулаем алганда, «Йолдызлар калка» повестен мин авторның уңышы һәм кыюлыгы дип саныйм. Повесть гади һәм аңлаешлы тел белән, истә калырлык итеп язылган. Чын әдәби әсәр кебек, мавыгып һәм яратып укыла.

Узган ел дөнья күргән барлык повестьларны күздән кичердек. Ул повестьлардагы геройларга бәя бирергә күчкәнче, башта әдәби герой төшенчәсе белән бәйле ике мәсьәләгә ачыклык кертеп узасы килә.

«Заман» дибез, «заман герое» дибез, тагын әле «заманның уңай герое» дибез. Бу хакта күп сөйләнә, күп языла. Ачыктан-ачык әйтелмәсә дә, «заман герое» дигәндә без күбрәк «уңай геройны» күздә тотабыз. Бу аңлашыла торган нәрсә. Әмма төгәл үк түгел. Әйтик, Ә. Баяновның «Ут һәм Су» романында бер-берсенә капма-каршы ике герой бар. Берсе — Фаез. Ул — уңай герой. Икенчесе — Борис. Бусы — уңай герой түгел. Әмма икесе дә — заман геройлары. Я булмаса, А. Расихның «Сынау» романында"ы Сафура белән Әлфияне алыйк. Берсе — әшәке, икенчесе бик әйбәт кеше. Әмма икесе дә — заман геройлары. Мондый мисалларны күп китерергә була. Моннан шундый нәтиҗә чыга: повестьлардагы образлар системасы турында сүз алып барганда, безгә «заман герое» һәм «уңай герой» дигән төшенчәләрне тәңгәлләштерергә ярамый икән.

Инде икенче мәсьәлә. Гадәттә без язучыны уңай герой иҗат иткән өчен мактарга күнеккәнбез. Бу — шулай ук бик аңлашыла торган һәм табигый хәл. Ләкин без мәсьәләнең икенче ягын истән чыгарабыз. Начар, тискәре образ иҗат итү дә язучыдан күп көч, зур талант сорый ич. Әйтик, «Ике буйдак» романы басылып чыккач, А. Расихны нигездә Рәхим образы өчен мактадык. Миңа калса, романның иң нык истә калган образларыннан Заһид Сафичны иҗат итү дә җиңел эш булмагандыр. Без хәзер генә А. Гыйләҗевны Бибинур карчык өчен мактадык һәм дөрес эшләдек. Шул ук вакытта Зөһрәбану өчен дә мактарга ярар иде. Ник дигәндә, укучыны геройларның уңае да, тискәресе дә тәрбияли. Уңайларыннан без үрнәк алабыз, тискәреләреннән гыйбрәт алабыз.

Әмма ни генә булмасын, мәсьәләнең төбе, асылы барыбер чорга, заманга барып бәйләнә. Һәр чорның әдәбият-сәнгать кешеләре алдына куя торган үз таләпләре, үз бурычлары була. Язучылар әнә шул таләпләрне күздә тотып иҗат итәләр, шул бу-

рычлар яктылыгыннан чыгып иҗат итәләр. Заманга карап, геройлар, эдәби-эстетик карашлар һәм аларга мөнәсәбәт тә үзгәрә бара.

Инде конкрет эшкә күчсәк, узган ел прозаикларыбыз күп кенә кызыклы образлар иҗат иткәннәр. Арада үрнәк алырдайлары күп, гыйбрәт алырдайлары да бар.

Үрнәк алырдайлары: Бибинур карчык, Рәфкат Миргазизов, Асаф һәм Сылу, Сәгъдия карчык, Фәнис, Карачурина, Галия һәм Заһир, Булат һәм Галимҗан, Нуриман һ. б., һ. б.

Гыйбрәт алырдайлары: Баһау, Гөлчәчәк һәм Тәбрия, Габделнур һәм Минҗан карт, Зәһрәбану...

Шушы истә калган образлар мисалында гына да бүгенге геройларыбыз хакында кызыклы күзәтүләр ясарга, төпле бер фикер йөртергә мөмкин. Иң куанычлысы шул, ул геройлар арасында тормышта актив позициясе булган, сүзе эштән аерылмаган геройлар, тулы канлы коммунист образлары, чын мәгънәсендә үрнәк алырлык кешеләр күп.

Күрәсез, җитди һәм актуаль мәсьәләләр күтәрү белән бергә, язучыларыбыз кызыклы гына образлар да иҗат иткәннәр икән. Шуның белән бергә, безне борчый, уйландыра торган мәсьәләләр дә байтак. Әдәби әсәрләребезнең иҗтимагый яңгырашы һәм колачы борчый, бүгенге повестьларыбызның фәлсәфи тирәнлеге борчый. Повестьларыбызның сәнгатьчә камиллеге борчый. Димәк, алда — яңа бурычлар, без яулыйсы, без яуларга тиешле яңа биеклекләр!

Салих Маннапов

# ДӨНЬЯНЫҢ КЫЛ УРТАСЫНДА...

Аларның бәрәңге бакчаларыннан ук Урал таулары башланып китә... Бáшта кечкенә генә, тәбәнәк кенә калкулыклар рәвешендә пәйда булалар да, аннары, тора-бара, әкренләп-әкренләп, сокландыргыч тауга әйләнәләр алар. Шулай итеп, бәрәңге бакчасы артындагы кылганлы калкулыклар бөек Уралга барып тоташа.

Кеше күңелендә шигърият туу да әнә шулайрак бара кебек. Анда да башта мәхәббәт һәм нәфрәтнең сизелер-сизелмәс, йомшак кына авазлары ишетелеп китәдер, кылганнарны кузгатып искән җил төсле, әлегә түбәннән генә аккан фикер агышы тоела башлыйдыр. Аннары инде алар зурая, көчәя; әлеге калкулыклар тауга әверелгән сыман үсә-үсә, әкренләп кеше рухының олы биеклекләре — Урал кебек буй җитмәслек мәгърур шигъри ил барлыкка киләдер... Хис-кичерешләр тау кыялары кебек биеклеккә һәм тау упкыннарыдай тирәнлеккә ирешәдер...

Безнең алда — шагыйрь Гәрәй Рәхимнең туган ягы...
Безнең алда — аның күңел җимешләре, иҗаты...

**Ирләр ул гел шулай:**
**Чәй кайнап чыкканчы гына дип китә дә...**
**Югала.**
**Һәм еллар хәбәрләр китерә:**
**— Билгесез югалды...**
**— Приказны үтәгәндә...**
**— Батырлык күрсәтеп...**
**Малайлар гел шулай:**
**Чәй кайнап чыкканчы гына дип китә дә,**
**Югала.**
**Һәм көн дә газетлар хәбәрләр китерә:**
**— Тайгада шәһәрләр төзелә...**
**— Чирәм җир сөрелә...**
**— Космостан әйләнеп кайттылар...**
**Көненә ничәмә мәртәбә куела самовар.**
**Көненә ничәмә мәртәбә әйтелә:**
**— Чәй кайнап чыга бит,**
**Кайтырлар...**
**Кайтырлар...**

60 нчы еллар уртасында матбугатта иseме күренә башлап, бүген дистәгә якын шигырь китабы, проза һәм сәхнә әсәрләре белән үз укучыларын тапкан әдипкә әверелде ул.

Г. Рәхим — әдәбиятка тормыш һәм иҗат максимализмы белән килгән буын вәкиле. Асылда төрле характердагы бу шагыйрьләрне ачык гражданлык позициясе, актив көрәш рухы берләштерә иде. Алар тормышка Тукайча турылык, Такташча кайнарлык, Җәлилчә кыюлык белән карарга омтылдылар. Бу — әдәбиятның олылыгын, иҗат эшенең җаваплылыгын аңлаудан туган зур һәм катлаулы бурыч иде. Аны үтәү өчен аларга үзләре сайлап алган төп юлдан тайпылмаска — «халыкның гасырлар буена... моң һәм хис белән өретелеп килгән күңел авазы һәм ритмына сизгеррәк булырга» (Р. Фәйзуллин) кирәк иде.

Г. Рәхимне шигърият үрләренә күтәргән сил — иң беренче чиратта үз буынын аның язмышын уйлап яну, яшьлек идеаллары, яшәү мәгънәсе, ил-халык алдында җа-

ваплылык турында уйлану. Җирне яктылыкка таба юнәлтү, кешене яхшылык ягына үзгәртү, шуңа җиң сызганып керешү сыйфатлары («Мин бит бу тормышны тазартырга дип килгән кеше дөньяга»)— шагыйрь иҗатының үз буыны белән уртаклыгын күрсәтүче икенче билге. Күзгә ташланып торган өченче гомуми үзенчәлек — шигъри ачышларны яңа эчтәлек рухына тиң форма белән дә ныгытып барырга омтылу. Дөньядагы барлык үзгәрешләрне күңелгә үтә якын алып, катлаулы заманда кеше матурлыгын раслау теләге белән янганлыктан, җаны-тәне белән гармониягә ашкынганлыктан — киеренке кичерешләр давылы булып танылды бу поэзия. Аның йөрәк тибешендәге аритмия — әлеге шул дулкынлану яки борчылудан, соклану яки нәфрәтләнүдән.

Г. Рәхимнәр буынының шул рәвешле тормышның яңа катламнарын ачарга тырышып мәйданга килүе — күптәнге хакыйкатьнең тагын бер кабат раславы: шигърияттә яңалыкка омтылу тойгысы яшәтә.

Көндәлек тормышыбызда да шулай бит ул... Ибе-җебе китереп эшләнгән фабричный паласлар, уңмый торган буяу төшерелгән ашъяулыклар берзаман туйдыра башлый, алардан күңел кайта, җан бизә. Шулай итеп әбиләр сандыгында үз сәгатен көтеп яткан чүпләмле сөлгеләр, йон җебеннән сугылган паласлар дөньяга чыга. Адәм баласы үз кул җылысы кермәгән әйберләрне нигәдер ятсынып куя, үзе бәйли, үзе тегә, үзе чиккән кульяулыклар белән мавыга. Бу кайберәүләр уйлавынча иң соңгы мода, «ретро», тагын әллә нәрсәкәй... Чынлыкта исә гадилеккә, табигыйлеккә сусау актарып чыгара ул сөлге-эскәтерләрне сандык төбеннән.

Әнә шундый тансык үзгәрешләр әдәбиятта да төрле юл белән бара. Күнегелгән, туйдыра башлаган бертөрлелектән качу берәүләрне, әйтик, ирекле үлчәмнәргә, шаккаткыч метафоралар парадына чакыра. Ягъни алар көтелмәгәнлек, гайре табигыйлек белән укучыны җәлеп итәргә омтылалар. Икенчеләре исә моның киресен — нәкъ менә җиргә, табигый яшәешкә якынайтучы юлны сайлыйлар... Беренче юнәлеш буйлап китсәң, шигырьнең эчке төзелешен катлауландыру, эстетик информация күләмен арттыру мөмкинлекләре ачыла бара; аннары инде санның сыйфатка күчүе дә мөмкин... Икенчесе буйлап барганда — материал каршылыгын җиңеп, тормыштан шигърият эзләү, аның үзенә генә ятышлы көен табу...

Г. Рәхим иҗатын карап-күзәтеп барган укучылар белә: шагыйрьгә бу юлларның икенчесе якынрак.

> **Без килгәндә сыйлар әйбәт иде —**
> **Табын саен алма туралды.**
> **Без килдек тә, бу да бар бит дип,**
> **Табыннарга аттык торманы.**

Як-якка каранып реверанслар ясап тормый, турыдан-туры ярып сала да куя!

Күрсәң, шул сыйфатын истә тотыптыр, Г. Рәхим шигырьләре турында сүз чыкканда, аларның төп үзенчәлеген — гадилек дип, һәртөрле формаль бизәклардән азат булу дип билгеләү гадәткә кергән. Янәсе, аңа форма өлкәсендә эзләнүләр чире кагылмаган, аның стиле сөйләп чыгуга гына корылган һ. б., һ. б. лар...

Ә тел очында һаман шул көй тора:

> **Зирекләрнең кара бөдрәләре...**

Зир-рекләр-рнең кар-ра бөдр-рәләр-ре...

Бу көй-моң тәгәл һәм нәфис такърарланып килгән «р» авазына да бәйле түгелме!... Шулай ук аерым башка шигырьләрдә дә юлларның, сүзләрнең музыкаль ачкыч булып кабатлануын да хәтерлисездер. Г. Рәхимнең мәгънәви кайтавазларга омтылуы шактый эзлекле күренеш икән ләбаса!

Бер очракта ул дулкын-дулкын булып килгән кабатланулар рәвешен ала, әлеге дулкынның һәр кагуы сиңа нәрсәдер алып килә, шул дулкын белән синнән нәрсәдер китә, аны берничек тә тотып, туктатып калып булмый:

> **...Озын төннәрдә мин,**
> **Ялгыз чыгып кухня ягына,**
> **Төне буе шигырь язып чыгам —**
> **Ялгыз әнкәмне сагынам.**

Икенче очракта шигырь юллары, текә Идел ярындагы Тәтеш басмалары кебек, кискен генә өскә күтәрә башлый — башлар әйләнерлек!.. («Әниләр зарын искә төшерик).

Яңа бизәкләрне сабыр гына өсти-өсти, инде ясый башлаган картинасын шигырьдән шигырьгә тулыландыра барырга да ярата шагыйрь. Мондый очраклар күбрәк. Шуңа күрә теләсә кайсы шигыреннән беренче юлларны гына алып карарга мөмкин. Мәсәлән, «Яшь кызлар нюньдәй келәчләр... Чирәмдә чал чәчле бер бабай... Аранда яшь колын... тибенә...». Якыннан карасаң, картинадан бигрәк, шигырьнең киндере күренә башлый, «буяулары» сылаштырып кына барган кебек. Сырлап, чәчәкле-чуклы итәргә тырышу юк. Чү әле, форма гадиләге дигәннәре, шушымы соң әллә?.. Ләкин шагыйрь-рәссамның төп үзенчәлеген, ул иҗат иткән дөньядагы тирәнрәк һәм олырак бәйләнешларны күрү өчен, «картина»ны читкәрәк китеп, ерактанрак карарга кирәктер... Тулаем шигъри панорама итеп күрерлек ераклыктан. Һәм, әлбәттә, вакыт ераклыгыннан.

Барыбызга да мәгълүм: «фикерне табигый рәвештә яшәтү» максаты бу буын шагыйрьләренең күбесен шигъри лозунг теленә һәм метафоралар энергиясенә игътибар иттергән иде. Г. Рәхимнең элеккерәк еллардагы иҗатына килгәндә, анда төрле күренешләр янәшәлегеннән яки капма-каршылыгыннан билгеле бер сәземтә чыгару өстенлек алган иде шикелле. Уңышлырак очракларда бу — тышкы күренеш-мөнәсәбәтләрдән этәрелеп китеп, күңел халәтен ачарга омтылу булып чыкты («Буыннар елъязмасы», «Әниләр зары», «Урамчар артында яшел болын»).

Әлеге шигырьләрдә рухи информация зур, ләкин ул әле шактый өстә ята. Шуның өстенә бөтенлек җитенкерәми, ассоциатив бәйләнешләр өзелә һәм сурәт чарпаланыш шагыйрьнең юлына аркылы төшәргә генә тора иде. Нияте никадәр изге булмасын, «Сабырларга» (1967) шигырендә, мәсәлән, сабырлыкны кораб белән чагыштырганнан соң, шырпы — домна кебек янәшәлекләргә мөрәҗәгать итүе фикер үсешенә булышмый. Булышмый гына түгел, аны ваклый, тарката башлый. Авылның самими тормышында ясалма бизәкләр, көязлек әллә кайдан күзгә бәрелеп торган кебек, табигый агышлы шигырьдә әз генә чамадан узып киткән матурлау, «кыю» чагыштыру да шунда ук үзенең аргык икәнлеген сиздерә. Ә поэтик идеясе ягыннан сыек буынлы тезмәне «сынландырулар» гына коткара алмый, әлбәттә («Хыял бит ул сыер түгел, чыбык белән куарга!.. яки ул бер дуңгыз түгел шыр акыртып суярга!» һ. б.).

Соңгырак чор шигырьләрендә Г. Рәхим вак детальләр, метафораларны чәкәләштерүдән бигрәк, нигез ташы булып ятарлык зур-зур кисәкләр, кантарлар «күтәреп килә» шикелле. Аларда фикер, төү башыннан тәгәрәп төшүче кар йомарламы төсле, беренче строфада ук зур тизлек ала, шигырь юлларын үзенә укмаштыра-укмаштыра күләмлерәк, көчлерәк була бара. Күңел драмасына үтеп керү тирәнәя, аның котелмәгән катламнары ачылып, хис сурәтен яңа төсмерләргә баета. Җан хәрәкәтенең юнәлеше кискен үзгәрә, бу инде узгынчы тәэсирләр, бер минутлык хисләр генә түгел, ә бәлки, тамчылап җыелган һәм бәялеп торган ихлас кичерешләрнең яшәү рәвешен үзгәртерлек дәрәҗәдә кеч-җегәр алуы, шул энергиягә юл ачылу:

> Мин авылга кайткач, ялгыз гына
> Чыгамын да ындыр артына,
> Карлтылар ышыгына кереп,
> Тынып калам...
> Һәм елыйм мин. Ялгыз рәхәтлектән...

Эчке тетрәнүләр белән телгәләнгән җан ачысы. Картинаның тышкы бөтенлеге әнә шул пәрә-пәрә килүне тагын да кискенрәк аерып күрсәтә. Димәк, күңел хәрәкәтенә тиң күренешләрне шагыйрь инде табигатьтән эзли, тирә-юньнән таба. Үз кичерешләре аша башка кешеләрне, дөнья фәлсәфәсен аңларга омтыла. «Гади» шигырьләрнең тәэсир көче менә шушы ике нокта — Дөнья һәм Кеше дигән полюслар арасында барлыкка килүче куәтле «магнит кыры»на бәйле булырга тиеш: Бер яктан, бу — Г. Рәхим поэзиясендә баштан ук күренгән сыйфатның — конкрет сурәттән күп мәгънәлелеккә һәм гомумиләштерүгә чыгу, үз «мин»ение «без»нең бер өлеше, мәңгелек чылбырның бер буыны итеп тою сыйфатының тагын да ныгый, тамырлана төшүе дигән сүз. Икенче яктан, күпчелек шигырьләрендә аны үзенчәлекле шагыйрь итеп

танытучы эстетик үзәк абайлана башлый: ул — тормышны өйрәнү һәм аңлаудагы эзлеклелек, тышкы охшашлыктан бигрәк эчке бәйләнешләргә нигезләнгән ассоциативлык. Аннары хәзер ул «кантарлар»дан башка ташларны да үз урынына куеп бара: бусы нигез салырга булса, икенчесе — дивар өяргә, ә менә бусы, нәфисрәге — тышлау өчен, облицовкага...

«Казан утлары»нда басылган «Табылдыклар өстәле» циклы да (1980 ел, 4 нче сан), шулай ук шагыйрьнең «тар шигырьләр үлчәве»н җимереп, кыска пьесалар, операга либретто, нәсер-каргышнамәләр, хикәяләр һәм повестьлар иҗат итүе дә нәкъ шул хакта сөйли. Сибгат ага Хәким әйтмешли, прозасы — күңелендә шигырь күплектән...

Г. Рәхимнең шигъри сазында иң нечкә кыл — сагыну моңы. Туган нигезне һәм яшьлекне сагыну, сафлыкка һәм табигыйлеккә сусау. Шагыйрь катлаулы чынбарлык, катлаулы язмышлар уртасында яшәешнең иң асыл, беренчел нигезләрен табарга омтыла.

**Мин еллардан гомер дигән**
**Бер челтәр үреп барам;**
**Матур һәм ямьсез үрелгән**
**Төшләрен күреп барам.**

Халык көнкүреше бизәкләреннән, туган як табигате төсләреннән, онытылмас хатирәләрдән һәм тормышның һәрдаим туып торган сорауларыннан үрелгән күзгә күренмәс моң челтәре. Аның бер җебе — заманнар, кыйблалар буталганда да тел һәм күңел пакьлеген саклап кала алган бабалары фаҗигасе. Икенче җебе — бил сынганда да илне ятларга бирмәгән әти-әниләре язмышы. Ә җирлегендә — «утыз яшьтә икенче кат чәч агартучы» кордашларының коммунистик иман бөтенлеге, әхлакый сафлыгы һәм рухи дәвамчанлыгы. Аларга да гомер челтәрен үрү, матур итеп үрү җиңел түгел. Һәр буынга тормыш үз лабиринтларын әзерләп тора, олы юлга һәр буын үз хаталары белән көрәшә-көрәшә чыга. Шуңа күрә дә бу иҗат бөтен асылы белән драматик. Ләкин ул — якты дөньяга үпкә, тәүбә итү һәм ваз кичү рәвешендәге елак шигърият түгел. Шигырь кадәр шигырьгә, кульяулык вазифасын йөкләп, күз яше сеңдерү — гөнаһ! Г. Рәхимнең шигъри герое үз дәрәҗәсен яхшы белә. Аның күңелен вак мәнфәгатьләрдән өстен торган җаваплылык хисе, ил-көн өчен яну тойгысы били. Кешеләрнең рухи матурлыгы өчен борчылудан аның йөрәге әрни. Шушы сабыр, җитди драматизм тормыш мәгънәсен, дөнья ямен нечкәрәк тояргa булыша.

Катлаулы бу тормышта, кайберәүләр зур тизлек белән үзләренең үткәненнән качып, дусларыннан, танышларыннан ераклаша барган бер вакытта, хисләр табигыйлеген, принциплар гаделлеген саклап калу бик кыен. Шагыйрь әйткәнчә, күбрәк «без әдәпле генә яшибез, бер-беребезгә каты дәшмибез»... Бүген гадилек, мәктәп дәреслегендәге теорема шикелле күптән ачылган һәм исбатланган, җиңел һәм әзер хакыйкать булып та аңлашылырга мөмкин («...Төптән уйланган, дөрес сүзләр генә сөйлибез...»). Шуңа күрә хакыйкатьне табудан да бигрәк, аны курыкмыйча, вакламыйча, ялтыравык кәгазьгә төрмичә күрсәтүе авыррак.

Менә шул уңайдан, шагыйрь шәхесенең бөтенлеге, шагыйрь «мин»енең зурлыгы хакында да уйланасың. Бервакыт үзе үк уйнап-көлеп: «Эш җайланды, тәнкыйтьчеләр уйлап тапкач яңа термин. Миндә хәзер ике мин бар — берсе үзем, бер — лирик мин»,— дип язса да, Г. Рәхим тормышта да, шигырьдә дә туры сүзле һәм вәгъдәле булып кала. Язмыш нинди генә сынаулар дулкынына ташламасын, ул алардан игелекле һәм кешелекле сыйфатларын җуймыйча чыгарлык көч таба. Чит-ятлар күзеннән ачык йөз, үткен сүз белән яшерелгән моңлы күңеле исә ак кәгазьгә генә ачыла.

Шагыйрьнең мондый холкы, тормышта һәм иҗатта эзлеклелеге туган җире һәм үзенең якташлары белән бәйле булырга тиеш. Бик күп сыйфатлар аңа «Көннәр язга авышкач» повестендагы Ычтуп дәдәй кебек җор телле, шаян һәм мут ил картларыннан, әсәрләнүчән, йомшак күңелле әнисе Фәкилә ападан килә дер. Бу иҗатның чишмә башы да туган төбәктә: аның һәр шигыре үз авылдашларының «үзгә бер моңы, үтә гади, ләкин гаять шигъри сүзләре булган җырларына» тартым. Опера өчен язган либреттосында исә («Каһәрләнгән мәхәббәт», Б. Мулюков музыкасы) шагыйрьнең

туган як тауларындагы чишмәләрнең барысы бергә кушылып җырлаган кебек: чөнки аңа бөтен поэзиясе, рухы, сулышы белән шагыйрьне үстергән халык стихиясе шаулап керә.

Шигъриятнең чын бәһасе, чын кадере тышкы бизәкләргә генә бәйләнмәгән. Шуңа күрә шагыйрьнең төп ориентиры һәркайчан үзгәрешсез кала: ул — тормыш, кешеләр, кешелеклелек. Шуңа күрә вак-төяк борчулар, көндәлек мәшәкатьләр генә аның башын идерергә сәләтсез, алар аның күңелен тарайта, язмышын каралта алмый.

Үзен бәхетле шагыйрь итеп тоя Гәрәй Рәхим. Сугыш белән яшьтәш булып та, аннан озынрак гомерле булганга күрә бәхетле ул.

**Кырык малай туып калдык**
**Кырык бердә.**

. . . . . . . . . . . . . . . . .

**Узган буын нәфрәтләрен**
**Бергә җигеп,**
**Дәһшәт көнен булдырмаска**
**Мең мәртәбә бурычлы без —**
**Кырык егет**

Канлы-яшьле еллар әчесе ана сөте белән кергәнгә күрәдер ахрысы, аның иҗатында да Бөек Ватан сугышы кичкән шагыйрьләр — Сибгат Хәким, Хисам Камалларга якынлык сизелә. Бу — гаҗәеп түземлелек («Мин яратам ахры бу дөньяны җанда матур яра булганга...»), язмышка каршы бару («Кил минем күрәчәгем!»), дөреслекнең күзенә туры карау («Барган саен минем юл өстемә әткәй кабере калкып чыга һаман...»).

Иҗатында ныклы реалистик җирлеккә басу өчен, крестьянча җитди исәп-гамь белән яшәү өчен шагыйрь бала чагыннан ук әзер: «Уенчыклар алып тормадык, Җир туфрагы белән уйнадык...»

Иген кыры аны каударланмаска һәм вакланмаска өйрәткән, кичерүчән һәм кеше хәленә керүчән итеп үстергән. Шул сыйфатлары, шифалы дым туфракны сугарган кебек, шигыренә дә көчә, аның җирлеген — ышанычлы, формасын — табигый, эчтәлеген тормышчан итә:

**Миңа монда җайлы сезнең белән,**
**Карт авылым монда, үз күгем.**
**Бер ялгызым гына, яшеренеп,**
**Бер елармын, ахры, мин бүген...**

Тормышны туган йорт тәрәзәсеннән яхшырак күрә шагыйрь, үзенең туган авылына да читкә китеп, тыныч кына карый алмый, сагышлы-моңлы чакларында төп нигезенә «кайтып елый». Әнә шундый инде ул туган туфрак, авыл туфрагы: сафлык һәм табигыйлек төсе дә ул, халкыбызның рухи чишмәсе дә.

**Нәкъ менә шушында**
**Тормыш башланып китәдер шикелле**
**Тоела күңелгә.**
**Нәкъ менә шушында —**
**Игеннәр иләндә.**

Безнең шагыйрьләрнең барысы да диярлек — игеннәр иленнән. Безнең җыр бразналары ерак гасырларда да таныш ызаннарга алып чыга. «Игенченең галәмара изге аты!» Урта гасырларда яшәгән хикмәт иясе әнә шулай дип язган һәм тагын: «Сиксән сигез ирде тарих ул көн мең дә, әйтелде шәһрь Болгар кәндләрендә» (ягъни бистәләрендә),— дип калдырган. Тормышны тук башаклы арыш тезәмнәрендә, хисапсыз күп ашлык кешелләрендә күргән бүгенге шагыйрь исә: «Дөньяның кыл уртасында языллды... бу җыр»,— дип белдерә.

Юк, болай дөньяга карап без аны нигезеннән йөз чөергән космополитика янсә дөнья уртасына чыгып баскан бер тәкәббер затка тиңләргә ашыкмыйк! Бу җырның мәгънәви төше конкрет. Туфрагы конкрет. Шунлыктан аның эчтәлегендә «Дөнья» те-

шенчәсе дә яңарак, киңрәк мәгънәләре белән ачыла. Ул — безнең сөенечләребез һәм көенечләребезне, мәхәббәт һәм нәфрәтебезне бергә туплаган даирә. Шагыйрьнең күңел башкаласы, өе исә менә шул дөньяның кыл уртасында: «Зур дөньяның йөзен шушы нәни өйдән күзәтәм. Дөнья матурлыгын сезгә — кешеләргә күрсәтәм...»



Дөнья уртасына нинди сүз әйтергә дип чыккан соң шагыйрь? Аның миссиясе нидән гыйбарәт?

Г. Рәхим иҗатында сафлыкны һәм табигыйлекне сагыну хисе өстенлек итә, дигән идек... Сагыну хисе үсә-үсә дә, борчылуга әверелә икән ул. Ә бу, борчылу дигәнебез — үзәгендә «йөгәне-ияре белән аргамак тупырдап торган» хис, хәрәкәткә чакыручы хис. Ил-җир, Кеше язмышы өчен җаваплылык хисе нәкъ менә шул борчылуга нигезләнә: «Ә бүгенгә — аз да, күп тә түгел — без җаваплы бугай дөньяга». Ул, сугыш кузгалган елны туган ир-егет, илләр йөзен сагыш-хәсрәт саргайтканын онытмаска өнди («сугыш булган җирдә сагыш бар»). Һәм, әлеге дә баягы, моңа кадәр дә аның шигырьләрендә күренгән таш образы нигез яки диван коруга гына түгел: «Бу таш белән беркемгә дә сукмадым мин, әмма кулга алдым»,— дип, сугыш уты кабызучыларны кисәтү өчен дә кирәк икән. Шулай итеп шагыйрьнең әсәрләрендә публицистик ачыклык белән фәлсәфи тирәнлек табигый кушыла, шәхси һәм иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең аерылгысызлыгы кыю раслана. Дөнья, ил образы, кеше алдындагы бурыч төшенчәсе дә ачыклана, конкретлаша төшә.

Шагыйрь тышкы иминлек, туклык артында торган рухи хәерчелекне, күңел китеклеген дә күрә, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең асылына, күңел каршылыкларына игътибар иттерә: «Утызга да тулмый яшибез, шул кадәрле тигез яшибез — әллә артык кызык кеше без, әллә бер дә кызык түгелбез...». Куркып яшәү һәм битарафлык — үлемгә тиң, җаваплылыктан качучылар — дезертирлар белән бер һәм аларга шагыйрьнең хөкеме рәхимсез. Гражданлык җаваплылыгы аның үзен дә зур таләпләр куеп яшәргә, үтемле темалар артына яшеренмәскә, сүз кыйммәтен тоярга өйрәтә. Шулай да әле шигырь җаясенең җебен бушата торган мавыгулар да очрап куя! Артык маңгайга бәреп әйтү («Әни кирәк», «Баш кирәк»), я булмаса чыпчыкларга туптан ату («Хыял», «Тагын»)... Чагыштыруны дәвам итеп әйткәндә, угы да бар, киеге дә күз алдында тора — тидереп кенә булмый үзенә!

Заман һәм аның өчен җаваплылык турында сүз иң югары дәрәҗәдә алып барылырга тиеш. Г. Рәхимнең, әнә шул җаваплылыкны истә тотып, бервакыт: «Халтурачылардан көн кадагына суккан темаларны тартып алырга кирәк!»— дип чакыруы хәтердә. Ә чын поэзиядә вак темалар, кечкенә төшенчәләр юк. Шагыйрьнең үз иҗатын исә ирләрчә җитди һәм эзлекле фикерләү рәвеше бер үзәккә туплый. Шул гомум җирлектә туган ил, халык, заман кебек гадәти, күнегелгән төшенчәләр дә яңа мәгънәләре белән ачыла: «Заманага лаек җырлар эзләп, йөрәкләрдән кайчак каннар тама...»

Шагыйрьнең үз иҗаты — олы максатлар белән янып яшәү, ачык иҗтимагый-сәяси юнәлешкә йөз тоту, югары эстетик зәвыкка, киң идея карашына ия булу, халыкның рухи һәм әхлакый нигезләренә таяну. Шуңа күрә ул ил-көн яшәешенә битараф кала алмый. Шуңа күрә аның күңелендә ятkан уйлар, хисләр чор үзенчәлегеннән, халык язмышыннан аерылгысыз: «Юк, шигырьдә йокы симертергә рөхсәт итми безгә бу замана».

Әйе, дөнья уртасына басып сүз әйтерлеге бар шагыйрьнең: шигырендәге шәхси кичерешләргә, лирик башлангычка «дөнья» һәм «заман» төшенчәләре белән билгеләнгән эпик масштаблылык үрелеп үсә.

«Масштаблы» дигәннән, без ул сүзне «киң колачлы», хәтта зур, күләмле мәгънәсендә генә аңларга күнегеп киттек. Аның беренчел нигезен — шартлы нисбәтне белдерүен бик искә алмыйбыз бугай. Ә бит, мәсәлән, болай да фараз итәргә була: масштаблырак булган саен, шигырьнең төше кечерәя һәм тыгызлана барырга тиеш. Гәрәй Рәхим дә шулайрак уйлый төсле. «Шагыйрь — нокта... Шул ноктага сыйган Галәмемнең бөтен җисеме...»— ди бит ул. Һәр шигырьне бер «төш» тирәсенә тупларга! Алардагы масштабның зурлыгы дөньяга караш бөтенлеге, тормышка мөнәсәбәт җитлеккәнлеге белән билгеләнергә тиеш! Шагыйрь үз иҗатында шушы кыйблага йөз тота һәм аның бу юнәлештә һәрвакыттагыча эзлекле булуы да күренә.

Яшәү мәгънәсен аңлау, сүз кадерен белү җәһәтеннән Г. Рәхим поэзиясенең фронтовик шагыйрьләр иҗаты белән аваздашлыгына игътибар иткән идек инде. Бу очраклы бер күзәтү генә түгел. Менә чагыштырып карыйк:

**Белсәң, әнкәй, дошман**
**тылларына**
**Разведкага барган чакларым.**
**Мин куркудан догаң гел**
**укыдым,**
**Җаным саклап кеше сатмадым.**
**(Х. Камал)**

**Мин әнкәйгә үкси-үкси**
**сөйлим**
**Шәһәрдәге дуслар турында:**
**— Алар, әнкәй, шундый**
**әйбәтләр, дим,**
**Кечесе дә, димен, зуры да.**
**(Г. Рәхим)**

Биредә уртаклык бармы? Бар. Фәлсәфи конфликт уртаклыгы. Бер яктан — һәр күренештән гүзәллек, тигезлек, эзләү һәм гармониягә омтылу, икенче якта — тормышның күптөрле, катлаулы, ә кайчакта рәхимсез чынбарлыгы. Бу ике зур көчнең килешмәүчән көрәше дә бик күп төсмерләрдән хасил була. Нәкъ менә шул ноктада— Г. Рәхимнең үз буыны, шәхесе, сүзе һәм шул сүзне әйтү рәвеше.

Нәтиҗәләр ясауны һәм соңгы сүзне укучы ихтыярына калдырып, аның уйлануларына бер этәргеч бирү өчен, шагыйрьнең иҗат үзенчәлеге турындагы тагын кайбер күзәтүләребез белән уртаклашыйк.

Беренче күзәтү: «Сары төс төяп күз килгән мәлдә, күңелне сагыш биләргә тиеш. Ләкин яз төяп кошлар кайтыр дип, сагышны шатлык җиңәргә тиеш».— Тормыш каршылыкларын гадиләштеребрәк күзаллау, җиңел, ваемсызрак оптимизм.

Икенче күзәтү: «Күпме көннәр үткәч, ярсу күңелем сыкрап куйды сагынып яз шигырен... Мин «Яшьлек» дип шигырь язган урында көне буе сары яфрак коела».— Аек акыл хәрәкәте, күренешләр арасындагы катлаулы бәйләнешләргә игътибар итү сизелә, әмма әлегә мөнәсәбәт сүлпән, шунлыктан киләчәккә ышанычның хәтта беркадәр күңел төшенкелеге белән алмашынуы бар кебек.

Өченче күзәтү:

**Гомер дигән пар ат һаман чаба**
**Кабатланмый ни дә, бар да таман.**
**Барган саен ләкин юл өстенә**
**Әткәй кабере калкып чыга һаман...**

Бу — тормышны үз төсендә күрүдән курыкмау, каршылыкларның бердәмлеген тану. Биредә инде, кирәк икән, көчсезне яклау, ышанычын югалтканга терәк булу, конфликтның уртасына ташлану теләге өстенлек ала башлый...

Шулай, шагыйрь, тормышның үзе кебек, беренче карашка гына гади тоела. Һәм бу «гадилек» иҗат мәйданына аяк баскан елларындагы туры, ачык, дөресен әйткәндә, өстәрәк яткан фәлсәфи сөземтәләргә, логик нәтиҗәләргә охшамаган.

Бүгенге укучы шигырьдән вәгазь көтми, ул катлаулы бу заманда үзенә теләктәш эзли, шагыйрь күңелендә йөргән иң яшерен серне белергә омтыла.

Г. Рәхимнең шигъри герое да үз-үзе һәм дөнья белән бәхәстә ачыла. Бу бәхәс аның үз-үзләренә югары таләпләр куеп яшәүче каләмдәшләре белән бер сафта атлавын, гомумән, поэзиябезнең төп юлыннан аерылмавын күрсәтә.

Хәзер инде шагыйрь «интеллектуаль» ачышлар белән генә шаккатырырга омтылуның ни дәрәҗәдә беркатлы булуын белә. Ул укучыга үгет-нәсихәт кенә тәкъдим итүдән саклана. Әмма соңгы чор шигырьләре, элеккеләргә караганда фәлсәфирәк! Чөнки аларда — җир фәлсәфәсе, дөнья гаме. Бу шигырьләр хислерәк һәм моңлырак та. Чөнки аларда — тирәндә яткан җан җылысы, рухи яшәеш тулылыгы.

Мәхәббәт — Гәрәй Рәхим иҗатының туфрагы, суты һәм һавасы. Шуңа күрә дә «сүз башласа, телләреннән җыр булып моң түгелә» аның. Шуңа күрә:

**Дөньяга булган сөюем**
**шушы нәни җыр булыр,**

— ди шагыйрь. Ә дөньяның камиллеге өчен көрәшүче, кеше рухының илаһи бөекләгән яклаган җыр — нәни була алмый!

## КИТАП КҮЗӘТҮ

# ФӘНГӘ ЯҢА ӨЛЕШ

Тарих фәннәре кандидаты Фоат Вәлиев озак еллар буе Себер татарларының тарихын, этнографиясен, материаль һәм рухи культурасын өйрәнү белән шөгыльләнә. 1980 елда Татарстан китап нәшрияты аның күләмле генә монографиясен рус телендә бастырып чыгарды. Хезмәт «XIX йөзнең икенче яртысында һәм XX йөз башларында Көнбатыш Себер татарлары» дип атала. Ул этнографик очерклардан тора.

Үзе дә шул якларда туып үскән Ф. Вәлиев Себердәге илледән артык татар авылын йөреп чыккан, бөтен шәһәрләрендә булган, өлкән яшьтәге бик күп кешеләр белән очрашып, кыйммәтле информациямәгълүмат алган. Шундый юл белән автор этнографик материал җыйнаган, ул төбәктәге кешеләрнең материаль һәм рухи культурасын, тормыш-көнкүрешен, гореф-гадәтләрен һәм төрле йолаларын өйрәнгән.

Китап кереш өлештән һәм җиде бүлектән тора. Беренче бүлектә Көнбатыш Себер татарларының килеп чыгышы һәм этник составы турында сүз бара. Анда әйтелгәнчә, төрки телле Себер татарлары башлыча Төмән, Омск, Новосибирск өлкәләренең авыл районнарында, Томск шәһәре тирәсендә, шулай ук Төмән, Тубыл, Омск, Новосибирск, Томск, Бараба, Тара һ. б. шәһәрләрендә яшиләр. Автор күп санлы һәм төрле-төрле чыганакларга таянып, Себер татарлары кыпчак кабиләләреннән килеп чыккан, дигән нәтиҗә ясый. Озак еллар буена тарихи бәйләнештә яшәү нәтиҗәсендә Себер татарлары башка халыклар белән якынлаша барганнар. Көнбатыш Себер рус дәүләтенә кушылгач, татарлар шул тирәдәге руслар белән якыная башлыйлар. Бу исә хуҗалык алып бару, тормыш-көнкүреш шартларында һәм культура өлкәсендә чагылыш таба. Автор моның уңай йогынтысын нигезләп һәм ачык итеп күрсәтә. XIX йөз урталарында Себер татарлары белән Идел буе татарлары арасында экономика, сәүдә, культура бәйләнешләре көчәя башлый.

Икенче бүлектә Тубыл губернасындагы Тара, Төмән, Тубыл өязләренең ул чактагы табигый-географик шартларына характеристика бирелә. Ул төбәктә яшәгән җирле татарларның саны һәм аларның кайсы җирләрдә таралып утырган булулары турында мәгълүматлар китерелә.

Китапның җыйнак кына күләмле өченче бүлеген дә кызыксынып һәм игътибар белән укыйсың. Биредә сүз патша властеның Көнбатыш Себердәге җирле халыклар белән, шул исәптән татарлар белән дә ничек идарә итүе турында бара. Көнбатыш Себер Рус дәүләтенә кушылганнан соң, анда волостьлар һәм башка төрле административ идарә органнары төзелә башлый. Идарә органнарына җирле халыкның югары катлау вәкилләре билгеләнеп куела. Волость идарәләре, старшиналар һәм авыл старосталары биредә халыкны буйсындырып тоту, ясак һәм башка төрле салымнар җыйнау өчен патша администрациясенең таянычы булып хезмәт итәләр. Автор моны озак еллар буена «Тубыл татарлары башлыгы» булып торган Кульмаметовлар нәселе мисалында ачык күрсәтә. Патша администрациясенә тырышып хезмәт иткәннәре өчен Кульмаметовларга патша властьлары тарафыннан берничә тапкыр затлы киемнәр, исеме язылган корал, зур мәйдандагы җир-су һәм урман бүләк итеп бирелә. Екатерина II указы белән аларның нәселе дворян дәрәҗәсенә күтәрелә. Шулай итеп автор җирле административ идарә органнарының сыйнфый йөзен дә ачып бирә.

Китапның дүртенче һәм бишенче бүлекләрендә Себер татарларының нинди хезмәт, һөнәр белән шөгыльләнүләре, хуҗалык алып бару ысуллары, эш-кәсепләре турында сөйләнә һәм халыкның материаль культурасына характеристика бирелә. XIX йөзнең икенче яртысында Тубыл губернасындагы татарлар иген игү, терлек асрау белән, шулай ук балык тоту, аучылык, һөнәрчелек белән шөгыльләнгәннәр. Шәһәрләрдә сәүдә дә җанлана башлый.

Автор татар авылларының архитектура төзелешен, йорт-җир җиһазларын, кием-салымнарын, бизәнү әйберләрен, аш-суларын тасвирлый. Моның кайбер үрнәкләрен фото-рәсемнәрдә күрсәтә.

Тарихи-этнографик әдәбиятта беренче тапкыр буларак, Ф. Вәлиев Көнбатыш Себер татарларының туй йолалары турында бай гына мәгълүмат бирә. Моңа китапның алтынчы бүлеге багышлана. Анда әйтелгәнчә, элек Себер татарлары зур-зур гаилә булып яшәгәннәр, өйләнгән балалары аерылып чыкмый торган булган. Ә инде XIX йөз ахырларына хәл үзгәрә: өйләнгән малайларны башка чыгару тәртибе керә.

Хезмәтнең соңгы, җиденче бүлеге дә укучыда зур кызыксыну тудыра. Монда Себер татарларының рухи культурасы турында фәнни яктан кызыклы һәм әһәмиятле материаллар тупланган. Автор төрле-төрле этнографик мәгълүматлардан аеруча әһәмиятлеләрен сайлап алган, аларга тарихи яктан аңлатма биргән. Китапта халык сөйләм иҗатының төп жанрларына да (әкиятләргә, бәетләргә, җырларга һ. б.) шактый урын бирелә.

Тара, Түбән һәм Тубыл татарлары кояш, ай, йолдызлар торышы буенча, яшьмтөшемнәрнең күләменә, кайбер хайваннарның һәм кош-кортларның үз-үзләрен тотышына карап һава шартларының үзгәрүен алдан әйтергә, иген уңышының ничек булачагын белергә өйрәнгәннәр. Халыкның буыннан-буынга күчеп килә торган тәҗрибәсе нигезендә терлекләрнең кайбер авыруларына диагноз куеп, аны дәвалау ысулларын белгели торган булганнар. Бу яктагы татарларда ел исәбенең төрле календарьлары булган. Автор үзенең хезмәтендә биредә таралган халык медицинасы үрнәкләрен дә күрсәтә.

Рухи культурага багышланган бүлек ахырында автор Себер татарлары арасыннан чыккан кайбер интеллигенция вәкилләре турында кыскача тарихи мәгълүматлар китерә. Аларның берсе — Ният Бакый Атнометов Тубыл халык училищесында төрки телләрне укыта. Ул төзегән «Татар һәм гарәп теле әлифбасы»н Россия фәннәр Академиясе бастырып чыгара.

1870—1880 елларда Ембай мәдрәсәсендә укытучы булып эшләгән Себер татары Мәүликәй Юмачиков гарәп телендә ике китап бастыра, татар телендә шигырьләр яза. Үз заманының талантлы кешеләреннән берсе — халык арасыннан чыккан Ситдыйк Мәһди улы Зәйнетдинов (1854—1927 елларда яшәгән) татар, башкорт, казакъ, үзбәк телләрен яхшы белгән, мәдрәсәдә гарәп телен өйрәнгән, русча иркен сөйләшкән. Ул үз ягының тарихын, халык җырларын, легендаларын, әкиятләрен бик оста итеп сөйли торган булган. Шуңа күрә аны һәркайда көтеп ала торган булганнар.

Узган йөз ахырларында укымышлы мөгаллимәләрдән саналган Хәнифә (Биби-Хәнифә) Ниязова Тара шәһәрендә кызлар укыткан, матур әдәбият белән шөгыльләнгән. 1897 елда аның «Тәгъзия» («Юаныч») исемле кечкенә күләмле поэтик әсәре Петербургта басылып чыга.

Революциягә кадәрге елларда Себер татарлары арасында гыйлем таратуга тәрҗемәче Хәҗҗәтулла Ченбаев шактый өлеш кертә. 1911—1917 елларда ул русчадан татарчага берничә популяр брошюра тәрҗемә итеп, Казанда һәм Оренбургта бастырып чыгара.

Көнбатыш Себер татарларының рухи культурасын үстерү һәм халыкны агарту эшендә катнашучылар арасында без Нигъмәтулла Сәйдуков исемен дә очратабыз. Узган йөзнең җитмешенче еллар башында бертуган Сәйдуковлар үз акчаларына Ембай авылында мәдрәсә ачып җибәрәләр. Монда ислам дине догматларыннан тыш математика, география, тарих һәм рус теле укыталар. Мәдрәсә китапханәсе өчен күп кенә китапларны Н. Сәйдуков Казаннан, Бохарадан, Төркестаннан һәм гарәп илләреннән кайтарта. Монда зурлар өчен дә уку залы була.

Тубыл татарлары укымышлыларына Себердә яшәүче прогрессив карашлы рус интеллигенциясе вәкилләренең йогынтысы зур булган. Мәсәлән, А. Маметов Тубыл шәһәрендә рус телендә чыгып килгән бер сатирик журналга мәкаләләр язгалый. Журнал редакторы Панкратий Сумароков өендә очрашкан чакта революционер язучы А. Н. Радищев А. Маметовка файдалы киңәшләр бирә һәм Россия белән Бохара арасындагы сәүдә элемтәләре турында китап язарга тәкъдим итә.

Китапның тагын бер уңышлы ягын күрсәтеп үтәргә кирәктер. Автор Себер татарларының башка өлкәләрдәге татарлар белән күпкырлы элемтәләрен, бәйләнешләрен күрсәтә. Аерым алганда, Себер татарларының материаль һәм рухи культурасына, хуҗалык эшчәнлегенә, гаилә-көнкүреш мөнәсәбәтләренә Идел буе татарларының йогынтысы зур була. Казан якларыннан барган татарлар К. Насыйри, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов әсәрләрен һәм башка китапларны тарату, уку-укыту эше белән шөгыльләнәләр, халыкны агартуда катнашалар. Идел буе һәм Урал ягы татарларының прогрессив йогынтысы Бөек Октябрь революциясеннән соң тагын да көчәя һәм яңа, социалистик юнәлеш ала.

Казаннан җибәрелгән иҗтимагый-политик әдәбият аша Себер татарлары Совет властенең беренче декретлары, яңа законнары белән, Ленинның социализм төзү планы һәм Коммунистлар партиясенең милли политикасы белән танышалар. Бу яктан алганда Татарстаннан килгән партия һәм совет работниклары, укытучылар, врачлар һәм башка төр белгечләр зур эш башкаралар.

Безнең яклардан барган коммунистлар һәм интеллигенция вәкилләре татар телендә «Азат Себер» газетасын чыгаралар. Ул 1919 елның декабреннән 1935 елга кадәр (башта Омскида, аннары Новосибирскида) чыгып килә. Революцион тәгълиматны пропагандалауда, культура-агарту эшенә, хезмәт ияләрен социалистик төзелешкә туплауда газета үзеннән лаеклы өлеш кертә.

Китапның соңгы битләрендә автор Себер татарларының Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң ирешкән казанышларына туктала. Партиябезнең ленинчыл милли политикасын тормышка ашыру нәтиҗәсендә һәм илебездәге тугандаш халыкларның эчкерсез ярдәме белән Себер татарлары экономика һәм культура өлкәсендәге артталыкны бетерә алдылар, промышленностьны һәм авыл хуҗалыгын үстерүдә гаять зур уңышларга ирештеләр. Хәзер бу якларда нефть һәм газ чыгару, аны эшкәртү промышленносте, урман хуҗалыгы һәм башка тармаклар кызу темплар белән үсә. Халыкның материаль тормыш һәм көнкүреш хәле яхшырганнан-яхшыра бара. Авылларда хәзер түбәсе кәс белән ябылган, җиргә сеңеп беткән балчык өйләр күрмисең. Алар урынына алтышар почмаклы зур-зур йортлар төзелеп киткән. Хәзер һәммәсендә газ, электр, радио, телевизор, холодильник. Авылларны заманча итеп салынган мәктәп, клуб, медпункт биналары, яңа магазиннар һәм балалар бакчалары бизи. Кешеләрнең тормыш-көнкүреш шартларында да үзгәрешләр зур.

Халыкның белеме һәм культура дәрәҗәсе дә нык күтәрелде. Совет властеның беренче елларында ук Себердә татар мәктәпләре ачыла башлый. Түбән өязендәге андый мәктәпләрдә беренче укытучылар коммунист Мөхәммәт Бабукин, Мөхтәр Искәндәров, Сәетҗан Мөхәммәдьяров, Тубыл өязендә — Заһит Мировалев, Хәсәен Шәйхелиев, Тара өязендә — Мөнзир Исхаков, Кәрим Рәхимов, һади Бәширов һ. б. иптәшләр була. Яшь буынны укыту һәм тәрбияләү эшенә Мөхәммәт Урамаев, Зиннур Бекшенев, Якуб Зәкиев кебек танылган укытучылар күп көч куялар.

Бу якларда яшәүче татарлар арасыннан күп кенә галимнәр, культура һәм сәнгать эшлеклеләре үсеп чыкты. Алар арасында без фәннәр докторлары Мидхәт Булатов-

ны, Хәмит Ярмөхәммәтовны, СССРның халык артисткасы Галия Измайлованы, РСФСРның халык артисты Фуат Мансуровны, СССРның атказанган спорт мастеры Галимә Шөгерованы һәм башка иптәшләрне күрәбез. Әнә шундый кызыклы фактларга бай бу китап. Ул күп көч һәм тырышлык куеп язылган җитди фәнни хезмәт.

Шулай да китап кайбер җитешсезлекләрдән дә азат түгел. Мәсәлән, Көнбатыш Себер татарларының барлык группалары да бер үк дәрәҗәдә тулы итеп тасвирланмаган. Аның төньяк-көнбатыш группалары, бигрәк тә ялутор татарлары өстән генә каралган. Шулай ук Казан татарлары белән себер татарлары арасындагы уртак якларны киметеп күрсәтү тенденциясе дә сизелә. Бу бигрәк тә китапның алтынчы бүлегенә карый. Автор, Казан татарлары йогынтысы астында Себер татарларының антропологик тибында европоид элементларының артуы һәм гомум аңлаешлы уртак тел таралу күзәтелә дип үтсә дә (кара: 38 бит), шул ук вакытта ул бу йогынтыны киметеп күрсәтә, хәтта, себер татарлары «татар буржуаз милләте формалашу процессыннан читтә торганнар», дип саный (45 бит).

Автор урыны-урыны белән себер татарларының примитив үсешен күрсәтү белән артык мавыга. Мәсәлән, Себер ханлыгын ул «примитив феодаль дәүләт» дип саный (22 бит). Бу аңлашылып җитми. Чөнки феодаль дәүләт артык примитив була алмаган кебек, примитив дәүләт тә феодаль дәүләт була алмый. Себер татарларындагы җир эшкәртү системасын да автор «примитив» (71 бит), ләкин шактый югары үсешкә ирешкән «өч басулы чәчү әйләнешенә» нигезләнгән (71 бит) дип карый.

Себер татарларының балыкчылык һәм аучылык, һөнәрчелек һәм сәүдә белән шөгыльләнүләре турындагы һәм бигрәк тә халык иҗаты турындагы бүлекләре дә тиешле анализ ясалмыйча һәм ачык мисаллар китерелмичә язылган. Иллюстрацияләрнең аз һәм түбән сыйфатлы булуы, карталарның бөтенләй булмавы да бу хезмәтнең бәясен киметә.

Китапта Көнбатыш Себер татарларының шул чордагы иҗтимагый-политик мөнәсәбәтләрен тикшерүгә аерым бер бүлек бирелсә, отышлырак булыр иде. Бу кимчелекне, әлбәттә, автор үзе дә сизә һәм моны фактик материалның җитәрлек булмавы белән аңлата (9 бит).

Тулаем алганда, Ф. Вәлиевнең хезмәте Көнбатыш Себер татарлары этнографиясен өйрәнүгә зур өлеш кертә. Ул Татарстан, Себер, Казагыстан һәм Урта Азия республикалары белгечләре арасында кызыксыну уятты. Кызганычка каршы, китап аз тираж белән басылган.

**АЛЬФРЕД ХАЛИКОВ,**
тарих фәннәре докторы, профессор.
**МӨСӘВИР ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН,**
СССР Журналистлар союзы члены.

# КҮҢЕЛ ЮАНЫЧЫ, ТОРМЫШ КӨЗГЕСЕ

Халык иҗатының кайсы гына өлкәсенә күз салма, шигъри матурлык, нәфислек чишмәләренә тап буласың. Бәрәкәтле катламнардан ургып чыккан ул «кәүсәр чишмәләре» яңадан-яңа буыннарны рухландырып тора... «Татар халык иҗаты» тупланмасының «Йола һәм уен җырлары» дип исемләнгән VI томын укыганда, күңелне шундый хисләр били ала[1].

И. Надировның җыентыкны ачып җибәрүче кереш мәкаләсендә халкыбызның йолалары һәм йола фольклоры, уеннары һәм уен җырлары, такмакларына фәнни күзәтү ясала һәм бу жанрларның поэтикасы тикшерелә. Автор татар халкының йола һәм уен фольклоры үзенчәлекләрен тугандаш һәм күрше халыкларның авыз иҗаты белән чагыштырма нигездә ачарга тырыша.

Китапка тупланган текстлар биш төркемгә бүлеп бирелгән. «Мәҗүсилек һәм борынгы чорлардан калган шигъри сүз үрнәкләре» дип аталган беренче бүлеккә халыкның борынгы хорафатлы йолалары бе-

[1] Йола һәм уен җырлары. Китапны төзүче, искәрмәләр хәзерләүче һәм сүз башы язучы И. Надиров. Казан. Татарстан китап нәшрияты, 1980.

лән бәйле ырымлау формаларының егермеләп үрнәге кергән.

Борынгылар, билгеле булганча, кешене күзгә күренми торган явыз көчләр әйләндереп алган дип ышанганнар һәм аларны төрле ырым такмаклары әйтеп җиңеп була дип уйлаганнар. Шундый мәҗүсилек карашлары китапта китерелгән текстларда да ачык күренә. Бу им-том итү, ырымлау такмазаларының фәнни әһәмияте зур. Беренчедән, алар борынгы бабаларыбызның тормышын, рухи дөньясын чагылдыру ягыннан игътибарга лаек. Икенчедән, әлеге такмазаларда халык поэзиясенең кабатланмас сыйфатлары сакланып килгән. Алар билгеле бер дәрәҗәдә төрки шигъри сөйләмнең әүвәлге яралгыларын өйрәнергә мөмкинлек бирә.

Икенче бүлек ел фасыллары белән бәйләнешле йолалар вакытында әйтелә һәм көйләнә торган әсәрләрне үзендә туплаган. Билгеле булганча, татар халкының календарь йолалары игенчелек, терлекчелек кебек хезмәт ихтыяҗы нәтиҗәсендә туганнар. Шуның өчен бу йолалар белән бәйле авыз иҗаты әсәрләрендә терлек-җәнлекләрнең үрчүен, игеннәрнең мул булуын теләү кебек мотивлар өстенлек итүе гаҗәп түгел.

XVIII гасырга кадәр бездә яңа елны мартның егерме берендә каршы алу гадәте булган һәм бу «Нәүрүз» дип аталган (нәүрүз — фарсы телендә яңа көн дигән мәгънәне белдерә). Бу көнне яшьләр, күбесенчә шәкертләр һәм балалар, өйдән өйгә йөетләр һәм махсус такмак-такмазалар («нәүрүз») әйтеп йөргәннәр. Нәүрүзләрнең эчтәлеге йорт хуҗаларына, аның гаиләсенә исәнлек-саулык, тазалык-байлык, яңа елның аларга муллык, тынычлык, бәхет китерүен теләүдән гыйбарәт булган. Менә китапта урын алган шундый әсәрләрнең берсе:

**Кыш китте, яз килде,**
**Үрдәк белән каз килде,**
**Былбылдан аваз килде,**
**Нәүрүз мөбәрәкбад.**

**Абзый, әшең уң булсын,**
**Телегәнең юш булсын,**
**Күңелләрең хуш булсын,**
**Нәүрәз мөбәрәкбад.**

XVIII гасырдан соң татарларда да яңа ел Юлиан календаре нигезендә декабрь ахырында каршы алына башлый. «Нардуган» дип йөртелгән әлеге бәйрәм көннәрендә авылларда «Нардуган» кичәләре уздырыла, ул кичәләрдә яшьләр төрле фал ачу, бәхет сынау, багучылык, юрау уеннары уйныйлар, җырлар җырлыйлар, бер-берсенә изге теләкләр телиләр. Мондый төр әсәрләр китапта аерым бер бүлекчәгә туплап бирелгән.

Мәҗүси ышанулар нигезендә барлыкка килгән әсәрләрнең бер өлешен келәүләр (теләкләр) алып тора. Алар гадәттә «Яңгыр боткасы», «Карга боткасы» һ. б. кебек йола ритуаллары өчен хезмәт иткән. Бу йолаларның төп функциясе җирдән муллык, күктән яңгыр, кояштан җылылык, табигатьтән мәрхәмәт сорауга кайтып кала. Заманалар узу белән, алар балалар репертуарына күчкәннәр һәм хәзер нәниләрнең күңел ачу такмаклары төсендә генә яшиләр. Китапта шул әсәрләрнең алты үрнәге китерелә.

Татар халкы яшәгән кайбер төбәкләрдә «Сөрән» дигән календарь йола бәйрәме билгеле. Ул апрель аенда, язны каршылау бәйрәме итеп уздырылган. Йоланың магик функциясе — йорт-куралы явыз рухлардан арындыру, үз-үзеңне гөнаһлардан чистарту. Моның өчен төрле ритуаллар (ут аша сикерү һ. б.) үткәрелгән. Бәйрәм кешеләрнең бер-берсенә кунакка йөрүе белән тәмам булган. Тора-бара бу йола сабантуйның бүләк җыю өлеше белән берләшеп киткән. Ул бигрәк тә Урал буе татарларында шактый тулы сакланып калган. Аларда сабантуй алдыннан бүләк җыюны «сөрән сугу» диләр, һәм бу йола ритуалы махсус җырлар башкару, йорт хуҗаларына теләкләр әйтү белән үрелеп бара. Пермь татарларыннан язып алынган һәм китапка кертелгән «сөрән җырларында», мәсәлән, мондый юллар бар:

**Ошбу ла йортның баскычлары**
**Барысы да бадъян агачы.**
**Ошбу ла йортның хуҗалары**
**Барысы да былбыл баласы.**

Китапның өченче бүлегендә туй йоласына караган әсәрләр туплап бирелгән. Туй этнографик яктан бик катлаулы йола һәм төрле төбәктә төрлечә уздырыла. Шуның өчен аның гомуми бер «сюжет сызыгы»н табу һәм шул вакытта кулланышка кергән поэтик әсәрләрне бер эзлеклелек белән төзү бик җиңел эш түгел. Әйтергә кирәк, И. Надиров бу бурычны уңышлы башкарып чыккан. Туй иҗатына караган бүлек «вучы

такмаклары» белән ачыла. Билгеле булганча, язучының мөгамәлә итүе еш кына шигъри форма алган. Мәсәлән, китапта китерелгәнчә, Ык буе татарларында яучы кызның ата-аналары белән сөйләшүне түбәндәгечә башлый торган булган:

> Ефәк баулы былбыл кош
> Бардыр синең илеңдә,
> Каеш баулы лачын кош
> Бардыр минем илемдә...

Китапта туй йоласы фольклорының төп өлешен кыз елату җырлары, сыктаулар алып тора. Алар, гадәттә, кызның үз өе белән, ата-анасы белән саубуллашуын, кияү өенә күченүе вакытында җырлана торган булган. Китапта кыз елату җырларының кырык өч үрнәге китерелә.

Туй вакытында башкарыла торган тагын бер төркем әсәрләр бар. Аларны «яр-яр җырлары» дип атау гамәлгә кергән. Ул җырлар да кызның үз өе белән саубуллашу вакытында башкарылган. «Яр-яр җырлары» эчтәлекләре белән «сыктаулардан» аерылып тора. Аларда кияү белән киленне мактау, теләк-киңәшләр өстенлек итә. «Яр-яр җырлары» әле безнең фольклор җыентыкларында беренче мәртәбә басылып чыга.

Туй мәҗлесе вакытында макташу, шаян эчтәлектәге җырлар җырлау — татар халкының борын-борыннан килгән күркәм гадәте. Ул бигрәк тә керәшен татарлары иҗатында нык чагылыш таба. Аларның мәҗлесе, мәгълүм булганча, кода-кодагыйларның, туган-тумачаларның кара-каршы җырлашулары тәсендә алып барыла. Китапның туй җырларына караган бүлегендә шулай ук әлеге ритуалга бәйле шигъри теләкләр — арбаулар да урын алган.

Татар халык уеннарының күпчелек өлеше төрле йолалар, сабантуй, җыен, аулак өй, кичке уен, өмәләр белән тыгыз мөнәсәбәттә тора. Шуңа күрә уен җырларын йола фольклоры белән бер төпләмдә тәкъдим итү бик урынлы.

Халкыбызның уеннарын һәм уен җырларын җыйнау һәм бастырып чыгару тәҗрибәсе бар инде. Татар халкының җырлы-биюле уеннары 1968 елда Х. Гатина тарафыннан аерым җыентык итеп чыгарылды (китапның фәнни редакторы һәм сүз башы язучы И. Надиров). Бу томга кергән җырның күбесе әнә шул җыентыктан алынган булып, аларга яңа чыганаклар һәм соңгы фольклор экспедециясе материаллары да өстәлгән. Китапның соңгы өлешендә бию такмаклары китерелә, «Искәрмәләр» бүлегендә исә җыентыкка тупланган материалларның чыганаклары, вариантлары, алар турында белешмәләр бирелә. Нәтиҗәдә томның фәнни кыйммәте тагын да күтәрелә.

Бу китап — халкыбызның йола һәм уен поэзиясен туплап, мәгълүм бер системага салып дөньяга чыгаруда беренче тәҗрибә. Шуның өчен җыентыкны төзүдә кайбер җитешсезлекләр булу беркадәр табигый хәл. Тулаем алганда, халык иҗатын филологик яктан тикшерүче галим тарафыннан әзерләнгән хезмәтнең нигезендә зур зәвык, фәнни осталык һәм тәҗрибә ята. Ләкин шунысы кызганыч, без анда урнаштырылган әсәрләрне бөтен барлыгы белән күз алдына китерә алмыйбыз. Билгеле булганча, йола һәм уеннар — халыкның синкретик (катнаш) сәнгате, аларның яшәешендә сәнгатьнең төрле төрләре — сүз, көй, бию, төрле хәрәкәт һәм гамәлләр катнаша. Без бу китапта шул катлаулы күренешнең бер ягын — башкарылу вакытында әйтелгән сүзләрне һәм кыскача гомуми тасвирламаларын күрәбез. Йола һәм уеннарны бөтен тулылыгы белән күрсәтү өчен музыкантлар, хореографлар, этнографларның катнашуы сорала. Фольклор әсәрләрен шулай әтрафлы тасвирламалар белән бастырып чыгару үрнәкләре совет фольклористикасында күренгәли башлады. Бездә дә моны гамәлгә кертер вакыт җиткәндер. Дөрес, искәрмәләр һәм аңлатмалар бүлегендә йола һәм уен җырларының көй үрнәкләре басылган музыкаль чыганаклар күрсәтеп барылган. Димәк, зарурият чыкканда шул чыганакларга мөрәҗәгать итәргә була.

Китап бер автор тарафыннан хәзерләнгән булса да, без аны бер коллектив хезмәт дип тә кабул итәбез. Чөнки аңа бик күп фольклор сөючеләр, гыйльми хезмәткәрләр, язучылар һәм студентлар тарафыннан язып алынган материаллар кергән. Материалларның шактый өлеше беренче мәртәбә басылган. Аларның иҗади географиясе гаять киң, җыентыкта татар халкының төрле төбәкләрдә яшәүче барлык этник төркемнәреннән язып алынган әсәрләр бар.

Татарстан китап нәшриятында зәвыклы, техник яктан камил итеп басылган бу китап фольклор сөючеләргә халкыбызның шигъри офыкларын киңрәк күрсәтә алырлык кыйммәтле чыганак булыр.

**РӘШИТ ЯГЪФӘРОВ.**

# КЕЧКЕНӘ РЕЦЕНЗИЯЛӘР

**Н. ДӘҮЛИ. МИН ҖИРДӘ КАЛАМ.** Шигырьләр, поэмалар. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1980.

Нәби Дәүли сугыш алды елларында әдәбиятка килсә дә, яшь каләмдәшләреннән һич тә калышмыйча, яшьләрчә өлгерлек белән иҗат итүче шагыйрьләрнең берсе. Күптән түгел авторның «Мин җирдә калам» исемле сайланма әсәрләре китап киштәләренә менде. Анда ике поэма, өч баллада, 200 гә якын шигырь һәм парча туплап бирелгән.

Шагыйрь бу сайланманы үзенең иҗатына бер йомгак рәвешендә, укучылар тарафыннан яратып кабул ителгән иң яхшы шигъри әсәрләреннән туплаган. Әсәрләр шагыйрьнең поэтик үзенчәлеген, аның иҗади һәм иҗтимагый позициясен тулы итеп күзалларга, кайбер гомумиләштерүләр ясарга мөмкинлек бирәләр.

Китапның бүленешеннән үк күренгәнчә, аның төп лейтмотивын хезмәт, табигать, кеше һәм аның тормыштагы урыны, яшәү мәгънәсе, гражданлык бурычлары, дуслык, иптәшлек, туганлык, яшьлек һәм мәхәббәт, гаилә һәм аның ныклыгы, киләчәк буын, җир һәм дөнья язмышы турында уйланулар билгели.

Китап шагыйрьнең иҗади кредосын билгеләүче шигъри кереш сүз белән ачылып китә. Анда автор үзенең туган җире белән мәңгегә бәйле булуын, аның язмышы, бүгенгесе һәм киләчәге өчен җаваплылык тоюын үтемле итеп күрсәтә, ачык итеп сурәтли. Бу фикер шагыйрьнең «Юл башы», «Мин җирдә калам» әсәрләрендә тагын да калку итеп үстерелә. Аларда җирсез-илсез, дус-тугансыз, сөю-мәхәббәтсез, янусыз, максатсыз, гүзәллек һәм бәхеттән мәхрүм булып, гаиләсез, ялгыз гына яшәү мөмкин түгеллеге исбатлана. Шагыйрь бүгенге чынбарлыкны ачык итеп күрә, тормыш хакыйкатен тирән итеп аңлый һәм аны шигырьләрендә дөрес итеп чагылдырырга омтыла. Ул иң матур шигырьләрен «Җир кешесе» Ленинга, аның «таң ягына таба юл салучы» акылына багышлый.

Ленинның юк җирдә үлгән
көне
Ленинның бар туган иртәсе,
Халыкларга барлык
гасырларда
Ленин белән юллар үтәсе,—

ди автор үзенең «Егерме беренче январь кичендә» исемле шигырендә. Шагыйрьнең кайнар публицистик рухлы, көр тавышлы, якты лирик моңлы үз ленинианасы бар.

Нәби Дәүли күп кенә шигырьләрендә акыл көченә ия булган җир улы, табигать баласы булып сөйли:

Мин ант итәм Җирнең улы
булып,
Хезмәтчесе булып калырга.
Кирәк чакта өскә шинель
киеп
Кулларыма кылыч алырга.

Шагыйрь галәм корабларына утырып җиһанны гизеп кайткан, җиде кат җир астына төшеп девон фонтаннары аттырган, салкын ташка җан өргән, басуларда мул уңыш үстергән фидакарьләргә мәдхия җырлый, кеше акылын зурлый. Шуның белән бергә шагыйрь «Син җир баласы», «Үстерденме чәчәк син үзең», «Табигатьнең зарын ишетсәң», «Аккош күле», «Кем ул явыз», «Каен ярасы» исемле шигырьләрендә табигать белән саксыз эш итүчеләрне, аның гармониясенә зыян китерүчеләрне бөтен җаны-тәне белән тәнкыйть итә.

Чәчәкләрне җирдән күп
өздең,
Үстерденме чәчәк син
үзең?! —

дип сорый ул замандашыннан.

Нәби Дәүли бала чагының бер өлешен ятимлектә, ир-егет чагының дүрт елын фашизм тоткынлыгында тел белән әйтеп бирә алмаслык рәхимсез җәбер-мәсхәрәдә, үлем белән яшәү арасында көрәшеп уздырган язмышлы шагыйрь. Шуңа күрә аның өчен туган ил, тынычлык, ирек, дуслар-туганнар һәм икмәктән кадерле бүтән бер нәрсә дә юк. Ул бөтен иҗатында ил, халык тормышы белән рухланып, аның якты омтылышлары белән канатланып, кайгылары, сагышларына борчылып, кешелек дөньясының язмышын кайгыртып яши.

Нәби Дәүлинең юмор-сатира жанрында да каләме үткен. Шагыйрь үзенең «КамАЗ машинасы кирәк миңа», «Мыштым», «Будильник сатып алдым», «Бер хәбәрсез югалдың», «Юл читендә», «Урындык һәм урын турында», «Әтәч турында тагын бер мәсәл» исемле әсәрләрендә җиңел юл белән көн күрергә теләүче әрәм тамакларны, хезмәт кешесенең ихтыяҗларына гамьсез генә караган бюрократларны, үз эшендә брак ясаучыларны, дуслык, иптәшлек мөнәсәбәтен оныткан, иптәшенә ышанычын югалткан, үз кабыгына бикләнеп яшәүче бәндәләрне утлы табада биетә, зәһәр ялкында көйдерә.

«Күзәтүләр — сүз әйтүләр» бәйләмендәге хикмәтле сүзләр, парчалар да игътибарга лаеклы. Алар бер уку белән хәтергә сеңеп калалар.

Әзһәр ГАБИДИ

**Х. МӘХМҮТОВ. КЕЧКЕНӘ ДӘ ТӨШ КЕНӘ.** Казан. Татарстан китап нәшрияты. 1980.

Соңгы унбиш-егерме ел эчендә халкыбызның поэтик иҗатын өйрәнүдә зур җанлылык сизелә. Н. Исәнбәт, Х. Ярми, И. Надиров, Ф. Урманчеев һәм башка тикшеренүчеләрнең төрле жанрларны өйрәнүгә багышланган фәнни хезмәтләре аерым җыентыклар булып басылды. Шулар арасына филология фәннәре кандидаты Хуҗиәхмәт Мәхмүтовның «Кечкенә дә төш кенә» исемле хезмәте өстәлде. Бу китап халык арасында иң киң таралган жанрларның берсе—табышмакларны өйрәнүгә багышланган.

Табышмакларыбызның кайбер үрнәкләре борынгы язма чыганакларда ук сакланып калган. Мәсәлән, XIV гасырда төзелгән «Кодекус куманикус»та («Коман мәҗмугасы»нда) иллегә якын табышмак китерелә. Х. Мәхмүтов гомумтөрки хәзинәгә кергән әлеге табышмакларга җентекле күзәтү ясап, аларның эчтәлекләрен, художество-тел үзенчәлеген хәзерге заман табышмаклары белән чагыштыра һәм кызыклы нәтиҗәләр чыгара. Җентекләбрәк караганда, моннан җиде гасыр элек теркәлеп калган табышмаклар хәзер халык телендә йөрүчеләреннән эчтәлеге белән дә, образлары һәм композициясе белән дә әллә ни аерылмый икән. Мәсәлән, сүзлектә китерелгән «Язда йаңи килен йугунадыр» дигән табышмак бүген: «Су буенда яшь килен сырлана (камыш)» формасында йөри. Х. Мәхмүтов шундый параллельләр аша, бу жанрның озын гомерле булуын, күп гасырлар буена традицион формасын һәм эчтәлеген саклап килүен исбат итә.

Китапта XIX гасырда һәм XX йөз башында табышмакларны җыю, бастырып чыгару һәм өйрәнү тарихы тәфсилле яктыртыла. М. Иванов, М. Салихов, Т. Яхин, К. Насыйри, Г. Арсланов, Х. Бәдигый, Н. Исәнбәт, Х. Ярми һ. б. ларның бу өлкәдәге эшчәнлеге бәяләнә.

Хезмәтнең бер бүлеген автор «Табышмак үткән юл» дип атаган. Ул бүлек табышмакларның барлыкка килүе, аларның тормыш-көнкүрештәге роле һәм жанрның хәзерге көндәге язмышын ачыклауга багышлана.

Фольклор жанрларының барлыкка килү һәм үсеш баскычларын билгеләү — катлаулы фәнни проблемаларның берсе. Х. Мәхмүтов бу өлкәдә Д. К. Зеленин, И. М. Колесницкая, В. П. Аникин кебек күренекле совет фольклорчыларының фикерләренә, тарих һәм халык иҗаты материалларына таянып, табышмак жанрының генетик чыганакларын билгели.

Галимнәр табышмакларның килеп чыгуын борынгы «яшерен тел», «тыелган сүзләр» белән бәйлиләр. Билгеле ки, борынгы кеше әйләнә-тирәсендәге нәрсәләрне җанлы итеп күз алдына китергән, киек-җәнлекләрдә кеше сөйләшен аңлау, ерактан ишетү сәләте бар дип ышанган. Шуның өчен кәсеп итү, ау урынында сүз барганда кешеләр «алар аңламый торган», «яшерен» сүзләр кулланганнар. Шул җирлектә борынгылар телендә аерым «яшерен сүзләр» репертуары барлыкка килгән. Табышмак жанрының генетик тамырлары шул борынгы яшерен телгә барып тоташуын фольклорчы күп мисаллар белән дәлилли.

Халык репертуарында акыл сынашу, күңел ачу функциясен үтәүче аерым бер эстетик жанр булып формалашканчы табышмак озын юл үткән. Борынгы чорларда ул яшьләрне әлеге яшерен телгә өйрәтү чарасы булып та хезмәт иткән, ягъни башлыча педагогик максатларны да күз алдында тоткан. Табышмак әйтешү аерым йолаларга да кергән. Табышмакны борынгы кешеләр аерым бер тылсым көченә ия дип белгәннәр. Х. Мәхмүтов бу фикерне дәлилләү өчен халкыбызның этнографиясенә мөрәҗәгать итә. Иҗтимагый-тарихи үсеш нәтиҗәсендә, табышмакларны тылсым көче итеп карау югалган. Нәтиҗәдә, алар күңел ачу, зиһен сынашу чарасы булып йөри башлаганнар.

Массалар тарафыннан гасырлар буе иҗат ителгән әсәрләр буларак, табышмаклар халыкның тормыш-көнкүрешен, аның тормышка карашын ачык чагылдыралар. Аларда халкыбызның үткән замандагы тормыш-көнкүреше, материаль һәм социаль хәле, кәсеп итү кораллары, әйләнә-тирәлеккә, җәмгыятькә, табигатькә карашлары ачык чагылыш таба. Хезмәтнең аерым бүлекләре әнә шул мәсьәләләрне яктыртуга һәм табышмакларның поэтик төзелешен өйрәнүгә багышланган.

Гомумән, Х. Мәхмүтовның бу китабы, татар халык иҗаты турындагы мәгълүматларыбызны тагын да киңәйтүче, бай эчтәлекле, аңлаешлы тел белән язылган фәнни хезмәт буларак, киң катлау укучыларның игътибарын җәлеп итәр дип ышанырга кирәк.

**Я. РӘШИТОВ.**

**Ф. ГЫЯЗЗЭТУЛЛИНА. СӘЛАМ ХАТЫ.** Шигырьләр. Казан. Татарстан китап нәшрияты, 1981.

Бүгенге укучының әдәбият яңалыклары белән танышу, әдәби продукцияне таләпчәнлек белән сайлап алу мөмкинлекләре зур. Ул үзе өчен яңа исемнәр ача, аларны күзәтеп бара, саф чиста авазларын ишетеп, сөенеп куя. Флера Гыйззәтуллинаның да яңа шигырьләр җыентыгы укучыларга әнә шундый куанычлы мизгелләр бүләк итә. Гади тел белән, тормышның гадәти генә хәлләре турында язылган, тыйнак, җыйнак шигъри юллар... Гомер буе куллары хезмәттән бушамаган, иң авыр эштән дә күңеленә ямь табып яшәп белгән шагыйрә генә яза аладыр бу юлларны:

Җир астыннан безнең
  күз нурлары
Җир өстенә күчте күмердә!
Ник төштем дә,
  ник көч түктем диеп,
Юк, үкенмәм гомер-гомергә!

Шагыйрәнең ил алдында, халкы алдында намусы ак. Шигъри кыйбласына ул үзе күмер чыгарган Донбасс шахталары, Себердә төзегән тимер юллары, кешеләргә эшләгән яхшылыклары аша килә. Шуңа күрә дә аның тавышы ышанычлы, әйтер сүзе тормышның үзеннән. Бу шигырьләр хезмәт кешесенә, замандашларыбызга дан җырлый һәм шул ук вакытта аларда җир язмышы, илләр язмышы өчен зур борчылу да бар.

Сабый булып туган
  кешелегем
Җиргә басып буын
  ныгыткач,
Җирдә мәхшәр барын,
Яшәү барын,
Күктә кояш барын онытмас.

Әйе, онытмаска тиеш. Ләкин җир йөзендә әле аналардан һәм шагыйрьләрдән тыш, туп коючылар, бомба ясаучылар да бар! Әнә шуңа күрә дә шагыйрә күңеле һәрвакыт уяу, бу турыда язганда аның тавышы тагы да җитдиләнә, кырысланa, үз-үзенә һәм башкаларга таләпчәнлеге арта төшә.

Гомумән, фикер тирәнлегенә омтылу Ф. Гыйззәтуллинаның күпчелек шигырьләренә хас. Аларда ясалма ялтырау, төчеләнү, кыланy һәм зарлану, язмышка үпкә тоту юк. Аның лирик герое да туры һәм ихлас, ярата икән — саф сөю белән ярата... Хыянәткә, өметсезлеккә, бәхетсезлеккә урын юк бу шигырьләрдә!

Тормыш—сөю-сагадәт белән шатлыклы, өметләре белән ләззәтле. Югыйсә, соңгы елларда лирик геройларыбыз аерылулар, җавапсыз мәхәббәтләр белән нык кына саташа башладылар, «саргаю-газаплану-лар» лирикасы басып китте кебек. Ә бит дөньяда зур сөю белән кавышып, гомерләренең ахырына кадәр бер-берсе өчен янып яшәүче парлар бар. Ф. Гыйззәтуллина әнә шундый гомерлек яр була алган, олы җанлы, саф күңелле кешеләрне күздә тоткандыр. Шуңа күрә дә, ул шигырьләрдәге сафлык, эчкерсезлек, ышаныч һәм якты нур булып, безнең күңелләргә дә үтеп керә.

Шагыйрә иҗаты өчен сөенерлек хисләр калдырган шигырьләр хакында кыскача гына булса да әйтеп үттек. Ләкин әле бу — шагыйрә инде ирешәсе үңышларга ирешкән, яулыйсы үрләрне яулаган дигән сүз түгел. Флера Гыйззәтуллина иҗатында борчылып телгә алырлык күренешләр дә бар әле. Иң күзгә ташланганы— җыентыкка кергән шигырьләрнең күбесе авторның үз исеменнән, үз «мин»еннән чыгып сөйләнә. Автор кайчагында үз шәхси дөньясына шулкадәр кереп чума ки, киң катлау укучылар өчен әлеге шигырьләрнең әһәмияте, кыйммәте аңлашылмый башлый. «Куркыныч үлемгә бирелү, күмелү, кушылу чиркангыч агымга... Кан коелып бетсә дә, җан тынмый икән лә якының янында булганда»,— кебек юллар җыентыкны бизи дип әйтеп булмый. Артык шәхси, авторның үзенә генә аңлашыла торган сүзтезмәләр һәм хисләр. Бәлки бу — тормыштан поэзия табып бетерә алмауның бер үрнәгедер?..

Шигырь-багышлауларның күбәеп китүе дә һаман шул бер тирәдә әйләнү баласе. Моңа мисал итеп «Ландыш карлар», «Толымыңны нигә бердән үрдең», «Дәү кызым, дәү гөлем», «Балам баласы», «Йолдызлы юл», «Ник дәшмисең, судья?!» кебек шигырьләрне китерергә була. Шул рәвешле, бер шигырьдән икенчесенә артык шәхси мотивлар, кичерешләр күчә башлый. Җыентыкның ахырына урнаштырылган «Кайттым бала чагыма» поэмасы да әлеге төр шигырьләрнең киңәйтелгән варианты кебегрәк тәэсир калдыра... Кыскасы, бу хәл гел бер урында, узганнарда гына таптануга әверелә күрмәсен иде.

Шагыйрәнең икенче җыентыгы дөнья күрде. Алда әле күпме язылася шигырьләр, әйтеләсе фикерләр һәм иҗат газаплары... Кайчандыр, курыкмыйча Донбасс шахталарына төшкән кебек, йөрәк җимеше — шигырьләрен дә әнә шул тирәнлектән эзләп табып, кешеләр күңелен җылыта алырлык дәрәҗәгә күтәрү... Иҗат дөньясында да «Ник көч түктем!?» дип үкенмәслек итеп яшисе иде!

**Фәүзия БӘЙРӘМОВА.**

# СЕБЕР ТАТАРЛАРЫ ӘКИЯТЛӘРЕ

*Бөек Ватан сугышына кадәр, 1940 елда, Новосибирск якларында, Бараба далаларында, Омскида, гүзәл Иртыш елгасы буйларында, Тобол һәм Төмән шәһәрләрендә Х. Ярми, С. Әмирев, В. Хаҗиев иптәшләр белән фольклор экспедициясендә катнашып, анда фонографка язып алынган җырларның шактый өлешен мин «Казан утлары» журналында (1964, 1978 елларда) бастырып чыгарган идем инде. Ләкин мин бу экспедициядә, әкият сөйләүче талантлы өлкән кешеләрне төннәр буе утырып тыңлый-тыңлый, күп кенә әкиятләр дә язып алган идем. Башта күбрәк җыр, шигырь белән шөгыльләнеп аларга кул тимәде. Әбер тотынгач аерыла алмадым. Халыкның таланты, осталыгы, нечкә хисе, фантазиясе, якты матур киләчәккә ышанычы чагылган бу әкиятләрне яңадан укып, карап, эшләп чистага күчереп чыктым. Алар халкыбызның иҗат фантазиясенә яңа байлык булып өстәлер дип ышанам.*

*МӨХӘММӘТ САДРИ.*

## Арпалып батыр

Борын-борын заманда, карындык япкан бер тәрәзәле кечкенә генә өйдә, карт белән карчык яшәгән. Аларның улҗары да, кызлары да булмаган, картайган көннәрендә ярдәм итәрлек бер кешеләре дә калмаган. Үзләре алтмыш яшькә җиткәннәр. Ашарга азыклары беткәч, ни эшләргә белмәгән карчык үзенең картына:

— И картым, ник ятып куйдың? Ашарга азыгыбыз юк бит, — дигән.

Карт, яткан җиреннән торып, кулына капчык учлаган да азык эзләргә чыгып киткән. Барган ди бу, барган ди, бер уңга караган, бер сулга караган. Бара торгач, күзе бер көлтәгә төшкән. Күтәреп караса, авыр гына арпа көлтәсе икән. Көлтәне күтәреп өенә кайткан. Карчыгы да бик сөенгән.

— Юкка гына чыкмыйча яткансың, чыккач эзләп тапкансың, — дигән.

Икәүләшеп эшкә керешкәннәр. Көлтәне агач белән тукмап, арпасын изеп, мичтә катырып ашаганнар. Карт белән карчыкның кәефе килгән, аларга хәл кергән, күңелләре күтәрелеп яшь чакларын искә төшергәннәр һәм татлы йокыга талганнар.

Иртә белән уянып китсәләр, боларның уртасында бер бала көлеп ята икән. Карт белән карчык сөенешкәннәр:

— Менә хикмәт, үскәч ярдәм итәрлек оланыбыз булды, — дигәннәр.

Ә олан, болар уянгач, күзгә күренеп үсә башлаган. Күп тә үтмәгән, ул сикереп торган, тәрәзәне әйбәтләп томалаган, утын алып кергән дә:

— Әни, менә утын, менә чыралык, мичкә ягып җибәр! — дип, урамга чыгып киткән.

— Олан безнең бәхеткә күзгә күренеп үсә, аны кем дип атыйк, — дигән карчык.

— И, карчыгым, бу арпа алып кайтып ашагач туган олан, исемен Арпалып дип кушыйк! — дигән карт.

Болар чыннан да яшәреп киткәндәй булганнар. Карчык мичкә ягып җибәргән, өйгә ямь кергәндәй булган, ә олан урамда берәр-икешәр потлы ташларны чөеп уйнаган да өйгә кергән һәм:

— Әни, ашыйсым килде, нәрсә пешерәсең? — дип сораган.

— И, улым, без бик фәкыйрь кешеләр, кичә атаң арпа көлтәсе табып кайткан иде, көлтә сукканнан калганны мичтә катырып пешерәм. Күрше авылда бик зур бай

бар, аның өендә көн дә коймак, көн дә кунак, безгә майга койган коймак ашарга насыйп булмаган күрәсең,— дигән.

Олан, әнисе сүзен тыңлаган да күрше авыл баена киткән. Өенә сәлам биреп кергәч, бай аңардан:

— Син кем малае, ни йомыш? — дип сораган.

— Мин Арпалып, күрше авылның Юнан улы, безгә берничә ашлык он белән май биреп торыгыз, бишләтә түләрбез, — дигән.

Бай моны мыскыллап көлгән дә:

— Вак-төяк өчен капчык чишмибез, он әнә биш потлы капчыкта, ярты мичкә май белән икесен берьюлы күтәреп китә алсаң, буш бирәм, — дигән.

Арпалып, бай сүзен раслатыр өчен шаһитлар чакырткан. Алар җыелышкан арада ул тагын да үсә төшкән, көче шактый арткан. Халык алдында да бай моннан көлгән. Бәхәсләшкәннәр. Шуннан олан биш потлы капчык онны уң җилкәсенә, ярты мичкә майны сул җилкәсенә салып чыккан да киткән. Бер дә туктамыйча өйләренә кайтып:

— Әни! Он белән май алып кайттым, коймак кой, — дигән.

Арпалып ае-көне белән үсеп, тугыз яшенә җиткән егет булган. Күп тә үтмәгән, әтисе белән әнисенә:

— Мин көчемне сынап карарга өйдән китәм, — дигән.

— Юк, балам, безне синсез кем асрар, кем карар, безне калдырып китмә, — дигәннәр картлар.

— Ярар, алайса бераз торам, кирәк кадәр ризык әзерлим, — дигән ул һәм тагын өч ел өйдә торган. Аннары әтисе белән әнисеннән рөхсәт сорап, көчен сынарга чыгып киткән.

Мәскәүдәме, Түмәндәме, анысын кем дә күрмәгән, бер батыр бар икән. Ул, Арпалып дигән батыр тууын ишетеп Көнчыгышка таба килә икән. Ә Арпалып көн кунышы тарафына карап сәфәр чыккан.

Бара торгач, Арпалып бер зур тирәк күреп алган. Көн җилсез булган, шулай да тирәкнең башы бер җиргә тия, бер күтәрелә икән.

Тирәк төбендә бер батыр ята булса кирәк, хәерле булсын, барып карыйм әле, дигән Арпалып.

Тирәк янына килсә, чынлап та бер батыр йоклап ята икән.

Әллә сугып үтеримме, дигән уй килгән аның башына, аннары: юк, егетлек булмас, уятырга кирәк, дигән.

Арпалып аны уятып:

— Син кем, барышыңмы, кайтышыңмы, барсаң кая барасың? — дип сораган.

— Минем исемем Тирәкалып, Арпалып исемле батыр туган икән, аның белән көч сынашырга барам, — дип җавап биргән ул.

— Син аны эзләп барма, мин Арпалыпның энесе булам, көчеңне сынарга теләсәң, башта минем белән сынап кара, кул — сугышыр өчен, көч — көрәшер өчен, сугышыйкмы, көрәшикме? — дигән Арпалып.

— Көрәшик, — дигән Тирәкалып.

Көрәшә башлагач та Арпалып тегене күтәреп бәргән... Тирәкалып көчкә торып, Арпалыпның биленә тотынып хәл алган да:

— Юкка Арпалыпны эзләп чыкканмын, энесе дә тотып бәрде, үзенә барсаң сугып үтерер, — дип, куркуга төшкән Тирәкалып, — Арпалыпны эзләмим, әйдә дуслашыйк! — дигән.

Алар дуслашканнар да Арпалып юлы белән көн кунышка таба киткәннәр. Көн үткәннәр, ай үткәннәр, зур күлләрне, елгаларны берәр генә атлап кичкәннәр. Ахырысында, бер юл чатына җиткәч карасалар, бер батыр үзеннән зур ташларны чөеп уйнап утыра икән.

— Син кем, исемең ничек, кая барасың? — дип сораганнар аннан бу батырның.

Ә ул бер зур гына ташны алып чөеп җибәргән дә:

— Исемем Ташалып, Арпалып дигән батыр туган имеш, аның белән көч сынашырга барам, — дигән.

— Син аны эзләп йөрмә, без өч туган, мин — Арпалыпның энесе, ә бу — минем энем. Син көчеңне иң әлек энем белән сынашып кара, — дигән Арпалып.

Болар көрәшә башлаганнар. Ташалыпны Тирәкалып шунда ук күтәреп аткан. Ташалып бераз хәл җыеп торып баскан да:

— Арпалыпны эзләп юкка юлга чыкканмын, кече энеләре дә җинде, ә үзенә бар-сам сугып үтерер, — дип курыккан Ташалып егетләргә. — Барып йөрмим, әйдә дуслашыйк! — дигән.

Алар дуслашканнар да Арпалып барган юлдан көн кунышка таба киткәннәр. Көн үткәннәр, ай үткәннәр, зур күлләрне, елгаларны берәр генә атлап кичкәннәр. Ахырысында бер каен урманы буена җиткәннәр. Каен урманына керергә юл булмаган.

— Бу урманда берәр баһадир булса кирәк, кешеләр урманга аннан куркып кермәгәннәрдер, юлы-сукмагы юк, әйдә, без үтеп керик әле,— дигән Арпалып.

Урман эченә кереп бара торгач, алар зур гына бер өй янына чыкканнар. Өйнең бүлмәләрендә кем дә булмаган, ә ашханәсендә олы казан ит пешеп утыра икән.

Арпалып уйлап-уйлап торган да Ташалыпка:

— Тирәкалып белән без өйдән читкәрәк китеп качып торабыз, ә син кал, өйнең иясе кайтып керсә — үтер! — дип әйткән.

Ташалып өйгә кереп яткан. Кич җитә башлагач, көчле җил-давыл чыккан, каеннар башларын җиргә ия-ия шаулашканнар, җил-давыл шавына ат кешнәве кушылган. Ташалып, урыныннан торып тәрәзәдән караган икән, күк атка атланган берәүнең туктаганын күргән. Үзенең буе аршын чамасы гына, ә сакалы кырык аршын икән. Сакалын биленә урап куйган. Өй янына туктагач ул:

— Әй, минем өйдә кем бар? Мине чыгып ал — дигән.

Ташалып аның каршысына чыккан икән, ул тагын да кайрат кырып[1]:

— Атымнан күтәреп төшер! — дип кычкырган.

— Төшәсең килсә, үз атыңнан үзең дә төшәрсең, — дип җавап биргән Ташалып.

— Әгәр үзем төшсәм, ачуымнан мин сине кабып йотам! — дигән җен карты.

Ташалып куркып аның янына барган, күтәреп төшермәкче икән, күтәрә алмаган. Ташалып булышлыгы белән ул атыннан төшкән дә өенә кереп түр башына утырган һәм тагын:

— Итле казанны күтәреп минем яныма китереп куй! — дип боерган.

Ташалып тыңламаган:

— Кирәк булса, үзең дә алып чыгарсың, — дигән.

Шул җавапны ишеткәч, җен карты сикереп торып егетнең бугазына ябышкан, аннары күтәреп алып идәнгә сыдырткан... Ташалып куркуыннан ни әйтергә белмәгән, кырык чиләк итле казанны моның алдына китереп утыртырга мәҗбүр булган. Җен картының буе бер аршын гына булса да казандагы итнең һәммәсен ашап бетергән.

— Шушы казанга әнә тегендәге итне тагын тутырып пешер, мин ятып йоклыйм, иртән шул итне ашагач ауга чыгам, — дигән ул Ташалыпка тагын эш кушып.

Иртә белән карт төнлә пешеп торган итне ашап бетергән дә:

— Атны өй янына алып кил, — дигән.

Атын алып килеп, егет аны чак-чак кына күтәреп утырткан. Атының биле машая машая[2] киткән.

Ташалып иптәшләрен чакырган. Аның янына килгәннән соң иптәшләре:

— Нигә үтермәдең? — дип сорагач:

— Сакалы бер генә аршын булса да, көче ул җеннең сакалындадыр, мине күтәреп алып сыдыртты, бик кайрат икән, көчем җитмәде, — дип җавап биргән.

Тегенең итеннән аш пешереп бергәләп тамак туйдыргач, Арпалып:

— Хәзер өйдә Тирәкалып калсын, инде без Ташалып белән читкәрәк китеп качып торабыз, — дигән һәм, — син бер нәрсәгә дә карама, сакалыннан учлап тот та күтәреп бәр, — дип өстәгән.

Тирәкалып өйдә калган. Кич җитә башлагач, көчле җил-давыл чыккан, каеннар башларын җиргә ия-ия шаулашканнар. Җил-давыл шавына ат кешнәгән тавыш кушылган. Тирәкалып тәрәзәдән караган икән, күк атка атланган берәүнең туктаганын күргән. Үзе бер карыш икән. Кырык карышлы сакалын биленә урап куйган.

— Һәй, мин моны сул кулым белән генә дә сугып үтерәм, — дигән егет аны күзәтеп.

[1] Гайрәтләнеп.
[2] Сыгыла-сыгыла.

Җен карты үз өендә кемнендер барлыгын сизеп:
— Әй, минем өемдә кем бар? Мине чыгып ал! — дип кычкырган.
— Кирәк булса, үзең дә керерсең! — дигән егет.
Ул тагын кычкырган. Тирәкалып чыкмаган.
Атыннан сикереп төшкән дә, карт, өенә кереп, түр башына менеп утырган.
— Әй, адәм заты, мине нигә чыгып алмадың? Итле казанны күтәреп минем алдыма китереп куй! — дигән.
Тирәкалып тыңламаган. Карт сикереп торып моның бугазына ябышкан. Егет куркып, итле казанны алдына китереп утырткан. Теге казандагы итне берүзе ашап бетергән дә:
— Шушы казанга янә тегендәге итне салып пешереп куй, мин ятып йоклыйм, иртә белән ауга китәм, — дигән.
Җен карты иртә белән торып төнлә пешкән итне ашап бетергән дә:
— Атны өй янына алып килеп мине күтәреп утырт! — дигән.
Картны озаткач, Тирәкалып иптәшләрен чакырган. Иптәшләренә җен картын нигә үтермәве сәбәбен сөйләп биргәч Тирәкалып:
— Инде икебездән дә һич нәрсә чыкмады, Арпалып, эш синең үзеңә калды, — дигән.
Өченче көнне өйдә Арпалып үзе калган. Кич җитә башлагач, көчле җил-давыл чыккан, каеннар җиргә кадәр сыгылганнар, давыл һәм каеннар шавына ат кешнәве кушылган. Үзе бер аршын, сакалы кырык аршынлы җен карты кайтып өе янына туктаган да:
— Әй, минем өемдә нинди адәм заты бар? Чык та мине атымнан күтәреп төшер! — дип кычкырган.
Арпалып аңар:
— Кычкырма, кендегең сүтелер, үз атыңнан үзең дә әйбәт кенә төшәрсең әле, — дип җавап биргән.
Ул гайрәтләнеп атыннан төшкән, түсен бозып, ачуланып өенә кергән дә түр башына менеп утырган. Ә Арпалып елмаеп кына кырын ята икән.
— Нигә ятасың? Шул пешкән итне казаны белән минем алдыма китереп куй! — дип боерган ул.
— Казандагы ит синә түгел, ул безгә пеште, аны без ашыйбыз, — дигән Арпалып.
Шул сүзләрне ишеткән карт, зәһәрләнеп батырның бугазына килеп ябышкан. Арпалып тиз генә торып, аны сакалыннан тотып алган да идәнгә китереп бәргән. Аннары, тышка алып чыккан, сакалы белән карт каенга бәйләп, асып куйган да иптәшләрен чакырып алган.
— Я, ни булды? — дип сораганнар алар.
— Шушы казандагы итне өчебез бергә ашыйк та ятып йоклыйк. Иртә белән мин сезгә бер ирмәк[1] күрсәтәм, — дигән егет.
Йокыдан торгач, Арпалып үзенең иптәшләренә:
— Мин аны сакалы белән бәйләп карт каенга асып куйдым, әйдә күрсәтәм, — дип тышка чыксалар, карттан җилләр искән икән, каенны тамырлары белән сөйрәп алып киткән.
— Хәзер безгә аны каен тамырлары җирне тырнап киткән эзләрдән барып табарга кирәк, — дигән Арпалып.
Җен карты каенны йөз сиксән чакрым өстерәп барган да, биек тау итәгендә сакалын өзеп калдырып юк булган. Нык бәйләнгән сакалын каеннан ала алмаган. Болар каен янында гына җир астына төшеп киткән бер юл тапканнар.
— Инде ни эшлибез, бу чокырга кайсыгыз төшә? Әгәр төшеп үтермәсәк, ул безгә көн күрсәтмәс, — дигән Арпалып.
— Бу эш безнең хәлдән килмәс, без булдыра алмабыз, үзең генә төшеп үтереп мен, — дигәннәр Ташалып белән Тирәкалып.
— Чокырның тирәнлеге йөз егерме аршыннан артык булмас, сакалны каеннан алыйк та өчкә бүлеп бәйлик, йөз егерме аршынга озынаер, — дигән Арпалып.

[1] Кызык.

Сакалны каеннан чишеп алганнар да аның очына утырып төшәрлек такта сыман агач бәйләгәннәр.

— Сез төшмәскә булгач, ни эшләмәк кирәк, үзем төшәм. Ләкин, иптәшләр, бер-беребезгә золымлык эшләмик, турылыклы булыйк,— дигән Арпалып, җир астындагы чокырга төшеп киткән.

Тирән, караңгы чокырда эзләнә-кармалана торгач аның кулы бер ишек тоткасына тигән. Ул бакыр тотка икән. Егет шул тотканы тарткач, ишек ачылып киткән һәм анда утырган бер кызны күреп алган.

— Ай, абый, син монда кайдан килдең? Әти сизсә, үзенне бер генә кабып йотар,— дигән бу кыз.

Арпалып кыз янына якынрак килеп:

— Әтиең кайда, әйт, мин аны үтерергә төштем, синең исемең ничек? — дип сораган.

— Минем исемем Бакырбикә, әтиемнең кайда икәнен белмим, минем Көмешбикә исемле апам бар, кайда икәнен ул беләдер, аннан сорап карарга кирәк,— дигән кызый.

Егет, Бакырбикә яныннан чыгып көмеш тотка тапкан. Көмеш тоткалы ишекне ачып керсә, Көмешбикә көмеш кебек ялтырап утыра икән.

— Ай, абый, син монда ничек килеп кердең, әтием сизсә, үзеңне бер генә кабып йотар, — дигән Көмешбикә.

Егет кыз янына якын килеп:

— Әтиең кайда, әйт, мин аны үтерергә килдем, — дигән.

— Минем Алтынбикә исемле апам бар, әтинең кайда икәнен ул белә, — дигән Көмешбикә.

Арпалып алтын тотканы табып алтын өйгә кергән. Алтынбикә алтын өйдә алтын кебек ялтырап утыра икән.

— Абый, син монда ничек керә алдың? Әти сизсә, үзеңне бер генә кабып йотар, сак бул! — дигән ул.

Егет аның янына якын килеп:

— Әтиең кайда, әйт, мин аны үтерергә килдем, — дигән.

— Атамны тиз генә таба алмассың, — дигән Алтынбикә курка-курка гына батыр егетнең йөзенә карап.— Әйтсәм әйтим, моннан чыккач бер ишек тоткасы бар, шуны табып ачып кергәч, мунчага килеп чыгарсың. Мунчаның вабулаты[1] астын бер аршын казыгач, кәнтәр[2] оясы булыр. Шул ояда кәнтәр ике йомырка басып утыра. Йомырканың берсен кулыңа алып сытсаң, әтинең хушы китәр, икенчесен сытсаң — җаны чыгар, — дип сөйләп биргән ул.

Алтынбикә сүзләрен Арпалып игътибар белән тыңлап чыгып киткән. Мунча ишеген табып ләүкә астын бер аршын казыгач, аннан кәнтәр очып чыгып киткән. Кәнтәр бөтенләй очып китмәгән, ул картның җаны булган икән. Мунча мичена менеп утырган. Ике йомыркасы оясында калган. Бер йомырканы учына алып сыткан икән, кәнтәр булып утырган җен үз төсенә кереп, йомарланып идәнгә килеп төшкән. Икенче йомырканы алып сыткач, җеннең җаны чыккан.

Арпалып, карт гәүдәсен аягы белән читкәрәк авыштырган да Алтынбикә янына кергән һәм аңар:

— Әйдә, җыен, атаң үлде, — дигән.

Алтынбикә сары яулыкка алтын өен җыеп, төйнәп алган. Яшереп куйган алтын саплы кылычын чыгарып Арпалыпка биргән.

Инде алар икәүләшеп Көмешбикә янына кергәннәр.

Көмешбикә ак яулыкка көмеш өен җыеп, төйнәп алган.

Аннары өчәүләп Бакырбикә янына кергәннәр.

— Әйдә, җыен, әтиеңне үтердем, — дигән егет.

Бакырбикә кызыл яулыкка бакыр өен җыеп, төйнәп алган.

Өстән яктылык беленеп торган караңгылыкка чыккач Арпалып:

---

[1] Ләүкәсе.
[2] Күгәрчен.

— Без арканга тотынып яктыга, югары менәргә тиеш, — дигән.

— Юк әле, башта без түгел, хәзинәбез чыгарга тиеш, безнең кырык чиләк алтыныбыз бар, — дигән Алтынбикә.

— Сезнеңчә булсын, алайса элек алтынны чыгарыйк, — дигән егет.

Очына бер чиләк сыман нәрсә бәйләп, аңар алтынны салып, арканны кыймылдатканнар. Тирәкалып белән Ташалып аны тартып алганнар икән, Арпалып урынына алтын чыккач бик шатланганнар. Арканны янә төшергәннәр, янә алтын чыккан. Берсе арты берсе кырык чиләк алтын бушаткач боларның күзләре ут булган.

— Арпалып менгәч бу алтыннарны безгә бирмәс, янадан күтәреп карыйк, бәлки, тагын алтын чыгар, Арпалып булса, арканны өзеп аны төшереп җибәрербез, — дип киңәш иткәннәр болар.

Тагын күтәреп карасалар, Бакырбикә килеп чыккан. Егетләр тагын да шатланганнар. Чиләкне төшергәннәр икән, көмеш кебек ялтырап Көмешбикә килеп чыккан.

Чиләкне кабат төшергәч, алтын кебек ялтырап, Алтынбикә килеп чыккан.

Олы кыз бик акыллы булган. Егетләргә ул:

— Безнең хәзинәбез бетмәде, калганын алырга кирәк, — дип чиләкне янадан төшерткән.

Чиләкне тартып менгергәндә, болар хәзинә урынына Арпалып менгәнен күргәч, арканны өзгәннәр. Батыр егет мәтәлә-мәтәлә зиндан төбенә төшеп киткән.

Арпалып ни эшләргә белмичә караңгы зинданда берничә көн-төн үткәргән. Инде үләр хәлгә җиткәч, тагын эзләнеп, капшанып караган икән, кулы бер тоткага тигән. Ул ишек тоткасы икән. Шул ишекне тартып ачып җибәргән дә яңа, якты бер дөньяга килеп чыккан.

— Гомерем бетмәгән икән, — дип уйланып алдына караса, алдында бер юл бар икән. Шул юл белән акрын гына атлап киткән. Юлда алмаз кылычы белән каенны тишеп каен суын эчкән. Бара-бара бер елга буена килеп чыккан. Елга аша каен агачыннан күпер салынган һәм шул күпергә җитәрәк, башка агачларга караганда ике мәртәбә биегрәк тирәк үсеп утыра икән. Шул тирәк башында зур гына сәмруг кош[1] оя корган — ул ике баласын калдырып азык эзләргә киткән. Арпалып, шушы тирәк белән күпер янына җитәрәк, көн кунышы ягыннан калын кара болыт килүен күргән. Җил-давыл чыккан. Ут шикелле ялтырап, яшен яшьнәп, күк күкрәп боз явып кила башлаган. Егет, сәмруг кошның балаларын бик кызганган. Агач башына менгән дә өс киемен салып, кош балаларының өстенә япкан, үзе ялангач калып, күпер астына төшеп ышыкланып торган. Җил-давыл белән килгән кара болыт бозлары хәтта күперне тишкәләп үткәннәр. Сәмруг кош, явым узып киткәч балалары янына очып төшкән һәм:

— Сезнең өстегездә нинди адәм зат киеме, аны сезгә кем япты? — дип сораган.

Кош балалары телгә килеп:

— Әни, үз киемен безгә япкан кеше күпер астында ялангач ышыкланып тора, аны ашый күрмә, ул безгә зур яхшылык эшләде, киемен өстебезгә япмаса, боз яуганда без һәлак булыр идек, — дигәннәр.

Балалары сүзен тыңлаган сәмруг кошның күңеле йомшарган, егетне тирәк янына чакырган, киемен алып төшкән. Өс-башына кигәч, егетнең бу якларга ничек килеп чыкканын, кая юл тотканын, теләген сорашкан. Арпалып барысын сөйләп биргәч:

— Минем балаларымны үлемнән алып калгансың. Син булмасаң, алар үлгән булырлар иде, инде күрсәткән яхшылыгыңа мин дә яхшылык эшләргә тиеш, моратыңа ирешергә ярдәм итәм, — дигән. — Ләкин минем өчен бик күп азык әзерләргә, кырык мичкә тургай тозларга кирәк, — дип өстәгән.

Сәмруг кош һавага күтәрелә икән дә, тургайларны суырып алып авызына тутыра икән. Ул, тургайларны күп итеп алып кайтып тора, ә егет тозлый бара икән. Шулай итеп, болар кырык мичкә тургай тозлаганнар.

— Инде боларның егерме мичкәсен бер бауга, икенче егермесен икенче бауга тезеп бәйләрсең дә, ике яклап иңсәмә салырсың, карным ачкач, башымны уң якка борып авызымны ачармын, шул чакта мичкәнең берсен бавыннан кисеп авызыма тыгарсың, янә ачыккач башымны сул якка борып авызымны ачармын. Шул вакытта та-

[1] Кешеләрне югары торган кош (миф)

гын бер мичкәне авызыма тиз генә тыгарсың, — дип өйрәткән сәмруг кош Арпалыпны.

Балаларына азык калдырып, егетне җилкәсенә мендереп, кош күккә күтәрелгән дә очып киткән. Оча торгач, сәмруг уң ягына борылып авызын ачкан, егет аңар бер мичкә тыккан. Аннары, башын сул якка борып авызын ачкан, егет икенче мичкәне авызына тыккан. Кош ашарга сораган саен берәр мичкә бирә барган. Зиндан төбенә җитәрәк, сәмругнең азыгы беткән.

— Инде карным ачып киткәндә нәрсә бирәсең? — дип сораган кош.

— Борчылма, берәр әмәлен табарбыз, — дигән егет.

Оча торгач кош уңга борылып авызын ачкан.

Егет, Алтынбикә биргән алтын саплы алмаз кылычы белән уң як сыйрагының балтыр итен кисеп сәмругнең авызына каптырган. Кош, зинданнан чыга башлагач, сулга борылып авызын ачкан икән, егет сулъяк сыйрагының балтыр итен кисеп каптырган.

Болар тар гына бер сукмак үткән җиргә төшкәннәр.

— Егет, инде җилкәмнән төш, моратыңа ирешерсең, мин күккә менеп үз юлыма очам, син үз юлыңа кит, — дигән һәм «карык» итеп авызын ачкан да егет юлда кисеп биргән итләрне чыгарып, Арпалыпның аягына ябыштырган. Кош, күккә менеп үз юлына, балалары янына очкан. Ә Арпалып үзен алдаган иптәшләрен эзләп киткән. Көн киткән, төн киткән, таң атканда алар учак ягып, ял итеп утырган урынга туктаган. Тегеләр тагын юлга җыенган арада, Алтынбикә кемгә дә сиздермичә, учактагы көлне җыеп Арпалыпка азык күмеп калдырган икән.

— Алтынбикә мине онытмаган, — дип, егет шул азык белән тамак туйдырган да алар үткән сукмактан атлаган. Шактый юл үтеп арыгач, тагын тегеләр учак ягып, ашап-эчеп киткән җиргә җиткән. Алтынбикә күмеп калдырган ризыклар белән туенган. Ял итеп, хәл алган да тагын болар артыннан киткән. Көн барган, төн барган, таң атканда, алар өченче тапкыр учак ягып маташканда, егет боларның каршыларына килеп баскан.

— Әй, хыянәтчеләр, — дигән Арпалып теге егетләргә, — алмаз кылыч белән сезнең башыгызны чабып өзәргәме, әллә икегезне ике кулыма тотып, берегезне-берегезгә сугып сөякләрегезне он итәргәме?

Тирәкалып белән Ташалып гаепләрен танып башларын игәннәр:

— Башларыбыз синең алда, ни эшләтсәң дә риза, гаебебез зур,— дигәннәр алар.— Икенче бервакытта да алай эшләмәбез, безне кичер! — дип гафу үтенгәннәр.

— Ярар, иелгән башны кылыч кисми, — дигән Арпалып ачуы бераз басыла төшкәч. — Хыянәтчеләргә, ялганчыларга икенче тапкыр шәфкать булмас!

Аннары Арпалып батыр Бакырбикәне Ташалыпка, Көмешбикәне Тирәкалыпка биргән. Алтынбикәне үзенә алган. Алтынны тигез итеп алтыга бүлгән. Өч пар булып, берсе-берсе белән саубуллашып, ризалашып өч юлга киткәннәр. Бакырбикә бакыр өй салган. Көмешбикә көмеш өй салган. Арпалыпның батырлыгы аркасында, Ташалып белән Тирәкалып та зур дәүләткә ия булган хатыннары белән матур гына көн күрә башлаганнар. Алтынбикә алтын өй салган. Арпалыпның карт әнисе белән әтисенә алтын өйдә алтын бүлмә биргәннәр. Арпалып батыр Алтынбикәсе белән алтын кебек ялтырап тигез гомер кичергәннәр, ди...

*(Түмән өлкәсе, Тобол районындагы Пушман авылында 1940 елның 27-28 июнендә Мөхәммәтнәби Уразметовтан язып алынды.)*

# Сукыр белән чукрак

Бер сукыр фәкыйрь кеше белән чукрак фәкыйрь кеше яшәгән. Берсенең колагы яхшы ишеткән, икенчесенең күзе яхшы күргән. Болар бәхәсләшмәгәннәр, бер-берсенә хыянәт итмәгәннәр, һәрвакыт дус, тату, гадел булганнар. Һаман бергә йөреп, хәер сорашып алган акчаларын, ризыкларын бергә тигез итеп бүлә торган булганнар.

Ләкин боларның дус, тату булуларына Иблиснең бик ачуы килгән. Шуннан үзенең бер оста шайтанына ул аларны ничек кенә булса да ызгыштырып дошман итәргә кушкан. Шайтан, боларның артларыннан йөреп, бик күп хәйләләр корып караса да,

ызгыштыру түгел, араларына чебен дә кертә алмаган. Аларны бернячек тә алдый алмавы турында кайтып сөйләгәч, Иблис:

— Әгәр аларны алдап ызгыштыра алмасаң, сине бер шайтанга да бирелмәгән каты җәзага тартам, — дигән.

Иблис җәзасыннан куркып елап барган чагында моңар бер кеше очраган:

— Нигә елыйсың, шайтан, ни булды сиңа? — дип сораган.

— Ике дус кешене ничә еллардан бирле ызгыштыра алмыйм, шуның өчен Иблис мине иң каты җәзага тарта, — дигән шайтан.

— Хи-и, мин аларны күз ачып йомганчы алдыйм, аерам, аның өчен миңа нәрсә бирәсең? — дигән.

— Шул эшне булдырсаң, үз башың хәтле алтын бирәм, — дигән шайтан.

— Үзләре кайда?

— Әнә мәчеткә кереп баралар.

Сукыр кеше белән чукрак кеше намаз вакытында мәчеткә кереп, садака җыеп бүлешәләр икән. Әнә бер карт:

— Мәгез! — дип чукракка садака бирә. Моны сукыр ишетеп тора. Акчаны шунда ук тигез итеп бүлеп кесәләренә салалар.

Менә шайтанга ялланган кеше кереп кычкырып сәлам бирә. Сәламне ишеткән сукыр үзенең чукрак дустына:

— Әнә, садака бирәләр, барып ал! — ди.

Күзле фәкыйрь сәлам бирүченең каршысына барып:

— Хәерене китер, миңа бир! — дип сорагач, теге кеше шактый ук кычкырып:

— Бусы үзеңә, бусы дустыңа! — дип, колак төбенә ике йодрык сала да мәчеттән чыгып китә.

Күзле карт үзенең дусты янына барып утыру белән сукыры:

— Миңа биргәнне син үземә биреп куй инде! — ди.

— Ул миңа бер нәрсә дә бирмәде, — ди күзле карт.

— Мин ишетеп утырам бит, берсе үзеңә, берсе дустыңа дип бирде ул, — ди сукыр карт.

Шуннан күзле картның җен ачуы чыгып:

— Кирәк булса, үзеңә биргәнне мә ал! — дип, сукырның авызына йодрык белән шундый итеп тондыра, картның тешләре коелып төшә. — Кирәк булса, миңа биргәнне дә ал! — дип, тагын берне тондыруы була, картның авызыннан кан китә.

Боларның үзара ызгышуларын читтән генә карап торган шайтан шатланып Иблис янына йөгереп кайта да:

— Кушканыңны үтәдем, талаштырдым, башың хәтле алтын бирәм дип, өченче кешене дә алдадым, — ди масаеп.

Шулай итеп, шайтан җәзадан котыла, ә фәкыйрь картлар бер-берсенә дошман була.

*(Омск өлкәсе, Усть-ишимда 1940 елның 24 июнендә Гали Әминевтән язып алынды.)*

## Көтүче кызы

Борын заманда Себердә бер бик фәкыйрь көтүче карт яшәгән. Аның карчыгы үлгән. Ул үзенең бердәнбер кызы белән калган. Карт сарык көтүе көткән, ә кызы соранып йөргән.

Беркөнне бу көтүче карт кайгыга төшеп кайткан. Әтисенең уйга калып, күңелсез генә утыруын күргәч, кыз аннан:

— Әти, сиңа ни булды, нигә бик борчыласың? — дип сораган.

— И-и, кызым, кайгым бик зур, — дигән карт. — Патша хәзрәтләре уйнапмы, чынлапмы миңа өч сорау җибәргән. Билгеләгән вакытка килеп, шуларга җавап бирмәсә, асып куярга кушам, дип әйткән.

— Яле, эти, әйтеп кара, патша сиңа нинди сораулар биргән икән? — дигән кыз.

— Патша «дөньяда нәрсә татлы» дип, аннары «дөньяда нәрсә каты?» дип, ә өченчесендә «дөньяда нәрсә ачы?» дип сораган, — дигән карт.

Сорауларны тыңлагач кыз:

— Әти, кайгырма, китәр алдыннан барысын да әйтеп бирермен,— дигән.

Сарайга китәр вакыт җиткәч, әтисе белән киңәшеп, кыз әлеге патшаның беренче соравына — дөньяда иң татлы нәрсә бала дип, икенчесенә — иң каты нәрсә җир сукалау дип, өченче соравына — дөньяда иң ачы нәрсә хатыннарның тулгагы, дип җавап бирергә кушкан.

Карт, сорауларга җавап биргәч, патша:

— Дөрес, ләкин болай оста җавап бирергә сине кем өйрәтте? — дип сораган.

— Унҗиде яшьлек кызым өйрәтте, — дип җавап биргән карт.

— Булмас, унҗиде яшьлек кыз боларны кайдан белсен, — дигән патша.

— Анысын белмим, — дигән карт.

— Кызың шундый уңган булса, менә ике ак җитен, берсеннән күлмәк, икенчесеннән чалбар суксын, — дигән патша.

Карт, кызы өчен кайгырып өйгә кайткан да аңар патша кушкан эш турында әйткән.

— Кайгырма, әти, бу эш тә кулымнан килә, — дигән кыз, әтисен тынычландырып.

Кыз, икенче көнне тау башына менгән дә суга башлаган. Шул чакта ул акбүз атка атланган бай киемле бер кеше килгәнен күреп алган. Бу шул әлеге патша икән. Ул кыз янына килеп җиткән дә:

— Минем акбүз атымның башын күргәч, сукма башың ничә мәртәбә сукты? — дип сораган.

Ә кыз аңар карап торган да:

— Минем сукма, башым күргәч, акбүз атың ничә мәртәбә атлады? — дип сорауга каршы сорау биргән.

Патша, гади бер кызның мондый җавабына аптырашта калып:

— Сугып маташма, әйдә, өеңә алып кайт! — дигән.

Болар кыз өенә кайтканнар. Патша аның әтисенә:

— Дүрт көннән кызыңны сараема алып китәм, — дигән.

Патша, әйтелгән көнне килеп, кызны сараена алып киткән. Сарайда ул патшаның яшь хатыны булып яши башлаган.

Көннәрдән бер көнне, патша каядыр киткәч, кыз тәрәзәдән ике кеше бәхәсләшкәнне карап, күреп торган. Бер арбалы кеше, арбасын атлы кешегә биреп торган икән. Юлда барганда, бия колынлаган да колыны арбага төшкән икән. Арба биреп торган кеше:

— Әһә-ә, минем арба колынлады,— дип колынны үзенә алырга маташкан.

Үзара бәхәс киткән. Шуннан болар:

— Безнең бәхәсне патша хәл итсен, — дип, сарайга килгәннәр икән.

Боларны көтүче кызы каршы алган.

Сарайга кергәч, арбасын күршесенә биреп торган кеше:

— Безгә патша хәзрәтләре кирәк, ул кайда? — дип сораган.

Ә кыз аңар:

— Патша өйдә юк, үгез бозаулаган икән, шуның кендеген кисәргә китте, — дигән.

Арбалы кеше бик гаҗәпләнеп:

— Булмас ла, син юкны сөйлисең, үгез ни эшләп бозауласын, сыер бозаулагандыр, — дигән.

— Шулай булгач, арба колынламыйдыр, бия колынлыйдыр бит, — дигән патшаның яшь хатыны.

Арбалы кеше бер нәрсә дә әйтә алмыйча сарайдан чыгып киткән.

Патша кайткач, сарай ялчылары аңар яшь хатыны турында төрле гайбәтләр сөйләгәннәр:

— Падишаһыбыз, яшь хатының синнән уздырды, рөхсәтеңнән башка кешеләр бәхәсенә кушылды, сине үгез кендеген кисәргә китте, дип мыскыл итте, — һәм шул сүзләргә тагын әлләниләр кушып сөйләп, патшаны котыртканнар.

Патша бик ачуланып, аңар сарайдан чыгып китәргә кушкан:
— Теләгән нәрсәңне ал да чыгып кит, — дигән.
— Ярый, — дигән кыз, — мин үз иркем белән килмәдем, сараеңа үзең алып килдең, миңе мәҗлес ясап озат, — дигән.
Мәҗлестә шактый гына эчеп патша исергән. Кыз, өчле ат җиктергән дә патшаны каретага утыртып, өйләренә алып киткән. Кызның әтисе яшәгән авыл тавына менгәндә, патша айный башлаган, күзләрен угалап:
— Мин кайда? Мине нигә сарайдан алып чыгып киттегез? — дип сораган.
— Син миңа сарайдан ни теләсәң, шуны алып чыгып кит, дигән идең, теләгәнемне — сине алып чыктым, инде бергә яшәргә әтиемә кайтабыз, — дигән кыз.
— Юк, атларны кире бордырт, сарайга кайтабыз, сараемда яшибез, — дигән патша.
Болар сарайга кайтып көн күрә башлаганнар. Ләкин бергә күп яшәмәгәннәр. Патша үлгән. Аның урынына көтүче кызы патша булып бик озак яшәгән, ди.

*(Новосибирск өлкәсе, Чаный районы, Тармакүл авылында язып алынды. Әкиятне тапшыручы бик яшь кенә кыз булганга, үзенең исем-фамилиясен әйтергә оялды.)*



## Бака кияве

Борында бер кешенең өч улы булган. Беренче улы утыз яшенә житкән, уртанчысына егерме биш яшь тулган, кече улы да егерме беренче яшенә житкән. Алар үзләренең буйдак булып калуларыннан куркып, әтиләренең өйләндермәвеннән зарланып сөйләшәләр икән.
— Беребез утызда, икенчебез егерме биш яшькә житте, өченчебез дә егет булып житте, хатын алмыйча картаябыз, бу турыда әти белән сөйләшергә вакыт, — дигәннәр алар.
Аларның үзара сөйләшкәннәрен әтиләре читтән генә тыңлап торган икән.
Иртә белән торгач, әтиләре боларның өчесен дә үз янына чакырып алып, аларга урманга барырга, ук ягы[1] белән уклар ясап кайтырга кушкан. Урманга барып кайткач карт аларга:
— Ясап китергән булсагыз, өйгә кертеп мич башында киптерегез! — дигән.
Кич белән тагын ятып йоклаганнар. Иртән торып, әтиләре олы улына үзенең ук ягын алып чыгарга кушкан. Алып чыккач:
— Инде атып җибәр, — дигән.
Егет атып җибәргәч, әтисе аңар ат җигәргә кушкан.
Шуннан карт белән егет атка утырып әлеге укны эзләргә киткәннәр. Ай киткәннәр, ел киткәннәр, балта сабы кадәр генә җир киткәннәр. Әйләнгән җирләренә агайры[2] чыккан, тулганган җирләренә тубылгы чыккан. Ай әйләнеп, ел әйләнеп болар бер шәһәргә килеп кергәннәр. Эзләп йөри торгач, шул шәһәрдәге бер бай өенең түбәсендә кадалып утыра ди егет атып җибәргән ук. Карт белән егет бер йортка төшеп урнашканнар да ук кадалган өйдәге бай кызын соратып яучы җибәргәннәр.
Бай үзенең кызын бу егеткә бирергә риза булган. Утыз көн уен, кырык көн туен ясаганнар. Эчкәнгә чиләк белән, эчмәгәнгә иләк белән эчерткәннәр. Туйдан соң карт:
— Син инде монда калып көн итәсең, — дип, улына күп кенә акча биреп өенә кайтып киткән.
Өенә кайтып кергәч, кече улы аның каршысына чыгып:
— Әти, юлыгыз уңдымы, абый кайда? — дип сорагач:
— И, улым, абыең кайгысын кайгыртудан файда юк, үз кайгыңны кайгыртырга кирәк, абыеңны калдырып кайттым, — дип җавап биргән дә өенә кереп ятып йоклаган.
Иртән торып, ашын ашап, чәен эчкән дә карт инде уртанчы малаена ук ягын алып чыгарга кушкан. Ук ягын алып чыккач, әтисе аңар да:

[1] Җәя.
[2] Камышка охшаган үлән.

— Атып җибәр! — дигән.

Егет атып җибәргән, этисе аңар ат җигәргә кушкан. Атны җиккәч, карт уртанчы улы белән әлеге укны эзләп киткәннәр. Ай киткәннәр, ел киткәннәр, инә буе җир киткәннәр. Әйләнгән җирләренә агайры чыккан, тулганган җирләренә тубылгы чыккан. Шулай әйләнгәләп йөри торгач бер шәһәргә барып кергәннәр. Егетнең угы шул шәһәрдә бер байның өй түбәсенә кадалып утыра икән. Болар бер өйгә төшеп урнашкан, шул бай кызын соратып яучы җибәргәннәр. Бай үзенең кызын егеткә бирергә риза булган. Утыз көн уен, кырык көн туен ясаганнар. Эчкәнгә чиләк белән, эчмәгәнгә иләк белән эчерткәннәр. Туйдан соң егетнең этисе:

— Син монда каласың, монда көн күрәсең, киленне ташлап китәргә рөхсәт юк, — дип, килене белән улына йорт салдырып, акчалар биреп өенә кайтып киткән.

Өендә кече улы аның каршысына чыгып:

— Эти, юлыгыз уңдымы, абый кайда? — дип сорагач:

— И, балам, абыең кайгысын кайгыртудан бигрәк үз кайгыңны кайгырт! — дип җавап биргән дә, ашын ашап йокларга яткан.

Иртә белән тамак туйдыргач этисе:

— Әйдә, улым, ук ягыңны алып чык та атып җибәр! — дигән.

Егет, кушканны эшләгәч, этисе аңар әйтеп ат җиктерткән. Ат җигелгәч икәүләп укны эзләп юлга чыкканнар. Ай киткәннәр болар, ел киткәннәр, балта сабы буе җир киткәннәр. Әйләнгән җирләренә агайры, тулганган җирләренә тубылгы чыккан. Анда барганнар, монда килгәннәр, барлык шәһәрләрдә, авылларда булганнар, укны таба алмаганнар. Инде диңгез буендагы ерак бер шәһәргә барып кайтыйк дип, икенче бер юлга чыксалар, уклары бер бака өстендә кадалып утыра икән. Карт, атны туктатып тугарып җибәргән дә бака өстендәге укны саклык белән генә алган, улына җир өй казырга тотынган. Җир өй әзер булгач, баканы шунда керткәннәр.

— Киленем шушы була инде! Әй, улым, мин сиңа абыйларыңны кайгыртудан бигрәк үз кайгыңны кайгырт дигән идем бит? Менә хәзер шушы хатының кайгысын кайгырт! Киленне ташлап китмә, өйгә кайтырга рөхсәт юк, шушында көн күрегез! — дип әйткән дә карт, атын җигеп, улына акчалар биреп өенә кайтып киткән. Егет, бака кияве булып җир өйдә калган.

Берничә ел үткәч, этиләре хәбәр җибәреп, уллары белән киленнәрен кунакка чакырган.

— Улларым белән киленнәрем миңа кунакка болай гына килмәсеннәр, ә җинел арбалары алтыннан булсын, аларга маңгайларына яфрак кадәр генә ак төшкән — барысы да бер төсле җем кара өчлек атлар җигелсен, алларында кучерлары утырсын, артларында сакчылары булсын, өч киленем дә бүләк алып килсен, бүләкләре берсеннән берсе яхшы булсын, бүләге белән кайсысы уздырса, яраткан киленем шул булыр, — дигән карт.

Этисе кунакка чакыргач, егеткә кайгы төшкән.

— Абыйларымның җигәргә атлары, алтын арбалары, барысы да бар. Минем бака хатыным белән җир өемнән башка бер нәрсәм дә юк, арба итеп өемне җигәр идем, балчыгы коелып бетәр, инде ни эшлибез, анда ничек барабыз? — дигән егет бакасына карап.

Ә бака бер нәрсә дә әйтмәгән, тик «бакакакъ, бакакакъ» дип кенә кычкырып куйган.

Этисенә барыр көннәр якынлашкан саен егет күбрәк борчылган. Беркөнне шулай уйланып йөри торгач ул арып, ятып торам дип кенә яткан да каты йоклап киткән. Шул вакытта бака, карап туймаслык асыл түбәтәй чигеп, бер нәрсә дә булмаган кебек, аны тәрәзә төбенә куеп чәй әзерләгән. Аннары:

— Әйдә, тор, чәй эчеп ал! — дип ирен уяткан.

Егет чәй эчәргә утырган. Шул чагында карашы тәрәзә төбендәге карап туймаслык матур түбәтәйгә төшкән.

— Менә гаҗәп, — дигән ул. — Минем хатын булдыра икән! Ләкин иртәгә безгә китәргә кирәк, бер түбәтәй белән генә юлга чыга алмабыз! — дигән бакага.

Кич белән егет йокларга яткан. Ә таң белән бака, егетнең этисе күрергә теләгән алтын арбага җем кара атлар җиктергән, бүләкләр хәзерләгән, сакчылар китерткән дә ирен уяткан:

— Тор, китәргә вакыт, безне көтәләр, — дигән.

Егет уянып тышка чыкса, чынлап та, алтын арбага җигелгән яхшы атларда кучерлар һәм сакчылар көтеп торалар икән.

Ашап-эчкәннән соң болар юлга чыгып киткәннәр.

Өч малай да кушкан сәгатькә килеп җитеп, урам әйләнеп этисе капкасыннан бергә барып кергәннәр.

— Улларым килде, киленнәрем килде! — дип карт боларны каршы алган, уллары, киленнәре алып килгән бүләкләрне күрсәтергә бик күп белеш-танышларын, кардәшләрен кунакка чакырган. Кунаклар, кече улы хатынының бүләкләрен исләре китеп мактаганнар. Ә өлкән абыйлары көнләшеп, бүләкләре яхшы булса да «бака бака инде» дип мыскыл иткәннәр.

Карт та өлкән уллары хатыннарына караганда кече улы хатынын мактап:

— Минем иң яраткан киленем — кече улымның хатыны! — дип баканы бик мактаган.

Уллары белән киленнәре этиләрендә өчәр көн кунак булып өйләренә кайтып киткәннәр.

Егет уйланган:

— Минем хатын бака булмаска тиеш, шуның серен ничек белергә икән? — дигән.

Өйгә кайтып су буенда уйланып йөргәндә моның каршысына бер карчык килеп чыккан. Егет аны хөрмәт итеп күрешкәч:

— Сез күпне күргән, күпне кичергән, күпне белгән олы кеше; миңа бер киңәш бирә алмассызмы? — дигән.

— Сөйлә, нинди киңәш кирәк? — дип әйткән аңар бу карчык.

— Минем хатыным бака, шуның бака булуына шигем бар, ул чынлап та бака микән, әллә әдәм затыннан микән? — дип сораган.

— Синең хатының бака түгел, бака тунын кигән кыз кеше, — дигән карчык.

— Аның ул тунын салдырып буламы? — дип тагын сораган егет.

— Аны чишендерәсең килсә, базарга барып май ал, урманга барып сирашка[1] шикелле шартлап яна торган коры утын алып кайт та, олы мичкә ягып коймак койдырырга куш; мичкә яккач, тышка чыгып яшеренеп карап тор, — дип өйрәткән аны бу карчык.

Шул киңәшне тыңлап ул базарга барып май алган, урманга барып коры утын күтәреп кайткан.

— Менә сиңа май, он, утын да яхшы. Миңа тәмле коймак коеп бир, хатын! — дигән егет.

Бака мичкә ягып эшкә керешкәч, үзе өйдән чыгып яшеренеп карап торган.

Коймак коеп тирләгәч, бака үзенең тунын салып ташлаган һәм ул ай белән кояш кебек нурлы, якты йөзле, зифа буйлы, искиткеч матур кыз булып чыккан. Егет йөгереп өйгә кергән дә хатынның бака тунын мичкә ташлаган.

— Һай, яндым! — дигән кыз, егеткә тимер итек, тимер кием һәм тимер таяк белән агач таяк биргән. — Бу авыр киемнәрең карындык калынлыгы булып юкарганчы, тимер таягың инә кадәр калганчы мине эзләгәч, агач таягыңны диңгезгә салырсың, ул күпергә әверелер, мине шул күпердән чыккач табарсың! — дигән дә бу кыз юк булган.

Егет бер күрүдә гашыйк булган хатынын эзләп юлга чыккан. Ай киткән бу, ел киткән... бик озак йөри торгач диңгез буена килеп чыккан. Арып-талып бер өй ишеген каккан икән, бер бәләкәй кыз ишек ачып:

— И-и, минем җизнәм бит бу! — дип өйгә алып кергән дә, — кара әле, минем җизниемә тимер киемнәр кидереп нигә азаплаган, апам? — дип, чишендереп икенче кием кидерткән дә ял итәргә кушкан.

Бераздан:

— Апа, җизни килде, сөенечкә ни бирәсең? — дигән тавышка егет сикереп торган. Шуннан егет белән кыз шау-гөр килеп, кочаклашып, үбешеп күрешкәннәр.

*(Новосибирск өлкәсе, Чаный районындагы Тармакул авылында, 1940 елның 20 маенда Насыйбулладан (фамилиясе күрсәтелмәгән) язып алынды.)*

[1] Ширпы.

**Гомәр Саттаров,**
филология фәннәре докторы, профессор

# УНБЕРЕНЧЕ КАРАШ

*Тагын да Казан шәһәре исеменең килеп чыгышы хакында*

Казан шәһәре исеменең килеп чыгышын, ягъни «Казан» полисонимының этимологиясен ачыклау зур тарихи-культура һәм тарихи-лингвистик әһәмияткә ия.

«Казан» атамасына мөнәсәбәтле рәвештә татарларда, илебездәге башка халыкларда һәм чит илләрдә байтак кына ономастик берәмлекләр (мәсәлән, фамилияләр, вокзал һәм чиркәү исемнәре, урам атамалары, поселок һәм совхоз, газета һәм журнал исемнәре һ. б.) ясалган.

Казан шәһәре исеменең килеп чыгышына берничә караш бар. «Казан» сүзенең күп мәгънәлелеге яки аның омоним (әйтелешләре ягыннан охшаш) сүзләр тәшкил итүе шәһәр атамасының килеп чыгышына карата төрлечә фикер йөртүгә китергән.

Хәзерге фәнни әдәбиятта бу мәсьәләне унбер төрле аңлату билгеле.

1. «Шәһәр нигә Казан дип аталган?» дигән борынгы топонимик легендада Болгарның соңгы идарәчесе Габдулла ханның улы Алтынбәкнең хезмәтчесе су алганда алтын казанын исеме билгесез елгага төшереп җибәрүе, шуннан соң бу елгага Казан исеме бирелүе һәм аның янына салынган шәһәргә дә «Казан» дип исем кушылуы риваять ителә.

Казан елгасы һәм шәһәре исеме алтын казанга бәйле рәвештә барлыкка килгән дип аңлатуның фәнни нигезе юк. Менә шуңа күрә Н. Баженов: «Казанка елгасы исемен аңа төшеп киткән казан белән бәйләп аңлату тулысынча уйдырма»[1],— дип саный. Чувашларның аш пешерү савытын (казанны), «хуран» дип атап та, Казан шәһәрен Хозан яки Хузан дип йөртүләре бу атаманың «казан» сүзеннән алынмавын раслый.

2. Казан шәһәренең исеме башта салынган урынының казан сыман тирән чокырлы, казанлыклы булуыннан чыгып алынган дигән караш та бар. Мәсәлән, В. В. Радлов[2], М. Худяков[3] һәм А. Н. Сергеев[4] шушы фикердә торганнар. Казан шәһәре атамасының килеп чыгышына карата бөек рус революцион-демократы А. И. Герцен да шушы карашта була[5]. Ләкин Казан (шулай ук Иске Казан) урнашкан урыннарда күзгә ташланырдай казанлыклар юк. Казанлыклар, башлыча, биек тау араларында булалар. Казанлык сүзенә нисбәтле рәвештә барлыкка килгән ойконимнар, башлыча, шундый төбәкләрдә урын алалар. Мәсәлән: Казанлык — Болгариядәге, Казанджик — Төркмәнстандагы шәһәр, Югары Казанлык, Түбән Казанлык — Дагстан АССРдагы кумык авыллары, Казан-Кутган — Кыргызстандагы кыргыз авылы, Казан-Чункур — Казагыстандагы казакъ авылы һ. б.

3. Казан шәһәренең исеме Казан елгасы исеменнән алынган, ә елгага бу атама аның төбендә казан сыман чокырлар, чоңгыллар булуыннан чыгып бирелгән дигән карашны беренче башлап 1767 елда ук П. Н. Рычков әйтә[6]. Бу карашны XIX йөздә М. Н. Пенигин, М. С. Шпилевский һ. б. галимнәр яклый. Безнең көннәрдә профессор Е. Г. Бушканец[7], башкорт топонимисты А. А. Камалов[8] Казан топонимы шушы юл белән барлыкка килгән булырга тиеш дип карый.

[1] Баженов Н. Казанская история. Казань, 1847, 4 б.
[2] Карагыз: Протоколы Общества естествоиспытателей при императорском Казанском университете с приложениями. Казань, 1875, 14 б.
[3] Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства. Казань, 1923, 244 б.
[4] Сергеев А. Н. Опыт объяснения названий русских городов.— Сборник в память статистического съезда 1870 года, вып. II. Нижний Новгород, 1875, 626 б.
[5] Герцен А. И. Затерянная статья о Казани (публикация И. Яковлева) — «Литературное наследство», т. 61, М., 1953, 20 б.
[6] Рычков П. Н. Опыт Казанской истории. СПб, 1767, 102 б.
[7] Бушканец Е. Г. Казань (путеводитель). Казань, 1964, 14 б.
[8] Камалов А. А. Некоторые вопросы изучения топонимии Башкирии.— Ономастика Поволжья, 3. Уфа, 1973, 180 б.

Казан елгасына исем аның чоңгыллы, казылмалы-казанлыклы булуыннан чыгып бирелгән дип әйтүнең ышандыру көче юк. Чөнки бер генә елганың да төбе тоташтан тигез булмый. Физик-географик объектларга исә, күбесенчә аларның үзләренә генә хас билгеләреннән чыгып исем бирелгән.

4. XIX йөздә яшәгән һәм иҗат иткән байтак кына галимнәр П. Н. Рычковның: «Иске Казанга Алтын Урданың Чыгтай улусында ханлык иткән Казан-Солтан хан яки Казан исемле башка бер татар принцы нигез салган булуы ихтимал» (103 бит),— дип фараз итүен яклыйлар. Аларның бу юнәлештә ничегрәк фикер йөртүләрен бәян итүдән элек, Казан сүзенең кеше исеме булып кулланылу-кулланылмау мәсьәләсен ачыклыйк.

Борынгы заманнарда төрки халыкларда нәни балага каты, нык металл һ. б. әйберләрнең исемен бирү йоласы булган. Бу исә бала таза, нык булсын, авыруларга, усал көчләргә бирешмәсен дигән теләктән чыгып эшләнгән. Менә шуңа, тимер, балта, казан, кылыч һ. б. шундый катылык-ныклык сыйфаты хас булган хуҗалык һәм хәрби коралларның атамасы ир балаларга исем итеп кушылган. Шуның нәтиҗәсендә төрки халыкларның күбесендә: Тимер, Тимеркәй, Тимербәк, Тимерҗан, Тимербулат, Таштимер, Тимерхан, Тимерша, Тимеркотлык, Котлытимер, Тимергази, Тимергали, Тимерхуҗа; Балта, Балтакай, Балтай, Балтач, Балтан, Балтабай, Балтакол, Бишбалта; Урак, Ураккай, Уракай, Уракчы; Казан, Казанай, Казанбәк, Казанчы, Казантирәк, Казанбай; Кылыч, Булаткылыч, Кылычарслан кебек кеше исемнәре кулланылышта йөргән.

Димәк, Казан исемле шәхеснең булуын антропонимик мәгълүматлар раслыйлар. Тарихи мәгълүматлар исә Алтын Урда ханнары арасында Казан-Солтан дигән ханның булуын күрсәтәләр[1]. Менә шуңа Казан каласына Казан исемле шәхес нигез салган һәм әлеге шәхескә мөнәсәбәтле рәвештә шәһәр «Казан» дип аталган дип карарга, һичшиксез, нигез бар. Болай карау дөреслеккә туры киләме соң?

Иң элек бу мәсьәләдә XIX йөз галимнәренең карашлары бердәм булмавын әйтергә кирәк:

а) кайбер галимнәр Казан исемле шәхеснең кем булуын конкрет күрсәтмиләр. Мәсәлән, профессор Карл Фукс «Казан шәһәренең кыскача тарихы» дигән китабында (рус телендә. Казан, 1817, 31 бит): «Казан, мөгаен, үзенең исемен нигезләүчесе исеменнән алгандыр»,— дип яза, әмма аның кем булуы турында конкрет сүз алып бармый. А. С. Дубровин да: «Казан шәһәренә Казан исемле кеше нигез салган дип карау дөресрәк булыр, әмма аны нигезләүче кеше үз исеме белән акчалар суктырган Чыңгыз хан улы (Казан-Солтан хан — Г. С.) булгандыр диярге кыенсынам»[2],— дип мәсьәләне ачык калдыра. Немец галиме М. Фасмер[3] шәһәр атамасы «казан» («котел») сүзеннән яки төрки кеше исеме Казаннан килеп чыккан булырга тиеш, дип карый;

б) күренекле татар галиме Ш. Мәрҗани[4] һәм Н. Ф. Прокофьев[5] Иске Казанга Батый нәселеннән булган Казан хан нигез салган дигән фикердә торалар. «Мөстафадәл-әхбар» исемле хезмәтендә исә Мәрҗани Казан шәһәрен нигезләүче шәхес итеп Батый хан улы Сартакны күрсәтә (1 том, 97 бит). Ләкин Сартакның әтисе Батый ханнан соң бары бер генә ел ханлык итеп, 1256 елда үлүен[6] искә алсак, Казан шәһәре аның тарафыннан нигезләнгән дип әйтү өчен җирлек булмавы ачыклана;

в) Казан университеты профессоры Н. П. Загоскин Казан хан дип Алтын Урда ханнарыннан Тода-Мәңгүне саный. Ул бу нәтиҗәгә бернича чыганакка таянып фикер йөртү аша килә. Ш. Мәрҗанинең русча басылган тарихи очеркындагы мәгълүматтан чыгып, Алтын Урдада Казан дигән хан булган дип карый, әмма Сарай ханнарының исемлекләрендә бу исемне бөтенләй очратмый.

Немец галиме И. Һаммер «Алтын Урда тарихы» (1840 ел) исемле хезмәтендә Тода-Мәңгүнең «Казган» (аш пешерә торган савыт), ә аның абыйсы Мәңгү-Тимернең «Килка» (маныпган җәймә) дигән кушаматлары булуын хәбәр итә. И. Һаммер бу кушаматларның халык арасында гына йөрүе, рәсми булмавы, алар тарафыннан чыгарылган акчаларга язылмавы турында яза. Н. П. Загоскин Казан археология, тарих һәм этнография җәмгыяте кабинетында «Казан хан» исеменнән сугылган акча булуын искәртә һәм, болардан чыгып, «Казан» сүзе Тода-Мәңгү ханның кушаматы, Тода-Мәңгү шул ук Казан хан, Иске Казанга 1288 елда Тода-Мәңгү хан нигез салган дигән нәтиҗәгә килә[7].

Билгеле ки, акчаларда кушамат түгел, бәлки ханның яки патшаның чын исеме языла. Ниһаять, бер генә музей каталогында да «Казган хан» исеменнән сугылган акча исәпкә алынмаган. Бу бер мөһим факт. Икенчедән, Тода-Мәңгү 1287 елда тәхеттән

---

[1] Абулгази Бахадур хан Хивинский. Родословное древо тюрков.— «Известия общества археологии, истории и этнографии», т. XXI, вып. 5—6. Казань, 1907, 133 б.

[2] Дубровин А. С. Указатель города Казани и достопримечательностей с кратким очерком древностей Казанской губернии. Казань, 1890, 2 б.

[3] Фасмер М. Этимологический словарь русского языка, т. 2. М., 1967, 159 б.

[4] Марджани Ш. Очерк истории Булгарского и Казанского царств (перевод В. В. Радлова).— Труды IV Археологического съезда в России, т. 1. Казань, 1884, 41 б.

[5] Прокофьев Н. Ф. Полный путеводитель по Казани и окрестностям. Казань, 1910, 30 б.

[6] Стэнли-Лэн-пуль. Мусульманская династия. Инглиз теленнән В. Бартольд тәрҗемәсе. СПб., 1899, 191 б.

[7] Загоскин Н. П. Спутник по Казани. Казань, 1895, 18—19 битләр.

ваз кичә [1]. Н. П. Загоскин Иске Казанга нигез салынган вакыт дип санаган 1288 елны инде Алтын Урдада башка хан патшалык итә. Дәүләт эшләре белән бөтенләй диярлек шөгыльләнми башлаган, бөтен вакытын аллага табынып үткәргән Тода-Мәңгү Казанга нигез салган дип карау чынбарлыктан ерак.

Дөрес, 1295—1304 елларда Иран — Әзербәйҗан дәүләтендә Чыгтай нәселеннән булган Аргун ханның улы Газан (Казан) исемле икенче бер шәхес ханлык иткән. Кайбер тарихчылар, шул җөмләдән XVIII йөз шагыйре һәм галиме Габдерәхим Утыз Имәни, Казан шәһәрен әлеге Газан хан төзеткән дигән карашта торган. Ш. Мәрҗани бу карашның хата булуын, чөнки Газан ханның беркайчан да Идел буе Болгарстанына килмәве һәм аны белмәвен күрсәтә [2]. Тарихи чыганакларда да Газанның Болгар җиренә килүе турында сүз юк.

Туктамыш белән Аксак Тимер арасындагы сугышта (1390 еллар) Казан баһадир һәм Казанчы баһадир исемле гаскәр башлыкларының катнашуы билгеле [3]. Мәгълүм булганча, алар шәһәр салу белән шөгыльләнмәгәннәр, бәлки, киресенчә, тыныч, төзек шәһәрләрне вату, җимерү белән дан казанганнар. Р. Фәхретдинов: «Гомумән, Казан шәһәре ниндидер Казан хан тарафыннан салынган дигән фикер бу исемнәрнең (дересрәге, исем белән атаманың — Г. С.) тышкы лингвистик охшашлыгына гына нигезләнгән һәм фәндә кабул ителә алмый»,— дип язуы белән бик хаклы («Ташлар моңы». Казан, 1978. 173 бит).

5. Башкорт теле галиме, мәрхүм профессор Җ. Г. Киекбаев архивында «Казан» атамасының килеп чыгышын «каен» сүзе белән бәйләп аңлаткан язма бар (Бу турыда безгә профессор М. З. Зәкиев хәбәр итте). Җ. Г. Киекбаев моны дәлилләү өчен Башкортстандагы Казанлы авылының исемен нигез итеп ала һәм бу атама «каенлы», «каеннар күп үскән урын» дигән мәгънә белдерә дип карый. Шор телендә һәм хакас теленең койбал, сагай диалектларында «каен» сүзе «казың» рәвешле әйтелә. Без биредә «казың» сүзенең «Казан»га якын, охшаш булуын күрәбез. Ләкин бу факт кына әле «Казан» атамасының «казың» («каен»)нан алынган дип нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирми.

Беренчедән, безнең регионлардагы борынгы һәм хәзерге төрки телләрдә каен агачы төшенчәсен белдерү өчен каен һәм хуран (чувашча) сүзләре кулланыла.

Икенчедән, «каен күп үскән җир» төшенчәсен белдерә торган борынгы топонимнар безнең якларда иран телләреннән алынган «-сар» кушымчасы ярдәмендә ясалганнар. Мәсәлән, Татарстандагы берничә татар авылы Каенсар дип атала. Безнең карашыбызча, Каенсар топонимы Каенлы (Түбән Кама районындагы татар авылы) һәм Каенлык (Кукмара һәм Актаныш районнарындагы татар авыллары) исемнәреннән борынгырак. Моны түбәндәге фактлар раслап тора:

а) «-лы», «-лык» кушымчалы географик атамалар саф төрки (татар) топонимнары, ягъни алар бер телдә сөйләшүче кабилә яки халык формалашкач барлыкка килгәннәр;

б) гомумтөрки «-лы», «-лык» кушымчасы хәзерге татар топонимиясендә дә киң кулланыла. Алар үсемлек, агач, кош, хайван, балык, бөҗәк, минерал, корылма һ. б. белдерә торган исемнәргә ялганып килү юлы белән күп кенә топонимнар ясыйлар: Кыяклы, Камышлы, Зирекле, Баланлы, Каенлы, Керәнле, Каргалы, Чуртанлы, Чебенле, Кигәвенле, Балчыклы, Ташлы, Буралы, Тукмаклы, Тигәнәле, Бакалы, Чүпрәле, Баулы, Шомыртлык, Усаклык, Ташлык, Алмалык, Чиялек һ. б.;

в) «-сар» кушымчасы, киресенчә, хәзерге татар топонимиясендә продуктив түгел. Ул агач исемнәренә кушылу юлы белән ясалган субстрат топонимнарда гына диярлек сакланып калган борынгы форма. Мәсәлән, Карамасар — Апас районындагы татар авылы Юкәсәр — Зеленодольск районы Мулла иле авылының бик борынгы урамы. Имәнсәр кыры — Арча районы Түбән Көек авылының басу, Усаксар — Биектау районы Ташсу авылы янындагы урман, Колмаксар — Лениногорск районы Аланлык (Аналык) авылының колмак күп үсә торган урыны, Зирексәр — Арча районы Кызыл Утар авылының зирек агачлары күп үсә торган су буе исеме һ. б. Татарстанның Апас районында яшәүче подберезье керәшеннәре сөйләшендә комнаксар сүзе «колмаклык», түмгәксәр сүзе «түмгәклек» мәгънәсендә кулланыла. Каюм Насыйри Чабаксар шәһәре исеменең килеп чыгышы хакында болай дип яза: «Вә янә ул вакытта авылларыннан (Тутаркасы һәм Юртакасы дигән Казан ханлыгы чорында татар, аннан соң чуваш авылларыннан — Г. С.) берничә чакрым җирдә Идел яры өстендә бер кечкенә урманлык яки чыбыклык (кустарник дигән шикелле) җирләре бар икән. Үзләре чыбыксар дип әйтәләр икән, ягъни чыбыксар — күп чыбык үскән җир дигән мәгънәдә; хәзер дә әйтәләр куаксар, каенсар дип. Бу һәм шул мәгънәдәдер. Анда Иван Грозный Чабаксар каласын салгач та исеме һаман шул чыбыксар дигән сүздән ерак китмәгәндер» [4].

Өченчедән, Казанлы яки Казанлык атамаларының Казан елгасы бассейнында һәм Казан шәһәре тирәсендә урын алмавы игътибарга лаеклы факт. Башкортстандагы Ка-

---

[1] Стэнли-Лэн-пуль. Күрсәтелгән хезмәт. 201 б.

[2] Марджани Ш. Очерк истории Болгарского и Казанского царств.— Труды IV Археологического съезда в России, т. I. Казань, 1884, 41 б.

[3] Тизенгаузен В. Г. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. т. II. М.— Л., 1941, 131—135 битләр.

[4] Насыйри К. Сайланма әсәрләр. II том, Казан, 1975, 42—43 битләр.

занлы авылының исеме XVI—XVII гасырларда бирегә күчеп килгән казан татарлары-на мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килгән булырга тиеш. Түбән өлкәсенең Вагай районындагы Казанлы авылының исеме дә шушы фикерне раслый. Бу авылда нигездә тарлары казан татарларын, гомумән, касанлы дип йөртәләр. Татарстанның Башкорт-казан татарлары яшәгәнгә, себер татарлары аны Касанлы дип атаганнар. Себер та-стан белән чиктәш районнарында авыл халкын хәзер дә типтәр, башкорт, казан кешесе яки казанлы дип өчкә бүлеп йөртү гадәте бар.

Профессор Кирәй Мәргән Башкортстандагы Казанчы дигән авыл исемнәре җирле башкорт ыругы исеменә, ә Казанлы атамасы казан татарларына мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килгән дип карый («Кызыл таң» газетасы, 1969 ел, 11 сентябрь саны).

Шушы фактлардан чыгып, Казанлы дигән авыл исемнәре казан татарларына (ягъни этнонимга) мөнәсәбәтле рәвештә, чагыштырмача шактый соң барлыкка килгән дип санаймыз.

6. Тарих фәннәре кандидаты Һ. В. Юсупов: «Казан топонимы казан этнонимыннан (ыруг-кабилә исеменнән) килеп чыккан булса кирәк, элекке татарларда «Казан тау җыены» булу шулай дип уйларга этәрә. Билгеле булганча, аларда җыен—ыруг-кабилә төзелеше калдыгы»[1],— дип яза. Автор конкрет күрсәтмичә генә, «Казан» атамасы Кубаньда, Украинаның көньягында, Каспий диңгезенең төньяк-көнбатыш яры буйларында күп таралган, ди. Төркиядә Казан исемле шәһәр булуын искәртә һәм боларның килеп чыгышын төрекмәннәрнең казан-салор кабиләсе исеме белән бәйли. Кара диңгез һәм Азов буе далаларына казан кабиләсенең Төрекмәнстаннан килүе, аннан болгар кабиләләре белән бергә, Урта Идел буена күтәрелеп, соңыннан Казан ханлыгын төзүләре бик мөмкин дип саный.

«Казан тау җыены» булудан чыгып кына Казан каласы атамасының асылында казан этнонимы ята һәм ул төрекмәннәрнең казан-салор кабиләсеннән килә дип әйтү өчен җитәрлек фактлар юк.

Казан арты татарларында, Һ. В. Юсупов күрсәткән «Казан тау җыены»ннан тыш, Кала тау, Мукшы тау, Кара тау, Биек тау, Казак, Кушкапка, Яссы болын һ. б. җыеннар да булган. Әлеге җыен атамаларының кайберсенең нигезендә этноним яту ихтималы булса да (мәсәлән, «Мукшы тау җыены» атамасында), Кала тау, Биектау, Казан тау, Яссы болын, Кушкапка һ. б. җыен атамаларының асылында да этнонимнар ята дип әйтүе кыен. Безнең карашыбызча, Кала тау җыены үзенең исемен элек тә кала яки крепость (кальга) булган тау исеменнән, ягъни «Кала тавы» исеменнән алган. Кара тау, Биек тау җыеннары атамаларының асылында да тау исемнәре (микротопонимнар) ята. Яссы болын, Кушкапка җыеннары исеменең микротопонимнарга нигезләнеп ясалган булуы бернинди бәхәс тудырмый. «Казан тау җыены» исеменең килеп чыгышы да әлеге җыен үткәрелә торган таулы урын — Казан елгасының сулъягындагы сөзәк тау буйлары, ягъни Казан елгасы тавы исеме белән бәйләнешле булырга тиеш.

Һ. В. Юсупов кабилә исемен казан-салор дип күрсәтсә дә, чынбарлыкта төрекмәннәрнең әлеге кабиләсе салор исемен генә йөрткән. Казан-Салор шул кабилә җитәкчеләреннән бер шәхеснең исеме, аны икенче төрле Казан алып дип йөрткәннәр. Казан-Салор төрекмәннәрнең төп бабасы саналган. Угыз ханның алтынчы буыны булып исәпләнә: «...Казан-алып, аның әтисе Энкеш, аның әтисе Ата,, аның әтисе Тимер, аның әтисе Салор, аның әтисе Таг-хан, аның әтисе Угызхан»[2].

Күргәнебезчә, салор кабиләсенең исеме Угыз ханның оныгы Салор исеменнән алынган. Абулгази Баһадур ханның «Шәҗәрәи тәркмән» әсәрендә бу кабилә исеме һәр җирдә «салор ил» дип кенә (ягъни «казан-салор» дип түгел) бирелгән.

Казан атамасы Һ. В. Юсупов телгә алган урыннарда алай күп таралган дип әйтеп булмый. Мәсәлән, Кара диңгез һәм Азов диңгезе бассейнына караган 5200 елга арасында төрки исемнәре бик күп булса да, бер генә Казан исемле елга да юк. Бары тик Николаев өлкәсендә генә Казанка дигән район үзәге бар. Төрки халыкларның борынгы ватаны булган Алтайда һәм Көньяк Себердә исә, киресенчә, Казан гидронимы һәм ойконимы, аларның вариантлары байтак: Казанка, Казанду, Казан-кол— Алтайдагы елгалар, Казановка, Казановтар — Хакасиядәге елгалар. Борынгы төрки теленең Енисей ядкарьләрендә Казан (КЗН) сүзе топоним буларак кулланылган[3]. Казан яки Казанка гидронимы һәм ойконимы Урта Азиядә, Казагыстанда, Уралда һәм Түбән Идел буенда күп очрый.

Шушы фактларга таянып, Казан атамасы һәм аның вариантлары төрекмәннәрнең салор кабиләсе яки аның башлыгы Казан-Салор исеменә мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килмәгән дигән нәтиҗәгә киләбез.

7. Башкорт язучысы Йосыф Гәрәй «Уфа, Казан ни исемле» дигән мәкаләсендә Казан атамасының килеп чыгышы турында төрле фикерләр булуын әйтеп китә («Кы-

---

[1] Юсупов Г. В. Антропонимы в булгаро-татарской эпиграфике.— Личные имена в прошлом настоящем и будущем. М., 1970, 252 б.
[2] Кононов А. Н. Родословная туркмен. Сочинение Абу-л-Гази хана Хивинского. М.— Л., 1958. 70—74 битләр.
1962, 94 б.
[3] Батманов И. А., Аргачи З. Б., Бабушкин Г. Ф. Современная и древняя Енисейка. Фрунзе.

зыл таң» газетасы, 1970 ел, 4 сентябрь саны). «Казан — кеше исеме яки ыру исеме, алай булмаса, үлән исеме диясе килә»,— дип яза ул. Йосыф Гәрәйнең соңгы фикере безнең якларда казан сүзе борынгы заманнарда «су үләне» (үги ана яфрагы яки бака үләне) мәгънәсендә кулланылган булырга тиеш, дип фараз итүгә корылган. Әмма Казан сүзенең безнең җирлектә «үги ана яфрагы» яки «бака үләне» төшенчәсен белдерү өчен кулланылган булуы бу мәкаләдә тиешенчә дәлилләнмәгән. Үги ана яфрагының (Й. Гәрәйчә «казан үләне»нең) «казан җир»дә — түбәнлектә, чокырда, уйсулыкта үсүеннән чыгып яки, В. В. Радлов күрсәтүенчә, казан сүзенең телеут телендә «әрекмән», «бака үләне», «үги ана яфрагы» үләннәре исеме булып кулланылуына нигезләнеп кенә безнең бабаларыбыз борынгы заманнарда үги ана яфрагы, бака үләнен яки әрекмәнне «казан» дип атаганнар, әлеге үләннең исеме Казан елгасы һәм Казан шәһәре исеменә күчкән дип әйтә алмыйбыз.

8. А. Х. Халиков, борынгы төрки телдә кас, касикъ сүзләренең «кабык», «агач кайрысы», «тышча» мәгънәсен белдерүләреннән чыгып, кас сүзе татар телендә нечкә әйтелеш алып, «кәс» (дерн) мәгънәсенә ия булган һәм болгар чорында каз сүзе («Борынгы төрки сүзлек»тә «кас» дип бирелгән, А. Х. Халиков язганча, «каз» түгел — Г. С.) «кабык»ны гына аңлатмыйча, «чик», «кырый» мәгънәләрен дә белдергән дип карарга кирәклеген гөман итә. Каз сүзенең тагын да борынгырак формасы каш рәвешле булган булса кирәк, чөнки борынгы төрки телләрдә «каш» сүзе «кырый», «яр, чик» мәгънәсен белдергән, дип дәвам итә А. Х. Халиков һәм боларга таянып, «Казан» исеме борынгы болгарлар тарафыннан бирелгән һәм ул «чик» (граница) мәгънәсен аңлаткан, дип нәтиҗә ясый. Казан сүзе ике өлештән тора: каз (сүзнең нигезе) һәм -ан (суффикс), соңгысы борынгы төрки телләрдә урын, өлкә, территория төшенчәсен белдерә торган кушымча булган булса кирәк, ди ул[1].

А. Х. Халиков, В. В. Иванов һәм И. М. Ионенко, бергәләп язган брошюрада: «Төрки телләрдә кап ~ каб сүзе «савыт, сыешлык, территория» мәгънәсен белдергәнгә каб-ан эчке (керә торган) чикнең башын, «каз-ан» тышкы як чикнең башын белдергән булырга мөмкин»[2]— дип фараз итәлә.

Әмма болай гөман итү өчен тиешле тарихи-лингвистик нигез юк. А. Х. Халиков каш > каз (ш > з) күчешен тел аспектында бөтенләй дәлилләп тормый. «Борынгы төрки сүзлек»тә исә «каш» сүзеннән тыш «кыдыг» сүзенең дә «кырый, чик, яр» мәгънәләрен белдерүе теркәлгән (440 бит). Билгеле булганча, казан татарлары әлеге төшенчәне белдерү өчен чик сүзен кулланалар. Бу — бик борынгыдан килә торган болгар-татар сүзе. Тарихи-лингвистик фактлар шул турыда сөйлиләр. Борынгы болгар телендә чикъ ~ чига сүзе «чик, әйләндереп алынган урын, рубеж, окоп»[3] төшенчәсен белдергән. Чагыштырыгыз: чувашча — чике, нугайча, хакасча, шорча — чик; уйгурча — чәк, чәгара; үзбәкчә — чек, шегара; казакъча, каракалпакча — шек, шегара; төркмәнчә — чәк, карачай-балкарча, кыргызча — чек. Чегем — Кабарда-Балкариядәге елга исеме. Чегем гидронимы, беренче компонентын балкар телендәге чек «чик», ә икенче компонентын тува телендәге хем ~ гем «елга» сүзләренә бәйләп, «чик буе елгасы» мәгънәсен белдерә дип аңлаталар[4].

Идел-Кама болгарлары телендә «кабан» сүзе эчке як чик башы, «казан» сүзе исә тышкы як чик башы мәгънәсен белдерсә, башка болгар шәһәрләренең берәрсендә генә булса да әлегедәй географик атамалар сакланып калган булыр иде.

9. В. Л. Егоров «О времени возникновения Казани» дигән мәкаләсендә «Казан шәһәренә 1370 елда болгар князе Хәсән нигез салган һәм ул үзенең нигезләүчесенең исемен алган»[5] дип карый. Бу карашның тарихи яктан да, лингвистик яктан да нигезләнмәгән булуын тарихчылар да (С. Х. Алишев, Ә. Г. Мөхәммәдиев һ. б.), телчеләр дә (Р. Г. Әхмәтҗанов) күрсәтеп, тәнкыйтьләп чыктылар һәм кире кактылар[6].

Тюрколог И. Г. Добродомов һәм тарихчы В. А. Кучкин исә болгар-татар теленең тарихи-лингвистик фактларын, закончалыкларын бозып күрсәтү исәбенә булса да В. Л. Егоров карашларын якларга һәм акларга тырышалар. Казан атамасы «гарәби чыгышлы иң гади мөселман кеше Хасан»нан алынган дип таныган хәлдә, алар: «Казан формасы шактый борынгы болгар-чуваш формасы Хазанг > Хазанга кайтып кала, борын тартыгының башта тел арты тартыгы булуы югалгач, «нг» тартыгы «н» гә әверелгән. Татар телендә чуваш теленнән Хасан топонимын үзләштергән вакытта, әле күпчелек төрки телләрендәге кебек, «х» тартыгы булмаган, шуңа ул аны «к (къ)» тартыгы белән алмаштырган... Казан топонимы XIV гасырның икенче яртысында барлыкка килгән»[7],— дип язалар.

---

[1] Халиков А. Х. О времени, месте возникновения и названия города Казани.— Из истории культуры и быта татарского народа и его предков. Казан, 1976, 14 б.

[2] Иванов В. В., Ионенко И. М., Халиков А. Х. О времени возникновения и названия г. Казани. Казань, 1974, 15—16 битләр.

[3] Фехер Г. Ролята и културата на прабългарите. София, 1968, 153 б.

[4] Коков Дж. Несколько поволжских и других параллелей в адыгской ономастике.— «Ономастика Поволжья. 3», Уфа, 1973, 418 б.

[5] «Советская археология», № 4, 1975, 86 б.

[6] Алишев С. Х., Мухамадиев А. Г. Об одной ошибочной версии возникновения Казани.— Вопросы историографии и источниковедения. Казань, 1975, 124—127 б.; Ахметзянов Р. Г. О топониме Казань.— Вопросы историографии и источниковедения. Казань, 1975, 133—136 битләр.

[7] «Вопросы географии», сб. 110. Топонимика на службе географии. М., Изд. Мысль», 1979, 161—162 битләр.

Идел-Кама болгарларына X йөзләрдә гарәпләрдән кергән Хәсән исеменең нечкә әйтелешле булуы кабер ташы язмаларына теркәлеп сакланган [1]. Татарлар чуваш теленнән Хәсән топонимын үзләштергән вакытта, татар телендә «х» тартыгы булмаган дип караганда да, Хәсән исеме Кәсән рәвешен генә алган булыр иде [2]. Мәсәлән, себер татарлары әле дә татар әдәби телендә Хәсән, Хәсәнә дип әйтү норма булып саналган кеше исемнәрен Кәсән, Кәсәнә рәвешле әйтеп йөртәләр. Хәсән урынына Хасан, Хасаннан Хазан формасының барлыкка килүен шулай ук ясалма катлауландыру дип карарга мөмкин. Авторлар уйлаганча, чуваш теле тибындагы иске болгар телендә, ике сузык аваз уртасында килгәндә саңгырау «с» тартыгы яңгырау пары «з»га күчү нәтиҗәсендә Хасаннан Хазан барлыкка килсә, чувашлар Казанны хәзер дә Хазан рәвешле әйтерләр иде. Болгар-татарларга гарәп һәм фарсы телләреннән кергән (Хәсән, Хәсәнә, Халисә һ. б.) кеше исемнәрендә интервокаль позициядәге саңгырау «с» тартыгының «з»га күчү очраклары юк.

Димәк, Хәсән исеменнән Казан полисонимын китереп чыгару өчен тарихи-фонетик җирлек юк.

10. Без Казан шәһәре исеменең килеп чыгышын, Татарстанның җир-су исемнәрен (конкрет әйткәндә, составларында каз-кар сүзе булган: Каз иле, Кар иле, Казкаш, Казанер, Карлы һ. б. географик атамаларны) анализлауга нигезләнеп, Казан шәһәренең исеме Казан елгасы исеменнән алынган, Казан гидронимы исә, үз чиратында, борынгы төрки каз кабиләсе исеменә (этнонимына) нисбәтле рәвештә барлыкка килгән һәм «каз кабиләсе елгасы», «каз кабиләсе яши торган төбәктәге елга» төшенчәсен белдерә дигән карашны алга сөргән идек [3].

Бу караш галимнәр арасында төрле фикерләр уятты. Профессор А. Х. Халиков Татарстан җирлегендә болгарларга кадәр үк борынгы төрки каз кабиләләре яшәвен, бу кабиләләрнең, Урта Иделгә болгарлар килгәч, алар составына кушылып китүен инкарь итеп: «Каз кабиләләре мифик, алар булмаган» [4],— дип язды. Биредә шуны күрсәтеп үтәргә кирәк: XX йөз башында ук Н. А. Спасский әйтелеше ягыннан без сүз алып барган каз кабиләсе атамасына исеме бик якын, охшаш булган каҗи (рус орфографиясендә каджи) кабиләсе турында: «Идел болгарларының каджи исемле кабиләсе Казанка елгасы буенда яшәгән һәм XII гасырда аларның князьләре Казан-хан Иске Казан шәһәрен нигезләгән, бу шәһәр 275 ел яшәгән» [5],— дип язып чыкты.

Профессор М. З. Зәкиев исә: «Г. Саттаровның «каз» тамырын «каз» дигән кабиләләр белән бәйләве (А. Халиковның каз кабиләләрен мифик дип игълан итүенә карамастан) этнонимнарның лингвистик системасына ныграк туры килә. Казан яки каз сүзе белән бәйләнгән топонимнар һәм этнонимнар да бик күп. Андый топонимнарны Көнчыгыш Европада һәм СССРның Азия өлешендә генә дә А. Х. Халиков 50 дән артыкны саный. Каз тамырыннан булган этнонимнар исә түбәндәгеләр: хазар (әрмән чыганакларында — казар), казакъ, кыргыз (кырказ)... Каз сүзен гомумән «күчеп йөрү» (кочевать) мәгънәсен бирә торган берәмлек дип караучылар да бар... Күчмә казларны, кыр казларын кайбер төрки кабиләләр тотем, ягъни үзләренең нәсел башлары дип уйлаганнар һәм үзләрен каз дип атаганнар. Моның шулай икәнлеген без кыу кабиләләренең булуы белән дә исбатлый алабыз. Кыу борынгы төрки теленең бер диалектында шул ук кыр казы мәгънәсен биргән. Шушы сүзгә нигезләнгән этнонимнар системасы бар: кыу кеше, кыуман (кыубән), кыуманды, кыуар, кыучак (кыпчак). Казан шәһәре тирәсендәге топонимнарда каз (Казан) һәм кыу (кыубан, кабан) тамырының икесенең дә булуы каз сүзенең бу очракта «чик» мәгънәсендә түгел, ә «кыр казы» мәгънәсенә кайтып калуын исбатлый. Ә каз кабиләләре кайдан килгән соң? Безнең уебызча, бу тирәләргә, болгарларга кадәр үк, хазарлар (казарлар) килеп урнашкан булган. Шул казарларның тору урыны булганга, торак урыны да, елга да Казан дип атала башлаган булырга тиеш» [6],— дип язып, безнең карашка кушыла, аны хуплый, тагын да тулыландыра һәм үстерә.

Элегрәк язылган хезмәтләребездә бәян ителгән карашыбыздан баш тартмыйча, аны Казан шәһәре атамасы этимологиясенең дөреслеккә туры килүе мөмкин булган бер варианты дип саныйбыз. Алга таба сүз Казан полисонимының килеп чыгышына карата яңа бер гипотеза турында барачак.

11. Төрки телләрдә тау-чокыр һәм су чыганакларын аңлатучы сүзләрнең «җир эченә уеп керү», «җирне казып керү», «җирне чокырайту» төшенчәсенә кайтып кала

---

[1] Карагыз: Юсупов Г. В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. М.—Л., 1960, 2 нче таблица. Хакимзянов Ф. С. Язык эпитафий волжских булгар. М., 1978, 189 б.

[2] Чувашлар гарәби чыгышлы Хәсән («яхшы, иң шәп, матур, чибәр») исемен Касан рәвешле үзләштергәннәр. Карагыз: Л. В. Данилова. К изучению арабо-иранских элементов в чувашской антропонимике.— II Сб.: Диалекты и топонимия Поволжья. Чебоксары, 1980, 132 б.

[3] Бу турыда тулырак мәгълүматларны карагыз: Саттаров Г. Ф. Топонимика края и некоторые вопросы этногенеза казанских татар.— Татар тел белеме мәсьәләләре, III китап, КДУ нәшрияты, 1969, 175—180 битләр; аныкы ук. Происхождение названия Казань.— «Ономастика Поволжья, 2», Горький, 1971, 155—165 битләр.

[4] Халиков А. Х. О времени, месте возникновения и названия города Казани.— Из истории культуры и быта татарского народа и его предков. Казань, 1976, 13 б.

[5] Спасский Н. А. Очерки по родиноведению. Казанская губерния, 1913, Казань, 218 һәм 232 битләр.

[6] Зәкиев М. З. Татар халкы теленең барлыкка килүе. Казан, 1977, 93 б.

торган бербөтен система тәшкил итүләренә һәм төрки тел закончалыкларының җирле топонимиядә чагылышын анализлауга таянып, Казан елгасының атамасы (җирне) казыган>казган>казан терминына нигезләнеп ясалуы һәм әлеге елга буенда барлыкка килгән шәһәргә дә Казан дигән исем бирелүе турында инде матбугатта язып чыккан идек[1]. Биредә шушы фикерне тарихи-лингвистик-ономастик аспектта тагын да ныграк дәлилләргә алынйык.

Иң элек шәһәр исеменең икенчел, ә елга атамасының беренчел булуы мәсьәләсе бәхәсле тоелырга мөмкин. Топонимика фәне мәгълүматларына караганда, башлыча зур һәм урта зурлыктагы елга исемнәре бик күп очракта тарихи-административ объект булган торак пунктлар исеменнән борынгырак. Менә шуңа күбесенчә елга исемнәреннән шәһәр исемнәре барлыкка килгән: мәсәлән, Мәскәү елгасы исеменнән Мәскәү шәһәре исеме, Воронеж елгасы исеменнән Воронеж шәһәре исеме, Самара елгасы исеменнән Самара (хәзерге Куйбышев) шәһәре исеме һ. б. ясалган. Тарихи язмалар Казан шәһәре исеменең дә Казан елгасы исеменнән алынуын хәбәр итәләр[2].

Төрки телләрдә тау, чокыр, су атамалары бербөтен семантик кыр тәшкил итә дигән идек. Мәсәлән, уй — җирне ую, шуннан: уйсу җир, уйсулык (Тобол елгасына коючы Уй дигән елга бар); уба — җирне убу, шуннан Уфа елгасы, упкын сүзләре ясалган; ермак, ерганак — җирне еру, ерту; чокыр — җирне чуку (чоку), казу, ягъни чукылган, казылган җир, урын; ор — җирне ыру, ермау; сыза — җирне сызу, уентыклы итү; инеш — җиргә иңеп керү, шуннан иңкү җир, иңкүлек; казан — җирне казу, җирне казып керү һ. б.

«Казан» гидронимы ике өлештән тора: каз — сүзнең тамыры һәм -ан үткән заман сыйфат фигыль формасы. Шушы тамырдан татар телендәге казык, казылма (шуннан Татарстанның Буа районындагы Казма<Казылма авылының атамасы), казылдык, диалектларда казыма (лом), казан (су төбендә барлыкка килгән чокыр, чоңгыл) сүзләре ясалган. Борынгы заманнарда Монголиядәге Чаа-Холь елгасы буендагы уйсулыклы урын Казан исемен йөрткән[3]. Кыргызстанда Джерказар исемле елга һәм авыл бар.

Тюркологлар «-ан» кушымчасы үткән заман сыйфат фигыль ясаучы «-ган -кан» кушымчасыннан килеп чыккан дип санparam[4]. Бу кушымча белән ясалган борынгы төрки топонимнар һәм кеше исемнәре шактый күп һәм алар билгеле бер ономастик система тәшкил итә. Мәсәлән, Сасаган, Джуган (Жуган), Кучурган, Кабан, Ташан — Урта һәм Түбән Днепр бассейннарындагы елгалар; Кабан — Казан шәһәрендәге зур күл; Шуган, Баскан һ. б. — Татарстандагы татар авыллары; Боерган, Сатылган, Караган, Ишәйгән, Табылган, Теләгән һ. б. — борынгы төрки-татар кеше исемнәре һ. б.

Профессор Н. А. Баскаков та Казан шәһәре исеменең асылында төрки-татар казан (котловина, котел) <каз (копать)+ан (аффикс) сүзе ята дип карый[5]. Соңгы вакытта М. З. Зәкиев тә Казан, Казар, Каспий, Казбек, Кавказ атамалары составында урын алган каз компонентының килеп чыгышын казу («копать») сүзенә кайтып калса кирәк дигән карашны алга сөрә[6].

Димәк, Казан елгасының исеме, «(җирне) казыган елга» мәгънәсен белдергән хәлдә, мәгълүм фонетик үзгәрешләр кичереп, «Казан» әйтелешен алган, дигән нәтиҗәгә киләбез. Болгар бабаларыбыз тарафыннан аның буена салынган кала да елга исеменә нисбәтле рәвештә Казан каласы дип аталган.

---

[1] «Социалистик Татарстан», 1978, 17 февраль.

[2] Карагыз: Курбский А. М. Избранные сочинения. СПб., 1902, 18 б.; Казанская история. М., 1954, 128 б.; Әхмаров Г. Казан тарихы. Казан, 1910, 18 б.

[3] Древнетюркский словарь, 439 б.

[4] Карагыз: Алпаров Г. Сайланма әсәрләр. Казан, 1945, 65 б.; Баскаков Н. А. Каракалпакский язык, т. II. М. — Л., 1952, 397 б.; Кононов А. Н. Грамматика современного турецкого литературного языка. М. — Л., 1956, 251 б.

[5] Баскаков Н. А. Тюркизмы в названиях московских улиц. — «Советская тюркология», № 2, 1979, 29 б.

[6] Карагыз: Зәкиев М. З. Татарское языкознание 70-х годов в свете достижений советской лингвистики. — Сб.: Проблемы типологии татарского и русского языков. Казань, 1980, 37 б.

# ЯКТЫ ТӘРӘЗӘЛӘР УРМАНГА КАРЫЙ...

Художник Шишкинның мәһабәт нарат урманы буендагы алтын иген басуын тасвирлаган «Арышлар» исемле әсәрен һәм кояшлы таңда балаларының уйнавын сагалап торучы аюны сурәтләгән «Нарат урманында иртә» дигән атаклы картинасын без балачактан ук беләбез. Алар табигатьтәге могҗизалы матурлыкны аңларга өйрәтәләр, бөек Ватаныбызга карата олы мәхәббәт хисләре тәрбиялиләр. Шишкин картиналары безгә Пушкин һәм Тукай шигырьләре, Чайковский һәм Сәйдәшев моңнары шикелле үк якын. Аның әсәрләре аша без гади кешеләрнең хис һәм омтылышын тоябыз, күңелне иркәли торган гүзәллек белән очрашабыз.

Шишкин — чын мәгънәсендә халык художнигы, безнең горурлыгыбыз. Табигать җырчысы булган бу олы художникның дөньяга карашы рус культурасы чәчәк аткан, халыкның революцион кузгалышы көчәя барган елларда формалаша.

XIX гасырның икенче яртысында илебез сынлы сәнгате зур үзгәрешләр кичерә. В. Перовның «Өчәү», В. Суриковның «Бурлаклар Иделдә», И. Репинның «Запорожье кешеләре» кебек атаклы әсәрләре әнә шул чорда иҗат ителә. А. Венецианов һәм Г. Сорока беренчеләрдән булып туган як табигате мотивларына мөрәҗәгать итәләр. И. Левитанның рус табигатенә дан җырлаган мәшһүр әсәрләре пейзаж юнәлешендә эшләүче яшь буынга яңа юллар ача.

Шушы күәтле рәссамнар белән бер чорда илебезнең данлы улы Иван Иванович Шишкин да иҗат итә. Сәнгать дөньясында аның хезмәтләре аерым бер урын алып тора. Рәсем остасының картиналарында Ватан образы бөтен киңлеге белән — эпик һәм монументаль сыйфатлар аша ачыла.

И. И. Шишкин 1832 елның гыйнварында Алабуга шәһәрендәге артык бай булмаган купец гаиләсендә дөньяга килә. Әтисе Иван Васильевич югары культуралы һәм мәгълүматлы кеше була, фәнне ярата, тарих белән кызыксына һәм хәтта үзләренең шәһәре турында китап та бастырып чыгара. Булачак рәссам уңайлы шартларда тәрбияләнеп үсә, кечкенәдән үк рәсем ясау белән «җенләнә». Әтисе Казан гимназиясенә биргәннән соң, ул үзе кебек сәнгатькә гашыйк балалар белән дуслашып китә, алар бергәләшеп төрле-төрле рәсемнәр ясый башлыйлар.

Малайның кечкенәдән рәсемчелек белән мавыга башлавына, ихтимал, калын яшел урманнарга бай булган Идел-Кама якларының матурлыгы да сәбәп булгандыр. Табигатьне ул кечкенәдән үк ярата. Сокланып кына калмый, аны җентекләп өйрәнә дә. Кулындагы альбомына үзе яраткан күренешләрне төшерә. Тәкә яр буена урнашкан Алабуга тирәсендәге нарат урманнары, су буе манзаралары, зәңгәр киңлекләр булачак останың фикерләү сәләтенә зур йогынты ясый. Туган җиренең гүзәллеге аны, кызыктырып, сәнгатьнең серле һәм авыр сукмагына алып килә. Унтугыз яшьлек егет, якты хыяллар белән дәртләнеп, Мәскәүнең сынлы сәнгать һәм архитектура училищесына укырга керә. Биредә ул беренче тапкыр танылган осталарның әсәрләрен күрә. Айвазовский картиналары аны таң калдыра. «Әгәр аның рәсемендәге таулар һәм диңгезләр шулай яхшы икән, бездәге кыр һәм урманнар алардан кай җире белән ким булырга тиеш соң...» — дип фикер йөртә егет.

Дүрт ел уку дәверендә Иванның йыклы һәм максатчан характеры, эшкә булган гаҗәеп сәләте формалашып өлгерә. Җәйге каникул вакытларында ул әтисе йортына кайта, Алабуга тирәсендәге урыннарны рәсемгә төшерә.

Ниһаять, 1856 елда Шишкинның хыялы чынга аша — ул Петербургтагы сәнгать

академиясенә укырга алына. Беренче шатлыклар һәм сайланган тормыш юлының дәреслегенә беренче шикләнүләр була. Әмма борчулы тойгыларны бер-бер артлы килгән уңышлар каплап китә — аның хезмәтләре көмеш һәм алтын медальләр белән бүләкләнә.

1860 елда Академияне тәмамлаганнан соң ул чит илгә командировкага бару хокукын ала. Ләкин художник ашыкмый. Ул 1861 елның язында Алабугага кайта. Кадерле туган яклар. Шишкин яңадан илһамланып эшкә тотына: шәһәр һәм Кама тирәләрен рәсемгә төшерә, Болгар ягын сурәтли, Казан тирәләреннән этюдлар яза.

Алдагы елның язында ул үзенең ике дусты белән чит илләргә чыгып китә. Укырга, эшләргә, көнбатыштагы музейлар белән танышырга ниятләнәләр алар. Шишкин, сәнгать академиясе пенсионеры буларак, 1862—65 елларда Дрезден, Мюнхен, Прага, Цюрих, Лейпциг һәм Дюссельдорф шәһәрләрендә була, пейзаж осталыгы серләрен үзләштерә. Ләкин рәссам туган ягын сагыну хисләреннән арына алмый. Өч ел йөргәннән соң ул вакытыннан алда, Россиягә, үзенең Алабугасына кайта һәм анда дәртләнеп эшкә керешә. Ул чактагы язмалар рәссамның зур программалы картиналары өчен хәзерлек материалы булып хезмәт итәләр.

Шишкин Германиядә яшәгән чакта Петербургның мәдәният тормышында зур вакыйга була. Ул вакытларда сәнгатьтә өстенлек алган академик юнәлеш тарафдарлары белән килешмичә, демократик рухлы яшь рәссамнар, «Художниклар артеле» дигән оешма төзиләр. Аның җитәкчесе И. Н. Крамской була. 1871 елда ул оешма «Күчмә күргәзмәләр иптәшлеге» дип үзгәртелә. Бу оешма вәкилләренә Белинский, Добролюбов һәм Чернышевскийларның революцион эстетикасы зур йогынты ясый.

Илгә кайткач Шишкин әлеге Иптәшлекнең член-учредителе (оештыручысы) була һәм үзе дә күчмә күргәзмәләрдә актив катнашып килә. Шул дәвердә аңа танылу да килә: 1865 елда инде аңа академик дәрәҗәсе бирәләр, ә 1875 елдан ул профессор исемен йөртә башлый.

Ул елларда иҗат ителгән картиналарында Шишкин Кама буе табигатенә, үзенә таныш булган мотивларга еш мөрәҗәгать итә.

1878 елгы күчмә күргәзмәдә Шишкинның «Арышлар» дип аталган яңа картинасы — иң яхшылардан саналган эше күрсәтелә. Бу — матурлыкка гимн, кешенең хезмәтенә мәдхия җырлау. Әлеге картина Алабуга янындагы бай иген кырларында күргән тәэсирләр йогынтысында языла. Алтын арышлар шулкадәр җанлы итеп бирелгән — аз гына җил истеме, менә-менә тирбәлә башларлар шикелле. Кырны бүлеп торучы чәчәкле-үләнле юл өстендә карлыгачлар уйнаклый, офыкта болытлар сизелмәнә... Рәссам яшенле яңгыр алдыннан була торган билгеләрне һәм көннең торышын ышандырырлык итеп бирә алган. Офыкка тоташкан иген кыры уртасындагы наратлар исә рәсемгә мәһабәтлек, мәгърур иркенлек өсти.

Үзенең «Урман киңлекләре» (1884) дигән картинасын Шишкин төньяк Урал тауларына, аның куе урманнарына багышлый. Иртәнге томан һәм тонык кояш нурлары белән уратылган урман күле картинага аерым бер гүзәллек өсти.

«Нарат урманындагы иртә» (1889) әсәре — чын мәгънәсендә халыкчан картина, рәссам иҗат иткән хезмәтләр арасында иң популяры, иң уңышлысы. Алгы планга ауган агач тирәсендә кайнашучы аюлар гаиләсен куе һәм бераз арттарак мәһабәт горур наратларны сурәтләү әсәрне бер карауда истә калырлык итә. Урманның салкынча һавасын тойгандай һәм көмеш чыкларын күргәндәй буласың, хәтта...

Шишкин күбрәк җәйге мотивларны сурәтли. Ләкин аның «Кыш» (1890) дигән картинасы да бар. Әнә, зәңгәрсу күк астында ап-ак карлары белән оеп утырган урман кышкы әкиятне хәтерләтмимени!

1891 елның көзендә сәнгать академиясе залларында Репин белән Шишкинның берләштерелгән юбилей күргәзмәсе ачыла. Шишкин анда 555 эшен тамашачылар хөкеменә куя. Күргәзмә зур уңыш белән уза.

«Алабуга янындагы Афанасий әрәмәсе» (1898) дигән картина останың соңгы эшләреннән берсе була. Ул Кама буе урманнары «хуҗа»сының саубуллашу җыры булып та исәпләнә. Әсәр зур бер иҗатчы гомеренең йомгагы рәвешендәрәк кабул ителә.

Шишкинның иҗат юлы Казан белән дә нык бәйләнгән. Иҗатының башлангыч чорында ук художник Казан коллекционеры А. Ф. Лихачев белән дуслаша. Җәйләрнең

берсендә аның Березовка авылындагы утарында кунакта да була, анда күп кенә рәсемнәр ясый. Нәкъ менә Андрей Федоровичның тырышлыгы белән Шишкинның кайбер этюдлары коллекционерның картиналар галереясенә керә, ә инде 1895 елда алар яңадан ачылган шәһәр музеена бүләк ителәләр. Художникның «Үзәнлек юлы», «Тегермән», «Шалаш» дигән бу беренче этюдлары хәзер Казанда саклана.

Казанда сәнгать мәктәбе ачылу уңаеннан, Шишкин күргәзмәгә ике картинасын — «Дачада» (1891) һәм «Урман аланы» (1897) әсәрләрен җибәрә. Соңгысы гаҗәеп дәрәҗәдә матур һәм гади. Кояшлы зәңгәр күктәге каурый болытлар зур осталык белән ясалган, яшел төсләр гармониясе исә күңелдә якты хисләр уята. Бу аланны, бу ачыклыкны без кайдадыр күргәнбездер шикелле. Әйе, ул — безнеке, Казан һәм Идел буйларыныкы!

Казандагы сәнгать мәктәбенә рәссам тагын «Урман», «Теке яр», «Урман юлы» дигән хезмәтләрен дә бүләк итә. Хәзер алар республикабызның сәнгать музее коллекциясендә саклана.

Югарыда әйтелгәннәрдән тыш, безнең музейда художникның «Алабуга» янсә «Имән урманы буенда» (1874) дип йөртелә торган таң калырлык әсәре саклана. Никадәрле тәэсир көче анда! Реалистик буяулар белән сугарылган бу картина безне бөтенләе, конкретлыгы белән әсир итә. Мәһабәт имәннәр, урман итәгендәге крестьяннар, янып торган учак янындагы арбалар бу картинага тормышның үзеннән килеп кергәннәр...

«Нарат урманында кич» (1875) әсәре яңгырдан соң баеп баручы кояшны гаҗәеп нәфислек белән күрсәтеп бирә. Күп еллар буе Алабугада шәхси җыелмада сакланган бу картина шулай ук безнең музей залын бизи.

Сынлы сәнгать белән беррәттән, рәссам графика өлкәсендә дә күп эшли. Оста офортчы һәм литограф буларак, ул каләм-карандаш, тушь, акбур белән ташка һәм кәгазьгә рәсемнәр ясый. Аның мондый рәсемнәре чит илләрдә дә дан казандылар.

Гомеренең соңгы елларында, сәнгать академиясенең пейзаж мастерское җитәкчесе буларак (1894—1895), Шишкин нәтиҗәле педагогик эшчәнлек тә алып бара, талантлы рәссамнар тәрбияли.

1898 елның язында йөрәк өянәге бер кулына мольберт тактасы, икенче кулына пумала тоткан бөек рәссамның гомерен өзә. Бу вакытта аңа алтмыш алты яшь була.

Шишкин — рус пейзаж сәнгатенә нигез салучыларның берсе, бу юнәлештә яңа офыклар ачкан рәссам. Ул — урманның, табигатьнең җанын аңлауда тиңдәшсез белгеч. Урман шигъриятен сурәтләүдә Шишкин ирешкән биеклекне аңа хәтле һәм аннан соң да яулый алган рәссам булмады. Ул Россия һәм безнең як урманнарының бөек җырчысы иде. Рәссамның сәламәт һәм шат күңелле сәнгате аның үз рухы, табигате һәм оптимистик холкы белән тәңгәл килә.

Замандашларының истәлекләре буенча рәссам урман баһадиры булып күз алдына килеп баса. «Гайрәтле, киң җилкәле, дулкынланыбрак торган чал чәчле... Йөзендә йомшак елмаю... Аның образы шундый иде»,— дип искә алалар аны. Икенче бер замандашы Шишкинны төп кебек таза, арыслан ялыдай чәчле, киң колачлы һәм көчле тавышлы, рәхәтләнеп елмая-көлә белүче кеше итеп тасвирлый.

Үзенең өлкән иптәше турында Репин менә ничек сокланып яза: «Барыбызныкыннан да куәтлерәк булган баһадир И. И. Шишкинның тавышы яңгырый; мәһабәт яшел урман шикелле, ул безне сәламәт елмаю һәм дөрес сөйләме белән яулап ала иде...

Эшли-эшли йөк ташучыныкы кебек сөялләнеп, бирчәеп беткән бармаклары белән үзенең рәсеменә буяулар төшерә... Шундый тупас хәрәкәтләрдән соң рәсем ниндидер могҗиза белән нәфис һәм сокландыгыч рәвешкә керә».

Шишкин иҗатын күчмә күргәзмә мәктәбендәге хезмәттәшләре дә югары бәяләделәр. Бу мәктәпнең рухи җитәкчесе Крамской белән дә алар якын дус булалар, еш кына бергә эшлиләр. Крамской урманнар «хуҗасы» булган дустының өч портретын ясаган икән, бу һич тә очраклы хәл түгел.

Якташыбыз Шишкин турында уйланганда безнең күз алдына Крамской тарафыннан иҗат ителгән рәссам образы килеп баса. Ул кояш нурларында коенучы куе яшеллек фонында сурәтләнгән. Биек үкчәле итектән, ачык костюмнан, киң эшләпәдән, этюдниклар һәм зонт тоткан килеш басып тора. Күзләрен кыса төшеп, ерак киң-

лекләргә карый, әйтерсең, киләчәктә ясый торган картинасына материаллар җыя.

Әйе, Иван Иванович Шишкин яшүсмер елларыннан ук кулына этюдниклар алып, аркасына рюкзак асып, табигать кочагына чыгарга ярата. Алабуга тирәсендәге төбәкләрне, Кама буендагы гүзәл каеннылыкларны, Мәскәү янындагы урманнарны йөреп чыга, үзенең полотноларына кирәкле дип тапкан төсләр, мотивлар, манзараларны сайлый. Рәссам фәкать натурадан ясарга дигән бердәнбер кагыйдәгә буйсына һәм аңа беркайчан да хыянәт итми. Табигатькә баш ию, этюдниклар белән эшләү аның иҗат методының нигезен тәшкил итә. Табигатьне шулай җентекләп өйрәнү, әсәрләре өчен бөртекләп материал җыю Шишкинга чын мәгънәсендә сәнгатьчә дөреслекне күрсәтергә мөмкинлек бирә.

Пейзажчылар яшел табигатьне сурәтләү никадәр авыр икәнлеген яхшы беләләр. Кайберәүләр хәтта җәи төсләрен «читләтеп» узарга тырышалар. Шишкин исә бу бурычны искитәрлек кыюлык белән башкарып чыга. Аның табигать сурәтләренә күз салыгыз: төсләр гармониясе, яшел дөньяның катлаулы төсмерләре ифрат зур нечкәлек, нәфислек белән үреп бирелгән.

Урман — Шишкинның сәнгать патшалыгы. Ул аңардан үзе яраткан мотивларны, матур образларны эзләгән һәм тапкан, агачларның төзелешен тирәнтен өйрәнгән. Урман тормышы — үсемлекләр дөньясы, ешлыклар, аланлыклар, аулак урыннар — болар һәммәсе дә аның стихиясе.

Рәссамның әсәрләрен беләләр һәм яраталар. Һәркайда аның хезмәтләреннән репродукцияләр очратырга мөмкин. Шишкин — халык хөрмәтен казанган рәссам. Бу уңышның сере нәрсәдә соң?

Барыннан да элек — һәркем өчен балачактан ук газиз һәм кадерле булган туган якның шигъри урыннарын күңелгә үтеп керерлек дәрәҗәдә тасвирлау осталыгында. Икенчедән, рәссам иҗатының образлылык, зур дөреслек, төгәллек, яхшылык рухы белән сугарылуында, тасвирлау алымнарының халыкчанлыгында. Шишкин олысыннан алып кечесенә кадәр — балаларга да, зурларга да ошый, төрле һөнәр ияләренә аңлашыла. Ул үзенең иң яхшы хезмәтләрендә тормышның һәм туган җирнең матурлыгын, мәһабәтлеген сәнгатьчә раслауга, образларны гомумиләштерүгә ирешә. Аларда — героик башлангыч, яшәү көче. И. И. Шишкин әсәрләре 1870—90 еллардагы рус культурасында халыкчан характерлар өчен барган көрәштә әһәмиятле роль уйнады.

Шишкин үзенең иҗатын ике гасыр чигендә — сәнгатьтә ике төрле караш — күчмә күргәзмәчеләр белән «сәнгать дөньясы» вәкилләре арасында кискен көрәш башланган чорда тәмамлый. Соңгы агым тарафдарлары аның полотноларының әһәмиятен кечерәйтеп күрсәтергә тырышалар, аны натурализмда, шигъриятлек җитмәүдә гаепләләр. Әмма алар хаклы түгел иде.

Шишкин хәзер дә пейзаж сәнгатенең иң оста вәкиле булып кала. Рәссамның бай мирасы һәм халыкның әлеге мираска булган ихлас мәхәббәте әнә шул хакта сөйли. 1948 елда Третьяков галереясында Шишкин әсәрләреннән оештырылган күргәзмәдә мең да остаһың өч йөзләп картинасы куелган хәзинә белән танышырга туры килде. Зал тамашачылардан өзелеп тормады, күргәзмә искиткеч зур уңыш белән барды — олы сәнгатьнең якты бәйрәме иде бу!

Шишкин яклары — әкияти матурлык иле. Анда хәзер дә мәгърур наратлар үсә, офык буйлап урманнар һәм алтын иген басулары сузылган. Әмма Кама буйлары зур үзгәреш кичерде. Горур елга ярларында яңа шәһәрләр үсеп чыкты. Бередән илебезнең барлык төбәкләренә КамАЗ машиналары юл ала. Чаллы янәшәсендә икенче бер яшь-яшь шәһәр — Түбән Кама калыкты. Атаклы художникның якташлары, мул сулы елганы буып, зур ГЭС төзеделәр. Кама өстендә чал дулкыннар чайкала, тизйөрешле лайнерлар су яра, баш өстендә акчарлаклар әйләнә...

Шишкин туган Алабуга шәһәре дә үсте, үзгәрде. Күптән түгел ул үзенең 200 еллыгын бәйрәм итте. Патша империясенең Трехсвятское дип аталган элеккеге бер почмагы бүгенге көндә Совет Татарстанының промышленность, уку һәм культура үзәгенә әверелде.

Алабугада И. И. Шишкинның музее ачылды. Ул художник туып-үскән, балачак һәм яшьлек елларын уздырган йортта урнашкан. Бина яхшы сакланган, бүлмәләре реставрацияләнгән. Музейны карарга ел саен меңнәрчә кешеләр килә. Бередә Чехосло-

вакия, ГДР, Франция, АКШ һәм башка чит илләрдән кунаклар еш була. Шишкин яклары кешеләрне юмарт матурлыгы, җылы һәм ягымлы елмаюы белән үзенә тарта.

И. И. Шишкинның тууына 150 ел тулу уңаеннан партия, совет оешмалары һәм республикабыз иҗат коллективлары вәкилләреннән республика юбилей комиссиясе төзелгән иде. Инде байтак кына эшләр башкарылды. Алабугада киң җәмәгатьчелек һәм Татарстан иҗат оешмалары катнашында җыелыш үткәрелде. Останың истәлеген мәңгеләштерү йөзеннән Казан кинохроника студиясе «Киң Иделдә» киножурналы өчен махсус чыгарылыш әзерли. Алабугадагы сәнгать мәктәбенә И. И. Шишкин исеме бирелде, Казан урамнарының берсе шулай ук бөек рәссам исемен йөртә. Алабуга шәһәрендә киләчәктә якташыбызга һәйкәл куелачак. Татарстан сынлы сәнгать музеенда атаклы художник әсәрләреннән зур гына күргәзмә оештырылачак.

Бүген, данлы якташыбызның тууына 150 ел тулуны билгеләп үткәндә, совет кешеләре аның таланты каршында баш ияләр, титаник эшчәнлегенә, сәнгать һәм туган ил хакына барлык гомерен багышлавына хөрмәт белдерәләр. Шишкин — рәсем сәнгате күгендә якты бер йолдыз, аның яктысы безнең өчен көннән-көн нурлырак, ягымлырак, кадерлерәк була бара.

**ХАРИС ЯКУПОВ,**
СССРның халык художнигы.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ФӘННИ-ПРАКТИК КОНФЕРЕНЦИЯ

КПСС өлкә комитетының Политик мәгариф йортында республика партия-хуҗалык һәм идеология активының КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре, СССР Верховный Советы Президиумы Председателе Л. И. Брежневның «Истәлекләр» дигән әсәрен тикшерүгә багышланган фәнни-практик конференциясе булды. Конференциядә катнашучылар алдында «Истәлекләр» турында КПСС өлкә комитетының беренче секретаре Р. М. Мусин чыгыш ясады.

Фикер алышуда түбәндәге иптәшләр катнашты; Э. А. Канчурин — КПССның Киров райкомының беренче секретаре; Г. А. Ахунов — ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе; Н. В. Фролов — фрезерчы, Социалистик Хезмәт Герое; Р. Г. Балтанов — профессор, С. В. Курашов исемендәге Казан дәүләт медицина институтының философия кафедрасы мөдире; В. К. Скороходкин — халык депутатларының Вахитов район Советы башкарма комитеты председателе; Ф. Ә. Илдарханова — ВЛКСМ өлкә комитеты секретаре.

Конференция эшендә КПСС өлкә комитеты бюросы членнары һәм членлыкка кандидатлар катнашты.

## ТАТАРСТАН ЖУРНАЛИСТЛАР СОЮЗЫНЫҢ IX СЪЕЗДЫ

19 ноябрьда Казанның Пресса йортында Татарстан Журналистлар союзының IX съезды булды.

Журналистлар союзы идарәсенең отчет чорындагы эшчәнлеге турында докладны идарә председателе, «Социалистик Татарстан» газетасы редакторы Ш. Х. Хамматов ясады.

Фикер алышуларда «Советская Татария» газетасы редакторы Ю. Б. Щелыванов, Татарстан АССРның телевидение и радиотапшырулар буенча Дәүләт комитеты председателе Ф. Г. Надыйров, «Теплоконтроль» производство берләшмәсе слесарь-инструментчысы, Социалистик Хезмәт Герое Н. М. Гыйлаҗев, Әлмәт шәһәрендә чыга торган «Знамя труда» газетасы редакторы П. М. Голышев, «Азат хатын» журналының баш редакторы В. Ф. Ихсанова, «Казан утлары» журналының баш редакторы урынбасары Р. С. Мөхәммәдиев, Татарстан китап нәшрияты директоры Г. Н. Шәрәфетдинов, Казан дәүләт университетының журналистика кафедрасы мөдире Ф. И. Әгъзәмов, «Вечерняя Казань» газетасы редакторы А. П. Гаврилов иптәшләр катнашты.

Съездда шулай ук КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, СССР Журналистлар союзы идарәсе члены, КПСС Үзәк Комитетының «Агитатор» журналы баш редакторы М. П. Габдуллин иптәшләр чыгыш ясады.

Съезд эшендә КПСС өлкә комитеты секретаре Ф. А. Садыйков, ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов иптәшләр катнашты.

Оештыру Пленумында Татарстан Журналистлар союзы идарәсе председателе итеп Ш. Х. Хамматов, идарә бюросы членнары итеп Ф. И. Әгъзәмов, Ш. М. Вәлиев, Р. К. Зәкиев, В. Ф. Ихсанова, Р. Г. Максудов, Ф. Г. Надыйров, Г. Н. Шәрәфетдинов, Ю. Б. Щелыванов сайланды.

## БӨТЕНРОССИЯ ФӘННИ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

25—27 ноябрьда Казанда «Милли музыка культураларының бер-берсен баетуы» дигән темага культура һәм сәнгать вузлары студентларының Бөтенроссия фәнни-практик конференциясе булды. Казан дәүләт консерваториясендә үткәрелгән әлеге конференциядә Россия Федерациясендәге һәм күп кенә союздаш республикадагы 25 вуз вәкилләре катнашты. Конференциянең секцияләр эшенә Мәскәү һәм Ленинград шәһәрләреннән килгән күренекле галимнәр һәм музыка белгечләре җитәкчелек итте. Пленар утырышта һәм секцияләрдә СССРдагы тугандаш халыклар культуралары арасындагы күпкырлы бәйләнешләр, аерым алганда, милли музыка культураларының үзара бәйләнеше һәм йогынтысы тарихы, аларның бер-берсен баетуы, фольклор һәм профессиональ композиторлар иҗаты арасындагы үзара мөнәсәбәт өлкәсенә кагылышлы теоретик проблемалар, музыка укыту һәм башкару сәнгате мәсьәләләре турында докладлар тыңланды.

## СЪЕЗД КАРАРЛАРЫ ЯКТЫЛЫГЫНДА

КПСС Үзәк Комитетының «Әдәби тәнкыйть турында»гы карары кабул ителүгә ун ел тулу уңае белән В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетында фәнни-теоретик конференция уздырылды. Конференцияне кереш сүз белән КДУның филология факультеты деканы, доцент Я. Г. Сафиуллин ачты. «КПССның XXVI съезды әдәбият һәм әдәби тәнкыйть турында» дигән доклад белән ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Г. Ахунов чыгыш ясады. Ике көн дәвам иткән киңәшмәдә галимнәр «КПССның XXVI съезды карарлары яктылыгында әдәби тәнкыйтьнең актуаль мәсьәләләре» темасына эшлекле сөйләшү алып барды.

## ЯШЬ ЯЗУЧЫЛАР КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

Буада яшь һәм башлап язучыларның республика зона конференциясе булды. СССР төзелүнең 60 еллыгына багышланган бу конференцияне ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты һәм Чувашия АССР Язучылар союзы белән берлектә Татарстан Язучылар союзы үткәрде.

Конференцияне кереш сүз белән Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе урынбасары Илдар Юзеев ачты. КПССның Буа райкомының беренче секретаре Р. А. Фейсханов конференциядә катнашучыларны кайнар котлады, аларга иҗатларында уңышлар теләде. «КПССның XXVI съезды карарлары яктылыгында күп милләтле совет әдәбиятының бурычлары» дигән темага доклад белән тәнкыйтьче Ринат Мөхәммәдиев чыкты. Конференциядә катнашучылар алдында шагыйрьләр Сибгат Хәким, Илдар Юзеев, драматург Туфан Миңнуллин, язучы Мөхәммәт Мәһдиев, чуваш язучылары Юрий Семенов, Константин Петров чыгыш ясады. Шул ук көнне язучылар районның «Ватан», «Искра», Тельман исемендәге колхозларында булып, әдәбият сөючеләр белән очраштылар.

Әдипләр ике көн дәвамында башлап язучыларның кульязмаларын анализладылар, район газеталарында әдәбият-сәнгатьнең яктыртылышына күзәтү ясадылар, яшь тәнкыйтьче Фәиз Зөлкарнәев, яшь шагыйрьләр Нияз Акмалов һәм Ркаил Зәйдуллин иҗатларын тикшерделәр. Соңыннан Буа район культура йортында язучылар һәм һәвәскәр башкаручылар катнашында әдәби-музыкаль кичә үткәрелде.

## КАМАЗДА МУЗЫКА БӘЙРӘМЕ

1—3 декабрьдә Чаллыда Татарстан Композиторлар союзы идарәсенең күчмә пленумы һәм Музыка фестивале үткәрелде. «КамАЗ» автомобилен, Кама ГЭСын төзүчеләр янына республикабызның сәнгать осталары — композиторлар, музыкантлар, җырчылар килде. Фестиваль дәвамында музыка сәнгате осталары Чаллы, Түбән Кама хезмәт ияләре белән очрашулар үткәрделәр. Очрашуларда 10 меңнән артык тамашачы катнашты.

Пленум утырышында республика музыка сәнгате эшлеклеләренең соңгы елларда ирешкән казанышлары, совет кешесенең иҗади хезмәте темасын яктырту буенча алар алдында торган яңа бурычлар турында иҗади сөйләшү булды. Татарстан Композиторлар союзы идарәсе председателе М. Яруллин докладында буенча фикер алышуда композиторлар Б. Мулюков һәм А. Блинов, пленум кунаклары — РСФСР Композиторлар союзы идарәсе секретаре В. Агафонников, Чуваш АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе А. Васильев, Чуваш АССРның атказанган культура работнигы А. Михайлов катнашты. Пленар утырышта ремонт-инструментлар заводы мастеры И. Аркаев, ТАССР Язучылар союзының Чаллы оешмасы җаваплы секретаре Р. Вәлиев, «Сердәш» вокаль-инструменталь ансамбле җитәкчесе, үзешчән композитор Г. Гобәйдуллин композиторларга үзләренең фикерләрен һәм теләкләрен белдерделәр.

Пленум эшендә КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, ТАССР культура министры И. Н. Алиев катнашты.

Чаллыдагы Музыка фестивале «Энергетик» культура сараенда сәнгать осталарының зур концерты белән тәмамланды.

* * *

ВЛКСМ Үзәк Комитеты һәм СССР Язучылар союзы инициативасы белән Бакуда яшь язучыларның киңәшмә-семинары булып узды. Ул КПСС Үзәк Комитетының «Иҗат яшьләре белән эшләү турында»гы карары чыгуга биш ел тулу уңаеннан үткәрелде. Анда, семинар җитәкчеләренең берсе буларак, шагыйрь Равил Фәйзуллин да катнашты.

## МӘГЪРИФӘТЧЕ ШАГЫЙРЬ ЮБИЛЕЕ

Республикабыз җәмәгатьчелегенең XIX йөзнең күренекле мәгърифәтчесе һәм шагыйрь Мифтахетдин Акмулланың тууына 150 ел тулуны киң билгеләп үтте. Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында узган юбилей кичәсен ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Г. Ахунов ачты. Акмулланың тормышы һәм иҗаты турындагы доклад белән В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты галиме М. Госманов чыкты.

Юбилей кичәсендә КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов катнашты.

Соңыннан Татарстан сәнгать осталары концерты булды.

## ЮБИЛЕЙ КИЧӘЛӘРЕ

* * *

Казанның Төзүчеләр культура сараенда күренекле татар совет язучысы, СССР Дәүләт премиясе лауреаты Кави Нәҗминең тууына 80 ел тулуга багышланган кичә булды. Анда КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, ТАССР Министрлар Советы председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов, республикабызның партия, совет, профсоюз, комсомол оешмалары, иҗат союзлары, культура учреждениеләре, хезмәт коллективлары вәкилләре катнашты.

Кичәне тәнкыйтьче Р. Мөхәммәдиев ачты. ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Г. Ахунов Кави Нәҗминең тормышы һәм иҗаты турында сөйләде. Өлкән әдипләр Г. Минский белән С. Хәким Кави Нәҗми турында истәлекләре белән уртаклаштылар.

Соңыннан Татарстан сәнгать осталары концерты булды.

* * *

Казанның Актерлар йортында композитор Солтан Габәшинең тууына 90 ел тулуга багышланган кичә булды. Компози-

торның иҗаты турында сәнгать фәннәре кандидаты М. Нигъмәтҗанов доклад ясады. Композиторның шәкертләре һәм замандашлары: Татарстанның халык артистлары Сара Садыйкова, Галия Кайбицкая һ. б. мактыргыч истәлекләр сөйләделәр. Аннары сәхнә осталары концерт күрсәтте.

Фойеда тамашачылар композиторның тормыш һәм иҗатына багышланган кызыклы күргәзмә карадылар. Аны сәнгать ветераны Исмәгыйль ага Һилалов оештырган иде.

## ИҖАДИ ПӘНҖЕШӘМБЕ

Татарстан Композиторлар союзында үткәрелә торган «иҗади пәнҗешәмбе»ләрнең берсе композитор Шамил Шәрифуллинның зур симфоник оркестр өчен язылган «Җыен» исемле концертын тикшерүгә багышланды.

Сөйләшүдә катнашучылар яңа әсәргә югары бәя бирделәр. СССРның халык артисты, профессор Н. Җиһанов әсәрнең теле заманча, образлы фикерләү ягыннан яңа, шул ук вакытта милли җирлектә булуын билгеләп үтте. ТАССР Композиторлар союзы идарәсе председателе М. Яруллин, композитор Б. Трубин, сәнгать фәннәре кандидаты, доцент А. Абдуллин да, концертның яңалык буларак кабул ителә торган сыйфатларына, образлар тәгәллегенә, партитурадагы тембр тавышларына игътибар итеп, әсәргә тулаем уңай бәя бирделәр.

## КЫЗЫКЛЫ ОЧРАШУЛАР

Казан дәүләт педагогия институтының актлар залында шагыйрь Сибгат Хәким иҗатына багышланган әдәби кичә булды. Анда язучылар, артистлар, композиторлар, институт укытучылары, студентлар катнашты.

Сибгат Хәкимнең иҗаты турында тәнкыйтьче Р. Мөхәммәдиев сөйләде, шагыйрьләр Р. Миңнуллин, Р. Гатауллин, Ә. Мәхмүдов үзләренең шигырьләрен укыдылар. Шагыйрьнең иҗади дуслары — композиторлар С. Садыйкова һәм З. Хәбибуллинның катнашуы да кичәгә нур өстәде.

Сибгат Хәким кичәдә үзенең иҗаты турында сөйләде, яңа шигырьләрен укыды. Соңыннан җырчылар Р. Ибраһимова, Ф. Сөләйманова, Ф. Насретдинов, Г. Казанцева һәм Э. Җәләлетдинов башкаруында шагыйрь сүзләренә язылган җырлар җырланды.

* * *

8 декабрьда Казанның Актерлар йортында язучы Гариф Ахунов белән очрашу кичәсе булып узды. Ул үз укучыларына Африкага сәяхәте турында кызыклы истәлекләр сөйләде, сорауларга җаваплар бирде. Кичәнең икенче бүлегендә республиканың танылган нәфис сүз осталары язучының әсәрләреннән өзекләр укыдылар.

* * *

21 ноябрьда Казанның «Тасма» производство берләшмәсе клубында зур әдәбимузыкаль кичә булды. Кичәдә Гөлшат Зәйнашева, Рәдиф Гатауллин, Рәшит Әхмәтҗанов, Рәфкать Кәрами, Эдуард Мостафин, Роза Хәлиуллина, яшь шагыйрьләр Нияз Акмалов, Госман Садә, «Яшь ленинчы» газетасы хезмәткәре Сәйдә Зыятдинова яңа әсәрләрен укыдылар, тамашачыларга бүгенге әдәбият турында сөйләделәр. Җырчылар Рафаэль Сәхәбиев, Флера Сөләйманова, Миңгол Галиев, Зөһрә Сәхәбиева тамашачыларның яраткан җырларын башкарды.

## ЯҢА МУЗЕЙ

Балтач районының Карадуган урта мәктәбендә Муса Җәлил музее ачылды. Аны булдыруда мәктәпнең герой-шагыйрь исемендәге пионер дружинасы зур эшләр башкарган укучылар көрәшче-әдип турында сөйләүче бай материал туплаганнар, шагыйрь туган якларга барганнар, Муса Җәлилне күреп белүчеләр белән очрашканнар.

Музейга 600 экспонат тупланган. Алар арасында шагыйрьнең шәхси әйберләре дә, аңа багышланган картиналарның төп нөхсәләре дә бар. Мәктәп музеена Казандагы Максим Горький музее хезмәткәрләре шефлык итә.

## ЯЗУЧЫГА — КОЛХОЗ ПРЕМИЯСЕ

Буада язучы Мөхәммәт Мәһдиевка районның «Искра» колхозы премиясе тапшырылды. Колхозчылар аның «Фронтовиклар» романын соңгы елларда авыл тормышыннан алып язылган иң яхшы әсәр дип бәяләгәннәр һәм язучыга колхоз премиясе бирү турында карар чыгарганнар. Лауреат дипломы тапшырганда колхоз председателе М. Мөхәммәтҗанов авторга колхозчыларның наказларын җиткерде, аңа иҗатында яңа уңышлар теләде.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ


Әлмәт шәһәренең үзәк китапханәсендә поэзия кичәсе үткәрелде. Язучылар оешмасының җаваплы секретаре Әдип Маликов һәм «Әлмәт» әдәбият берләшмәсе җитәкчесе Фәрит Гыйльметдинов тыңлаучыларны нефть ягы шагыйрьләре иҗаты белән таныштырдылар. Гамил Афзал, Казаннан килгән шагыйрә Флера Гыйззәтуллина, яшь шагыйрь Роберт Рәкыйпов яңа әсәрләрен укыдылар.

Язучылар оешмасының чираттагы утырышында «Язучы һәм тормыш» дигән мәсьәлә тикшерелде. Ә. Маликов нефть ягы авторларының әдәби эшчәнлегенә тукталды, партиянең XXVI съезды куйган бурычлар һәм язучыларның тормыш белән элемтәсе турында сөйләде. Фикер алышуларда Г. Афзал, әдәбият берләшмәләре җитәкчеләре Фәрит Гыйльметдинов, Нур Әхмәдиев (Азнакай), Әзһәр Габиди (Сарман), Факиль Зәйнәгыйтдинов (Баулы), яшь язучы Әсрар Галиев катнашты.

# СОҢЛАДЫК

**РАЗИМ ВӘЛИУЛЛИН** музыкасы

**ГӘРӘЙ РӘХИМ** шигыре




Уңда ак ай батты, сулда ал таң атты...
Күзгә-күз карарга кыймадык.
Кеше күрер, кайтыйк инде, дидек,
Әллә иртәләдек, әллә соңладык.

Унҗиде яшь иде безгә ул чак,
Кыңгыраулар кебек чыңладык.
Күрешербез әле, дип аерылдык,
Әллә иртәләдек, әллә соңладык.

Бүген минә ничә еллар үткән,
Кинәт тирән бер уй уйладык:
Без сөйгәнбез. Моңа төшенергә
Без соңладык, ахры, соңладык.

## КИЛӘСЕ САНДА:

Проза.

**НУРИХАН ФӘТТАХ.** **Сызгыра торган уклар.** Роман.

**РӘФКАТЬ КӘРАМИ.** **Өзелгән чәчәк.** Хикәя.

**РОЗА ХАФИЗОВА.** **Сөенечле хәбәр.** Хикәя.

Поэзия.

**ГАМИЛ АФЗАЛ.** **Абыйлар үткән юл.**

**Шагыйрәләр иҗатыннан үрнәкләр.**

Очерк.

**ӘХӘТ ГАФФАР.** **Бакча.**

Әдәби тәнкыйть.

**ФОАТ ГАЛИМУЛЛИН.** **Юл кешесе.**

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

**КАЗАН УТЛАРЫ**
**(ОГНИ КАЗАНИ)** ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал, орган Союза писателей Татарии

Индекс 73210